
ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

3. 1994





# ЯҢАЧА МӨНӘСӘБӘТЛӘР

Инде матбугатта хәбәр ителгәнчә, 15 февраль көнне Мәскәүдә Татарстан Республикасы Президенты М. Ш. Шәймиев һәм Россия Президенты Б. Н. Ельцин җитәкчелегендәге делегацияләр ике арадагы Шартнамәгә кул куйдылар.

«Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында ике якка да караган эшләрне аныклау һәм вәкаләтләрне бүлешү турында» дип аталган бу Шартнамә барлыгы тугыз статьядан тора. Андагы статьялар Татарстан Республикасы һәм Федераль дәүләт хакимияте органнарының вәкаләтләрен, ике якка да караган эшләр сферасын, яңача багланышларны билгели.

Кул кую вакытында чыгыш ясаган Б. Н. Ельцин һәм М. Ш. Шәймиев Шартнамәнең зур әһәмиятен билгеләп үттеләр, җәмгыятьтәге сәяси һәм икътисадый реформаларның гражданнар арасындагы татулыкка, милләтләрнең үзара килешеп яшәвенә һәм кеше хокукларының өстенлегенә таянырга тиешлеген басым ясап әйттеләр.

Шартнамәгә РФ Президенты Б. Ельцин, ТР Президенты М. Шәймиев, РФ Хөкүмәте Рәисе В. Черномырдин, ТР Премьер-министры М. Сабиров кул куйган.

Сөйләшү ике якның да Конституцияләрен хөрмәт иткән хәлдә, тигез шартларда барды. Шартнамәгә тарих үзе бәя бирер. Һәрхәлдә, ул Татарстанның мөстәкыйльлегенә, матур киләчәгенә хезмәт итәргә тиеш. Хәерле сәгатьтә!

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**3**

**(857)**

**1994**

КАЗАН

## *Бу санда*

З. ВӘЛИЕВА. Мөстәкыйльлеккә Татарстанның үз юлы . . . 3

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Г. АФЗАЛ. Ачы язмышлар. *Шигырьләр* . . . 6
М. ХӘБИБУЛЛИН. Хан оныгы Хансәяр. *Тарихи роман* . . . 12
С. ГӘРӘЕВА. Нинди тын. *Шигырьләр* . . . 100
Ш. ҖИҺАНГИРОВА. Ышанам. *Шигырьләр* . . . 104
С. ЗЫЯ. Ике Әнисә, бер Мәхмүт. *Хикәя* . . . 107
Ф. ӘҺЛИЯ. Ашкынулар юшкыны. *Шигырьләр* . . . 115
Ф. БӘШИРОВА. Хатын-кызларга. *Шигырьләр* . . . 119
И. СИРМАТОВ. Сүнгән учак. *Хикәя* . . . 122

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

Ф. СӘФӘРГАЛИЕВА. Бәлки... *Шигырьләр* . . . 128

Татарстан Язучыларының XII съезды алдыннан 131

ПУБЛИЦИСТИКА

Ф. ЛАТЫЙФИ, Р. ЯКУШ. Шыгырдан феномены 135

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

М. ВӘЛИ. Әмирхан ага Еники белән әңгәмә *(Әдипкә 85 яшь тулу уңаеннан)* . . . 148

КИТАП КҮЗӘТҮ

Э. МОСТАФИН. Сабыр савытлары бар икән . . . 158

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕНДӘ – ТАТАР ШӘХЕСЛӘРЕ

Л. ХӘМИДУЛЛИН. Яңа табышлар . . . 161

МӘДӘНИЯТЕБЕЗ ТАРИХЫНА

М. ӘХМӘТҖАНОВ. Кульязма китапларда кече жанрлар . . . 167

СӘНГАТЬ

В. ДУЛАТ-АЛИЕВ. Бәхет кошының канаты тиеп киткәндер... . . . 185

Китаплар дөньясында . . . 188
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан . . . 190

*Баш мөхәррир*
**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*
**Гариф Ахунов**
**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова**
**Тәлгат Галиуллин**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Зиннур Мансуров**
**Рөстәм Мингалимов**
**Фәрваз Миңнуллин**
**Минтаһир Минһаҗев**
**Мөхәммәт Мәһдиев**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашаҗ Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Индус Таһиров**
**Наис Гамбәров**
*(җаваплы сәркатип)*
**Тәуфикъ Әйди**
*(бүлек мөхәррире)*
**Марсель Әхмәтҗанов**

Безнең адрес: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 49-36-60,
баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09,
җаваплы сәркатип — 53-36-12,

*бүлекләр:*

шигърият, фән,
хатлар — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, сәнгать,
тәнкыйть — 49-36-63,
корректорлар — 49-36-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

Статья З. ВАЛИЕВОЙ «У Татарстана свой путь к суверенитету».
«Проза и поэзия»: исторический роман М. ХАБИБУЛЛИНА «Внук хана Хансюяр», рассказ С. ЗИЯТДИНОВОЙ «Две Анисы, один Махмуд», рассказ И. СИРМАТОВА «Потухший костер», стихи Г. АФЗАЛА, С. ГАРАЕВОЙ, Ш. ЖИГАНГИРОВОЙ, Ф. АГЪЛИУЛЛИНОЙ, Ф. БАШИРОВОЙ.
«Творчество молодых»: стихи Ф. САФАРГАЛИЕВОЙ.
«Навстречу XII съезду писателей Татарстана».
«Публицистика»: статья Ф. ЛАТИФИ, Р. ЯКУША «Шигирданский феномен».
«Литературная критика»: статья М. ВАЛИЕВА «Беседа с Амирханом Еники» (в связи с 85-летием писателя).
«Библиография»: статья Э. МУСТАФИНА «Чаша терпения».
«Выдающиеся личности — на страницах истории»: статья Л. ХАМИДУЛЛИНА «Новые находки».
«К истории культуры»: статья М. АХМЕТЗЯНОВА «Малые жанры в рукописных книгах».
«Искусство»: статья В. ДУЛАТ-АЛИЕВА о Ларисе Масловой.
«В мире книг».
«Дневник общественно-культурной жизни».
«На наших обложках»: «Зайтуна Мавлюдова» — картина художника Ч. Ахмерова; известный поэт Р. Гаташ.

## In our issue:

Z. Valieva's article «Tatarstan Has Its Own Way to the Sovereignty»
«Prose and Poetry»: M. Habibullin's historical novel «Hansuyar khan's grandson»; S. Ziyatdinova's story «Two Anisas, one Mahmut; I. Sirmatova's story «Extinct Bonfire»; the verses of G. Aphzalova, S. Garaeva, Sh. Gigangirova, Ph. Agliullina, Ph. Bashirova
«The Works of Youth»: the verses of Ph. Saphargalieva.
«Meeting the XII Congress of Tatar Writers» «Publicism»: the article written by Ph. Latiphi and R. Yakush «Shigirdan's Phenomenon»
«Literary Gritique»: M. Valieva's article «The Conversation with Amirkhan Eniki» (in connection with 85 anniversary of writer)
«Bibliography»: E. Mustafina's article «The Cup of Patience».
«The Eminent Persons in History»: A. Hamidullin's article «The Finds»
«To the History of Culture»: M. Ahmatzyanova's artiele «The small Genre in the Manuscript Books»
«Art»: V. Dulat-Aliev's article is about Larisa Maslova.
«In the World of Books»
«The Diary of the Social and Cultural life»

● Авторлар фикере редакция фикере белән туры килеп бетмәскә дә мөмкин.

● Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

● Журналда басылган язмаларны күчереп басканда, «Казан утлары»ннан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

*Мөхәррирләр:* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзадә Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Гөлназ Хөснетдинова.

Производствога бирелде 7.02.94 ел. Басарга кул куелды 10.03.94 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 22 786. Заказ А-65. Бәясе 330 сум.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.
© «Казан утлары», 1994 ел.



**Зилә Вәлиева,**

Татарстан Югары Советы
Рәисенең беренче урынбасары

# МӨСТӘКЫЙЛЬЛЕККӘ ТАТАРСТАННЫҢ ҮЗ ЮЛЫ

**1993 елның 2—6 декабрендә Америка Кушма Штатларының башкаласы Вашингтон шәһәрендә Төрки халыкларның III конференциясе булды. Конференциягә төрки халыклар яшәгән 20 дән артык дәүләт вәкилләре килгән иде.**

**Бу югары форумда Татарстан Югары Советы Рәисенең беренче урынбасары Зилә ханым Вәлиева да катнашып, конференция исеменә Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев һәм Югары Совет Рәисе Фәрит Мөхәммәтшинның котлау хатын тапшырды. Ул анда «Мөстәкыйльлеккә Татарстанның үз юлы» дигән доклад белән чыгыш ясады.**

**Түбәндә укучыларыбыз игътибарына шул докладны тәкъдим итәбез.**

Хөрмәтле кардәшләр, ханымнар, әфәнделәр!

Мин Сезгә мөстәкыйльлеккә омтылучы Татарстан Республикасы халкыннан, аның Президенты Минтимер Шәймиевтән, Татарстан Парламенты Рәисе Фәрит Мөхәммәтшиннан кайнар сәламнәр алып килдем. Ышанам ки, демократик Америка жирендәге бу очрашу, үзебезне борчыган мәсьәләләрне уртага салып сөйләшү эзсез үтмәс, төрки халыкларның дөнья күләмендә берләшүенә, тупланүына сәбәпче булыр.

Безнең бу жыеныбыз яңа заман күренеше. 1985 елда элеккеге СССРда башланган үзгәртеп кору сәясәте, тоталитар режимның җимерелә башлавы дөньяның бүленешен үзгәртте. Яңа заманның кыенлыклары элекке СССР халыкларына зур сынау булса да, бу үзгәрешләрнең, гомумән алганда, уңай якларын да танымыйча булмый. Менә шушы заманда элек бер-берсенә каршы торган халыклар һәм дәүләтләр дуслаша, якынлаша башладылар. Яңа бәйсез төрки дәүләтләр төзелеп, үз язмышларын үзләре хәл итә башлады. Шушы дәүләтләр арасында Татарстан Республикасы да бар икәнлеге бу форумда катнашучыларга мәгълүмдер.

Татарстан — төрки халыклар арасында лаеклы урын тоткан татар халкының тарихи Ватаны. Ул элеккеге СССР һәм Россиядә яшәүче җиде миллионлы татар халкының рухи мәркәзе генә түгел, мәдәният, сәясәт һәм икътисад өлкәләрендә регионнарга тәэсир итүче көч тә.

Татарстан Республикасы борынгы төрки дәүләт — Идел буендагы Бөек Болгарның, Алтын Урданың һәм Казан ханлыгының хәзерге варисы булып тора.

Республика халкының күпчелеген төрки халыклар — татарлар, чувашлар, башкортлар һәм башка туганнарыбыз тәшкил итә.

Шулай итеп, Татарстан төрки дөньяның аерылгысыз бер өлеше ул.

Шул ук вакытта аның бүгенге хәле яңа төзелгән бәйсез төрки дәүләтләрдән шактый аерыла. Экономик, фәнни, интеллектуаль мөмкинлекләребез зур булса да, дәүләт буларак терелү, аякка басу зур кыенлыклар аша бара.

СССРдагы һәм Россиядәге элекке автономияле республикалардан беренче булып Татарстан 1990 елның августында үзенең дәүләт суверенитеты турында Декларация кабул итте. Һәм менә инде өч ел буена республика демократик юл һәм хокукый ысуллар белән эзлекле рәвештә үзенең дәүләтчелеген ныгыта: 1992 елның мартында үткәрелгән референдумда Татарстан халкы тагын бер кат үзенең ихтыярын раслады; шул ук елны Татарстанның суверен дәүләт икәнлеген раслаган Конституция кабул ителде; Россия белән үзара мөнәсәбәтләр хакында дәүләт һәм хөкүмәт югарылыгында сөйләшүләр алып барыла, килешүләр төзелә.

Шулай итеп, Татарстан Россиянең федератив дәүләт төзелешендә реаль сәяси реформа үткәрүенә йогынты ясарга тырыша, үзара мөнәсәбәтләрне яңача коруның конструктив юлларын тәкъдим итә. Татарстан позициясенең хаклылыгын сентябрь аенда федерализм мәсьәләләренә багышлап Казанда үткәрелгән халыкара конференциядә катнашучы дөньякүләм абруйлы сәясәтчеләр һәм галимнәр таныдылар.

Кызганычка каршы, Россия Федерациясенең яңа Конституциясе проектында республикалар суверенлыгы һәм чын федерация, милләтләрнең һәм халыкларның үзбилгеләнү хокукы кире кагыла. Шулай итеп, төрки дөньяның бер өлеше булган Татарстан, Башкортстан, Якутия-Саха, Чувашия һәм башка республикаларның мөстәкыйльлеге куркыныч астында калды.

Менә шушы шактый катлаулы шартларда Татарстан үзе сайлаган юлдан тайпылмый. Татарстан парламенты Россия Конституциясе проектына аерым мөнәсәбәт белдергән карар кабул итте. Халыкның күпчелеге Россияне унитар дәүләт, үзәкләштерелгән империя итеп калдыруга каршы чыга. Милләтләрне, республикаларны элеккедән дә хокуксызрак калдыру Татарстанда гына түгел, башка милли республикаларда да зур борчылу уята. Кызганычка каршы, Көнбатыш илләре республикаларның суверенлыгын юкка чыгаруны Россиядә демократия үсеше дип бәялиләр. Ә чынлыкта исә бу гамәлнең Россия киләчәгенә дә, демократиягә дә, дөнья иминлегенә дә зур зыян китерүе ихтимал.

Менә шуңа күрә Татарстан парламенты республикабыз Конституциясенең 61 маддәсен Россия Конституциясе эчтәлегенә кертергә тәкъдим итте. Ә анда болай дип әйтелә: «Татарстан Республикасы — Россия белән вәкаләтләрен һәм ике якка да караган эшләрне тапшырышу турындагы Килешү нигезендә ассоциацияләшкән суверен дәүләт, халыкара хокук субъекты».

Безнең терәгебез һәм ышанычыбыз нәрсәдә соң? Беренчедән, хакыйкатьнең безнең якта булуы, республика халкы аңында дәүләтчелек идеясенең борынгыдан яшәп килүе; икенчедән, Татарстанның экономик, технологик потенциалы, жир асты һәм жир өсте байлыкларының муллыгы, интеллектуаль көчләрнең һәм кадрларның югары әзерлеге; өченчедән, Татарстанның эчке һәм тышкы политикасы кешеләрнең һәм халыкларның уртак мәнфәгатьләрен яклауга юнәлдерелә. Республикада төрле милләт вәкилләренә тигезлек гарантияләнә, шул ук вакытта татар халкының милли үсеше өчен кирәкле шартлар тудырыла. Татарстанда татар һәм рус телләре тигез хокуклы дәүләт телләре дип танылды. Хәзер ике теллелек программасы буенча яшь буынны тәрбияләү өчен шартлар тудырыла. Сәяси партияләрнең, җәмгыятьләрнең хәтта рәсми хакимияткә оппозициядә булганнарының да, газета яисә журналларның цензурага куелганы яки тыелганы юк.

Кайвакыт Татарстан сәясәтен сепаратизм итеп, реформаларга каршы итеп күрсәтергә тырышалар. Республикадагы стабильлек һәм тормыш дәрәҗәсенең чагыштырмача югары булуына «коммунизм утравы» дип ярлык тагарга маташалар. Чынлыкта исә бу Татарстанның мөстәкыйльлек юлыннан баруына тискәре мөнәсәбәт тудыру өчен эшләнә. Нәкъ шул ук максат белән кайвакыт Татарстанның мөстәкыйльлеген ислам радикализмы тәэсире дип куркытканнары да искә төшә.

Без хосусыйлаштыру, икътисади реформалар ягында. Россия федерациясе һәм аның өлкәләре белән бергәләп башкарган экономик программаларыбыз кимеми, ә киресенчә, арта бара. Татарстан Россия белән бер үк экономик мохиттә яши. Соңгы бер ел эчендә генә дә Россия һәм Татарстан хөкүмәтләре арасында нефть табу, милек, мәгариф, экология мәсьәләләре буенча килешүләр төзелде. Суверенлыкны без Россиягә керү яки чыгу дип кенә аңлатмыйбыз. Мөстәкыйль булу элекке империя үзәгенә — Мәскәүгә дә, беркемгә дә буйсынмыйча үз ирегебез белән берләшеп, кирәк булса вәкаләтләр алмашып, хезмәттәшлек итү дип саныйбыз.

Хосусыйлаштыру, ирекле икътисад, базар мөнәсәбәтләре үзәкләштерүдән азат булган шартлар таләп итәләр. Гомумән әйткәндә, Татарстан икътисади һәм сәяси реформалар үткәргәндә элекке СССРның башка төбәкләре өчен үрнәк булырлык кануннар чыгарырга, аларны гамәлдә кулланырга тырыша.

Татарстанның бәйсезлеге башка илләр белән икътисади, мәдәни бәйләнешләрне чикләүне түгел, ә киресенчә, аларны киңәйтүне күздә тота. Хәзер Россия һәм аның регионнары белән экономик хезмәттәшлек бермә-бер арта бара. Ләкин Татарстанның икътисад, фән, мәдәният, мәгърифәт өлкәләрендә хезмәттәшлек итүе тигез хокуклылык нигезендә үз ихтыяры белән алып барылырга тиеш.

Татарстан мәнфәгатьләреннән чыгып, без Көнбатыштагы һәм Көнчыгыштагы төрле илләр, фирмалар белән зур күләмле уртак программалар төзибез. Безнең төп партнерларыбыз — Германия, Америка Кушма Штатлары, Англия, Италия, шулай ук, Япония, Көньяк Корея һәм, әлбәттә, Төркия фирмалары. Татарстанның чит илләр белән турыдан-туры бәйләнешләре һәр ике якның мәнфәгатьләренә җавап бирә һәм, экспертлар әйтүенчә, аларның киләчәктә нәтиҗәлерәк һәм киңрәк булуына Татарстанда уңайлы шартлар җитәрлек.

Татарстанның Төркия белән элемтәләре аеруча нык үсә. Төркия-Татарстан уртак ширкәтләре уңышлы эшли, бергәләп газета-журнал, китаплар чыгару юлга салына, укучы яшьләр алышу башланып китте, Татарстанда төрек уку йортлары ачыла, телевизион тапшырулар күрсәтелә. Казан белән Төркия арасында һава күпере торган саен җанлырак була бара. Бу эшләрдә Төркиянең мәрхүм Президенты Тургут Озалның игелекле хезмәтен билгеләп үтәргә кирәк. Ул ике тапкыр Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев белән очрашып, ике ил арасындагы мөнәсәбәтләрнең үсүенә юл салып калдырды. Төркия Президенты Сөләйман Демирель шушы мөнәсәбәтләрнең тагын да киңрәк колач белән үсүенә һәм киңәюенә гарантия булып торыр дип ышанабыз.

Татарстанның ишекләре бөтен илләргә дә ачык. Без яңа төзелгән бәйсез төрки дәүләтләр белән багланышларга да яхшы карыйбыз. Бакуда һәм Ташкентта рәсми вәкилчелегебез бар, Казакъстан, Кыргызстан, Төрекмәнстан белән дә хезмәттәшлек, үзара дуслык яхшыра бара.

Шул ук вакытта бәйсезлеккә ирешкән дәүләтләр тарафыннан Татарстанны тану, бертигез итеп санау сизелми. Әлбәттә, халыкара хокук нормалары, Россия белән бәйләнешләр факторы барлыгын аңларга була.

Ләкин без дә халыкара хокук нормаларын хөрмәт итәбез, Россияне без дә Берләшкән Милләтләр Оешмасының, халыкара бердәмлекнең абруйлы әгъзасы буларак таныйбыз. Иртәме-соңмы Татарстан-Россия мөнәсәбәтләре, рәсми килешү нигезендә, дәүләтара мөнәсәбәтләргә әйләнәчәк. Шуңа күрә төрки дәүләтләрнең Татарстанны танырга ашыкмавы, хәтта гуманитар мәсьәләләр буенча да Татарстан белән уртак эшләрне Россия аркылы башкаруы төрки халыкларның терелүенә зыян китерә.

Без бер юнәлештә дә каршылыклар яки дошманлык эзләмибез, ә уртак мәнфәгатьләр һәм уртак проблемаларны чишәргә омтылабыз.

Шул ук Россиядә 4—5 миллион татар, шактый зур сандагы башка төрки халыклар яши. Россия төркиләрен тергезү буенча без Россиянең Милләтләр Комитеты белән берлектә ноябрь аенда махсус киңәшмә үткәрдек. Менә шул җыенда билгеләп үтелгәнчә, Россия өлкәләрендә яшәүче татарларны дәреслекләр, кадрлар белән тәэмин итү, мәдәни хезмәт күрсәтү өчен Татарстан бик күп миллион сум акча сарыф итә. Бу чыгымнарны Россия безгә кайтарырга, ә мәгърифәт, мәдәният эшләрен бергәләп күтәрергә тиеш дип саныйбыз. Мондый проблемалар буенча башка төрки дәүләтләр дә кардәшләребез яшәгән илләр белән, шул исәптән Татарстан белән һәм Россия белән махсус килешүләр төзесә, төркиләрнең терелүенә дә, демократияне үстерүгә дә файдалы булыр иде.

Безне кайбер төрки дәүләтләрдән Татарстанга, Башкортстанга күпләп качаклар кайту проблемасы да уйландыра. Без кайтучыларны кабул итәргә, урнаштырырга тырышабыз. Ләкин мондый фактлар төрки бердәмлекнең кайчагында матур хыял булып кына калуын күрсәтәләр. Кардәшләр бер-берсен рәнҗетмәскә тиеш.

Кыскасы, төрки дөньясының проблемалары шулкадәр күп һәм катлаулы, аларны хәл итү өчен иҗтимагый оешмалар да, фәнни-интеллектуаль көчләр дә, дәүләт органнары да, парламентлар да бергәләп тырышырга тиеш.

Газиз кардәшләр! Сүземнең ахырында мине бу мәртәбәле мәҗлескә чакырганыгыз өчен аны оештыручыларга чын күңелдән рәхмәт белдерәм, биредә күтәрелгән проблемаларны якын елларда хәл итүдә уңышлар телим.

Игътибарыгыз өчен рәхмәт!

# ШИГЪРИЯТ



## Гамил Афзал,

Татарстанның халык шагыйре

### Ачы язмышлар

Ул елларда һәркем — туган якта —
   Күз яшьләре белән бит юган.
Идел буе ачтан үлгән чакта
   Якты өмет белән кем туган?

Күзләрдә моң булган, маңгайда сыр...
   Алабута баскан бусага.
Бәлки, мин дә кирәк булганмындыр,
   Бер елмаер өчен булса да...

Намус качты илдән, иман качты,
   Бәйрәм итте заман ялгышлары.
Җан өстенә Дәҗҗал менеп басты —
   Даһиларның ачы язмышлары!

Елмаючы кирәк заманны аңлап,
   Күзе тонган кызыл мәхшәрдә.
Күпме мөмкин илне-көнне алдап,
   Ялган иман белән яшәргә!

Кем гаепле — без гаепле инде,
   Күзе тонган кара сарык булдык.
Әллә Намус, әллә Иблис көлде —
   Ялган диңгезендә гарык булдык.

---

Гамил АФЗАЛ (1921) — *шагыйрь, күпсанлы китаплар авторы. Ул — Татарстанның Г. Тукай бүләге лауреаты. Әлмәттә яши.*

## Камыр батыр

Ялыктырды бурыч, налог, план,
  Реализм дигән фәлсәфә...
Шүрәлеләр йөргән кара урман
  Шаулап торыр, Алла теләсә.

Камыр батыр сөйли: — Әй, билләһи,
  Каракошка угым тимәде,
Тугыз башлы дию белән тәки
  Сугышырга туры килмәде.

Җен карчыгы әйтә: — Хәтәр юлың,
  Һәр тарафтан шомлы җил исә,
Ак бүрегә атланып бар, улым,
  Башың исән кайтмас югыйсә...

Урман кызы — Юха Елан булды,
  Бик куркыныч, хәтәр көн булды.
Таракны ыргыттым — урман булды,
  Көзгене ыргыттым — күл булды.

Патша кызы утыра чәчен тарап,
  Юлбасарлар тулы урман, ди,
Хан да карак, вәзире дә карак,
  Сиңа гына ябышып чыгам, ди.

Җиде диңгез кичкән җирән атым
  Ефәк яллы, көмеш тояклы,
Бик үз итте батыр татар халкын,
  Оҗмах итеп күрде бу якны.

Каф тавыннан килгән Аждаһаның
  Карурманда башы киселгән,
Соры бүре ялый кара канын...
  Курыкмыйбыз кара песидән.

Алып батыр биргән алмаз кылыч
  Чөйдә эленеп тора шулай да...
Иген яхшы уңган, еллар тыныч,
  Уракка төшәрбез бу айда.

## Яңгырлы көз

Өстәл тулы — газет, китап тулы — киштә,
Күңел бармый эшкә, илһам килми һич тә.

Кемдер алга киткән, кемдер калган артта.
Дөрес бардыммы дип, күңелдә шик арта.

Алга бару кыен, туктап артка кара,
Юкмы туры бер юл, юкмы изге чара?

Кайда синең кәгъбәң, кайда нурлы кыйблаң,
Көзге яңгыр ява, шаулый шәрә урман.

Көзге яңгыр ява көзге шыксыз кичтә,
Гомер үтеп бара, даһилык юк һич тә.

Кайда кояш чыга, кайда кояш бата —
Бөтен күкне каплап соры болыт ята.

Дымлы, салкын һава, үзәннәрдә томан.
Һаман яңгыр ява, һаман шаулый урман.

Кемдер алга киткән, кемдер дошман булган,
Ямьле чорлар үткән, шомлы шаулый урман.

Шундый инде безнең озын гомер юлы:
Мәшәкатьләр тулы, борчылулар тулы.

Космонавтлар әйтә: «Тереклек юк Айда...»
Даһи шагыйрьләрнең васыятьләре кайда?

Алга бар, ди Тукай. Алла бар, ди мулла,—
Бу газаплы юлда, бу каһәрле юлда

Бүләк бирмәсеннәр, рәхмәт димәсеннәр,
Синең арттан килер иманлы нәселләр!

## Дога

Балкып торган идеал бир, Ходай,
Ак кыйбласы булсын сөремсез.
Икътисад-фәлән дип, алай-болай
Акча санап тору күңелсез.

Базар сәясәтен эт ашасын,
Бу йөрәккә нәфис моң кирәк,
Табигатьне күреп ямь табасың,
Сәясәтсез үсә тал-тирәк.

Спекулянт булып тумадык бит,
Кесәләргә ваучер куймадык,
Кояш нурын күреп туймадык без,
Чәчәк исен иснәп туймадык...

## Сәясәт

Сәясәттә сай йөзәсең, җаным,
Сәясәтнең төбе тишек аның.

Сөйләгәндә сүзе дөрес кебек,
Ә битлеген салса — тирес кебек.

Ә чынлыкта, ул сәясәт, иркәм,
Сине көчләү өчен кирәк икән.

## Кара таплар

Татар тарихында күптер
  Ак таплар, кара таплар.
Кара таплар белән никтер
  Бизәгән безне ятлар.

Бизәгән дә, әйтеп куйган:
  — Бу тапка кагылмагыз!
Ханыгыз, даныгыз булган
  Заманны сагынмагыз!

Җырлагыз гыйшык турында...
  Әнә бит, үсә арыш,—
Бәхетле колхоз кырында
  Социалистик ярыш!

* * *

Күңел белән ераклардан урап,
  Башта фикер туа, аннан сүз...
Замандашка ак бәхетләр юрап
  Кара күзләр талган кара күз.

## Интернационализм

Сез әшәке, без әшәке дими,
Нух пәйгамбәр кебек урыс карты
Татар малаена кызын димли...
Өстәлендә ярты.

* * *

Миннән беркем план көтми хәзер,
Пенсияңне ал да, тик ят, диләр,
Коммунизм әле ерак, диләр.

Тарих төпкеленә чумармын да,
Йөз ел үткәч калкып чыгармын,
Бер иркенләп һава сулармын да,
Алдыгызга килеп сорармын:

— Ниләр кырып яту, оланнар, дип,
Нинди хәзер сезнең планнар, дип...—
Символыгыз чүкеч-уракмы,
Коммунизм әле еракмы?

* * *

Тантаналы, барабанлы чорлар,
Кан калтырап торыр дошманнарың,

Сине зурлап халык җыру җырлар,
Һәм үтәлер барлык кушканнарың,

Кабереңнән чыгарып ыргытырлар
Коерык болгап торган куштаннарың...

* * *

Җиде бабаң хәерче дә ишәк,
Шулар каны синең тамырда.
Ничек итеп, оста хәер эстәп,
Тарихларга кереп калырга?
Күсәк тотып алга барырга да,
Кеше сатып медаль алырга,
Бүтәннәрне янган утка салып,
Үзең герой булып калырга!..

## Тәүбә ит

Бер — алдын, бер — артын күрсәтте,
Кырыкка кырланды бу заман.
Бу кадәр дәһшәтле, күсәкле
Кыргыйлык тарихта булмаган.

Бер — алдын, бер — артын күрсәтте,
Кырыкка кырланды бу дөнья.
Тәүбә ит, тешлә дә терсәкне,
Валлаһи йөрмәм, дип, бу юлда!

* * *

Бөгелә-сыгыла таллар тирбәлә, һайт,
Табигатьнең рәхәт, мул чагы.
Читтә йөрмә, энем, иленә кайт,
Безнең илләр — җәннәт почмагы.

Көмеш айны алтыннарга маныйк,
Җанда кинә тотмый бер тамчы.
Илдә иркен сулап яшәп алыйк,
Тагын берәр Дәҗҗал чыкканчы.

## Чүплек башы

...Табигатьтән хәер сорамыйбыз,
Кирәк чаклы каерып алабыз,
Гигант адым белән барабыз, дип,
Акыл сатты пеләш бабагыз.

Шундый иде безнең «изге» бурыч,
Шулай яздык ватан ташына.

Исерек татар белән исерек урыс
  Бәйрәм итте чүплек башында.

* * *

Безнең уй-фикерләр чуар инде,
  Кемдер әйтер: «дөнья — куласа»
Даһи фикерләр дә туар иде,
  Бәрәңге кайгысы булмаса.

* * *

Кеше булып яшә, өлкән әкә,
  Агу чәчеп, давыл урганчы,
«Татар бетсен» дигән сәясәткә
  Ике куллап ябышып торганчы!

## Яңа юл

Большевиклар искелекне җиңде,
  Яңа юлга чыгып шат булдык,
Яңа юлдан барган идек инде,
  Колымага килеп тап булдык.

* * *

Ат аунаган җирдә төк калды,
Урманны кистеләр, төп калды.
Төп астында тирән тамырлар,
Шул тамырдан безне танырлар.



**Мөсәгыйт**

**Хәбибуллин**

# ХАН ОНЫГЫ ХАНСӨЯР

ТАРИХИ РОМАН

## 1

Артык баһадир Кыпчак даласына җыенуын хатыны Карлыгачка әйтмәде.

Кичә баһадирны Илһам хан үз сараена чакыртып алды да сарай хәрби мәктәбендә укыган тупчы азамат егетләре белән Карамалы кирмәне аша Саксин каласына сәфәр чыгарга кушты. Балигъ булган тупчы азамат егетләр аксакаллардан һәм ханнан фатиха алганнар иде инде, имтиханнарын да тапшырдылар — ханның аларны теләсә кай тарафка җибәрергә хакы бар иде. Әмерен әйтергә дәшкәч, Артык баһадир Илһам ханны тыныч кына тыңлап бетерде дә хан тынып калгач кына, тамак кырды. Янәсе, аның да әйтәсе сүзе бар.

— Атна-ун көн элек кенә билләренә кылыч таккан азатларым Саксинга юнәлсен, дидеңез, хан иям. Максатыңыз нидән гыйбарәт соң?..

— Баһадирым,— диде, урыныннан кузгалып, Илһам хан.— Бездән янә тынычлык китәргә тора. Багучыларым җиткерделәр, үзе вафат булса да, Чыңгыз ханның баһадиры Сүбәдәй исән икән, ул гынамы, янә Болгар юлында, диләр. Җәйли-җәйли килә, имеш. Димәк, үз көченә үзе ышана. Мәгълүм булганы шул: җиңгәчәм каласына юнәлә икән. Саксин каласында баһадиры белән Акбикә җиңгәчәй утыра. Ипле генә идарә итәләр иде. Сүбәдәй дүрт төмән белән яу чыккан. Баһадир Бачман белән җиңгәчәйнең генә көче җитмәс дип куркам. Кыскасы, азамат егетләреңне, атка куйган тупларны сынап карарга мөмкинлек бар, баһадир. Үзеңә мәгълүмдер, Сүбәйдәй баһадир вак-төяк дошман түгел, ике тапкыр чагышып карадыгыз.

— Үч алырга килә, димәк,— диде Артык баһадир үзалдына сөйләнгәндәй.

— Бәлкем, үч алыргадыр да. Ике тапкыр килде, ике тапкырында да кыйнап җибәрдек. Ачулы ул безгә, баһадир, үчле. Җитмәсә тәүге орышта

---

Мөсәгыйт ХӘБИБУЛЛИН (1927) — *прозаик, «Кубрат хан», «Илчегә үлем юк», «Шайтан каласы» һ. б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

хатыны белән углын алып калдык,— диде Илһам хан һәм ирен чите белән генә көлемсерәп куйгандай итте.

Менә анысын әйтмәсә, әйбәтрәк буласы иде дә, хан кадәр ханның авызын каплап буламы... Хак, Болгарда бер күзеннән мәхрүм калган Сүбәдәйнең Карлыгач атлы хатыны Артык кулында. Тату гына яшәп яталар, угланы Ташбай да балигъ булды, җитмәсә тупчылары сафында — меңбашы. Алай да ханның шул хакта искәртеп куюы баһадирга ошамады, ул янә тамак кырды, әмма бу юлы дәшмәүне артыграк күрде, ахры.

— Карамалы кирмәнендә озын-озак юанма, баһадирым,— диде Илһам хан, һични булмаган кебек. Ә Артыкның йөрәге тамак түренә җитеп тибә башлаган иде инде. Алай да дәшми калмады.

— Дөнья булгач төрле хәлләр була инде ул, хан иям. Әнә сез дә иш күгәрченнәрдәй марҗа ханбикә белән гөрләшеп торасыз бит. Мин дә Карлыгачымны яраттым.

— Ярату гаепме, баһадирым! — диде кинәт кенә Артыкның хәленә керергә теләгәндәй Илһам хан.— Яратмау гаеп. Ярата белгән кешедә иман бар, диләр.

— Хан оныгы Хансөярне дә алыйммы, хан иям?

— Угланың Ташбайны да, хан оныгы Хансөярне дә алырсың, баһадирым. Өч мең тупчы, алты мең җайдак ат, йөзгә якын олау сиңа. Бачман баһадир белән җиңгәчәйгә бүләкләр дә әзерләттем. Минем исемемнән тапшырырсың. Ә гүзәл кызлары Сөмбелгә бер сандык бирнә. Җиткән кыз бит инде. Миңа ул монда килеп киткәндә үк ошаган иде, якын иттем үзен. Сылу, акыллы, гүзәл.

— Якшы, хан иям, тапшырырмын,— дип, күкрәгенә кулын куеп, баш иде Артык.

— Тупчылар өчен иң әүвәл син җаваплы, баһадирым. Тик Бачман баһадир сүзеннән дә йөз чөермә. Саксин җирләренә ул баш. Җиңгәчәй аның сүзеннән чыкмый, диделәр. Иншалла, әле дә шулайдыр.

— Баш өсте, хан иям, шулай итәрмен.

— Карале, Артык баһадир, Ташбай углан атасының кем икәнен беләме?

— Анасы әйтмәгән булса, белми, хан иям,— диде Артык, колак яфракларына кадәр кызарынып.

— Әйе, үпкәләрлеге бар Сүбәдәй баһадирның болгарларга. Болгар җирендә ике төмән сугышчысы ятып калды, җитмәсә бер күзен югалтты, ул гынамы, сөйкемле хатыны безнең кулда...

— Кһм! — дип янә тамак кырды Артык. Илһам хан ялт итеп баһадирына күз төшереп алды да янә ирен чите белән елмайгандай итте.

— Аллаһы тәгалә язганны күрмичә кеше үлмәс, диләр бит, баһадирым, рәнҗемә хаңыңа. Мин тугрысын әйттем. Угланың Ташбайны, хан оныгы Хансөярне узындырма. Шул ук вакытта кимсетмә дә үзләрен. Кимсетелгән — кимсенер, узындырган — узыныр, дигәннәр бит.

— Якшы, хан иям. Мин аларга чын мәгънәсендә атакай булырмын.

— Син аларга моңа кадәр дә чын атакай булдың, баһадирым. Аннары сиңа янә үтенечем бар, Артык баһадир,— диде Илһам хан атакай каршына килеп, иңенә уң кулын куйды, күзләренә карады.— Синең гүзәл Карлыгачың һәрчак үзең белән далага чыга. Җәйләү вакытында бер хәл, ә менә Саксинга аны алып бармасаң иде. Сүбәдәй белән күзгә-күз очрашуы бар дип әйтмим, күңелеңә авыр ала күрмә... Әйе, җәйләүгә чыкмыйсың, баһадирым, кан дошманың белән орышырга барасың. Үзеңне дә, тупчыларыңны да сакла. Атка куйган тупларны нә урысларда, нә монголларда күргән кеше булмаган. Синең кулыңа Болгар халкы яңа корал тапшыра.

— Якшы, хан иям. Мин ни генә булмасын, оланнарны сакларга тырышырмын. Бер генә туп та дошман кулына эләкмәс.

Илһам хан тәхетенә барып утырды, аркасын тирәккә аударды, бертын дәшми торды. Ахырда, кулларын терсәклеккә куеп:

— Орыш кырында төрле хәл булуы бар, баһадирым. Сакла тупчыларың. Мин сиңа ышанам. Саксин каласы Болгар кулында калыр, иншалла. Ак юл сиңа, баһадирым. Казнабашны күрми китмә, мин аңа һәммәсен дә әзерләргә куштым. Инде хуш, баһадирым. Синнән сөенечле хәбәрләр көтәм...

Аркасында ханның карашын тоеп, Артык баһадир ишеккә таба борылды, ә тәхет ягын саклаучы азатны узуга, тирләп чыккан маңгаен сөртә-сөртә: «Менә, Сүбәдәй, безгә тагын очрашырга туры киләчәк бит әле...» — дип әйткәнен сизми дә калды. Аның үзалдына сөйләнә-сөйләнә чыгуын күреп, айбалта тоткан каравыл азат башын чайкап куйды. Атакай баһадирның үзалдына сөйләнерлеге бар иде шул. Чөнки ул әле бер генә орышка да кермәгән, яңа мыек төртеп чыккан егетләр белән корыч баһадир атын алган, инде ярты дөньяны яулап караган Сүбәдәй баһадир белән очрашасылары бар. Җитмәсә ул баһадир кулына утны-суны үткән сугышчылар. Хак, Бачман баһадир да төшеп калганнардан түгел, һәр мәргәне аткан угын очкан кошның күзенә тигезә. Әмма барыбер күңел тыныч түгел иде. Юк, Сүбәдәй белән күзгә-күз очрашудан курыкмады ул. Курыкканы хатыны Карлыгачтан иде. Ничекләр ул аңа ялганлар? Әйе, ни генә булмасын, ул аны үзе белән алмаска тиеш. Әлбәттә, угланы Ташбай да бара дигәч, чат ябышыр, Артык чарасыз калыр... Тик барыбер ул аны үзе белән алмас. Хан әйткән өчен генә түгел. Ярамый аңа Саксинга барырга. Аллаһы тәгалә биргән язмышны бер гомергә ике тапкыр сынамыйлар. Ахыры хәтәр бетүе бар. Ник дисеңме? Ташбаең бит аның угланы! Гәрчә Артык атасы канаты астында үссә дә, олан йөрәгендә үз атасы каны. Бабаларыбыз тикмәгә генә: «Куәтлек — атадан, мәрхәмәтлек — анадан»,— димәгәннәрдер. Хактыр, Ташбай угланы инсафлы, мәрхәмәтне дә ходай тәгалә тулык итеп биргән үзенә. Тәүфыйклылык исә адәм баласына ата-ана тәрбиясе белән керәдер. Аллага шөкер, Ташбай углан тәүфыйклы булып үсте, азмады-тузмады, ата-ана сүзеннән чыкмады. Ханның угланны меңбаш итеп күтәрүе дә шуннан, моны яхшы белә Артык. Әмма кайчак, хан оныгы Хансөярнең дә ярдәме тимәдеме, дип уйлап куя. Углан хан оныгы Хансөяр белән бергә уйнап үсте, сарайның егетләр мәктәбенә дә бергә керделәр. Үсәисәя төшкәч, тәмам аерып булмый башлады үзләрен. Карлыгач анасы моңа кинәнде, Артык та канәгать иде. Моның өстенә ике дус янына Җик Мәргән угланы Юлдаш килеп кушылды. Өч тугандай өч углан сарай хәрби мәктәбен тәмамладылар, ул гынамы, тупчы һөнәрен үзләштерделәр. Аргамаклар сайларга да өчәү бардылар. Борынгы төркиләр: «Ат сайлау — җан сайлау»,— дигәннәр, ир-ат сүзе дә шуннан калган булса кирәк. Угланнарның атларын ошатты Артык атакайлары. Атлар алырга кыпчакларга барганнар иде, угланнарның олуг белгечләрчә ат сайлауларын күреп, куанып бетә алмаган иде Артык. Хан оныгы Хансөяргә карашы үзгәрәк булса да, баһадиры Җик Мәргәннең угланы Юлдашны беренче көннән үк үз иткән иде Артык. Ә бер тапкыр далага чыккач, теге олан җырлап җибәрде, үсмер егетнең күңеле тулы моңлы тавышын ишетеп, Артык тәмам таң калган иде. Әле булса хәтерендә, шәкертләрнең барчасы да күзгә-күз карашып алдылар. Моңа кадәр Юлдаш угланның үз ишләре алдында җырлаганы юк иде, ә монда гүя егет күккә ашты, гүя йолдызлар атылды, хәтта табигать тынып калгандай булган иде. Тәненең чемер-чемер итеп китүен, күзләре дымлануын, күңеле ни кылырга белми чәбәләнүен, өзгәләнүен әле булса оныта алмый Артык. Әнә шул күңел күзләре яңа ачылып, кызлар кулын тотмаган егетләрне ул Саксин каласына алып китәргә тиеш. Үк корбан сайламый, диләр, кем белә, угланнарның орыш кырында ятып калулары да бар иде. Куркуы аның шуннан иде. Җитмәсә Ташбай угланның атасы Сүбәдәй баһадирны күрүе мөмкин иде. Бусы инде иң яманы, ул чакта яшәүдән яшәмәвең хәерлерәк булыр. Шушындый афәт булган хәлдә ничекләр Карлыгачы күзенә кайтып күренер?!.

Каланың Тау ягы урамына борылуга, Артык үзенә таба атлаучы Нисбах картны күрде. Мөхтәрәм картның кулында таяк, әмма сынын төз тотып атлый, гадәттәгечә, үзалдына нидер сөйләнә. Артык аңа ерактан ук сәлам юллады.

— Әс-сәламегаләйкүм, ил карты! Исән-имин генә торамсың?

Ил карты туктады, таягына учларын куеп, күкрәгенә терәде. Әле булса бишвакыт намазга йөргән Нисбах картны һич кенә дә туксаннан өстә димәссең: җилле йөри, җор телле, сүз эзләп кесәгә керми. Нисбах картны аяклы тарих дип тә әйткәлиләр, аның чынлап та белмәгән нәрсәсе юктыр кебек. Сәере шул булды, сәламен алуга, ул Артыкны тәмам шаккаттырды.

— Сүбәдәй бәдбәхет тагын Болгарга кузгалган икән.

Сине шунда китәсең дип ишеттем, Артык баһадир. Ашыга төшкән хан, ашыга төшкән. Сүбәдәйгә каршы тәҗрибәлерәк сугышчыларын вә азатларын җибәрсен иде. Хәер, Бачман баһадир ул бәдбәхеткә каласын бирмәс, иншалла.

— Аксакал, сер булмаса әйт әле, каян белдең минем Саксин каласына юнәләсемне?

— Кһм! — диде Нисбах карт, уч төбенә тамак кырып. — Ходай тәгаләдән һични яшереп булмый, баһадир. Әйе, тик хатыныңны ала күрмә. Орыш ул — хатын-кыз эше түгел. Калсын илдә. Иншалла, исән-имин әйләнеп кайтырсыз. Кһм, тик, ни, баһадир, угланнарың сакла. Аларда безнең киләчәк. Синең тупчыларыңда.

— Картаймасаң картаймассың икән, Нисбах бабай. Ул турында кайгыртасың, ә бит... — Артык уңайсызланды, тотлыгып калды. — Син, Нисбах бабай, зинһар, кичерә күр, берүк. Күрәм, исән-саусың. Сөякләрең шыгырдаганы да ишетелми әлегә, Аллага шөкер. Һаман да азамат ирдәй хөкем йөртәсең. Сере нидә шуның?

— Ата-баба канында баһадир. Аннары Ходай тәгалә кулында, ил баһадиры Артык. Сафлыкта вә пакълектә. Ким куйганда ике тапкыр намазга утыр, бер тапкыр мунчага барып, бал белән сыланып, буы җылымса ләүкәгә ятып тор, ахыр хәлдән тайганчы чабын да кайтып, бер касә куе кымыз эчеп, йомшак түшәгеңә ят. Уянгач, күз алдыңа гүзәл затлар килтер. Хәер, сиңа ул затларны чакырып торасы түгел, Карлыгачың үзе алиһә, диләр.

— Тамаша! Диде Артык, хәйран калып.

— Бер акыллы баш болай дигән, баһадир: әгәр дә мәгәр мин кырык яшьтән соң үземне саклаган кебек кырык яшькә чаклы саклаган вә сакланган булсам, ике гомер яшәгән булыр идем. Ләкин Аллаһы тәгаләдән бу хакта сорарга онытканмын икән. Шуның өчен һәр адымың Аллаһы тәгаләгә тапшырып яса. Сүбәдәй баһадирның даны бөтен төрки дөньясына таралган. Ике тапкыр болгарлар тарафыннан кыйналса, орышып туймаган икән әле. Тәкъдирен эзләвдер. Килсен. Сиңа, баһадир Артык, бер киңәшем бар. Саксинда Габдрахман атлы аксакал бар. Күр син аны, миннән сәлам тапшыр. Игелекле кеше.

— Нисбах бабакай, мин синең игелегең гомерем буена онытмам. Һәр орышка синнән фатиха алып киттем, Аллаһы тәгалә саклады, исән-имин әйләнеп кайттым.

Нисбах карт бер кулы белән таягына таянды, икенче кулы белән Артыкның җиңеннән тотты.

— Корыч баһадир атын алган сыңар күз Сүбәйдәнә беренче тапкыр җиңүче Болгар булды. Саксинны бирмә. Саксинны алса, Болгарны күзли башлар. Лачынны ук белән алмыйлар, лачынны җәтмәгә эләктерәләр, баһадир. Азамат тупчы егетләрең яшьләр, кыюлар, дип әйтәләр. Яшь йөрәк кайнар канлы була, орыш кыры Сабантуй мәйданы түгел, сакла үзләрен, ышаныч синдә. Әйем, баһадир Артык, миннән фатиха. Ак юл сиңа! Сау бул!

Артык баһадир, Нисбах карт кузгалып китkәч тә, бертын баскан урынында калды. Бу ни була инде тагын?.. Сүбәдәй баһадирның илаһи көче белән Болгарга килүе булса, нигә Илһам хан бар көче белән шул тарафка юнәлми, нигә яңа гына билләренә кылыч таккан яшь тупчыларын җибәрә, гәрчә атакайлары Артык баһадир булса да?.. Бу хакта һични аңламаса да, өенә таба кузгалды, олуг хан аңа әмер бирде, баһадир буларак ул аны үтәргә тиеш. Бары тик шул. Тик менә Карлыгачы барам дисә, нә кылыр?.. Кай тарафка гына сәфәр чыкмасын, моңа кадәр бер тапкыр да ир-канаты Артыктан калмады. Сувар, Саксин, Җукәтау калаларын әйтеп тә торасы юк, Хаҗитарханга кадәр ияреп барды ич! Әле калыр дисеңме?.. Әлбәттә, Ташбай уллары да һәрчак алар белән булды. Әле булса хәтерендә, Хаҗитарханга юнәлгәндә Ташбайга нибарысы җиде яшь тулган иде. Угланының атка атланып баруын күрер иде дә, Артык, күзләре дымланыр иде. Бала бит, сөйгән җефетенең угланы. Хатынны өзелепләр яратуы ниндидер җепләр белән угланга килеп ялганыр иде дә, чарасыз калып, йөрәге кысылып куяр иде. Карлыгач моны күрә, сизә-тоя иде һәм ир-канатын тагын да тансыклап сөяр иде. Әйе, алар гүяки бер энәгә саплаган җепләр иде: хатын да, ир дә, углан да... Хәзер менә алар аерылырга тиеш. Җитмәсә угланны орышка алып китә. Кемгә каршы дигән әле?! Сүбәдәйгә! Угланның чын атасына каршы...

Артык өенә ашыкмады. Уй сүрүен тиз генә өзәсе килмәде. Ахыр, тәмам истәлекләр эченә кереп чумды. Халык өзелми, үтә-сүтә тора, ә ул уйга баткан килеш, һични күрми атлый да атлый. Кай тарафка? Барыбер түгелмени.

Карлыгачны ул чынлап та яратты. Ул аңа бер арбада яткан чакта ук гашыйк булды, гәрчә әүвәл аңа өйләнү турында уйламаса да. Аңа рәхәт иде Карлыгач белән янәшә ятуы, гүя кан йөреше үзгәргән иде. Мәхәббәтнең булганына ул шунда ышанды, шунда инанды. Бар икән ул, сине тәмам сихерли икән. Бер-берсеннән качарга җыенгандай торган шомырт кара күзләрне, карлыгач канатыдай кыйгач кашларны күрер иде дә сулышы кысылыр иде. Күбәләк канатыдай җилпенеп торган керфекләр, йомры ияк, күпертен сусыл иреннәр, сул битендәге миң — барысы бергә елмаюга, Артыкның өстенә ишелеп килгән дулкындай тәэсир итәр иде. Өстендәге киеме дә үзгә, болгарныкына охшамаган, аягындагы башын чөеп торган итеге дә аны тәмам әкият кызы итәр иде. Һәрхәлдә, арбада хәлсезләнеп ятканда аның җан өмете ул — Карлыгач иде. Артык әле ул чакта аның кем икәнен белми иде. Орыш кырында төрле хәлләр була, магуллар исә еш кына хатыннары белән яу чыгалар. Берәр меңбашның хәләл җефетедер, дип уйлаган иде. Ә ул корыч баһадирның хатыны икән ич! Болгарлар тутый кошның үзен эләктергәннәр булып чыкты. Бу хакта аңа соңрак әйттеләр. Әмма Артык моңа бик үк шаккатмады. Алар җиңделәр, Сүбәдәй ике төмән сугышчысын, бөтен булган олавын ташлап качып китте, ә менә аның хатыны белән угланы алар кулында — әсирләр. Булды бераз курку, Илһам хан үзе күз салыр дип шикләнде — танасы түгел, мәгәр олуг хан ул уйлаганнан күп тапкыр әдәплерәк булып чыкты. Хан Карлыгачны аңа бирде һәм үзе үк никах мәҗлесенә килде. Рәхмәтле иде Илһам ханга Артык. Әнә шулай ул Сүбәдәй баһадир хатынына өйләнде. Күп тә үтми Илһам хан аңа баһадир дәрәҗәсе бирде. Ул гынамы, сарай хәрби мәктәбенә атакай итеп алды. Гомер уза, ул хәлләргә дә шактый вакыт узды инде, ана күкрәгенә ябышып яткан бала да балигъ булды, иртәгә-берсекөнгә сәфәр чыгачаклар. Инде ни язган ата белән угланга?.. Туган илләренә әйләнеп кайтырлармы?..

Карлыгачын ул беркайчан да сөеп туймады. Тансык булса булыр икән ир-атка хатын-кыз. Мөгаен, Ходай тәгалә берәүгә дә шушындый бәхетне бирмәгәндер, дип уйлый торган иде. Әмма ләкин әнә шул тансык вә илаһи мәхәббәт аларга уртак бәхет китермәде. Ташбайдан соң Карлыгач балага узмады. Карлыгач гаепне үзенә алды, ул моны Артыкны

тынычландыру өчен эшләде бугай. Ләкин, һәр ир-аттагы кебек, Артыкта да ир горурлыгы бар иде. Хатынына бу хакта ачыктан-ачык сиздермәсә дә, кайчак зарлангандай итте, гүя чынлап та Карлыгачы гаепле иде. Ә бит Карлыгач Сүбәдәйдән бала тапкан. Димәк, хатын-кыз буларак, ул бала табарга сәләтле һәм аның гаебе юк. Гаеп — ир-канатында, Артыкта. Баштагы мәлдә бу хәл өчен эчтән генә сызса да, Артык тора-бара күнекте тагын, Карлыгачына бу хакта сүз катмады, бөтен мәхәббәтен һәм ярату хисен угланы Ташбайга юнәлтте, әйе, гәрчә кан дошманы Сүбәдәйдән туганын белсә дә. Хәләл җефете Карлыгач та ир-канатындагы бу үзгәрешне күреп, тагын да нарасыйланыбрак аңа тартылды. Әнә шулай гомер үткәнен сизми дә калдылар — Ташбайлары балигъ булды, инде хәзер үз атасына каршы орышка барырга тиеш ул.

Йа Ходам, адәми затына ниндәен кайгы-хәсрәтләр генә өймисең дә ниндәен сынаулар гына куймыйсың. Һәм шул ук вакытта, Раббым, үзең үк сабыр итәргә, рәхимле вә миһербанлы булырга өндисең. Үлем дигәнең бер дә казык башыннан йөрми ләбаса, адәми затларың башыннан йөри... Үз янына алганчы, илаһи иман иткән адәмнәреңнең кайберсе теләкләрен ошбу хәсрәтле дөньяда ук канәгатьләндерсәң дә, бәлкем тәмугынамы, оҗмахынамы җыенуы да җиңелрәк булыр иде. Аталы-угланлы орышка китәбез, сөйгәнебез — анабыз илдә кала. Нә язмыш көтә бирсә дә аны да, нә язмыш көтә без ир-атларны?.. Сугыш корбансыз буламы, Раббым!?

Кыен хәлдә калган иде Артык. Ул хатыныннан беркайчан да, берни дә яшермәде, эчендәге — тышында иде. Ә монда ялганларга тиеш булачак, гәрчә ялганы изге ялган булса да. Шул ук вакытта орышка китүен әйткән хәлдә ни буласын да белә иде ул. Карлыгач алардан калмаячак. Ә анда — Сүбәдәй...

«Юк Карлыгачка бу хакта әйтергә ярамый. Ярамый!» — дип фикерен ныгытты Артык.

Ул ишегалдына керде, болдырга күтәрелде, ишек бавына кулын салды да бертын йөрәк кагуын тоеп, басып торды. Мәгәр Карлыгачы ир-канатының кайтканын сизгән икән инде, үзе үк ишекне ачты, якты йөзе белән көлә-елмая:

— Әтиләре дә кайтты, әйдә, кер. Нишләп урлашкан мәчедәй котың алынды? Күр инде, тәмам йөзе агарынган. Ул-бу булмагандыр бит? — дип шикләнеп куйды хатын.

— Юк ла, болай гына, әллә нигә кәеф китеп тора, — дигән булды Артык һәм, хатынының күзләренә туры карамаска тырышып, бусага аша атлады. — Күр әле, күңелем теләгәнне сиздең инде әллә, анасы, ат ите исе чыккан.

— Әллә беренче генә ашавыңмы? — дип шөбһәгә калды Карлыгачы.

— Иртәннән үк ат ите дип күңел кытыкланып йөргән идем, белеп торуыңны әйтәм...

— Ташбай кайтамы?

— Җибәрсәләр кайтыр, — диде кырт кына Артык.

— Бәс, син түгелмени оланнарның атакайлары? Башка берәүгә олактырмагансыңдыр ич азамат егетләреңне?..

— Хан дәшкән иде, Саксинга җибәрә. Сугыш атлары алырга диме, — дигән булды Артык һәм түгәрәк җиз тас белән җиз комган торган почмакка таба узды. Карлыгач аның янына сөлге тотып килде.

— Баланы да алып кайтасың булган, бәлеш тә куйган идем, — диде Карлыгач.

— Бәлешкә кайтып җитәр. Әзерләнә калдылар, — дия-дия, Артык хатыны кулыннан сөлгене алды, бер очын иңе аша ташлап, кулларын сөртә-сөртә, түр якка узды.

— Сөенче әйтәсе иткән идем үзеңә, — диде артыннан атлаган хатыны. — Әллә нигә кәефең юк.

— Кәеф китебрәк тора шул әле, анасы.

Инде һәммәсенә күнеккән иде бит, һич кенә дә нәкъ менә ничәмә еллар көткән сөенче булыр дип уйламаган да иде, чөнки Ташбае балигъ булды ич инде, тора башлауларына икенче дистә китте, ничекләр шул турыда уйламак кирәк, ә хатын дигәне аның алдына чыкты да дымлы күзләрен мөлдерәтеп бер карап алды да күкрәгенә капланды. Ни дип юрарга да белмәгән Артык, ярдәм эзләгәндәй, як-ягына күз ташлады һәм хатынын иңбашыннан кочып, тынып калды.

— Атасы, атасы дим, әйтергә дә оялам инде...

Артыкның зиһене ачылып киткәндәй булды, шайтан гына өметсез, диләр бит, ә ул адәм баласы, һәрчак өмет итте. Ләкин алай дип юрарга барыбер курыкты. Унөч елдан артык бер түшәккә башларын куеп йоклыйлар ич инде, буласы итсә булган булыр иде, башка бер-бер нәрсәдер. Үзенә охшаган күлмәк-фәлән алгандыр да, шул әйберне күрсәтеп, ирзатын сөендерәседер, дип уйлады. Ләкин эче белән сизде: алай гына түгел, күзләрендә үк әллә ниткән шатлык мөлдерәп тора.

— Әллә соң, анасы?.. Картайганда дим?! — Хатынның битләреннән алды, учларында кайнарлык тоеп: — Хакмы, анасы, дим?!

— «Кунакларым» килмәде, кендек әби, балага узгансың, диде...

Күп бәхетләр тойды Артык, Сабантуйларда батыр чыккалады, уктан туры атып бүләк алды, кылыч-сөңге белән көрәштә өстен чыкты, ниһаять, атакай дәрәҗәсенә иреште — барысы да бәхет иде, әмма мондый бәхетне тойганы юк иде әле. Артык хатынын кулына күтәреп алганын сизми дә калды һәм кая илтергә белми өй эчен йөреп чыкты, ул да түгел, зырылдатып бер урында әйләндерергә керешге.

— Башым әйләндерәсең ич, атасы, бу нишләвең инде тагын! — дия-дия, ир-канатына елышты Карлыгач.

Идәнгә бастыргач, ул аны янә кочагына алды һәм кайнар сулышын тоеп, битен-биткә терәде.

— Күгәрченем минем, былбылым!..

— Җибәр, атасы, чәй хәстәрләргә кирәк. Аш әзер. Бәлешем көяр...

Артык түргә узды, киез җәйгән сәкегә утырды һәм дисбесен алды. Дисбесен кулына алуы булды, сөенеч янына көенеч килде — ул китә, ә Карлыгачы балага узган. Орыш кырында ятып калса?..

Кинәт күз алдына Сүбәдәй баһадирның йөзе килде. Ә бит ул аны күрде, якыннан ук күрде — куе кара кашлы, озынчарак йөзле, сирәк сакаллы. Ул вакытта ике күзе дә исән иде әле, хәзер бер күзенә чүпрәк бәйләгәндер. Котсыз кеше түгел иде, хатын-кыз яратмаслык түгел. Карлыгач та беренче ирен онытмагандыр, гәрчә Артык янында ичмасам бер тапкыр да Сүбәдәйне теленә алмаса да. Өстә яткан, йөзгә баккан оныталамы соң! Хатын-кыз лабаса ул...

Ниһаять, Карлыгач табынга дәште. Табынга утыра-утыра Артык, юк-бар сәфәргә юл чыккандай:

— Берсекөннәргә китәсе булыр, анасы. Угланның да өс-баш киемнәрен караштыргалап куйсаң иде, минекен дә, — диде.

— Карармын-карармын, атасы. Әйдә, житеш. Мондый хәл килеп чыкмаган булса, үзем дә сезнең белән барыр идем әле. Язмаган күрәсең. Аллаһы боерса, исән-сау әйләнеп кайтсагыз, Казан якларына барып киләсе итәрбез. Әллә нигә шул якларга күңел тарта. Базарның кәттәсе анда икән бит хәзер...

— Болгарда да базар Аллага шөкер итәрлек.

— Анда кәттәрәк диләр шул, атасы. Әмир Хаҗины бик тә ипле ия диләр, беркөнне Җик Мәргәннең угланы Юлдаш килгән иде. Мактап кына калмады, тәмам сайрады инде менә. Бик тә күңелле як икән, Ходайның хикмәте.

— Ярар, анасы, исән-имин әйләнеп кайткач, барасы итәрбез. Кораб ялларбыз да... Ишкул бай әнә йөзләгән кораб тота. Акчасын гына түлә, тартучылары да бар, җилкәнчеләре дә...

— Илһам хан аның корабларына туплар куйдыртмакчы, дигән иден түгелме соң?

— Булды андый хәл. Куйдыртам, дигән иде. Бәлкем, куйдыртыр да. Мин исә, анасы, атларга куйдырылган туплар иясе.

— Анда озын-озак югалмассыз, шәт?

— Иншалла, тиз урарбыз,— диде Артык, хатынына туры карамаска тырышып.

— Көннәр матур тора болай.

— Җыен изге җан белән сәфәр чыгам, азамат егетләргә яңа унжиде тулып ята. Нарасый балалар диярсең. Һич гаепләре юк. Иншалла, барысы да әйбәт булыр. Кыпчакта ат күп, сайлап алырбыз да кайтып та җитәрбез. Син борчылма, анасы.

— Әллә соң барасы итимме, атасы? Кендек әби әйтә, атта йөреп, карындагы бала ныгый гына дигән була да соң...

— Куй шул әби сүзен, нә белә ул. Терк-терк селкетеп, нә кылырга җыенасың тагын!

— Юк ла, болай гына әйтүем. Ташбаемны да атта йөреп тапкан идем дим, таштай-тукмактай үсте әнә, берни дә булмас иде, дип кенә әйтүем,— диде Карлыгач, бәлешне табынга куя-куя.

— Ай-һай, исе дә исе бәлешеңнең! Өстен кара әле, кызлар йөземени! Туктале, анасы, бир әле үзем кисим,— дия-дия Артык пычакка үрелде.

## 2

Ниндидер тылсымга ия иде хан оныгы Хансөяр. Башта ул кыласы эшен төшендә күрде, ахыр үсә-исәя төшкәч, гүяки һәр кыен очракта, аның колагына кемдер пышылдаган сыман, нәкъ кирәк гамәлгә юнәлеш-кәңәшен бирер иде. Бу хәл бик еш кабатлана башлагач, ул сакалы агарып, бары тик өйдә генә кабул итә башлаган хәмзә Хафиз янына китте. Күптән түгел генә хан сәркәтибе булып утырган мәһди сурәтендәге бу кеше беренче сыйныфта укытып та йөрде. Хан оныгы Хансөяр аны бер күрүдә үз итте, беренче көннән үк аңа тартылды. Ошбу кеше сабак биргәндә шәкертләрнең берсе дә шылт итми тыңларлар иде һәм аннан ишеткәннәрен айлар буена сөйләп, хәйран калып йөрерләр иде. Мөгаллим буларак, мәһди Хафиз хан оныгы Хансөярне үзенә гашыйк итте. Мөгаллиме аның төшләренә керде һәм һәрчак аңа ниндидер чарада кәңәш бирде. Төштәге кәңәше тормышта һәрдаим чагылыш тапты. Бер уйлаганда искитмәле хәл иде. Әмма бу хакта хан оныгы Хансөяр хәтта якын дуслары Ташбай белән Юлдашка да әйтмәде. Бу хакта ул иң әүвәл туганые Кол Гали белән кәңәшәсе итте. Нинди шөһрәткә ия Хафиз мөгаллим? Нигә аны әүлия итеп күрәләр? Үзе инде ул мәһди Хафизның әүлия икәненә инанган иде, моны туганые хәзрәтләре Кол Гали дә расласа, ул мәһдинең өенә йөреп, ары таба да сабак алачак. Ошбу кешедә суфыйчылык кына түгел, берәүгә дә билгеле булмаган ниндидер шөһрәт вә кодрәт бар иде. Ул табибләр янында — табиб, суфыйлар янында — суфый, изгеләр янында — изге, хәлфәләр янында — хәлфә, дәрвишләр янында — дәрвиш. Аяклы тарих дигән Нисбах карт та аның белән бәхәсләшергә кыймый. Туганые Кол Гали язган шигырьләрен әүвәл аңа күрсәтә, диләр. Әйе, хак булса. Чөнки туганые Кол Гали дә олуг хәлфәләр санында йөри, хәзрәт сыйфатында мәчеттә утыра. Хан сәркәтибе сарайдан китә, ары таба мөгаллимлектән дә баш тарта — картлык галәмәте. Тик аның кебек акыл иясен Болгарда табу кыендыр. Хәтта хан үзе дә атна саен Хафиз мөгаллимнең өенә барып, кәңәш сорап йөри, диләр. Хан оныгы Хансөяр моңа ышанып җитмәде, әмма шулай булса да бер дә шаккатмас иде, чөнки Хафиз кебек кешене Болгарда табу чынлап та кыен иде. Тикмәгә генә халык: «Мәккәдә — Мөхәммәт, Болгарда — Хафиз», дип әйтмидер. Хан оныгы Хансөярнең Кол Гали туга-

ныена юнәлүендә һичнинди сер юк иде. Ул аңа еш керде. Озаклап сөйләшеп утырды. Һәм тел төбеннән шуны белде: туганые әле булса атасы Хажига кияүгә чыккан Зөләйханы ярата икән. Имеш, өйләнмәве дә шуннан. Бу хәлгә башта хан оныгы Хансөяр ышанмады, әмма туганые язган дастанны укыгач, нигәдер моңа ул да ышанган иде, гәрчә аның белән әңгәмәдә Кол Гали туганые ошбу хатын турында бер кәлимә сүз әйтмәсә дә. Хикмәт шунда, ул бүген төнлә туганые Кол Галине төшендә күрде. Бу хәл атна кич төндә булды, ә атна кич төнлә белән кергән төш хак була, диләр.

Туганые төшенә болай керде: абасы елгага кереп бара, су түшенә житкән, ә ул һаман керә дә керә. Һәм иң гаҗәбе — йөзеп китми иде. Хансөяр үзе яр башында тора, үзе нигәдер кычкыра алмый. Кычкыра да сыман, тик тавышы чыкмый... Шул халәттә уянып китте. Һәм бик озак түшәмгә карап, күргән төшен хәтере аша уздырып ятты. Ахыр, яман төш күрдем, туганыемның хәлен белергә кирәк, дигән фикергә килде. Туганыена таба атлаганда ул күргән төшен кат-кат күңеле аша үткәрде. Хикмәт — күргән төшнең асылын белүдә иде. Хан оныгы Хансөяр — аның туганые, сеңлесе Назлыгөлдән туган бала. Атасы Дәүран да дөнья арбасыннан төшеп калганнардан түгел. Идел белән Казан елгалары кушылган төбәккә Болгар каласына тиң булырдай кала күтәрде. Болгар дәүләтенең алыпсатарлары шул тарафка агыла хәзер.

Кол Гали туганые аны колач җәеп каршы алды, түрге өйгә әйдәде. Эчкәрс узгач, чәй табыны хәстәрләтте, бик озак сөйләшеп утырдылар. Туганые таштай-тукмактай сау-сәламәт иде — күргән төше турында сүз башларга да кыймады. Бары шул гына.

Ә икенче тапкыр болай булды. Болгар каласына кызларын ияртеп Бачман баһадир белән Акбикә килде. Сөмбел атлы кызлары Болгарга килгәч, көтмәгәндә урынга кала. Беренче Нәүрүз бәйрәме иде. Бәйрәмгә туганые Илһам хан аларны да дәштерде. Хан оныгы Хансөяр гүзәл кыз Сөмбелне шунда күрде. Тик уйчан вә көләч рәвештә түгел, урында яткан килеш: кыз кинәт каты авырып, тәне кызышып ята иде. Сарай табибы шунда йөри, әниләре, әтиләре барысы да кайгылы, Нәүрүз бәйрәме тәгаен хәсрәткә әверелгән иде. Акбикә өчен ошбу бала бердәнбер кыз, атасы Бачман баһадир өчен әйтеп тә торасы түгел. Ә бит ошбу баланы Сарбай хан кызы Акбикә олыгаеп кына таба — соңгы бала, кадерлеләрнең кадерлеседер. Кичәле-бүгенле генә уйнап-көлеп, Идел буйларына төшеп, бозлар кабарганны карап йөргән көләч вә шат бала тәннәре кызышып, битләре алсуланып, сулышы кайнарланып урында ята иде. Алиһәдәй гүзәл кызның кинәттән урынга калуы сарай табибларын гына түгел, бөтен каланы кузгаткан иде. Кыяр-кыймас кына хан оныгы Хансөяр дә кызлар ягына үтте. Аны туктатучы булмады, чөнки беләләр иде инде, сарай вә тәхет ягына еш кына кергәли, Илһам хан һәм ханбикә Мәрьям бу баланы якын итә, хәтта табынга да дәшкәлиләр иде.

Хан оныгы Хансөяр кабартылып куелган мендәрләр өстендә битләре эсселәнеп яткан Сөмбел янына якынлашты. Нәкъ менә якынлашты, чөнки авыру кыз янында табиблар урала, кыз балага нидер эчерәләр, бит-маңгаена кагылып алалар һәм эсселектән, һәм тән кайнарлыгыннан интеккән баланың хәленә керергә тырышып, баш чайкап куялар иде. Хаста баланың исә берәүне дә күрәсе килми, ул чарасыздан башын әле бер якка, әле икенче якка ала һәм ыңгырашып куя. Ни булды кичәлебүгенле йөгереп йөргән балага — берәү дә белми иде. Салкын тидеме, зәхмәт кагылдымы, әллә булмаса сихерләделәрме?.. Мең төрле сорау, ә җавап юк. Чибәрлеге вә сылулыгы исләр китмәле иде кунакка килгән кызның. Әллә соң күз тидеме балага, дип шикләнүчеләр дә булды, әмма моннан хаста балага ни җай да, ни җиңеллек.

Анасы Акбикә исә: «Мәне Аллаһы тәгалә каргады!» — дип, ир-канаты Бачман баһадирның йөрәген өзгәли. Әйе, ул бит әмир Хаҗидан Сарбай ханның гүзәл кызын тартып алып китүче. Ул! Бәлкем, чынлап та

Аллаһы тәгаләнең каргышы төшкәндер. Кыпчакларда булгаласа да, хатын-кыз урлау Болгарда сирәк була — булмый диярлек. Җитмәсә бит Акбикә кыз түгел, дөнья күргән әмир кадәр әмирдә кияүдә булган хатын. Балигъ булган Җаббар угланы Ашлы каласында биләмәле әмир булып утыра. Әнә шул ана үзеннән шактый яшь Бачман баһадирга тагылып, атасы каласы Саксинга кайтып китә. Һәм картаеп барганда Бачман баһадирга тиңе булмаган гүзәл кыз таба. Исеме дә телдән төшмәстәй — Сөмбел, гүзәллеген әйтеп тә торасы юк — күзләр чагылмалы нурлы йөзле.

Табиб һични кыра алмады, баланың хәле торган саен авырая гына барды. Гүзәл кыз Сөмбел инде анасын да танымас булды. Шуннан кем кәнәше беләндер сихерче карчыкны китерделәр. Мәрьям ханбикә чакырткан бугай, ул йөреде. Әллә нинди шылтыравык әйберләр, әллә ниткән үләннәр белән баланы өшкергәндәй итсә дә, сихерче карчык та һични кыла алмады. Шуннан соң Илһам хан имамны дәштерде. Сакалы биленә җиткән, өлкән яшьтәге хәзрәт килеп кергәч, сихерче карчыкны арт як ишектән тиз генә озаттылар. Хәзрәт, бисмилласын укый-укый, бала яткан сәке янына узды, Сөмбелне өшкерде, якын-тирәсендәге шайтаннарны куды. Хикмәт, бала бераз тынычлана төште — башын як-якка чайкамый, ыңгырашмый башлады. Ахыр күзләрен ачты, су сорады.

Илһам хан чишмә суы китерергә кушты. Мәрьям ханбикә гел Акбикә янында булды. Аналары Зөбәрҗәт ханбикә вафат булгач, сарай Мәрьям ханбикә кулына күчкән иде, ә ханбикә исә ни сәбәпледер Акбикәне һәм Бачман баһадирны якын итте, бәйрәм саен Болгарга дәштерде, бердәнбер кызлары Сөмбелне дә үз кызыдай якын күрә иде. Хәер, җитеп килгән кызны яратмау, якын итмәү мөмкин түгел иде. Һәммәсе аны яратты, һәммәсе аңа сокланды. Ә менә мөгаллимә Зөләйхага өйләнгән әмир Хаҗи Акбикәсе Бачман баһадирга тагылып киткәч, сарай тирәсенә аяк басмас булды, аннары ике туган арасыннан ташу суы узган сыман иде — бер-берсе белән аралашмадылар диярлек. «Булəсен булдек инде, абаем», — дип булса кирәк, Илһам хан да Казан ягына йөрмәс булды. Дөрес, Илһам ханның Шайтан каласына әле булса эче поша, кала минеке булырга тиеш дип бара, әмма абасы әмир Хаҗи белән ары таба бәхәсләшәсе дә килми иде, чөнки йә урыслар, йә магуллар яу артыннан яу йөреп торалар — берләшү хәерлерәк булыр иде дә, икесенең берсе башлап кул бирми, гәрчә илгә афәт килгәндә берләшәселәрен беләләр дә. Андый афәт әлегә юк, димәк, бер-береңә баш бирми яшәп тә була икән. Бу хакта хан оныгы Хансөяр хәбәрдар, әмма аның берьякка да кысыласы килми иде, гәрчә абасы Илһам хан шул хакта сүз кузгаткаласа да. Илһам ханны хан оныгы Хансөяр якын итте. Ошбу хан явыз вә куәтле магулларны ике тапкыр илдән куган кеше иде. Соңгы орышта хәтта үзе дә катнаша, яралана. Кыскасы, Илһам ханның Болгар җирендә абруе зур иде. Шулай булгач, дәүләтнең олуг ханын хөрмәт ит, өлкәннәрдән сабак ал, мөэмин мохитенә җайлаш, шул ук вакытта үзең сайлаган юлдан да тайпылма. Хан оныгы Хансөяр көннәрдән бер көнне Айга карап ант итте: нинди афәт-хәсрәтләргә генә тап булмасын, ватанына, ил-халкына тугры калыр. Калганын исә Аллаһы тәгаләгә тапшырды — язганы булыр, язмыштан узмыш юк.

Тик бернәрсәне белми иде хан оныгы Хансөяр — үзендәге тылсым көчен. Аңа Ходай тәгалә моңа кадәр үзе дә аңламаган тылсым көче биргән иде. Дөрес, бер тапкыр ул үз-үзенә шаккаткан иде. Әле булса хәтерендә, дәү әнисе урынга калгач, аны дәштерде — күрәсе итте бугай оныгын. Кызлар ягына кергәне юк иде әле аның. Шунда керде, шунда күрде ошбу яктагы җиһазны, гүзәллекне. Башта ул: «Әллә соң оҗмах шундый буламы?» — дип гаҗәпләнде. Җария кызлар йөгерешеп йөри, берсеннән-берсе матурлар, өс-башлары җемелдәп тора, кайберсендә әрфә күлмәк, аякларында алтын вә көмеш йөгерткән җиңел чүәкләр. Алар йөрмиләр, гүя йөзәләр сыман. Түр яктагы сәкедә дәү әнисе Зөбәрҗәт ята.

Ул аны кул изәп үзенә дәште. Сәке тирәсен алиһәдәй кызлар уратып алган. Барысы да елмаялар, көләч йөзлеләр, зифалар. Бермәлгә генә, бары тик бермәлгә генә хан оныгы Хансөяр үзен чынлап та оҗмахта итеп хис итте. Бары тик сәке янына килеп, дәү әнисе аның кулын алып, әүвәл яңагына, аннары маңгаена куйгач һәм шул мәлдә үк үзен яхшы хис итә башлагач, аптырап калган иде. Юк, үзе генә түгел, аны уратып алган җария кызлар да шаккаттылар — авыр хастада яткан ханбикә оныгының кулын алуга, торып ук утырды һәм баллы чәй сорады. Ә бит телдән язып ята иде ләбаса. Моңа ул үзе шаккатмады, дөресрәге ул ни булганын аңламады.

— Балакаем,— диде шул чакта ханбикә әбисе.— Балакаем, изге җандыр син. Кулың алуым булды, хәлем аруланды. Тамагыма үтмәгән чәем эчтем, зиһенем ачылып киткәндәй булды.

Дәү әнисе янә бәйнә-бәйнә нидер сөйләде, нидер аңлатты. «Изге кеше кагылуга, сукыр кеше күрә башлаган, урында яткан торып киткән, чукрак ишетә башлаган, имгәк атлап киткән тылсымга ия затлар була, диләр. Әллә соң синдә дә шул куәт бармы икән, балакаем?» — дигәне әле булса хәтерендә. Атнадан артык тамагына ризык алмаган ханбикәнең ашый башлавы хәбәрен җария кызлар шундук сарайга тараттылар. Әлбәттә инде, хан оныгы Хансөярнең тылсымы турында да онытмадылар. Тик ул чакта моңа бик үк игътибар итүче булмады бугай.

Әбисе вафат булып, аны җирләгәч, бу хакта бик тиз оныттылар. Мәрьям ханбикә җария кызларның беришен кияүгә бирде, беришен үз янында калдырды. Хәер, Хансөяргә барыбер иде. Тик әбисе янында булган бер хәлне янә онытасы юк. Көннәрдән бер көнне әбисе Зөбәрҗәт ханбикә янә дәштереп алды. Аны ишектән үк бер җария кыз каршылады, чөнки кызлар ягына керү катгый рәвештә тыела иде, әлбәттә инде, ир-атка, хәтта Илһам хан да ханбикә рөхсәтеннән башка ошбу якка бусаганы атлап керми иде. Ул килеп кергәндә әбисе изрәп йоклап ята, әйтерсең лә авырмаган да, хаста да түгел иде. Җария кыз елмая-көлә аны түргә әйдәде. Кыз шулкадәр чибәр вә гүзәл күренде аңа, текәлеп, тегенең күзләренә карады. Кыз шундук елмаюдан туктады һәм аңа таба килә башлады. Сәке янында ханбикәнең йокы тынычлыгын саклаучы кызлар шым булдылар. Үсмер булса да егет ич инде, ничекләр оялмый, аннары ханбикәләре күрсә! Аллам сакласын, иртәгә үк сарайдан куар. Кыз килде дә хан оныгы Хансөярнең күкрәгенә капланды. Тәмам каушый калды Хансөяр, ни кылырга белми кыздан аерылырга итте, тик юк кына бит, кыз аны коча ук башлады. Шуннан коты алынып түгел, оялудан бугай: «Тукта!» — дип кызның колагына пышылдады. Кыз гүя айнып китте, үсмер егетнең күзләренә карады һәм йөзен ике кулы белән каплап: «Абау, нишләвем бу!» — дип, китеп барды.

Калган җария кызлар бу хәлне күреп, чышын-пышын көлешә башладылар, Хансөяр исә ни кылырга белми бүлмә уртасында торараштай басып тора. Шунда бер чаясы: «Хан оныгы Хансөяр, мине дә кочагыңа алчы!» — димәсенме. Тагын көлешү вә үртәү китте. Әлбәттә, ханбикә әбисе йоклый иде, кызлар бик тә тыенкы вә тыйнак кыландылар, ләкин Хансөяр барысын да күрде.

«Күр әле моны, ахирәткәйләрем, әллә телен йотты инде, әллә Сәрвәр эретте инде үзен?» — дип үртәүләрен дәвам итте кызлар. Хан оныгы Хансөяр кисәк кенә борылды да кызлар ягыннан чыгып китте. Ләкин сарайдан чыгып китәргә өлгерми калды, кызларның берсе аны куып җитте һәм, әбиең дәшә сине, Хансөяр, диде. Әйләнеп керде, ә әбисе һаман йоклап ята, хәтта уянып та карамаган. Хан оныгы Хансөяр үзе артыннан чыккан кызның күзләренә карады һәм тыенкы, әмма катгый боерулы рәвештә: «Син хәзер чәчең белән идән себерәсең!» — диде. Теге бичара чынлап та иелде дә чәч толымнары белән идән себерә башлады. Кызлардан битәр бу хәлгә хан оныгы Хансөяр үзе шаккатты. «Тукта!» дип әйтер иде, кызга ачуы чыкты, әйтмәс иде: теге чын-чынлап чәче белән идән себерә.

«Инде тор! Минем яныма кил! Атың ничек?» — дип сорады Хансөяр.

«Миңлесылу», — диде кыз сабыр гына. Гаҗәбе шул иде, чая кыз күндәмләнеп калган, ул нәрсә боерса, шуны кылырга әзер тора һәм бер дә көлергә дә, шаяртырга да җыенмый иде кебек. Хан оныгы Хансөяр тынычлана төште һәм түмәргә барып утырды.

«Инде хәзер минем яныма утыр!»

Кыз килеп утырды. Тын гына чәчен сүтеп үрә башлады. Сүтә дә үрә, сүтә дә үрә толымын. Хәйран калмалы хәл иде. Ә бит чаяларның чаясы иде бу кыз, бүрәнә ярыгыннан да көләргә тора иде.

«Моннан соң миннән көлмә».

«Шулай итәрмен, хан оныгы Хансөяр».

Кызны түмәрдә утырган килеш калдырып чыгып китүенә ул үкенү тойды. Чөнки күп тә үтми әбисе уянып китә янә аны дәштерә, ә ул кай тарафка китүен әйтмәгән иде — аны бик озак тапмадылар. Сәере шул булды, нәкъ ул түмәрдә утыртып калдырган кыз килеп тапты аны — Миңлесылу. Ә бит ул сарайдан чыгып китеп, Рабига күленә таба киткән иде. Агачлар арасында уйланып йөрде. Гаҗәп хәл, кыз аны шуннан эзләп тапты. Һәм: «Әбиең дәшә сине, хан оныгы Хансөяр», — диде дә китеп тә барды. Хансөяр сарайга ашыкты, кызлар ягына килеп керүгә, теге кызны үзе утыртып калдырган түмәрдә күреп, гаҗәпләнәсе иткән иде, Зөбәрҗәт әбисе үз янына дәшеп алды.

Әбисе Зөбәрҗәткә бу юлы оныгының шифалы кулы да ярдәм итә алмады, ул Хансөяр белән саубуллашкандай ирен чите белән генә елмайды да баш очында утырган абыстайга үзе үк ясин чыгарга кушты... Әбисе Зөбәрҗәт якты дөньядан киткәч, Хансөяр әкрен генә ишеккә таба юнәлде һәм берьякта түмәрдә утыручы Миңлесылуны күреп, аның янына килде, акрын гына пышылдап: «Торып кит моннан, мин сине уяттым!» — диде. Сәере шул булды, кыз берни булмаган кебек торып китте. Бары тик шул.

Болар барысы да булган хәлләр. Шул хәлләрдән соң хан оныгы Хансөяр үзендә үзе дә аңламаган көч булуын сизеп алган иде. Шуңа күрә булса кирәк, ул Бачман баһадир кызы сырхаулап яткан ятак янына килде, сак кына кызның битенә кагылды һәм авыз эченнән генә: «Син хәзер күзләреңне ачасың һәм миңа багасың, атаң-анаңа елмаясың. Алар бик кайгыралар, син авыру түгел бит, шатландыр үзләрен. Син авыру түгел, син авыру түгел!..»

Пышылдап кына әйтте, ишеткәннәре ишетте, ишетмәгәннәре юк, әмма могҗиза булды: кыз күзләрен ачты, әтисе белән әнисенә елмаеп карады. Мөгаен, алты ай буена кояш күрмәгән кеше дә болай шатланмагандыр, кызның анасы Акбикә куанычыннан җылап ук җибәрде, Бачман баһадир исә башта хан оныгы Хансөяргә шикләнебрәк караса да, кызының елмаю тәэсире белән барысын да онытып: «Аллага шөкер, барсың икән әле, ишеттең гозерем», — диде.

«Син хәзер торасың да баллап чәй эчәсең. Чәйне юкә чәчкәсе һәм кура җиләге белән куе итеп ясап килтерегез», — диде хан оныгы Хансөяр. Барысы да диярлек була аның боерыгын үтәргә ташландылар, күп тә үтми гүзәл кыз Сөмбел елмая-көлә утырган җирендә баллап чәй эчә иде инде.

Шунда Акбикә анасы: «Күр әле моны, атасы, Назлыгөлнең угланы Хансөяргә рәхмәт әйт. Әллә тылсымга ия инде. Сәламәтләнде бит, атасы, кызыбыз. Иншалла», — диде.

Ләкин шау-шу белән аның бу сүзләренә игътибар итүче әллә булды, әллә юк — күмелеп калды.

Әллә ясин чыгарга, әллә өшкерергә чакырылган абыстай гына: «Бала кеше чирләми тормый, терелде, иншалла. Аллаһы тәгаләнең кодрәте барчабызга да җитәрлек. Димәк, тәкъдире җитмәгән балакайның. Раббыбызга рәхмәт әйтегез», — диде.

Юкә чәчкәсе, бал, кура җиләге белән чәй эчкәч, Сөмбелнең борын очына энҗедәй тир бөртекләре кунды, йөзендә елмаю хасил булды. Чит-ятлардан нигәдер беренче булып ул хан оныгы Хансөяргә игътибар

итте, энже тешләрен балкытып елмайды, рәхмәт әйтте, ул бит шушы егет тәэсирендә терелүен төшенгән иде. Коңгырт чәченең берничә бөртеге маңгаена төшкән, озын керфекләре кайтарылып, күбәләк канатыдай җилпенеп китә. Алгарак чыгып торган ияге — күр мине дигәндәй йөзчыраена горурлык билгесе өсти. Күперенке иреннәре кипшергән, ләкин баллы чәйдән соң үзенә тартып дымланып торалар.

«Син бирегә, ил-җиребез Болгарга җиде елга, җиде тугай, җиде болын, җиде кала үтеп килдең. Һәр күл буена туктап тонбоекларга сокландың, һәр чишмәнең челтерәвен тыңладың. Инде күңелең тынычлансын — шул чишмәләр кебек челтерәсен. Ят, ял ит, иртәнгә уянганда якты көнгә шатланасы итсәң, синнән дә бәхетле кеше булмас...»

Хан оныгы Хансөяр бу сүзләрне Сөмбелгә күңеленнән генә әйтте, әмма сизде-күрде кыз аны дикъкать белән тыңлады, гүя чынлап та ул аны ишетеп тора иде.

«Аллаһы тәгаләгә иман кылып, Газраил фәрештәдән баш тартып, көләч йөзең белән уянсаң, Нәүрүз-чәчкә бәйрәменә болынга төшсәң — Аллаһ синең чирең үзе үк җуяр. Хуш исле чәчәкләр арасында син үзеңне иң сәламәт, иң бәхетле кеше итеп тоярсың...»

Бачман баһадир кызы тыныч кына урынына барып ятты. Янында анасы гына калды.

Хан оныгы Хансөяр яңадан аны күрә алмады, азамат егет буларак, атларына туплар куярга дип, аларның барысын да Шайтан каласына алып киткәннәр иде. Ә алар әйләнеп кайтканда Бачман баһадирның сылу кызы Сөмбел Болгардан киткән иде инде.

## 3

Алты мең ат, өч мең туп аты, олау белән Артык атакай азамат егетләрен Саксин каласына алып китте. Сәфәргә чыккан көн кояшлы һәм матур булды. Зәңгәр күктә тургай сайрый, болында исә көтүченең моңсу җыры ишетелә. Артык атакай игътибар итә башлады: Болгарда иң матур җырчылар — көтүчеләр. Болын-тугайлар шулай тәэсир итәме адәм баласына, әллә кеше үзе ялгызлыктан моңсуланамы?.. Ни хикмәттер, аңлавы кыен иде атакайга. Артык үзе дә җырларга ярата. Әмма ярата гына. Ә менә аны йотылып тыңлаучыны күргәне булмады. Үзе исә адәм авызыннан моң ишетсә, сабыры төкәнә башлый, күзләре дымлана. Былтырларны Илһам хан җырчылар туе уздырды. Көй чыгаручыларга, җыр башкаручыларга ат кадәр ат бүләк итеп бирде. Азамат егетләр арасындагы Җик Мәргән угланы Юлдаш бүген атланып барган атын хан кулыннан җырлый-җырлый алды. Менә хәзер дә ул, болындагы көтүченең җырлавын ишетеп булса кирәк, озын көйгә җыр башлады һәм шуның белән атакай Артык күңеленә сагыш моңы салды. «Бирсә бирер икән Ходай адәм баласына тавышны, хикмәт»,— дип сокланып барды Артык атакай. Ә бит ул егетнең орыш кырында ятып калуы да бар. Йа хода, кайчан туяр икән бу адәм баласы сугыштан?..

Атна дигәндә Каргалы кирмәннәренә барып җиттеләр. Аларны хан угланы Булат каршы алды. Моңа кадәр Карамалы кирмәненең әллә ни хаҗәте юк иде, могуллар яу артыннан яу йөри башлагач, Илһам хан биредә дә гаскәр тотарга мәҗбүр булды. Булат әмир кирмәнне киңәйтү эшләре белән мәшгуль, Артык атакайга яңа ныгытмаларын, боҗралап өелгән туфрак-балчык өемнәрен күрсәтеп йөрде. Бу төбәктә Сүбәдәй баһадир бер тапкыр булып китте инде — җиңмәде дә болгарларны, җиңелмәде дә, әмма, койрыгы өзелгән кәлтә кебек, ярты гаскәрен югалтып китүе хак. Шуңа күрә булса кирәк, бу юлы ошбу сугыш чукмары Саксинга юл алган. Ике тапкыр җиңелеп, ике тапкыр кыйналып та акылга утырмаса утырмас икән бу Сүбәдәй дигән мәлгунь.

Дөресен генә әйткәндә, Артык атакайның яңабаштан корыч баһадир Сүбәдәй белән очрашасы килми иде. Юк, Ташбаен югалтудан түгел, Артык атакай Сүбәдәй баһадирның көчен вә орышу сәләтен белә иде — ошбу кеше һәр орыштан исән-имин котыла һәм үзенә дан өстенә дан өсти. Әйе, Болгарга ике тапкыр яу килеп җиңелде, әмма бит Болгарның үзенә яу килде, болгарлар ул мәлгуньнәр җиренә бармадылар. Иң гаҗәбе, җиңелә, мәгәр яу йөрүдән туктамый, әйтерсен Тәңресе алдында ант эчкән. Кайчан баһадир Артык: «Әллә соң бу Сүбәдәй дигәне һаман исә Карлыгачын оныта алмыймы, шул хатынны янә кулына төшермәкчеме?» — дигән шиккә дә калгалады. Алай дисәң, нигә Карамалыга килә, нигә туры Болгарга юл алмый?.. Аннары нигә аңа Саксин? Карлыгачының болгарда булуын беләдер ләбаса. Былтыр гына Илһам хан дүрт магул шымчысын тотып астырды. Димәк, Болгарда тагын да Сүбәдәй баһадир шымчылары бар һәм ул мөртәт Карлыгачның кемдә икәнен белә, угланы турында да хәбәрдардыр?.. Юктыр, булмаганны... Бөтен дөньяны һәм андагы халыкларны буйсындырырга керешкән Чыңгыз хан баһадиры Сүбәдәйнең максаты башкадыр — Болгарны буйсындыру һәм дәүләтен богаулап, ясак салу. Карлыгач ни, Карлыгач кебек кызларны меңәрләп әсир итә, берсенә күзе вә нәфесе төшмәсә, берсенә төшәр иде. Тик менә угланы — Ташбайны оныта алмыйдыр. Монысы хак булса кирәктер, кан биреп тапкан баланы җан биреп кенә онытып булса буладыр. Син әнә гелән кан бирмәсәң дә, углан өчен үлепләр торасың, гәрчә баккан булсаң гына да... һәй, бу дөньяны, туктаса туктамас икән әйләнүдән!

Өченче тапкыр Болгарга яу кузгалган бу Сүбәдәй. Өченче тапкыр бәхетен сынамакчы. Тик бу юлы Болгар җирендә башың салып калмагаең, Сүбәдәй. Мин сиңа каршы күрше-күләндә булмаган туплар белән барам. Ул тупларны тәкәббер әмир Хаҗи кешеләре ясый. Сер әле ул, дөнья сере. Яван остасы килтергән, диләр дә ул тупны Болгарга, тик бит аның янында болгарлы Бәкер эш итә, ул баш, чуенны да ул кайната. Хак, бу коралның дошман кулына төшүе дә бар, синең кулга, Сүбәдәй. Тик син аның җаена тиз генә төшенә алмассың. Болгар ул тупларны күрше урыслар яу килгәч кулланып карады инде, тегеләрнең котлары алынды, ачудан Ашлы каласын яндырып киттеләр. Ләкин Болгар урыслардан моның өчен үч алачак әле. Туганаен үтергән өчен хан оныгы Хансөяр яу килгән урыс кенәзе Изяславтан һәм Святославтан үч алырга ант итте. Артык атакай моны хуплады. Килер бер көн: ошбу атларга куйган туплар белән урыска юнәлерләр. Үч үчкә илтер, дигән борынгылар, нишләмәк кирәк, без башламадык. Ашлыны яндырулары, бөтен хатын-кызларыбызны әсир итеп алып китүләре — әле булса йөрәкне пәрә-пәрә өзә. Хан оныгы Хансөяр хаклы — яу килгәнгә яу бармасаң, ул халык узына һәм үзен бар халыктан да өстен күрә башлый.

— Атакай, ошбу корал Карамалыда каладыр бит? — дип сорады Булат әмир, кирмәнне карап йөргәндә. Бу хакта Илһам хан белән сөйләшү булмаган иде, әмма Артык баһадир әмирнең сүзен аска калдырасы килмәде, бары тик:

— Меңне үк булмас, биш йөзләп тупны калдырырмын, әмир,— диде.

— Мин синнән Җик Мәргән угланы меңбаш Юлдашны сорар идем, баһадир,— диде Булат әмир һәм баһадирның терсәгеннән алып, туктарга кушты.— Искәр, баһадир, Сүбәдәйнең кисәк кенә Карамалыга борылуы да бар. Ул явызга ышаныч юк. Инде бик авырга китә икән, Бачман баһадирга үзем ярдәмгә барырмын.

— Хуш, бигайбә, Аллага тапшырыйк, әмир, тик бит миңа бу хакта олуг хан-атаң берни дә әйтмәде.

— Әти Болгарда, без Сүбәдәй баһадир каршында, Артык атакай. Саксин китсә, Карамалы калмас, Карамалы китсә — Саксин. Миңа калса, Сүбәдәй баһадир тагын бер тапкыр болгарларның көчен сынап карамак-

чы. Хәер, аның максатын белүе кыен, шымчыларым житкереп торалар — һичкемгә һични сөйләми, уе-фикере көнгә берничә тапкыр үзгәреп тора икән.

— Әйе, каныкты Болгарга Сүбәдәй, каныкты.

— Атасына каршы орышка угланын да алып килгәнсең икән, баһадир?

Нәкъ шул сорауны көтмәгән иде Артык. Хәер, көткән иде, бирмәсә ярый дип тора иде, ә Карамалы әмире Булат гүяки аның чуанына басты.

— Баланы мин бактым, әмир. Тапкан түгел, баккан ихлас ата булыр, дигән борынгылар. Углан Сүбәдәйнең атасы икәнен белми, әмир Булат.

— Ләкин бит, Артык атакай, аның бу хәлне белүе бар,— диде Булат әмир баһадирның хәленә керергә теләгәндәй.

— Иң мөһиме миннән ишетмәсен, әмир.

— Иң мөһиме ятлардан ишетмәсен диген, баһадир Артык. Ятлардан ишетсә, синнән гайрәте чигүе бар.

— Булмастыр, әйтә алмамдыр, әмир Булат. Кыстама. Авыр миңа. Мин аны илаһи атасыннан да якын күрәм, ул үлгәнче, үзем үләргә риза. Жир-малга туймаган, жәйләүгә жир даулаган, шуның өчен илләр яулаган, калаларны жир белән тигезләгән Чыңгыз хан вафат, бүген аның урынында угланы Үгәдәй утыра. Сүбәдәй баһадир хәзер аңа буйсына. Тәүге килүдә жиңелеп, икенче килүдә Жаек суын да чыга алмый чигенеп, өченче килүен Саксинга өмет итеп киләме баһадир. Әйе, әмир Булат, мин аның угланы Ташбайны атасына каршы орышка алып килдем. Төрки вә мөслимнәр өчен зур гөнаһтыр бу. Тик мин чарасыз, әмир, чарасыз. Бер минем углан гына түгел, өч мең азамат егет арасында кызлар кулын тоткан кеше дә юктыр. Орыш кырына керткәнче, мин аларны һич югы өйләндерер идем, әмир Булат. Ир-ат бер-берсен үтерер өчен түгел, хатын-кызны сөяр өчен, ил-халкына дәвамын калдырыр өчен туа һәм яши. Яшәү мәгънәсе шулдыр ир-атның, әмир Булат.

— Син хаклы, син хаклы, баһадир, бәхәссез. Тик адәм баласы нәфесен тыя аламы! Мин күрәзә түгел, күрәзә буласым да килми, магуллар яу йөрүдән берни дә отмаслар. Еллар үтә-үтә булса да чарасыз калуларын, оныкларын бәхетсез итүләрен аңларлар. Тик соң булыр, әсәрләнергә, әрнешергә, үкенергә вә еларга оныкларына калыр. Ил атасының исән чакта дан тотасы килә.

— Иртәгә үк кузгалабыз, әмир Булат. Юл кешесенең юлда булуы хәерле. Язганы булыр. Ә менә сәнең корылмаларың миңа ошады. Тау божраң да, кирмәнең дә, дивар башына куйган тупларың да. Сүбәдәй түгел, кабереннән торып Чыңгыз үзе килсә дә, ала алмаячак бу кирмәнне.

— Алла боерса диген, баһадир. Саклангнны сакларммын, дигән Аллаһы тәгалә.

— Син хаклы, әмир. Сакланыйк, кормаларыбыз ныгытыйк. Ил иминлеге коралда, әмир Булат.

— Камил коралда һәм иманда, баһадир. Ходай тәгалә төрки болгарларын иманнан аермасын...

Жаек елгасына таба тупларны куйган атларны эчерергә алып төшеп киттеләр, баһадир белән әмир ат куучы азамат егетләргә, көр атларга сокланып карап тордылар.

— Өмет яшьләрдә, әмир Булат, яшьләрдә. Күрәсең атта ничек жилле йөриләр.

— Аның каравы сездә тәҗрибә, баһадир, осталык, хәйлә,— диде әмир Булат.

— Хәйлә — әйбәт, камил корал бигрәк тә әйбәт. Ир-ат сугыша — корал орыша, әмир.

Сарай бусагасында аларны Булат әмирнең өлкән хатыны көтеп алды, ул аларны йомшак вә ягымлы тавышы белән эчкәре дәште, чишендерде, сөлге тотып торып юындырды һәм түр якка табынга алып

керде. Артык атакай әмир Булатның эчкәре якта тагын ике хатыны белән исәнләште һәм ниндидер бер мәлдә Булат әмирдән көнләшеп куйды. Ир янында өч хатын да гүя тәгәрәп, аның һәр әмерен үтәп йөриләр иде. Дөрес, әмерне күбрәк өлкән хатын бирә, ләкин тегеләре дә тик тормыйлар, бер-берсенең сүзләренә каршы төшмиләр, киресенчә, шундук килешеп, кыласы эшне кылып куялар иде.

Ашап-эчкәннән соң аңа аерым бүлмәгә урын салдылар.

Ястыкка башы тиюгә, Артыкның күз алдына Карлыгачы килде. Юк, ул аның янына беркайчан да янә бер хатын алып кайта алмаячак, буласы хәл түгел бу. Карлыгач аның бердәнбере. Җитмәсә чыгып киткәндә булса да күңеленә нур көлтәсе салып куйды — балага узганмын, диде.

Әле булса хәтерендә: ул күңеленә охшар кызны бик озак көтте. Күз салмаган кызы калмады, әмма әллә нигә йөрәге кабул итмәде. Җик Мәргән баһадирының нечкәләр Зәйтүнәсен сөюен күрер иде дә: «Шулай яратып буламы икәнни бу хатын-кызны?» — дип шикләнеп куяр иде. Соңыннан, Карлыгачына гашыйк булгач, төшенде, ниһаять, хикмәтле нәрсә икән ич мәхәббәт дигәнең — гелән җирдән йөрми башлады, ятса — ул, торса — ул. Кыз түгел, бер балалы хатын; җитмәсә — әсир ителгән хатын, ә ул исә гүя шашты, сөеп кенә туя алмый бит үзен. Янында ятканда сагынып интегер иде.

Ташбае тагын: «Әти дә, әтием!»не теленнән дә төшермәде, әллә инде әнисе дә өйрәтте бераз.

Олан җисемле, куе канлы булып үсте. Уктан барысыннан да оста алды, зиһене дә саф иде. Орыш уеннарында бик күпләрне шаккатырыр иде. Очкан кошларны атып төшерде — һәйбәт, Сабантуйларындагы атышта хан кулыннан ат бүләге алды — бик шәп. Кыскасы, олан ул үзе көткәннән дә күркәмрәк булып үсте. Хәзер әнә меңбаш, хан үзе фатихасын бирде. Дөрес, хан оныгы Хансөяр дә олан Ташбайдан калышмады, ләкин үзеңнеке — үзәктә, дип юкка гына әйтмиләр икән шул, барыбер угланы өчен күбрәк горурланды, бигрәк тә хатыны Карлыгачка мактанды. «Ташбаем кебек оста мәргән юк шәкертләр арасында. Хан оныгы Хансөяр дә калыша төшә, Җик Мәргән угланы Юлдаш калыша хәтта», — дип Карлыгачына рәхмәтләр укыр иде.

Хан оныгы Хансөяр дә аны еш кына гаҗәпкә калдырыр иде. Әле Ташбайны да уздырып җибәрә, әле очкан кошка түгел, каккан баганага да тигезә алмый. Дөрес, олан еш кына сабагын калдырды, әле Казанга, әле Кашанга, әле Шайтан каласына китте. Артык атакай каршы килмәде, чөнки Хансөяр хан оныгы иде.

Ишләре кайчак хан оныгына көнләшеп карыйлар. Яшь чакта була торган хәл, моңа атакайның бик үк исе китмәде — кара көнләшү түгел иде аның кебек булырга тырышу. Ләкин хан оныгы Хансөяр үз ишләре өчен генә түгел, атакай Артык өчен дә сер тубалы иде. Зиһене үткер, күзе очлы, кулы нык. Көтмәгәндә ат өстендә могҗизалар ясый. Тәвәккәл, әмердә — карусыз, табигате — йомшак. Әңгәмәдәше акыллы булмаганда — бәхәсләшми, бары тик килешеп тора, ә инде әңгәмәдәшенең акыллы икәнен сиздеме — аерып алып булмый үзен. Кыскасы, хан оныгы Хансөяр үз ишләренең берсенә дә охшамаган яшь егет иде. Шәкерт егетләр үзара аны: сихерче, тылсымга ия, дип тә йөрештерәләр, ләкин Артык атакай моңа ышанмады, ышанмый. Олан сәләтле, кешенең ни әйтергә теләвен ярты сүзеннән аңлый — зирәк бала, шул гына. Хәер, аның атасы да бик зирәк була — хан кызы кадәр хан кызын ябыштырып алып китә. Балалары да ханбикәсен тартып алган, диләр. Имеш, Туйбикә атлы хатыны бала тапмаган, ә моңа килгәч, углан тапкан. Мәхәббәт могҗизасы, шул гына, бер дә гаҗәпләнәсе түгел. Яраткан ярдан гына сәләтле вә зирәк балалар туа, диләр — хактыр, күрәсең.

Ярты гасырга якын гомер иткән, орышларда өч тапкыр дошман коралыннан яраланган, әмма тәкъдир җитмичәме, әле булса атакай дәрәҗәсендә хәрби булып йөрү ошый иде Артык баһадирга. Хәрбилек

аның канына сеңгән иде. Башка һөнәрне ул белмәде, белергә дә теләмәде. Аннары теләсә дә үз-үзе белән һични кыла алмады. Кендегө аның хәрбилеккә ябышкан иде, угланы Ташбайны да шул юлдан алып китеп бара. Тик менә гомер дигәнең генә гелән кыл өстендә — Сират күперен кылыч йөзеннән үткән кебек — һәр орышка исән каламмы-юкмы, дип керәсең. Хәзер әнә үзе генә түгел, угланын да алып бара.

Тупчыларны озатканда оста Әхмәт үзе дә булды. Һәр атка ике туп куелган, һәммәсен яңабаштан карап чыкты. Магулларның бу коралны татып караганнары юк әле, тәүге күрүләре булыр — нә отар Болгар? Туп шартлауны күрмәгән атлар өркиләр икән. Шартлауга өйрәтү өчен атларның тәмам күзләрен бәйләргә, колакларына мамык тыгарга туры килде. Тик бит Сүбәдәй ике-өч мең сугышчы белән генә килмидер, кимендә өч-дүрт төмәндер. Синең өч мең тупчыңны беренче орышта ук сибептаратып ташламасмы корыч баһадир Сүбәдәй?.. Иншалла, ташламас. Шуның өчен алданрак бара бит инде Артык — алдан әзерләнү өчен. Дөрес, Карамалыдагы уйның анда ярамавы бар, алай да, алдан уйлаган — ике откан, диләр бит. Аннары туптан ике тапкыр атып булмый, бер атасың да олауларга таба чигенергә кирәк — тупларны корырга һәм янә алгы сызыкка... Юлга чыгар алдыннан Илһам хан: «Баһадирым, тупларны орыш кырында синең үзеңә сынарга туры килер. Ышанычым акласаң иде», — диде.

Бу таңда бик иртә уянды Артык атакай, егетләрен дә уятты. Ашадылар-эчтеләр дә сәфәр чыктылар. Болай ашыкмый да кебек иде Артык, әмма хан оныгы Хансөяр сизгән икән, куып җитеп:

— Атакай, нигә болай ашыгабыз? — дип сорады.

— Ашыгу түгел бу, тиз йөрергә өйрәнү, — диде Артык.

Хан оныгы Хансөяр атакайның җавабыннан канәгать калдымы, тагын нидер әйтергә теләп тә әйтмәдеме, атын борды да егетләре янына китеп барды. Артык баһадир офык читенә күз ташлады: аяз иде көн, ник бер болыт кисәге күренсен. Димәк, көн кызу булачак, якты көндә Саксинга җитү хәерле — җиллерәк баруы, димәк, дөрес.

Әле булса хәтерендә: угланы Ташбайга ун яшь тулганда баһадир Артык Сүбәдәй белән күзгә-күз очрашырга дип Карамалы ягына орышка китте. Ул вакытта баһадир түгел, мәгәр Җик Мәргәннең ярдәмчесе иде. Хан әмере шундый: баһадир орыш кырында ятып кала икән, төмән белән идарә итүне Артык үзенә ала. Аллага шөкер кылырлык, ул орыштан Җик Мәргән дә, Артык та исән-имин чыктылар. Илгә кайткач, Илһам хан аны баһадир итте. Яшерә алмый, аны баһадир иткән көнне сарайга Карлыгачы белән Ташбае да килгәннәр иде, Илһам хан аның иңенә баһадир тасмасын салгач, күзенә яшь йөгергән иде. Ә инде Карлыгачы белән Ташбае янына килгәч, куанып бетә алмады — бәхетле иде Артык, артыгы белән бәхетле иде. Шул көннән, шушы ишелеп килгән бәхетне югалтмагаем, дип курка башлады. Һәм менә сынау көне килде — алар Сүбәдәй белән орышырга тиешләр.

Сакмар елгасы буена җиткәч, атларны утлауга туктаттылар, тамак ялгап алдылар. Ризык көлчә белән казылыктан тора, үзләре белән әйрән йөртүчеләр дә бар, кымыз исә олауда, олау нык кына арттан килә иде. Ашап-эчкәч тә юлга кузгалдылар. Артыкның далада кунасы килми, тизрәк Саксинга җитәсе, Бачман баһадирны күреп, һәммә нәрсәне дә ачыклыйсы бар иде.

Ат өстендә барганда төрле уйларга биреләсең. Артык баһадир янә Сүбәдәйне исенә төшерде. Корыч баһадир беркемнән дә курыкмый килә. Димәк, үз көченә ышана. Ашыкмый гына җәйли-җәйли килүен Артык ошатмый, иллә һични кыла алмавыннан бераз эче поша иде. Ә бит бериш елгыр егетләрен җибәреп, нәкъ Җигүлеат таулары тирәсендә магулларның котларын алганнар иде. Тик моны эшләү өчен вакыт тар калды шул. Сүбәдәйне йолыккалап торганда шәп буласы иде югыйсә.

Җиткерделәр Артыкка, олуг хан Үгәдәй әнә баһадиры Сүбәдәй ни сораса, шуны бирә икән. Ә баһадир һаман Болгарны онытмый, чөнки ике тапкыр кыйналды — үч аласы килә. Ярты дөньяны гизәп чыгып та җиңелү гарьлеген кичермәгән Сүбәдәй Болгарда ике төмәнен, бер күзен югалтты. Ары таба тагын кыйналды. Җитмәсә хатыны белән угланын алып калдылар. Ачуы килерлек икән шул. Аннары олуг ханы алдында гына түгел, бөтен магул халкы алдында йөз-оятына калды. Болгардан җиңелеп кайткач, имеш, Чыңгыз хан алдына кем атыннандыр салдырып алган ияр ташлаган икән, ә күпне күргән Чыңгыз хан макталган баһадирына: «Шул да булдымы бүләк?!» — дип каш җыерган, имеш. Шуннан Сүбәдәй баһадир Чыңгыз хан алдында ант эчкән: йә Болгарны яулыйм, йә орыш карында ятып калам, дип әйтеп әйткән, диләр...

Җилле генә юырткан ат җаена уйга чумып бара Артык баһадир. Азамат егетләре аңардан бер тотам калмыйлар. Ничәмә көн ат өстендә, ә аруның әсәре дә юк. Тәмам җанына тиде бу Сүбәдәй. Ике-өч елга бер яу йөри, Болгар халкы күзенә ак төшердеме?! Хәер, анысы хактыр — төшерде, сыңар күздән мәхрүм итте. Тик моның белән корыч баһадир Сүбәдәйнең ачуын гына китерде бугай. Ә бит Карлыгачы белән шул хәтле бәхетле яшәп киткәннәр иде. Артык кайчак өйдә әрле-бирле йөргән хатынына карап торыр-торыр иде дә: «Кил әле, күгәрченкәем, яныма!» — дип, кочып, кулына күтәреп алыр иде. Ә тегесе шуны гына көткән кебек аның муенына сарылыр, кайнар сулышы белән: «Батырбаем минем, Артыгым!» — дип җанны эретер иде. Карлыгач үзе дә сөелә, шул ук вакытта сөя дә белә шул. Онытып буламы андый мизгелләрне.

Янәшәсенә Ташбай угланы килеп юрта башлады.

— Атам, бер киңәшем бар. Кояш баюга таба тәгәри. Әнә теге елга янында төн куныйк. Кичтән калага кермик,— диде

— Якшы,— диде Артык угланга карамый гына.— Боерыгым житкер. Елга буена туктыйбыз. Ул арада олау да килеп җитәр.

Елга буена туктагач, Артык су янына төште, итеген салып аягын юды, тәһарәт алды. Аннары яр өстенә менеп, юл намазлыгын җәйде, ахшам намазын укыды. Ул арада бавырчылар казан элеп, аш хәстәрли башладылар.

Артык итекләрен киде дә яр кырыена утырды. Елга киң түгел, алай да балыклар чума, якында гына үрдәкләр бакылдый. Азамат егетләре бер читкәрәк китеп, мәзәк сөйлиләр. Көлешәләр. Эңгер инде, ул да түгел мәче башлы ябалак иңри башлады. Тора да иңри, тора да иңри. Ниһаять, тәмам караңгы төште. Күк йөзен йолдызлар чуарлады. Сәер хәл, Җигүлеат таулары янында да шулай күккә карап яткан иде. Ул вакытта Артык берьялгызы иде — Карлыгачы да, Ташбае да юк иде. Иртән сугышка керәсе иде, ә монда исә калага җитәр-җитмәс туктап калдылар. Артык атакайның калага бүген үк барып керәсе килгән иде, ни сәбәпледер угланы килеп туктатты һәм ул карусыз аның теләгән үтәде. Шик юк, угланны хан оныгы Хансөяр җибәргәндер. Хәер, хан оныгы үзе тәкъдим итсә дә, Артык атакай каршы килмәгән булыр иде. Иртәнге якта, якты көндә калага килеп керү хәерлерәк булыр.

Арыган тәнне бик тиз йокы басты, үзеннән ерак түгел урнашкан җансакчыларын чакырып алды, каравылларны тикшереп чыгарга кушты һәм ат ияренә башын салып, йокларга ятты.

Артык уянганда азамат егетләре торганнар, йөгерә-йөгерә елга буена төшеп баралар иде инде. Артык та торды, буыннарын язып алды да су буена төште, бит-кулын юды һәм яр өстенә менеп, бавырчысы хәстәрләгән табынга утырды.

Шулчак кала яклап:

— Һай-һай-һай! — дигән аваз ишетелде. Ул да түгел, азамат егетләр иярләрен куя башладылар, атларына менделәр.

Кайсыдыр моннан оран салды:

— Һай-һай-һай!

Оран салучы меңбаш Юлдаш иде. Аның тавышы каршы яктагы калкулыкка барып бәрелде, елга буендагы талларга килеп орынды, яр буйларында бераз тибрәлеп торды да елгага кереп чумды. Артык авызын кул аркасы белән сөртте дә, ашка амин тотып, сикереп торып басты һәм:

— Атларга! — дип боерды. Бу аның туган иле, туган җире, туган дала башы. Әнә шул дала башын, туган җирен ниндидер Күрәлән елгасы буйларында туып-үскән, Артык өчен чит-ят булган Сүбәдәй баһадир яуларга килә.

Бирмәс ул аңа илен!

Бирмәс! Карлыгачын да, Ташбаен да бирмәс!..

## 4

Хан оныгы Хансөярне көтмәгәндә атасы Дәүран Шайтан каласына чакыртып алды һәм ул көн буена каланың серләрен өйрәтте.

Шул вакыттан башлап, кала кирмәне хан оныгы Хансөяр өчен тәмам сер тубалына әверелде. Каланың өстәге тормышы, корылмалары, җир астындагылар белән чагыштырганда кечерәеп калды. Ошбу серле каланың җанлы тормышы җир астында икән ич! Шайтан каласында ул оста Әхмәт белән танышты, бик рәхәтләнеп сөйләшеп утырды. Тархан Бәкер угланы оста Әхмәт зыялы вә хөрмәткә ия кеше иде. Хатыны да ипле, чибәр һәм кунакчыл булып чыкты.

Кем кушуы буенчадыр, атасы аңа тоньюлларын да күрсәтте. Бу юлларны бары тик атасы һәм әмир Хаҗи гына белә икән. Атасы аңа, оста Әхмәт тә хәбәрдар, дигән булды. Хан оныгы Хансөяр атасы кылган могҗизаларга исе-акылы китеп йөрде. Барча тоньюлларын да, андагы амбарларны да атасы ясаткан икән, ләкин боларның һәммәсенә дә әмир Хаҗи хуҗа икән. Хәтерендә: җир астына манара аша керделәр. Икенче катка күтәрелгәч, атасы ниндидер таш кисәген боргандай итте һәм шундук ишек пәйдә булды. Башын ия төшеп, шул ишеккә юнәлде, Хансөяр аңа иярде. Керделәр, атасы үрелеп кенә кисәү агачы алды, ут салды һәм кул изәде.

— Атам, әтием, — диде ул ниндидер баскычлардан төшеп, тау куышына килеп кергәч. — Без кай җирдә?

— Без борынгы бабаларыбыз бакыр кайнаткан тау куышында, углан, — диде атасы һәм алга атлады. — Барысын да исеңдә тот, мин сине ары таба бирегә әллә алып килә алам, әллә юк. Урыс үзенә, магул үзенә илгә яу йөри башладылар. Борын заманда ошбу куышта бабаларыбыз дошманнардан качып торганнар.

— Шулай зурмыни бу мәгарә?

— Бик зур. Ошбу мәгарәдән өч якка өч тоньюлы китә. Берсе елгага барып чыга, яр кырыена ук, икенчесе — чуен кайнатучылар гөбәгенә, өченчесе — урманга. Кашан урманы тарлавыгы аша бирегә бер төмән сугышчыны яшерергә була. Киптерелгән ит, азык-төлек бер елга җитәрлек. Һәммәсе дә мәгарә тирәли кызылган амбарларда саклана. Менә бу мәгарәне әмир Хаҗи сиңа тапшырырга, барсын да күрсәтергә кушты. Мин әмиремнең әмерен үтим, углан.

— Нигә соң, әтием, боларны әлегә кадәр сер итеп сакладың?

— Кемнән?

— Әйтик, миннән.

— Әниең белә, күргәне бар. Әмир Хаҗи белә, бирәдә хәтта торып-торып китә. Ә менә сиңа моны белергә иртәрәк иде әле. Хәзер балигъ булдың, билеңдә хан тарафыннан тагылган кылыч, миннән дә фатиха алыр көнең җитте. Әмир Хаҗи нә урысларга, нә магулларга ышанмый. Шуның өчен ошбу мәгарәне сакларга кушты. Һич югы халкыбызның берише сакланып калыр. Яу яшенле яңгыр кебек бит ул, килә дә яндыра-

талый, бала-чага белән хатын-кызны әсир итә дә китә. Ә туган җир кала. Ил кала.

— Чуен кайнатучылар да биредәме?

— Чуен кайнатучылар бу мәгарәне дә, тоньюлларын да белмиләр. Аларның эшләре башка. Әмир Хаҗи аларга яхшы түли, торулары Кашан каласында. Зарланганнарын ишетмәдем.

— Тупларны да биредә коялармы?

— Бирелә. Туп коючы Яван үлде, урнысы оҗмахтадыр, әйбәт кеше иде. Аның урынына тархан Бәкер углы Әхмәт калды.

— Бирелә кайчандыр Болгар бабай яшәгән, диләр. Әллә юри, әллә чын, имеш, ул әле дә күренгәли икән.

— Яшәгән. Һәм күңеле саф вә ихлас кешегә әле дә күренгәли.

Хан оныгы Хансөяр чак кына көлеп җибәрмәде, әмма кисәү яктысында атасының җитди йөзен күреп, тыелып калды.

Атасы аңа һәр тоньюлын күрсәтте, бөтен булган амбарларны, хәтта хәзинә-байлык амбарын да ачмыйча гына күрсәтте.

— Бу амбарның ачкычын әмир Хаҗиның берәүгә дә биргәне юк. Үзе генә керә. Кайчак шунда хәтта куна кала,— диде ул.

— Амбарны син казыткансыңдыр бит?

— Мин казыттым.

— Казыган кешеләр исәндер бит?

— Алар әллә кайчан җир куенында инде, углан. Бу юлны белүләре аларга кыйммәткә төште шул...

— Мөмкин хәлме... Бу бит...

— Мөмкин, углан, мөмкин. Әмир әмере. Алар түгел, үзем дә куркып йөргән идем әле. Тик әмир миңа тимәде. Әйдә, әмирнең кабул итү куышына кереп чыгыйк. Мин аны тәгаен сарай кабул итү бүлмәсе итеп ясадым.

— Тупларны монда кояләр, беләм. Дары каян килә соң Болгарга?

— Дарыны чин вә табгач сәүдәгәрләре китерә, углан. Аларның бер дә Болгар белән сәүдә итүне өзәселәре килми.

Атасы бер ишекне ачты, ишек калын имәннән ясалган, авыр иде. Авыр булса да бик җиңел ачылды кебек.

Хансөяр башын ия төшеп, алдан китте. Эчкәре керә-керә, андагы җиһазны күргәч, таң калды. Тәмам тәхет бүлмәсе кебек иде. Түр якта тәхет, тәхет византия чүпрәге белән капланган, терәкләренә барс сурәте ясалган. Ике яклап түмәрләр куелган. Түмәрләр ишеккә таба түбәнәя киләләр. Димәк, әмир Хаҗи абасы бирелә дә нәкъ сараендагы кебек кабул итә кешеләрне.

Хансөяр түр якка узды, тәхетне капшады, сул яктагы кечкенә өстәлгә игътибар итте. Өстәлдә көмеш савытлар, чынаяклар, бик тә матур итеп нәкышланган кувшин. Кувшин зур гына көмеш табакта утыра, суы да бар бугай, корсагы дымланган.

— Әмир Хаҗига нигә кирәк булды микән монда тәхет, атам?

— Тәхетне мин ясадым, аңа ошады. Мактады. Мин кинәндем. Ә хәзер, әйдә, азык-төлек куелган мәгарәләрне күрсәтәм. Белеп кит. Дары мичкәләре тутырылган мәгарә әнә теге почмакта, ә менә монда ук-кораллардыр. Мин сиңа мәгарә эчендәге амбарларның картасын биреп калдырырга тиеш, углан. Әмир Хаҗи әмере. Әмирнең Шайтан каласын сиңа калдырырга исәбе. Әйдә, янадан тәхет куышына керик. Син Корьән Шәрифкә кулың куеп ант ит, углан. Ошбу кала серен һәм мин биргән картаны берәүгә дә күрсәтмәссең. Шайтан каласы ошбу көннән синеке, углан. Бу әмир Хаҗи теләге. Угланы Җаббар һәм кызы Энҗебикә Ашлы каласында һәлак булгач, каланы сиңа калдырырга булды. Тик янә бер нәрсә өчен ант итәрсең — Всеволод Оля Оя кенәзләре Святослав һәм Изяслав кенәзләрдән Ашлы каласын яндырган, хатын-кызларыбызны әсир итеп алып киткән өчен үч алырсың.

Алар кире тәхет ягына керделәр, түр якка уздылар һәм кечкенә бәрхет җәйгән өстәлдә яткан Коръән Шәрифне күрде Хансөяр, өстәл янына тезләнде, сак кына кулын изге китапка куйды.

— Инде ант ит, углан.

— Йа Раббым, мин мөэмин-мөселманнарыбызны рәнҗеткән өчен изге юлдан язган кяфер күршемез кенәзләреннән үч алырмын. Мин ул залим кяферләрне һәлак итәрмен. Җәһәннәм газабы шул булыр аларга. Йа Раббым, мәнем антымны кабул ит. Йа Раббым, ошбу Шайтан калам бәла-казалардан сакла, имин яшәргә фатиха кыл!..

— Хак, үч үчкә илтер, углан,— диде Дәуран атасы угланны юатырга теләгәндәй.— Ашлы хатын-кызларымызны бауга тезеп, әсир итеп алып киткәндә халкымыз кан-яшь түкте. Анаң Назлыгөл боларның барысын да үз күзләре белән күрә. Коръән Шәрифтә: «Аллаһуга һәм Расуленә каршы сугышкан яки җир өстендә бозыклык кылган кешеләрнең җәзасы: үтермәк яки асмак, яки уң кулын, яки сул кулын кисмәктер, ягъни үтерүчене үтерергә, талаучыны асарга, ә талаучыурлаучының аягын-кулын кисәргә, яки илдән сөрергә»,— дип тикмәгә генә әйтелмәгәндер. Аннары янә изге китапта: «Бу җәза аларга дөнья газабы, ахирәттә аларны тагын да яманрак җәза көтә»,— диелгән, углан.

— Тик бит шул ук китапта: «Берәү угрылык кылып, золым иткәннән соң тәүбәгә килсә, алган малны иясенә тапшырса һәм бөтен булган бозыклыктан баш тартса, Аллаһы тәгалә аның тәүбәсен кабул итеп, гөнаһын ярлыкар. Аллаһы тәгалә һәрчак ярлыкаучы һәм рәхимле»,— диелгән бит, атам.

— Әй углан, явыз кенәз ишләре бер гаепсез Җаббар бәкнең изге канын коялар, халкымызның иманын мыскыл итәләр, каланы көл итеп, пыр туздырып талап китәләр. Аллаһудан ярлыкау юк аларга. Була да алмый.

— Каланы ничә кенәз яндыра?

— Ике туган киләләр — Святослав белән Изяслав. Мәрьям ханбикә аларның һәммәсен дә белә. Хәтта ул да каргады бәдбәхетләрне. Гөнаһка керәсем килми, углан, Илһам хан ул яуны белгән, дип, әйтеп әйтәләр. Имеш, абасына үч итеп, урыс кенәзләрен Ашлыга котырткан. Тик берүк бу хакта берәүгә дә сөйлисе булма. Кеше сүзе кеше үтерер, диләр. Аллам сакласын, юк гөнаһың бар итеп, вакытсыз тәмугка керерсең.

— Атам, мин ул кенәзләрдән үч алырмын. Мин бу хакта изге китапка кулым куеп ант иттем.

— Яхшы, углан. Инде картага күз сал.

— Бу картаны кем сызды соң?

— Мин, углан, мин. Җир асты каласының бары тик ике картасы бар. Берсе — әмирдә, берсе миндә иде, хәзер синдә була инде. Сакла син аны, углан. Менә монда һәммәсе дә сызылган. Елга буена төшә торган төньюлы да, урман тарлавыгына чыга торганы да, манарага юнәлгәне дә. Манара аша кергәндә сак бул, ишек бик тиз ачыла һәм бик тиз ябыла.

— Аллаһымыз саклар, иншалла, атам. Без бит, атам, Артык атакай белән Саксин каласына китәбез. Картаны үзем белән алыйммы?

— Карта синеке, углан, яшереп калдырасыңмы, үзең белән аласыңмы — ихтыярың. Мин ул хакта хәбәрдар, дошманны урыс ягыннан көткән идек, ә ул әнә кай тарафтан килә.

— Магуллар күчмә халык, диләр. Алар килерләр дә яндырырларталарлар да китеп тә барырлар, ә менә урыслар килсә, төпләнеп калулары да бар. Урысның күптән күзе кыза Болгарга, атам.

— Күршең яман булганчы, сыерың кысыр булсачы, дигәннәр, углан. Яманлык яхшыга илтмәс аларны да. Бер чыкмаса бер чыгар, Аллаһы тәгалә оныкларыннан булса да үч алыр.

— Бирсен Ходай,— диде Хансөяр. Һәм чыгарга дип кузгалды.

## 5

Изге китап өстенә кул куеп ант итсә дә, хан оныгы Хансөяр урыс тарафына юнәлеш ала алмады, бүген бөтенләй капма-каршы якка юл тота — Саксинга. Ул хәбәрдар иде — Каракорымда тәхеттә Чыңгыз ханның Үгədәй атлы угланы утыра. Урыс кебек эчә икән үзе. Димәк, юмарт кеше, баһадирлары ни тели, шуны раслап торучы. Атасы заманыннан ук шөһрәткә ия Сүбәдәй баһадир уң кулында утырадыр. Бу хакта аңа Илһам хан әйткән иде. Илһам хан абасы аның белән ачыктан-ачык сөйләште, бернәрсә дә яшермәде. Шуңа Хансөяр аңа тартылды, олуг ханны ихтирам итте. Ә менә атасы аның хакында яман хәбәр җиткергәч, тәмам уйга калды. Чынлап та, дошман Ашлы каласын яндырып-туздырып йөри, хатын-кызларны бауга тезеп, әсир итеп алып китә, ә ошбу калага кул сузардай арада торган Илһам хан гаскәренә елга аша чыгып, дошманны куарга әмер бирми. Атасы әйткәчтен, бер тапкыр очрашкач, хан оныгы Хансөяр абасы Илһам ханга туп-туры: «Ашлы каласын яндырганны карап торулары яман булгандыр»,— дип әйтте. Кыю кыланды хан оныгы Хансөяр, әмма олуг хан моңа бер дә күтәрелеп бәрелмәде.

«Хак, Ашлы — абам биләмәсе. Хак, урыслар Ашлыга яу килделәр, таладылар, бик күп халкыбызны әсир итеп алып киттеләр. Яман эш. Сугыш-яуны кәсеп итеп күрә башлаган урыс күршеләребез өчен гадәти хәлдер бу. Ләкин минем аларны, бигрәк тә олуг кенәз Всеволод Олы Ояның угланы кенәз Юркәйне моның өчен бер дә яклыйсым килми, киресенчә, мин күршеләребезгә ачулы, үч алырга җай көтәм. Шул ук вакытта абамны да аклыйсым килми: әлегә кадәр миңа Шайтан каласын бирми. Шайтан каласы минеке. Олуг ханмы мин, юкмы, хан оныгы Хансөяр! Шайтан каласын миңа биргән хәлдә, мин аңа ярдәмгә бару гына түгел, урысларны әсир итеп тотып китерәсе иткән идем. Берләшергә кирәк безгә, аерылышмаска. Ә без ил-җир бүлешәбез! Мин монда, хан оныгы Хансөяр, бер абам әмир Хаҗины гына түгел, үземне дә орышам. Әйе, беләм, ул да хаклы түгел, мин дә. Ул да баш бирми, мин дә баш бирергә теләмим. Ләкин кем кемгә баш бирергә тиеш соң — йола вә гореф-гадәт буенча — олуг ханга түгелме? Ә олуг хан кем?! Аннары гайрәтле кенәз Всеволод Олы Оя күптән вафат, ә угланы Юрий белән мин солыхта».

Боларның барысын да ишетүе кыен иде. Әмма хан оныгы Хансөяр олуг ханга бер сүз дә әйтмәде. Олуг кенәз Юрий хәйләкәр дә соң. Солыхта булгач, Болгарга үзе килми, ә башка туганнарын җибәрә. Имеш, аның аларга катнашы юк. Бәлкем, юктыр да. Кенәзләр дә үзара тату яшәмиләр, гәрчә адым саен чиркәүгә кереп, Ходай алдында тәре үбеп антлар итсәләр дә. Шул ук вакытта аның Илһам ханны да аклыйсы килмәде. Гаеп атта да, тәртәдә дә бар иде. Әмма аңа хәлнең асылына төшенергә бирмәделәр — Саксин каласына алып киттеләр. Ә бит олуг хан белән сөйләшкәннән соң ашыгыч төстә азамат егетләрен алып, Владимир каласына таба кузгалырга ният иткән иде. Тик бирелән исәнимин әйләнеп кайтса, Ашлыга яу килгән кенәзләрне ул барыбер эзләп табар. Табар да үч алыр. Нинди юллар белән? Аңысын ныклап уйлыйсы бар: сәүдәгәрләргә ияреп барырмы, алай беләнме, бөтенләй башка сурәттәме? Әйтик, гап-гади мосафир булыпмы? Ни генә булмасын, ул барыбер Ашлы каласы халкы һәм туганые Җаббар өчен үч алачак!

## 6

Карамалы кирмәнендә хан оныгы Хансөяр берүзе бер бүлмәдә кунды. Булат әмирнең икенче хатыны Сарбай ханның төпчек кызы икән, аны ни сәбәпледер колач җәеп, якты йөз белән каршы алды. Һәм аерым бүлмәгә озата килде. Бүлмәгә кергәч, әйтте:

— Борчылмагыз, балакаем. Сүбәдәй зур гаскәр белән килми. Бачман җизнәй аңа каласын бирмәс. Тупларыгыз белән сез дә килгәч... Табанын бик тиз ялтыратыр.

— Карале, җиңгәчәй, сез бар нәрсәдән дә хәбәрдар икәнсез бит.

— Хәбәрдар, балакаем, хәбәрдар. Соңгы орышта үзем дә катнаштым ич. Теге мөртәтләрнең берсен әсир итеп алып кайттым. Элек Акбикә түткәй дә яу саен ук-җәя асып чыгар иде.

— Кызлары Сөмбел дә анасы кебек кыюмы?

— Сөмбеләме, балакаем? Сөмбеләм минем оҗмах фәрештәсе ул. Аңа гашыйк булмаган егет калмады бугай инде, Саксинда дим. Мәргән кыз ич. Егетләр белән бер җайда ярыша. Кыз кешегә килешеп тә бетмидер дә инде, анасы да яшь чакта шулай булган ич. Әле булса хәтеремдә, уктан алганда барысын да уздырыр иде, егетләрне дә. Яраталар инде үзен, барысы да ярата. Кыз булу бер бәхет булса, чибәр булу икеләтә бәхет, диләр бит.

— Юл бик озын булды, тузанлы...

— Әй, гелән онытып торам икән ләбаса. Мунчага бар, хәзер үк кит. Хәйретдин! — дип дәште ишек аша яшь бичә. — Хәйретдин дим, кер әле бире.

Ишектә дәү вә иләмсез гәүдәле, башына кәләпүш кигән ир-ат пәйда булды.

— Хан оныгы Хансөярне мунчага алып бар, йомышчысы бул.

— Рәхмәт сезгә, байбикә, мең рәхмәт.

— Бәрәкалла, рәхмәтләр әйтеп торырга. Башта юын, чистарын, аннары чәй хәстәрләрбез. Хәйретдин дим, син анда салкын кымыз алып барырга онытма. Эссе мунчада кунакның сусап калуы бар. Себеркенең дә җиллесен сайла, әмир киштәсеннән ал, мәтрүшкә кыстырып бәйләгәнен... — диде дә яшь бичә чыгып китте.

Тик шундук яңадан ишектә пәйда булды.

— Балакаем, сөйкемле йөзең, татлы телең өчен рәхмәт, — диде.

Хан оныгы Хансөярнең күңелен шатлык хисе биләп алды. Ошбу җиңгәчәсенең холкы вә кешеләр белән мөгамәләсе Сөмбелгә дә күчкән булса, ул аны тагын бер күрәчәк. Саксин каласында уннарча халык яши, һәммәсенең үз урамы, үз тыкырыгы. Алай да күпчелеген кыпчаклар тәшкил итә, аннары болгарлар, әзәриләр, әрмәннәр, угызлар, хәтта гөрҗиләр дә, бөҗәнәкләр, угызлар, башкортлар да бар икән. Саксин — Идел — Җаек буйларында яшәгән халыкларның уртак каласыдыр. Болгарга сәүдәгәрләр Саксин аша үтә. Базары булган каланың халкы да бай була.

Мунчадан соң тирләп-пешеп, баллап чәй эчеп утырганда хан оныгы Хансөяр моннан ике-өч ел гына элек Болгарда күргән Бачман баһадир кызы Сөмбелне күз алдына китерде. Тутасы дөрес әйтә, чибәр иде кыз, гәрчә гәүдә-сыны яңа гына түгәрәкләнә башлаган булса да, күзе булган кеше (бигрәк тә үсмер егет моны күрми калмады). Хансөяр дә күрде һәм берничә көн гүзәл кызның йөзен хыялыннан җибәрә алмый йөдәп йөрде, гүя кыз аны сихерләгән иде.

Шулвакыт аны әмир Булат дәштереп алды. Хансөяр битен-башын сөлге белән сөртте дә, хезмәтче Хәйретдингә рәхмәт әйтеп, әмир янына ашыкты. Ул килеп кергәндә Булат әмир Артык атакай белән чәйләп утыралар иде, аны табынга кыстадылар.

— Утыр әйдә, Хансөяр, утыр-утыр, тартынып торма. Без менә Артык атакай белән Сүбәдәй баһадир турында сөйләшеп утырабыз әле. Сәер хәл, нә куа аны монда, ни калган аңа биредә? Ике тапкыр кыйнап җибәрдек бит инде.

— Миңа калса, — диде тезләрен чәнчеп табынга утырган хан оныгы Хансөяр, — Сүбәдәй баһадир мәрхүм Чыңгыз ханның васыятен үти. Аурупа илләренә чыгу өчен Болгар магуллар өчен бугазга кадалган сөяк булып тора. Ә Чыңгыз хан мәрхүм угланы Җүсигә диңгезгәчә яшәгән халыкларны яулап алырга кушкан.

— Нинди дингезгә?

— Әдрән дингезенә кадәр дип уйлыйм. Миңа бу хакта Кол Гали хәзрәтләре сөйләгән иде.

— Һы, һич булмас димә, бәлкем Сүбәдәй баһадирның уенда чынлап та шул хыял ятадыр, Артык атакай, син нә уйлыйсың?

— Канга сусавыдыр. Каз каны эчеп йөри, диләр бит, мөртәтне.

— Кем әйтте? — дип сорады әллә юри, әллә белмичә Булат әмир.

— Кһм, әмир, беләсең булса кирәк, аның хатыны миндә бит, Карлыгачым — Сүбәдәй хатыны.

— Һы, кичә үлгән булсам, бүген белми калган булыр идем, кичерә күр әмирең, баһадир. Кан эчә, димәк, кансыз, явыз ул адәм.

— Явыздыр, явыздыр, анысына шигем юк, — диде Артык атакай һәм, амин тотып, тора башлады.

— Йокларга вакыттыр. Иртән иртәрәк кузгаласы итәрбез. Рәхмәт, әмир, чәең тәмам сөякләрне эретте.

Атакай чыгып киткәч, әмир Булат хан оныгы Хансөяргә бакты.

— Атакайга ни булды?

— Кәефе китеп тора. Угланы Ташбай, меңбаш дим, Сүбәдәйнеке бит. Атакай ул баһадирны угланы белән хатыны артыннан йөрмиме дип шикләнә.

— Менә сиңа мә! Һич булмас димә, — диде кинәт кенә тынычланып әмир Булат. — Тик ялгышмыйк әле, энекәш, ялгышмыйк. Сүбәдәй баһадир хатын-кызга мохтаж кешеме. Аяк астында уралалардыр әле. Аннары, илдә хатыны бар, диделәр, угланы. Сәүдәгәрләр барысын да җиткереп торалар, иншалла. Тегесе моның икенче әйләнеп кайтуына тагын бер малай табып куйган, ди. Юк, Сүбәдәйгә хатын кирәкми, Сүбәдәй, мөгаен, мәрхүм Чыңгыз ханга биргән вәгъдәсен үтәргә телидер.

— Бик ихтимал, — диде хан оныгы Хансөяр.

— Менә нәрсә, хан оныгы Хансөяр. Алай-болай эшләр начарга китә икән, бирегә чаптар җибәрегез. Үзем киләм ярдәмгә. Мин бу хакта Артык атакайга да әйттем, сиңа да әйтәм. Ул онытса, чаптарыңны үзең юлла. Аннары мин аның тупларыннан да баш тарттым. Ул монда биш йөз тупчысын калдырырга иткән иде, кирәкми. Орышның яманы Саксинда булачак. Инде бар, ял ит. Иртәгә юл чыгасың...

## 7

Саксин каласы күренүгә, бер төркем азамат егет алдан элдерделәр, әмма Артык атакай аларга тукталырга кушты һәм тупчылар олавын уртага алырга, ике меңбашны алга җибәреп, уртага олауны кертеп, арттан Юлдаш меңбашка барырга боерды.

Ташбай меңбаш белән хан оныгы Хансөяр азамат егетләре белән алдан киттеләр. Артык атакайның күңеле тыныч түгел иде. Саксин белән ике ара якынайган саен, Сүбәдәйне еш-рак күз алдына китерде. Әле ат өстендә килеш, әле чабып бара, имеш, әле юртасында утыра. Тезләрен җәйгән, уң кулын тезенә куйган, буын-буын бармаклары кәкерәеп тора, сул кулында касә — әллә кан эчә, әллә кымыз. Ә менә йөзен тәгәл генә тәгаенләй алмый. Ташбай угланы алдан китте. Күңел тынычсызлыгы, бимазалануы шул углан өчен ләбаса! Үзе генә килгән булса, үлсә дә үкенмәс иде, ә менә Ташбае... Җитмәсә Карлыгачына, орышка китәбез, ул гынамы, Сүбәдәй белән күзгә-күз очрашачакбыз, дип әйтмәде. Гомер булмаганны, атлар алырга барабыз, дип ялганлады.

Әллә соң барлык азамат егетләрен дә хан оныгы Хансөяргә тапшырып, нинди булса сәбәп табып, Ташбай угланын илгә кайтарып җибәрсенме?.. Юк, анда вөҗдан газабы гына кичерер — ватан алдында, орыш була калса — кырда ятып калган егетләре каршында?..

Артык атакай җансакчысын дәшеп, меңбашларның хәлен белергә кушты һәм ашыкмаска боерды. Аннары икенче җансакчысын мулланы чакырырга җибәрде.

— Олауда тирбәлеп кенә бармасын әле, ат менеп тиз генә мине куып житсен,— диде.

Болгардан ук бергә чыккан, әмма олауда гына сәфәр кылган мулла ат менеп, янына килеп житкәч, атлар атлаган көйгә:

— Саксин каласы еракмы әле, мелла?— дип сорады.

— Калага килеп життек инде, кул сузымы гына калды, баһадир,— диде аптырабрак калган мулла.

Артык алга бакты, чынлап та даланы бер итеп, Саксин каласы җәйрәп ята иде. Мәчет манаралары күккә баккан, күп булмаса да биекләр, мәһабәтләр. Ул арада Бачман баһадир егетләре килүчеләрне күрделәр бугай, кала яклап өермә күтәрелде, бер төркем атлы алдан барган меңбашларга таба килә иде.

— Әләмнәрне күтәрегез! Быргычылар, керешегез!— дип боерды Артык атакай.

— Урра, урра, туганнар, кардәшләр!— дип кычкырышты азамат егетләр.

Бачман баһадир егетләре килеп туктауга, барысы да бер җай белән атларыннан төштеләр һәм күкрәкләренә кулларын куеп, баш иделәр дә ат башларыннан тотып, акрын гына тупчыларга таба кузгалдылар. Һәр меңбаш тупчылары башында әләмнәр җилфердәде, быргылар ярсынды.

Ике меңбаш та атларыннан төшеп, саксинлыларны көтеп алдылар. Йа Хода, иң алдан дияргә була Бачман баһадир кызы Сөмбел килә ләбаса. Хан оныгы Хансөяр атын йөгән башыннан тоткан килеш, аңа таба атлап китүен сизми дә калды. Ни тамаша житкән, ни тамаша үскән. Толымнары түшендә, тәңкәләре зеңли, үзе елмая, күзләре елтырый.

— Сөмбел!

— Хансөяр!

Әллә тагы икесе берьюлы кычкыргангамы, үз тавышларын үзләре ишетмәделәр, әллә соң йөрәкләре генә бер-берсенә шулай дәште! Күзгә-күз карап туктап калдылар, бермәлгә генә, бары тик бермәлгә генә өнсез тордылар. Беренче булып Сөмбел аңга килде.

— Без сезне кичә көткән идек, хан оныгы Хансөяр.

— Булат туганыйда булдык, җибәрмәде,— дип аклангандай итте Хансөяр.— Сәлам сиңа, Бачман баһадир кызы Сөмбел.

Сөмбел аның янына ук килде, камчы тоткан кулын иңенә куйды.

Ул арада алар янына меңбаш Ташбай килде, баш иеп сәлам юллау урынына бер тезенә төште, кызның җилән чабуын үпте.

— Саксин гүзәлләренә кәттин-кәттин сәлам!— диде ул.

— Барыгыз да исән-саумы соң, Сөмбел?!

— Аллага шөкер. Әйдәгез, атланыгыз атларыгызга, алар сезне көтәләр. Капкалар ачык!

Барысы да атларына менделәр. Артык атакай килеп житте һәм баш иеп кенә кызга сәлам бирде дә камчысы белән:

— Минем арттан, юртып кына!— дип боерды.

Бачман баһадир кызы исә аргамагын арт аякларына бастырды һәм аты дүрт аякка басуга, сызгырып җибәрде, туры айгыр кош кебек алга очты, бары тик муенындагы өрфә яулыгы гына очып калды, аны исә кыз артыннан кузгалган Хансөяр тотып алды һәм өрфә акъяулыкны әләм итеп күтәрде.

— Саксинга! Саксинга!

Калага өйлә вакытында гына кереп беттеләр. Капкаларны япкач, сарайга таба кузгалдылар. Сарай болдырында аларны Бачман баһадир, Акбикә һәм кыпчак куштаннары, кала имамы көтә иде. Кунаклар сарайга якынлашуга, алар барысы түбән төштеләр дә Артык атакайны һәм аның меңбашларын кушкуллап күрешеп, каршы алдылар. Аннары имам

сәфәр сүрәсен әйтте. Бары тик шуннан соң гына азамат егетләрне алдан әзерләп куелган йортларга озаттылар. Бачман баһадир һәм Акбикә янында мелла Хакимҗан белән атакай Артык кына калдылар. Акбикә аларны сарайга әйдәде.

Шунда йөгереп алар янына бикә кызы Сөмбел килде. Артык кыз баланы күрде дә тан калды — чибәр вә сылу иде кыз бала, хәтта Сөмбелгә мелла Хакимҗан да игътибар итте, ачкан авызын яба алмый торды бугай. Һәм бүлмәгә урнашкач, юынып тәһарәт алгач кына, янәшәсенә килеп утырган атакайга:

— Ошбу баланы фәрештәләр үпкәндер, күз алмалы түгел үзеннән,— диде.

— Кызлары чибәр,— диде Артык ни өчендер Карлыгачын күз алдына китереп.— Андыйлар сирәк була. Ходай тәгалә моңа барысын да ишеп биргән: йөзне дә, сынны да, мөлаемлекне дә.

— Әйе, житкән кыз, тәмам өлгергән. Тәнендә җаны булган егетнең күзе төшмәсә, ул егетне табибка күрсәтергә кирәк булыр иде.

— Күрмәденмени, Бачман баһадирның кайгысы кызында түгел, кайгысы йөзенә үк чыккан. Ишек төбендә Сүбәдәй баһадир. Аны монда нигә килә дип беләсең? Әнә шундый чибәрләрне бауга бәйләп, күпләрен богаулап Каракорымга озатырга. Әйтте миңа кала имамы, Бачман баһадир Илһам ханнан гаскәр сораган икән, ә ул өч мең тупчы җибәргән.

— Бирешмәбез, баһадир, иншалла, бирешмәбез. Хәйлә белән булса да җиңәрбез.

— Дөнья илләрен талаган Сүбәдәй хәйләсез орышадыр, дип уйламыйсыңдыр, шәт. Ул бәдбәхеттә мең төрле хәйлә бардыр. Болгарда сөрлексә дә, башка халыкларны бик тиз җәтмәсенә эләктерә. Ишеттек, житкерделәр.

— Һич булмас димә, атакай Артык. Тик шайтан өметсез, ди бит.

— Мелла башың белән шайтаннар турында сөйләп утырма әле. Тизрәк ашка дәшсеннәр иде дә, табын янында киңәшергә иде — нә кылабыз. Бачман баһадирның йөзеннән үк күрдем, ниндидер өметсезлек чалымнары бар сыман, Сүбәдәйнең кем икәнен барыбыз да беләбез. Аны җиңүе җиңел дигәннәр барысы да ожмахта утыралар инде. Мин җүләр һаман тарткалашам.

— Бачман баһадир да.

— Шул без икәү генә калдык бугай инде, ике баһадир. Калганнарын, урысларны әнә күптән киез астында тончыктырды. Сәүдәгәрләр житкереп тора, барысын да ишетеп торабыз, кем, мелла Хакимҗан.

— Иншалла, Раббымыз калдырмас, ил басарга юл куймас.

— Карале, мелла Хакимҗан,— диде дисбесен тарта-тарта Артык атакай.— Хәзер безне аш янына чакырырлар, ягъни мәҗлескә. Кем сыйфатында кабул итәрләр безне, ә?.. Белмисең?.. Юктыр шул, юктыр. Ә бит аңа Илһам хан гаскәр ышандыргандыр. Гаскәрдә кимендә ике-өч төмән була. Син бит минем өчен мелла гына түгел, рухи атам да, киңәшчем дә, сер саклаучым да. Әйт әле сер булмаса, Илһам хан Бачман ханнан хат алганны сиңа әйттеме?

— Гөнаһка керәсем килми, баһадир, булмады андый хәл. Ә мин, баһадирым, Бачман баһадирга ышанам.

— Мин дә ышанам. Тик әллә нигә минем яңа гына мыек чыгып килгән егетләремне күрде дә йөзенә караңгы пәрдә инде диярсең, кара коелды. Бачман баһадирны мин беләм, ул шундук уйлады: орышчылар түгел болар.

— Ә тупларың?

— Туплардан да шул авызларыннан әниләре сөте кипмәгән яшьләр атачак бит инде, мелла Хакимҗан.

— Бар нәрсә дә Аллаһы тәгалә кулында, баһадир Артык. Язганны күрербез. Мәҗлестә меңбашлар да, ягъни угланнар да булыр бит?

Артык атакай түр яктагы мендәргә күчеп кырын төшкән меллага күз ташлап алды. Сәер хәл, мелла Хакимҗан аңа һәрчак җавап табар иде. Ялгышып та җавапсыз калмас. Ахыр чиктә Коръән шәрифкә таяныр, Аллаһы тәгаләгә юллар. Китап сүзләре белән бәхәс җебен ныгыту әйбәт, вәләкин тормыш җисмәсе җиргә якынрак тора шул. Бәлкем, ул Аллаһ чынлап та җирдә булган һәммә нәрсәне күреп, күзәтеп торадыр, хаким булмыйча гына хөкем итүе шуннандыр. Әйткән бит Коръән шәрифтә: «Теләгән кеше Коръән белән гамәл кылсын да, үзенә Раббысының җәннәтләренә бара торган туры юлны сайласын»,— дигән.

Кунак бүлмәсендә алар икәүдән-икәү генә, ни әйтсәң дә шаһит юк. Ләкин ни әйтә ала баһадир Артык мелласына? Һични! Мелла һәрчак хаклы. Тик хакыйкатьне һәрчак изге китаптан гына эзләү үзе хата түгел микән? Шул ук изге китапта: «Хакны ялган диючеләргә кыямәт көнендә үкенеч килер, җәһәннәм чокырына орыр», димәгәнме. Димәк, изге китап бирәүгә дә ялган сөйләргә кушмаган. Ә кайбер очракта изге китап сүзләренә таянып, акны кара дип өстен чыкканың да бар синең, мелла Хакимҗан. Тик бу хакта синең белән бәхәсләшәсем генә килми.

— Артык баһадир, кешенең Аллаһ каршындагы хөрмәте билгән җире вә байлыгы белән түгел, иманы белән үлчәнәдер, хак дингә инануы белән һәм изге гамәлләр кылуы белән.

— Һәй, мелла, синең белән әңгәмә вә гәп тотып утыру үзе бер дөньядыр, үзе бер гомердер. Алай да, нигә һаман мәҗлескә дәшмиләр? Әллә соң азамат егетләрем урнашкан өйләргә барып кайтасымы, мелла Хакимҗан?

— Әйе шул,— дип кырын төшкән җирдән кузгалды мелла Хакимҗан.— Барып килү хәерле булыр, хәлләрен дә белербез.

Җансакчылары аларны озата барды. Ләкин ярты юлда аларга меңбашлар үзләре каршы очрады. Иң алдан Ташбае килә. Җилле килә, башын чөя төшкән, бер башка ишләреннән буйлырак. Угланын күрүгә, Артык атакайның янә йөрәге кысылып куйгандай итте.

— Безгә бара идегезме, атакай?— диде хан оныгы Хансөяр.

— Әйе. Әллә сезне дә мәҗлескә дәштеме Бачман баһадир?

— Юк, дәшмәде. Без, атакай, сездән кичке уенга чыгарга рөхсәт алырга бара идек. Бик әйбәт урнаштык, барысы да җайда.

— Чыгарсыз,— диде Артык, мелласына карап елмаеп куйды.— Кызлар да буладыр инде анда. Кыпчак кызлары, чаялар, җорлар, чибәрләр...

— Йә-йә, Артык, угланнарны ялыктырма, күп сорашма. Оялтасың.

— Рөхсәт, рөхсәт, дидем бит инде.

— Урра!— дип өчесе тиң кычкырганнарын, ахрысы, сизми дә калдылар. Ташбай угланының күзләре елтырап китүен күреп, Артык үзе дә шатланды.

— Һәр меңбаш, һәр йөзбаш, һәр унбаш үз кешеләре өчен җаваплы. Искәрдегез!?

— Искәрдек, атакай!

«Менә шулай,— дип уйлады Артык, угланнар яныннан йөгереп китеп баргач.— Шулай. Тормыш ул. Бүген күңел ачасыз, иртәгә, бик ихтимал, орышка керергә туры килер. Бәлкем әле кайберләрегезгә орыш кырында ятып калырга да туры килмәгәе... Ташбай, Ташбай... Юк-юк, аның Ташбае шәһит китмәс, Аллаһы тәгалә аны саклар...»

## 8

Атакай буларак, Артык мәҗлес түрендә утырды. Ул бик күп ашады, алга куйган бер ризыктан да баш тартмады. Бишбармак та ашады, кымыздан, әчә балдан да йөз чөермәде, чия төнәтмәсеннән дә. Аның онытыласы, сөйләшәсе килде. Мелла исә әче әйберләрдән бөтенләй баш тартты, бары тик ризык-нигъмәтләрдән генә авыз

иткәндәй капкалап утырды һәм күбрәк тыңлады. Ул яугир түгел иде, шуның өчен дәшми утыруны артыграк күрде. Аннары Бачман баһадир янәшәсендә утырган имам хәзрәтләре дә дәшми, ул да ризык-нигъмәт белән мәшгуль, әйтерсең дә бүген-иртәгә каланың һәм халыкның язмышы да хәл ителми иде. Артык атакай тупчы егетләрен мактады, минем мең тупчым, дошманның бер төмәненә каршы тора ала дип шапырынды. Күпне күргән, бихисап орышларда катнашкан, җиңү тантанасын, җиңелү гарьлеген җаны-тәне белән татыган, Ходай саклап, әлегә кадәр исән-имин яшәгән Бачман баһадир башкаладан килгән тупчылар башы Артык баһадирны тыенкы гына тыңлап утырды. Кала башлыгы Бачман баһадир уйлана иде — бәхәссез, кала кадәр каланы Сүбәдәй явыннан бер тупчылар гына коткара алмас, гәрчә Артык атакай шулай дип ярпачланса да. Кала имамы баһадир Бачманнан җавап көтте, кунакның шапырынуын ул да ошатып бетермәде, мәгәр сүз әйтергә кыймады. Атларга куйган туплар һәммәсе өчен дә яңа корал иде, шуның өчен булса кирәк, Бачман баһадир да дәшми утыруны артыграк күрде. Алай да сабыры төкәнде, әйтеп куйды:

— Карале, баһадир, әллә соң иртәгә тупчыларың сынап карыйбызмы? Әйе, ядрәләр салмый гына.

— Бик әйбәт булыр иде,— дип сүзгә кушылды ир-канатын куәтләгәндәй Акбикә бичәсе.— Артык баһадир мең тупчысын куяр, ә без бер төмән сугышчыбыз аңа каршы җибәрербез, атасы дим?

— Кһм,— дип кисәк тамак кырды Артык, әмма сер бирергә теләмәде.— Кһм, кем, ни, сылу бикәм. Мин риза. Сынашыйк. Егетләремез дә чирканчык алырлар. Тик багучылар да булсын иде.

— Алышучылар булса, Саксинда багучылар җитәрлек, баһадир. Бөтен төрки дөньясының ачык авызы бездә.

— Килешле тәкъдим, бикәм, килешле,— диде Бачман баһадир хәләл җефетен куәтләп.

— Алайса хәл иттек. Иртәгә иртәнге якта Аллага тапшырабыз?!

— Тапшырабыз, баһадир. Әзерлә тупчыларыңны,— диде Бачман баһадир сүзне төгәлләп.

Мелла Хакимҗан Артык баһадирның кыланышын табынга утыргач та килештермәгән иде, иллә каршы әйтергә кыймады. «Әйдә, алышсыннар,— дип уйлады ул.— Кем белә, бәлкем, тупчылар орышта бөтенләй артык чылбырдыр».

Мәҗлескә хан оныгы Хансөяр чакырылмаган иде, мелла Хакимҗан шуңа шөкер кылды. Чөнки Артык баһадир чынлап та узынуның чигенә җиткән, тыяр әмәл калмаган иде. Атакайның кыланышы хан оныгы Хансөяргә ошамас, бәхәсләшеп китәрләр һәм икесе тиң көттә баһадир Бачман алдында мәсхәрәгә калырлар, дип борчылуы иде. Ул белә, Артык баһадир дөньяви бәхәсләрдә сәяси осталыктан мәхрүм заттыр, гәрчә орыш кырында тәмам җен сыйфатына керсә дә. Олуг шәех тарафыннан баһадир Артык егетләренә мелла итеп җибәрелгәч, ул тәмам коелып төшкән иде. Авылга җибәрсәләр, бер хәл, анда халык сабыр була, монда исә җыен яшь-җилбәзәк, җитмәсә сәяси яктан баһадирлары ташка үлчим. Аның бер дошманы бар: Сүбәдәй баһадир. Бары тик аны белә ул. Башка дошман аңа дошман түгел. Юк, Болгарның дошманы бер Сүбәдәй генә түгел, урыслар да бар. Алар да болгарларның канын бик күп койдылар. Баһадир, телгә беткән булса да, мантыйк фикергә сәләтле түгел, ә менә хан оныгы Хансөяр бар яктан да зиһенле, аңа биргән Ходай сәләтне. Шулай инде, берәүгә ишелеп килә, берәүдән сүтелеп тора, ә җеп очы бер Аллаһы тәгалә кулында. Ул нә кыла, шул булыр. Илһам хан җибәргән тупчы егетләрнең хәрби уенда ук отылулары бар иде, шуның өчен мелла Хакимҗан кыяр-кыймас кына:

— Тикторганда хәрби алыш җыены уздыру килешерме икән соң, бикә?— диде һәм өстәде:— Кеше көлкесенә калмабызмы? Саксинда Сүбәдәй шымчылары да бардыр, күрерләр, баһадирларына җиткерерләр, һәр кешегә сакчы куя алмассың ич...

— Алышу — азамат егетләрне сынау ул, мелла Хакимҗан. Әйдә, алышыйк. Бикә әйтмешли, минем егетләр дә чирканчык алыр, тупчылар да сынау узарлар. Магулларда ике орышның берсендә туп кебек корал күренмәгән иде кебек,— диде Бачман баһадир.

— Сүбәдәй үзе кай тирәдә соң? Бик якын булса дим?..

— Багучыларым җиткереп торалар, Сүбәдәйгә бирегә җитәргә шактый бар әле. Ашыкмый ул, җәйли-җәйли килә.

— Димәк, көченә ышана,— диде моңа кадәр бер кәлимә сүз дәшми утырган имам.

— Мин үз тупчыларыма ышанам. Яшь булсалар да уцлылар, батырлар. Иншалла, бу юлы да йөземә кызыллык китермәсләр.

— Анысы хак, заманында урыслар явыннан Болгарны шул туплар гына саклап калды.

— Саклый алмады шул, атамыз Сәлим хан яучыларга өч мең алтын-көмеш чыгарып бирде.

— Аның каравы, бикә, урысларның өч мең сугышчысы кирмән буенда ятып калды.

— Яу йөргән кенәзгә сугышчы ни ул,— дигән булды кайнарлана башлаган мелла Хакимҗан.— Алай да кенәз китте бит, китте! Димәк, курыкты, әнә шул туплардан курыкты. Болгарда хәзер махсус тупчылар бар. Беришен без аларның монда алып килдек.

— Тик, кем, мелла Хакимҗан, алдан кычкырмасак иде. Сүбәдәй баһадир да дөнья арбасыннан төшеп калган адәм түгел ич! — диде кала имамы.

— Кычкырам, кычкырам, имам, кычкырам, чөнки хакым бар.

Бачман баһадир кәперәя башлаган Артыкка карап, ирен чите белән генә елмаеп алды, мәгәр сүз әйтмәде.

— Азамат тупчы егетләрең яуда сынарбыз,— диде Акбикә.— Йә, табындагы ризыклардан җитешеп утырыгыз әле. Артык баһадирым, житеш әле, әнә бавырын да кап, үпкәсен дә. Кызларым куырды.

— Сөмбел кызың дамы? Бикәм, дим?..

— Сөмбел кызым да, Сөмбел кызым да, баһадирым. Җитеш.

— Кызыңыз чибәр, сылу, бикә, ай-һай, тормас ул сезнең җайда. Бигрәк килешле инде, балакай, фәрештәләр затыннан диярсең. Күрдем дә менә, билләһи, Карлыгачыма охшатып куйдым. Күзләре дә, үзе дә гел Карлыгач инде менә. Җиткән икән инде кызыңыз, бикәм, җиткән. Углан-нарын башлы-күзле итәргә теләп, яучылар җибәрүчеләр дә булгалагандыр инде, бикә?

— Булды, булды, баһадирым, кызлы йорт баллы була бит, балга чебен-черки кунмый торамы,— диде Акбикә эчке бер горурлык белән гүзәл кызы Сөмбел өчен кинәнеп.— Үзеннең Карлыгачың ни хәлдә соң, баһадир?

Артык баһадирның йөзе ачылып китте.

— Рәхмәт, рәхмәт, бикәм. Карлыгачым белән пар күгәрченнәрдәй гөрләшеп торабыз.— Үрелә төште һәм бикәнең колагына: — Балага узды, олгаймыш көнендә,— диде.

— Бирсен Ходай, бирсен Ходай. Исән-имин дошманны җиңеп, ил-Болгарыңа әйләнеп кайтырга язсын, баһадирым.

— Һәй, бикәм, Карлыгачым минем изге зат бит. Йөзен намазлыктан алганы юк, иншалла, Аллаһыбыз ташламас, ярдәм кулын сузар. Менә сез олгаймыш көнегездә әнә нинди гүзәл бала таптыгыз бит әле. Уртак бәхет — җан куанычы, ди бит.

— Ташбаең күрдем дә шаккаттым, баһадир. Тәмам ир-егет булган. Меңбаш икән үзе.

— Меңбаш, меңбаш, бикәм. Углан биленә Илһам хан үзе кылыч такты.

— Нигә соң Карлыгачың да үзең белән алмадың?

— Киләсе дә иткән иде. Әллә нигә тыелып калды шунда.

— Әллә соң Сүбәдәенә тап булырмын дип курыктымы, баһадирым?
— Алай астыртын сөйләшергә өйрәнмәгән мин, бикәм.

«Һәе, менә ул Сарбай хан кызы. Күр инде нинди сорау бирә дә, кай яктан кабыргага төртә». Артык тәмам айнып китте сыман, җайлабрак утырды, тамак кырды, әмма әйтер сүз тапмады. Күр инде, тәмам авызны томалады да куйды, җүнсез хатын, дип үзалдына зарланып алды Артык. Тик дошмани утыруны да килештермәде, ир-ат ләбаса ул.

— Чынын гына әйткәндә, курыктым, бикәм. Карлыгачым — минем җанымдыр, Ташбай угланым — тәнемдер. Җаным белән Карлыгачым тоеп торсам, Ташбаем үз янымдадыр янә җаным тыныч.

— Ташбаең атасына кылыч күтәреп чыгармы соң, баһадир?
— Ул аның атасы икәнен белми, бикәм.

— Ә белсә, белсә, нә кылырсың, баһадирым! Чарасыз кала күрмә, чарасыз дим. Әйт син аңа бу хакта.

— Булмастыр анысы, бикәм. Куркам. Аннары нигә кирәк аңа моны белү. Мин — атасы, мин бактым, мин кеше иттем аны.

— Ә җан — җан аныкы, баһадир. Җан тартмаса да, кан тарта, диләр бит. Сүбәдәй утыз-кырык мең сугышчы белән килә. Без бу хакта хәбәрдар. Җитмәсә, Ташбай кебек угланы янында — Күлкән. Илдә тагын бер малае калган, диләр. Тайчин атлы бугай, шулай диде сәүдәгәрләр.

— Сүбәдәй минем кан дошманым. Мин бары тик шуны гына беләм, бикәм. Мин аңа, ул миңа ошбу дөньяда көн күрсәтмәс хәлдәбез. Кайчак уйга калам, бикәм, әллә, мәйтәм, Карлыгачын онытa алмыймы, шуңа яу йөриме Болгарга?

— Ул очракта Сүбәдәй туры Болгарга яу йөрер иде, баһадир.

— Болгарга теше үтмәсә, Саксиннан башларга ниятләгән булса? Мин ышанмыйм аңа, ышанмыйм, бикәм. Күп халыкны алдады инде ул корыч баһадир. Чыңгызы вафат, олыс түрәсе Җүси дә. Ул һаман Болгар дип авыз суын корыта. Үз башына гына булса ярар иде, бикәм.

— Тупчыларың берсе миңгә тора диден бит, җиң син аны, баһадир, җиң. Җиң дә данга күмел!

Артык үз янына күчеп утырган бикәгә тәгаенләбрәк карады.

— Бу хәл бер минем тупчыларым кулыннан гына килмәс, бикәм. Илһам хан, әмир Хаҗи читтә торалар. Менә шуны аңлап җиткермим мин. Алай да мин Бачман баһадирга ышанам. Без аңа Саксин каласын бирмәбез.

— Илһам хан безгә гаскәр ышандырган иде, баһадирым, ә ул тупчылары белән сине җибәргән. Саксин Сүбәдәй кулына төшсә, Болгар озак яши алмас, баһадир. Сүбәдәй барыбер Карлыгачыңа барып җитәр. Ат астына аркылы ятмыйлар, алай гына котылып булмас Сүбәдәйдән.

— Инде соң, бикә, язганы булыр. Тик мин каланы Сүбәдәйгә бирмәм, әйе, ат астына аркылы ятып булса да, каланы саклармын, бикә.

— Сиңа Илһам ханга түгел, әмир Хаҗига хезмәт итәргә булган, баһадир. Минем аңа ышанычым зуррак.

— Ул да безне читкә какмады, бикәм. Туплар аныкы, корал аннан.

— Гаскәр Илһам ханныкы, корал әмир Хаҗиныкы. Ике туган ана бүлә. Болгар-ана — туган ил ул, баһадир, — диде Акбикә һәм Артыкны калдырып, күчеп утырды.

Хикмәт, ике туган ике юнәлештә хәрәкәт итә икән шул. Тик максатлары бер ич — илне Сүбәдәй кулыннан йолып алып калу. Сүбәдәйгә Саксинны алу җиңел — кала далада. Магуллар атта орышалар. Урмансуларны яратып бетермиләр. Болгар каласы исә урман эчендә дияргә була. Аннары чигенгәндә Сүбәдәй Саксинга кереп, үзе белән бер кыпчак табибен алып китә. Димәк, Саксин юлы аңа таныш.

Артык атакай тыенкы гына елмаеп утырган Бачман баһадирга карады. Кем Саксинда түрә? Бикәме, Бачман баһадирмы? Бер Хода белә. Кем генә булмасын, кала аларныкы — Болгар төбәге. Сакларга кирәк каланы, бирмәскә Сүбәдәйгә, бирмәскә!

## 9

Иртән уянгач, Артык баһадир кичә кич мәҗлестә булган хәлләрне күзаллап ятты. Әйе, кичә ул килешмәстәй күп сөйләде.

Табында без барыбыз да батыр, барыбыз да әтәч шул. Ул да кичә әтәчләнде. Баһадирга хас сыйфатмы бу? Һич юк! Булган хәл өчен үкенү, үртәлү аңа соңрак тагын бер килде — азамат егетләрен алышка чыгаргач. Иртән торып, алар янына ашыкты, алышка җыенырга боерды. Ә үзе күзәтә башлады. Азамат егетләре атакайларының боерыгын карусыз үтәргә керештеләр.

Туып килгән көн матур, күк йөзе аяз, дөнья шәме — кояш мөлдерәп күтәрелеп килә.

Артык җансакчысыннан атын соратып алды, атланды, тезелеп баскан тупчылары каршыннан йөреп чыкты. Ул алышка Юлдаш меңбаш тупчыларын алырга булды. Калганнары тамаша кылырга, гыйбрәт алырга тиешләр иде. Әлбәттә, ихлас дошман юк, ләкин бу хәрби уен алар өчен зур сынау иде. Ул арада бер чаптары килеп тә җитте: Үргәнеч капкасы аша Бачман баһадир сугышчылары хәрби уен үтәсе җиргә китеп тә баралар икән инде. Җилле халык кыпчаклар, кай арада җыенганнар да, кай арада орыш үтәсе кырга юнәлгәннәр. Артык атакай кулын күтәрде.

— Азаматларым, угланнар! Шулай да үзеңезне орыш кырында дип уйлагыз. Курыкмагыз! Атаңызның йөзенә кызыллык китермәгез! Алга! Кузгалдык!..

Кыпчак халкын аңлавы кыен иде. Бу халык беренче булып Болгарга кушыла. Болгар ханнары ни сәбәпледер хатыннарны гелән кыпчак ханнарыннан алалар. Шуннан туганлашу башлана. Икесе дә төрки халык, гореф-гадәт-йола бер, хәтта тора-бара дин дә исламга әверелә. Бары тик Илһам хан гына Үльдәмирдән Мәрьям атлы марҗа кызына өйләнде. Һәм гомерен бер хатын белән уздырып ята. Булат угланы Карамалыда өч хатынга ия, ә хан кадәр хан... Ханбикәсе марҗа?.. Әллә соң шуңа — хатыны марҗа булганга Саксинга гаскәр җибәрмәдеме Илһам хан? Бик ихтимал ич! Тикмәгә генә борынгылар: «Ир — баш, хатын — муен»,— дип әйтмәгәндер. Күрәсең, марҗа хатын ир-канатын Үльдәмиргә таба боргандыр. Чыңгыз ханның җиңелмәс баһадиры Сүбәдәйне һәм нойоны Җәбәйне пыр туздырып, җиңеп кайткач, ни сәбәпледер, Үльдәмир кенәзе Юркәй Илһам ханга кораб-кораб бүләкләр җибәрә һәм борынгы бабаларыча солых төзи. Имеш, «кайчан таш өскә калка, колмак бата», шул чакта ошбу солых бозылыр. Илһам хан әллә йомшаклык күрсәтте, әллә хатын йогынтысына бирелде — килеште. Аксакаллар: «Ибраһим каласын кайтарып, әҗерен түләсен, шуннан солыхка тамгаң салырсың»,— дип әйтсәләр дә, Илһам хан солыхка тамгасын сала. Тик Юркәй кенәз үзе килмәсә дә, күп тә үтми шул ук урыслар Ашлыга яу киләләр ләбаса. Илһам хан сәясәтен аңлавы кыен иде Артык баһадирга. Әмма ни генә булмасын, ул Болгар баһадиры һәм дошман кай тарафтан гына килмәсен — Артык алгы сафта булыр.

Артык атакайны меңбаш Юлдаш куып җитте.

— Максатың бердер синең, меңбаш: укчыларны сибеп тарату. Калганы синең эш түгел. Бердәм һөҗүм сафын югалткан укчылар болгансалар, шул җиткән. Игелек сиңа, меңбаш Юлдаш.

Азамат егетләре сафка тезелә калды, Артык баһадир тамаша кылырга килгән Акбикә белән Бачман баһадир янына килде. Сынбат гәүдәле, аз сүзле Бачман баһадир атыннан төшкән һәм имам хәзрәтләре белән нидер сөйләшеп тора иде, шуңамы, Артык туп-туры бикә янына килде, атыннан төште, сәлам бирде.

— Бачман мең тупчыңа биш мең укчы куйды, баһадир. Сынап карыйк, кем алдырыр. Укчыларның максаты тупчыларга җиту. Корбансыз булмас, корбансыз уен булмый.

— Тупчыларым уктан алмаслар шәт, бикә?

— Алмаслар, баһадир. Һәр укчының үз тамгасы. Кем ала, җавабын да үзе тотар. Андыйларны бездә таш атып үтерәләр.

Көтмәгәндә кала халкы уен үтәсе төбәккә җыела башлады. Моны көтмәгән Бачман баһадир белән Акбикә күзгә-күз карашып алдылар һәм икесе дә елмайдылар. Шаккатасы түгел иде, кыпчак халкы гомер-гомергә хәрби уеннарны яратты. Бачман баһадир сакчыларына халыкны туктатырга, орыш кырына якын җибәрмәскә кушты. Ул арада кашыклар кактылар, бау суздылар. Ниндидер киез җәйгән арба китерделәр, Бачман баһадир бикәсе белән анда күтәрелде. Артыкны, мелланы, имамын дәшеп алды.

Артыкның күзе тупчы егетләрендә иде. Халык шау-шу килә. Ә тупчы егетләр тезелеп, сафка басканнар. Укчылар күренмиләр әле. Менә офык читендә өермәдәй җайдаклар күренде. Алар әле сибелделәр, әле җыелдылар, әле таралдылар. Кайдандыр, җир астыннан диярлек баһадирның сылу кызы Сөмбел килеп чыкты, янында ахирәте. Бикә аларны арбага дәште. Сөмбел атасы янына килде, колагына нидер әйтте. Бачман баһадир хатынына күз сирпеп алды да, теге баш игәч, кызына ияк какты.

Акбикә эшнең нидә икәнен аңламаган, күрәсең, ир-канатына үпкә катыш караш ташлады.

— Атасы, син рөхсәт иттеңме?

— Барсыннар, уен ич,— диде ата кеше.

— Кыз балаларны хәрби уенга...— дигән булды Акбикә, гәрчә үзе шушындый уеннарда катнашып үскән булса да.— Тәмам ирдәүкә итеп бетердең инде үзен, атасы.

— Ил язмышы бер ирләр кулында гына түгел, бикәм, хатын-кызлар кулында да.

Артык баһадир бикә янынарак күчеп басты. Аңа нидер әйтергә һәм уй-фикерен борып җибәрергә теләде, әмма тел очына җай сүз килмәде. Шулчак берәү:

— Киләләр, киләләр!— дип кычкырды.

Чынлап та, биек булмаган үргә меңләгән җайдак менеп баскандай булды, алар бертын гына туктап калгандай иттеләр дә янадан кузгалдылар. Шулчак алар каршына Сөмбел белән ахирәте килеп җиттеләр. Сибелеп һөҗүмгә күчәргә җыенган гаскәриләр туктап калдылар, берара тыз-быз йөрделәр. Артык күреп торды, гаскәрбаш меңбашларын чакырып алды, атларыннан төшми генә киңәштеләр. Шуннан соң гына яуга кузгалдылар.

Юлдаш меңбаш та тик тормый, тупчыларына тагын да җәелебрәк басарга боерды һәм кисәү агачларына ут алдырды. Ниһаять, ат тояклары тупылдаган тавыш та тамашачыларга килеп иреште. Халык шаулаша башлады. Киртәләргә бәйләгән атлар да тынычсызланырга тотынды. Кайсы тартылды, тезгенен өзеп, далага чыгып чапты, кайсы әрнүле кешнәде. Артык баһадир моңа бер дә борчылмады, аларның атлары туп тавышына күнеккәннәр, өйрәтелгәннәр иде инде, ә менә Бачман баһадир атлары дулый башласалар, нишләр укчылар...

Укчылар бик тиз якынайдылар. Юлдаш меңбаш кисәү агачларына ут алырга боерды. Менә укчыларның ат башлары аермачык күренә, егетләрнең «урра!» тавышы яңгырады. Юлдаш меңбаш кулындагы кисәү агачын филтәгә төртте һәм шундук укчылар ягында ыгы-зыгы китте, бериш җайдак кисәк кенә туктап калды, беришенең аты дулады — бөтенләй кире якка алып киттеләр. Ләкин шактый зур төркем, туплар тетенен ерып, якын ук килделәр. Җәяләрендә уклар. Тупчыларны тулганага алгач, Бачман баһадир уенны туктатырга боерды. Ул Артык баһадирга карамады, арбадан төште дә укчылар башында килгән меңбашына таба китте. Артык шунда гына күрде, меңбаш ат башына кара чүпрәк бәйләгән иде — күзен каплаган. Ә күзе күрмәгән ат, кая кусаң, шунда бара.

Артык та арбадан сикереп төште. Бачман баһадир артыннан йөгерде. Бу отылу иде, укчылар аз санлы булсалар да, тупчыларны тулганага алдылар. Хак, моңа кадәр туп гөрселдәвен ишетмәгән атлар гына түгел, кала халкы да курка калган иде, ләкин таптылар бит җаен укчылар, тулганага алдылар тупчыларны. Ул арада атасы янына Сөмбел кызы килде, атыннан төште. Аның ат башына кара чүпрәк капланган иде.

Уен бетүен аңлатып, баһадирның җансакчылары колгә башына бәйләнгән әләм белән хәбәр сала; халык гөжли, шау-шу, ләкин укчылар вә тупчылар янына халыкны җибәрмиләр.

— Атам, атам! — диде кыз әтисенә якын килеп, атыннан төшә-төшә.— Без аларны җиңдек, җиңдек! Бик тиз тулганага алдык.

— Рәхмәт, кызым, алдырдыгыз, рәхмәт. Гатаулла меңбаш, хәзер үк укчыларыңны алып кит.— Бачман баһадир кызына таба иелде һәм:— Атларның күзләрен бәйләргә кем кушты? — дип сорады.

— Мин, атам.

Менә моны аермачык ишетте Артык баһадир һәм меңбашы Юлдашны дәшеп алды. Кай тарафтандыр хан оныгы Хансөяр белән меңбаш Ташбай килеп чыктылар. Ни өчендер Бачман баһадир аңа мөрәҗәгать итте:

— Хансөяр меңбаш, ошадымы орыш?

— Укчыларга дан диярга генә калды, баһадир.

Баһадир Бачман кызының иңенә кулын куйды.

— Бүген ял. Бәйрәм.— Ул Артык баһадирга таба борылды.— Баһадир каршы түгелдер бит?..

— Мин азамат егетләремә кичке уенга чыгарга рөхсәт бирдем инде, баһадир. Ә син үзең кара.

— Син хаклы, баһадир. Ә без кичке мәҗлестә әлеге уеннан нәтиҗә ясарга тырышырбыз.

Бер уйлаганда, баһадир Бачман хаклы иде. Уен аларга ниндидер тәҗрибә өстәде. Киңәшергә кирәк. Бәлкем, тупчыларны алгы сафка чыгарырга кирәк булгандыр. Хәрәкәт итә-итә атарга?.. Хан оныгы Хансөяр дә күзәткәндер, Ташбай угланы да — алар ни әйтерләр иде икән?.. Тик аларга тияргә кирәкмәс. Кичке уенга чыксыннар, ял итсеннәр. Яшьлек ике килми...

Бүлмәсенә кайткач та, сәкегә сузылып, кулларын баш астына куйган хәлдә, бик озак уйланып ятты Артык баһадир. Тупчылары белән Саксин каласын шаккатырырга килгән Артык баһадир көлкегә кала язды. Күз ачып йомганчы Бачман баһадирның укчылары аның тупчыларын тулганага алдылар.

Ниһаять, аны мәҗлескә дәштеләр. Табында шул ук кешеләр. Кала имамы гына күренми. Артык шул хакта сорагач, Бачман баһадир:

— Аны никах укырга алып киттеләр. Тарханымның кызы кияүгә чыга,— диде.

— Җитешеп утырыгыз, кунаклар,— диде Акбикә, ризык-нигъмәтләрне күчергәләп.

Артыкның кәефе юк иде, кичәге җор телен гүя җил алган иде.

— Рәхмәт, бикә, әллә нигә тамактан үтми тора. Мин укчыларны шулай тиз тупчыларга җитәрләр дип уйламаган идем, бикә. Ә ул әнә ничек булып чыкты. Укчылар күз ачып йомганчы тупчыларымны боҗрага алдылар.

— Кызым Сөмбел укчыларга атларның күзләрен ябарга дип барып әйтмәгән булса, укчыларның тупчыларга килеп җитүләре икеле иде, баһадир.

— Алай икән,— диде үзалдына сөйләнгәндәй, беренче тапкыр ризыкка үрелеп, Артык баһадир.— Алай икән. Димәк, бу хәйләне сөнен гүзәл кызын җиткерә, бикә?

— Ул җиткермәсә, башка берәү җиткерер иде. Һәр чирнең үз даруы була, баһадир, бер дә исең китмәсен. Җитеш әнә, аша.

— Меллам, син ничек уйлыйсың? Безне шулай Сүбәдәй баһадир да төп башына утыртмасмы?

— Барысы да Хода кулында, баһадирым. Аллаһы тәгалә ошбу кызга хәйлә җибәргән. Күзен бәйләгән ат сукыр тавык бит ул. Кая кусаң, шунда бара.

— Кһм, анысы шулайдыр шулаен, кем, меллам. Тик бит бу ысулны мөртәт Сүбәдәй дә куллана ала. Кем әйтә ала, кала халкы арасында аның шымчылары булмагандыр, дип. Димәк, безгә бер-бер башка чара кулланырга кирәк. Бәхәссез, алгы сафта тупчылар булырга тиеш, ләкин тупларын ату белән чигенсеннәр, алгы сафка укчылар чыксыннар. Төтен арасыннан дошман килеп чыгуга...

— Мин дә шул турыда уйлап тора идем, Артык баһадир,— диде кала түрәсе.— Тупчылар, укчылар, сөңгечеләр, аннары ыргакчылар. Иң соңыннан кылыччылар ябырыла.

— Бачман кардәшем, магул гаскәре башында корыч баһадир Сүбәдәй тора. Үзе генә киләме ул?

— Угланы Күлкән белән. Агасы Җәбәй нойон, аяклары сызлауга сылтап, яу йөрүдән баш тарткан, диләр. Багучыларым әйтүе буенча, Сүбәдәйнең безгә өч-дүрт көнлек юлы калган икән. Ашыга төшсә, ике көндә килеп җитүе дә бар. Әмир Хаҗидан чаптар килде — Җик Мәргән баһадирын ярдәмгә җибәргән.

— Йа Аллам, бирсен Ходай,— диде, мелласына күз ташлап, Артык.

— Болгарның олуг ханы Илһам сезгә безне юллады, баһадир.

Бачман баһадир дәшмәде. Артык башын түбән иде. Ул хаклы иде. Илһам хан — Болгарның олуг ханы. Иң әүвәл ил иминлегенә ул җаваплы иде югыйсә.

— Борчылма, баһадир, ризык-нигъмәт бар, корал бар. Гаскәр әзер. Хак, мин, Сүбәдәй баһадир кебек, бер Саксинымнан дүрт төмән сугышчы җыя алмадым, әмма өч төмәнгә якын ат менгән сугышчыларым бар. Сүбәдәй баһадир белән беренче орышуыбыз гына түгел, Артык кардәш, иншалла, каланы саклап калырбыз.

Артык баһадирга, янәшәсендә бавырсак капкалап утырган мелла Хакимҗан пышылдап кына яңа хәбәр житкерде:

— Баһадир кызы Сөмбелне атларның күзләрен бәйләргә хан оныгы Хансөяр өйрәткән,— диделәр.

Инде амин тотарга җыенган Артык кырпачага яңадан утырды. Ләкин мелланың сүзләрен Акбикә дә ишеткән икән. Ул тыенкы гына:

— Ул бала бер тапкыр кызымны Газраил тырнагыннан алып калган иде инде, мелла Хакимҗан.

Әйе, җинаятьме бу? Түгел, әлбәттә. Ләкин барыбер күңелне нидер тырнап алды. Артык янә амин тотарга җыенып, торып китәргә талпынды. Юк, хан оныгы Хансөяргә үпкәләмәде ул. Дөрес эшләгән. Дошманның да бу ысулны уйлап табуы бар иде. Тик барыбер кәефе кырылды. Җитмәсә, Акбикә хан оныгы Хансөярне яклап утыра. Хыянәтме бу, җинаятьме? Бер Хода белә, бер Хода хөкем итсен. Әмма аның да бу хәлгә бәһа бирергә хакы бардыр бит. Ул аның меңбашы, аңа буйсынырга тиешле кеше!

— Артык атакай, утырың, утырың,— диде сабыр гына Акбикә, баһадирның борсалануын күреп.— Гасабиланма, баһадир. Яңалык әйтәм үзеңә, сөенче.

— Йа Хода, әйтә күр, бикәм, әйтә күр. Сөенчегә сөенмәгән кешене күргәнем юк әле минем.

— Баһадир, кичә кич миңа синең Ташбаең белән хан оныгы Хансөяр килеп керделәр. Берсе минем кызым Сөмбелне җитәкләгән, икенчесе — Айгөлне...

— Йә-йә, бикә, ымсындырма инде алай. Яшьләр арасында нә булмас. Әллә соң кызларны рәнҗеткәннәрме, тузга язмаганны?..

— Юк-ла, баһадирым, юк-ла,— Акбикә ир-канаты Бачман баһадир ягына күз төшереп алды.— Атасы дим, син дә тыңла әле.

— Миндә дә булдылар алар, бикәм. Мин фатихамны бирдем инде.

— Бик әйбәт, аталары. Бик әйбәт.— Акбикә һични аңламый утырган, мәгәр күптән инде аңлаган Артык баһадирга таба борылды.— Баһадир, угланың миннән Айгөлне сорады. Хан оныгы Хансөяр мәнем кызымны алып китәм дип куркәләнде. Нишләем, мин дә риза булдым. Бактым да балаларга, елап та җибәрдем. Яшем ага да ага менә, тыелып кына торасы иде дә. Кем яшь чакта гашыйк булмаган да, кем өйләнмәгән дә, кем кияүгә чыкмаган...

— Карале, бикәм, мин кая соң, мин — атакайлары. Әллә соң мине риза булмас дип уйлауларымы?..

— Ярый, хуш, аларны гына озаткан идем, каршыма тагын җиде егетең килеп басты, барысы да кызлар җитәкләгән. Бикәмез, безгә дә фатиха бирегез, дип торалар. Түзмәдем, күрдем дә үзләрен кычкырып елап та җибәрдем. Бәхетләре генә була күрсен инде.

Артык битен генә сыпырды да сикереп үк торды һәм әле булса чәйләп утырган мелласы Хакимҗанга:

— Син нәрсә карадың, меллам, ә?! Нәрсә карадың?! Борын төбендә — орыш. Ә синең егетләреңдә кыз кайгысы!

— Кыз түгел, өйләнү кайгысы, баһадир,— диде тыныч кына мелла Хакимҗан.

— Сабыр ит, баһадир,— диде Бачман баһадир.— Иртәгә синең тарафка тагын унлап егетең кыз ияртеп килмәгәе әле. Бикәдән фатиха алырга тагын килгәннәр, ата-аналары белән үк. Кызлар үзләре.

— Кыпчак кызларымы?!

— Кыпчак кызлары, баһадир. Бездә кызлар бөтен азамат егетләреңә дә җитәрлек, иншалла.

Бу, әлбәттә шаярту иде, Артык баһадир көлемсерәргә итте, әмма иреннәре тыңламады.

— Никтер егетләрең башта безгә киләләр, әллә синнән куркалар инде, баһадир? — диде Акбикә, Артыкның күзләренә туры карап.

— Сез барысына да фатиха биргәнсез. Изге эштер, бәхәсләшәсем килми. Мәгәр мин бар бит әле — атакайлары! Бәлкем, мин дә фатиха биргән булыр идем.

— Утыр әле, кардәш, утыр. Утырып сөйләшик. Инде болай килеп чыккан икән, килешик. Хан оныгы Хансөяр никах укытамыз, дип бара, угланың Ташбай да, калган егетләрең дә. Мин имамыма әйттем, бер ишне дә кире борма, дидем.

— Тор әле, меллам, тор. Ишелеп утырма. Синең дә никах укырга хакың бардыр бит?! — диде Артык, үзе дә сизми сабыры төкәнә башлап.

— Йөрәккә йөгән салып булмый, баһадир. Өйләнергә теләгән егетләреңә каты бәрелмә, бәхиллегем юк! — диде Акбикә җитди төстә.

— Бикәм,— диде, аның янына ук килеп, Артык.— Бикәм, аппагым, мин риза, риза. Тизрәк угланымны күрәсем килә. Башта атасы белән киңәшкән булса соң. Айгөл дигән кызны җитәкләгән, диден бугай, ул бала миңа ошады. Тик, бикәм, борын төбендә орыш ич. Кайсы шәһит була, кайсы кала, дигәндәй...

— Яшьләрнең күңелләрен төшерү килешмәс, баһадир,— диде бикә һәм Бачман баһадирга карап:— Без атасы белән уйлаштык-уйлаштык та табышкан яшьләргә иртәгә үк никах укытырга, туй итәргә булдык.

— Иртәгә үк, һич кичектерми?!

— Иртәгә үк, һич кичектерми, баһадир Артык.

— Ләхәүлә-вәләкуәтә, бикә. Туй ук, бу ни дигән сүз инде? Нә калым, нә бирнә, дигәндәй. Минем егетләрнең күтләрендә бер ыштандыр.

Мелла Хакимҗан тамак кырды.

— Калым бар безнең, бикә, бар. Илһам хан бирде,— диде.

— Мелла хаклы, калым бар икән шул. Тик бит аны Илһам хан башка максат белән бирде. Нә ашарбыз, кем исәбенә яшәрбез?..

— Сабыр, сабыр ит әле, кем, мелла Хакимҗан. Сабыр итеп тор.

— Рәсүлемез Мөхәммәд әйткән...

— Торып тор дим, меллам, торып тор! Сүз миңа бирелгән, мин егетләрнең атакайлары. Әйе, мин аларның аналары да, аталары да. Минем янә бер сорыйсым килә: бикә, килешерме бу хәл?

— Нигә килешмәсен, баһадирым, нигә килешмәсен ди. Куанасы ит, угланың өйләнә. Яшьлек ике киләме. Инде әйтмәсен әйттерәсең инде. Алай-болай була калса, ичмасам, Аллаһым үзе сакласын, кояш нурында барыбызга да урын җитәрлек, ирләре шәһит булсалар, әйе, дәвамнары калыр, баһадир, дәвамнары. Ил куәте балада ич! Син үзең соң, кайдан таптың Карлыгачың? Орыш кырында түгелме?!

Артык кулларын җәйде.

— Тукта әле, тукта әле, бикәм, нигә сез мине үгетлисез. Үгетләмәгез сез мине. Миңа сез базарбаш Габдрахманны табып китерегез. Мин аңа акча бирәм, ә ул миңа кияүгә чыгасы кызларның ата-аналарына мал-бүләк табып китерсен. Шул гына. Янәшәсендә басып торган мелласы, баһадирыннан бу сүзләр чыгуга, кулын күтәреп дога укып алды, аңа карап, һәммәсе дә дога укырга керештеләр. Килешү шуның белән тәмамланды.

## 10

Артык баһадир өйләнергә теләгән барлык егетләр белән дә сөйләшеп чыкты, иң соңыннан хан оныгы Хансөяр белән угланы Ташбайны дәшеп алды. Аңа калса, бу эшне алар башлаучы иде. Сөйләшә вә аңлаша торгач, шулай булып чыкты да. «Ярый,— дип килеште ул эчтән генә.— Үз ярларын Саксинда тапканнар икән, бихуш, кавышсыннар. Кияүгә чыга торган кызга кияү табу бер бәхет булса, орышка керә торган егеткә өйләнү — ике бәхет».

Атакай Артык күрде: өйләнәсе егетләр генә түгел, калган ишләре дә тырышып тупларын чистарталар, атларын карыйлар, ук-җәяләрен барлыйлар, кылычларын чарлыйлар. Койма аша азамат егетләргә Саксин кызлары карап тора. Кызлар, тупчы егетләр бергә килеп урнашкач та, тамаша күрергә килгәндәй, коймага килеп сарылганнар иде. Беренче көнне Артыкның моңа бер дә исе китмәгән иде, бүген исә кияү күзләргә килгән кызлар аның эчен пошыра башладылар. Әмма күз алдына Ташбай угланы сайлаган, килен буласы кыз Айгөл килүгә, үзалдына елмаеп куйды. Сукыр түгел, күрде, күзәтте, атасының фатихасын алгач, Ташбай үрле-кырлы гына сикермәде — шатлыгы күзләренә генә түгел, йөзенә үк бәреп чыкты. Ул атасы алдына тезләнде дә баш иде. Артык аның башына кулын куйды һәм гүя тәненә ниндидер тетрәнү иреште. Углан шатлыгы аңа да күчкәндәй булды. Әйдә, өйләнсен, бикә әйтмешли, ир китә, хатын кала. Ташбае орыш кырында ятып калса, һич югы Карлыгачына киленен алып кайтыр. Аннары кызлар тапкан угланнар киләчәктә ил терәге булачак ич. Кем ул ир кеше? Ир кеше — ил саклаучы, игенче, көтүче, гаилә башы, иң мөһиме, хатын-кыз канында дәвамын калдыручы. Димәк, иргә чыккан хатын илне — ил, ирне — ир итүче икән бит. Ил киләчәге хәзер алар кулында. Углан чынлап та Айгөлгә гашыйк икән — тигез гомер итсеннәр. Ул гынамы, гашыйк кешене сөйгәненнән аерсаң, аның чиргә сабышуы ихтимал. Ил данын, халык санын дәвам итү өчен бары тик бер юл бар — ике затның мәхәббәт аша кавышуы. Мәгәр бу хәл адәм баласы өчен үзенә бер тантана булсын иде. Юкса ил — ирсез, халык дәвамсыз калыр. Мелла хаклы, ир-ат чын егет икәнен орыш кырында корал тотып кына расламый, аның иң зарур максаты хатын-кыз тәненә үз дәвамын сызып калдыру. Сиңа да килде ич ул бәхет, Артык. Шулай булгач, карасыннар Саксин кызлары тупчы егетләрне, күзләсеннәр... Кем дә кем өйләнергә тели — иртәгә үк никах укыта башларга. Каладагы бар мулланы чакырып.

Артык азамат егетләрен дәшеп алды, барлык меңбаш, йөзбашлар да җыелгач, арбага менеп, аларга күз ташлады һәм бөер түреннән чыккан тавыш белән болай диде:

— Азатларым, кем дә кем Саксин кызларына өйләнергә тели, иртәгә иртән үк сарай каршына парлашып килсеннәр. Никах уку булачак һәм иртәгә үк туй да итәрбез. Куанычы — сезгә, мәшәкате — миңа. Артык атакаегыздан сезгә ошбу изге эшкә фатиха!

— Урра! Урра! — кычкырды азамат тупчы егетләр. Очлымнар һавага очты, бер-берсен котлау, кочаклашу китте. Артык арбадан төште, меңбашлар атакай каршына килделәр.

— Рәхмәт сиңа, атакай, — диде хан оныгы Хансөяр.

— Игелек сиңа, атаем, — диде угланы Ташбай.

Артыкның күзләре дымланды, читкә борылды, бармак очы белән яшь бөртеген сөртеп алды һәм калтыранган тавышын сизәрләр дип булса кирәк, җансакчысы тотып торган аты янына атлады.

— Бүген кичке уенга, иртәгә никах укытырга, — диде хан оныгы Хансөяр, арбага менеп басты һәм шулай дип барчасына да кычкырды. Койма буена килеп сарылган кызлар да чыркылдаша башладылар. Артык атакай, тамак төбенә килеп тыгылган яшь төерен йота-йота, сарайга таба кузгалды. Туй мәсьәләсендә бикә белән киңәшәсе, Бачман баһадирны күреп, багучыларыннан килгән хәбәрне беләсе бар иде. Иртәгәсе туйны Сүбәдәйнең бозып кую ихтималы бар иде.

## 11

Хан оныгы Хансөяр аңа каршы алырга килгән көнне үк гашыйк булды. Сөмбел аның күз алдында үсмер чакта авыру килеш сакланган. Монда исә җиткән кыз басып тора. Нурлы йөзеннән күзләрең алмалы түгел. Бөтен кыланышы, зифа гәүдә-сыны, елмаюлары, тулыланып киткән калку күкрәкләре күз ташлау белән үзенә җәлеп итә һәм әсирләндерә иде. Ул аны бу кадәр чибәрләнеп китәр дип уйламаган иде, баксаң күзең алмалы түгел ләбаса!

Сөмбел атыннан төште, аңа таба килә башлады. Юк, алиһәдер бу, кайчандыр бит очларына ут капкандай сырхаулап яткан кыз түгелдер. Хан оныгы Хансөяр аның кулына кагылды һәм кызның һәр буыны зеркүен, тоемлы хәбәр итүен сизүгә, чак кына аягына төшмәде. Ләкин моны меңбаш Ташбай эшләде. Үкенү соңрак килде. Ә бит ул да аягына төшә ала иде. Хан оныгы, янәсе, горур. Юкла, бер дә горур түгел, ул бары тик каушап кына калды. Кыйгач кара кашлы, зәңгәр күзле, кайтарылып торган керфекләре лепердәшеп куялар, бит очындагы миңе әле чокырчыкка бата, әле үзалдына елмая кебек. Сусыл алсу иреннәрендә кинаяле, мәгәр үз иткән мөлаем елмаю.

Мәхәббәт аны әнә шулай үз ташкынына алып кереп китте. Ул аңа шул хакта әйтәсе итте, әмма тел очына бер генә матур сүз дә килмәде. Хансөяр тирә-ягына күз ташлап алды, барысы да күрешә, таныша. Атакай угланы Ташбай да Сөмбел белән килгән кызга нидер сөйли, әмма ул да сүз таба алмый изалана, кызның коралларына соклануын аңлатырга теләп, әле хәнҗәренә, әле кылычына кагылып ала. Аларга Сөмбел дә игътибар итте.

— Минем ахирәтем ул, Айгөл, — диде.

— Егете меңбаш Ташбай. Мәргәнебез. Атакай угланы, — диде хан оныгы Хансөяр ни әйтергә аптыраудан.

Аннары алар сарайга таба кузгалдылар.

Хан оныгы Хансөяр атта барган Сөмбелдән күзен ала алмады. «Мин аңа гашыйк, мин аңа бер күрүдә гашыйк», — дип тәкърарлады. Һәм шунда гына аңлады Саксинга ни өчен ашкынуын. Бачман баһадир кызын күрергә теләгән икән ич, күңеле тарткан. Ул бүген иң бәхетле кеше. Хак,

күрүгә каушады, кызның җанын эретердәй татлы сүзләр әйтә алмады. Ләкин ана багар, аны күрер өчен Аллаһы тәгалә үзе аны бирегә алып килгәненә тәгаен инанды. Сөмбел кебек сылуны аның очратканы булмады, булса да берәү дә болай әсәрләндермәде, күз явын алмады. Ул бер күрүдә Бачман баһадир кызына гашыйк.

Урнашкач, төн килгәч ул һавага чыкты. Күк йөзенә бакты, Аллаһы тәгаләдән үтенде — шул кыз белән мин бәндәңне кавыштыр, дия-дия догалар укыды. Күк йөзен чуарлаган йолдызлар арасыннан аның йолдызын эзләде, чөнки аңа балачакта: «Һәр кешенең үз йолдызы була, һәр кеше үз йолдызы белән туа»,— дип әйтә торганнар иде. «Мин аны таптым, мин бәхетле,— дип пышылдады ул, әйтерсең лә кем дә булса аны тыңлап тора иде.— Күңелем күк йөзендә булса, күзләрем синдә, Сөмбел, синең йолдызыңда...»

## 12

Кызлар тавында хан онычы Хансөяр аны үзе эзләп тапты. Ташбай Айгөл белән Сөмбел янында иде инде.

— Хәерле кич, кызлар!

— Сине көтәбез, Хансөяр,— диде Ташбай.— Сөмбел тәмам таптыра башлады.

— Менә ул мин, Сөмбел туташ.

— Әйдәгез «Әйлән-бәйлән» уенына,— диде Айгөл һәм Ташбайның кулыннан алды.

— Бара торыгыз, без хәзер,— диде Хансөяр.

— Ә без, хан онычы Хансөяр, елга буена төшәбез. Төшәсеңме минем белән?

Сорап тора тагын, төшми буламы. Кыз үзе үк аның кулыннан алды, һәм алар йөгерә-йөгерә елгага таба киттеләр. Яр өстенә килеп туктагач, сулышларына кабып бертын тордылар да, кыз егетнең күкрәгенә башын салды. Хансөяр аны кулына күтәрде һәм бер урында зырылдатып әйләндерергә тотынды. Аннары аякларына бастырды да күзләренә карады.

— Мин сине яратам, Сөмбел. Сөмбелем дим...

— Мин дә, мин дә сине яратам, хан онычы Хансөяр.

— Моннан ары мин сине берәүгә дә бирмәм, берәүгә дә.

— Мин синнән берәүгә дә китмәм, хан онычы Хансөяр. Пәйгамбәремез сораса да.

— Мин синең калаң Саксинга Сәмрау кош канатында очып килдем, Сөмбел.

— Мин синең бире киләсеңне төшемдә күрдем. Күргән төшемне анама сөйләгәч: «Гашыйк буласың, балакай, тик башың югалтма»,— диде. Ә минем ул башны югалтасым килә, Хансөяр.

— Илгә дошман килә, Сөмбел. Яман дошман.

— Дошманга каршы син яу чыгасың, син, Хансөярем.

— Минем орыш кырында ятып калуым бар, Сөмбел.

— Тәкъдирдән узып булмый, хан онычы Хансөяр. Ләкин без бүген бергә, минем синнән аерыласым килми. Орышка мин дә синең белән чыгармын.

— Син хатын-кыз, Сөмбел. Асыл затның максаты башкадыр.

— Беләсең килсә, хан онычы Хансөяр, борынгы кыпчак хатын-кызлары дошман белән ирләр сафында орышканнар. Ир вә хатын бер затта булган.

— Борынгы бабаларыбыз чорында, бик ихтимал, шулай булгандыр да, Сөмбел. Хәзер заманалар үзгәрде. Кораллар камилләшә, орышлар ямманлана бара.

— Син мине куркытасың, хан онычы Хансөяр.— Кыз егетенең күкрәгенә таянды, гәүдәсен читкәрәк алды.— Караңгы төште. Тик иртәгә бу

көн булырмы, кабатланырмы бу мизгелләр, хан оныгы Хансөяр! Адәм баласы үлми ич, тәне кала җаны күккә аша һәм бала сурәтендә кире әйләнеп кайта. Орыш кырында ятып калсак — ахирәттә бергә булырбыз. Орыш кырында, изге юлда һәлак булган кеше шәһит оҗмах иясе булыр, ди.

Хансөяр кызлар тавы ягына каерылып карады. Ул тарафтан җыр тавышы килә, аерым кычкырган авазлар ишетелә. Яр астында тасма кебек сузылып яткан елга төсмерләнә. Кояш баеган тарафта офык кан төсенә кергән. Орыш кан коюдан тора, адәм канын коюдан. Алар бирегә иң яман корал алып килделәр — туплар. Кем исәбенә бетәр орыш. Магулларда туплар юк, диләр. Димәк, аларның дошманны җиңүләре бар. Илгә данны җиңүче китерә. Тик орыш кырында адәм канын койган кешене данга күмәргә ярармы икән? Аннары бөтен дөнья халыкларын яуларга керешкән магулларны яңа корал гына туктата алырмы? Тупларны кулга төшереп, янә дә дәртләнебрәк, куәтләнебрәк илләр яуларга керешмәсләрме?.. Бу хакта бераү дә белми, моны бары тик бер Аллаһы тәгалә беләдер. Тик, белгәчтен, нигә орыштыра микән адәми затларын? Бит аның кодрәте барысына да җитәргә тиеш...

Елга буенда утлаган атлар пошкырганы ишетелеп китте. Яр буендагы таллар, әрем куаклары күңелгә нindидер үзе дә аңлап бетермәгән шом сала. Сөмбел дәшми, ул аңардан җавап көтә. Нинди җавап бирә ул аңа? Ул аңа гашыйк, ул аның өчен гомерен бирергә дә риза. Менә хәзер, шул мизгелдә үк. Тик бит ул гомерне бирү өчен башта игелеген күреп каласы иде.

Хан оныгы Хансөяр дәшмәде, ул кызның кулыннан алды да елгага таба төшә башлады, кыз карусыз буйсынды, ул да һични әйтмәде, әйтерсең лә йөрәкләре сөйләшә иде. Һәм шулай да түгелме соң?! Кайнар куллары аша кайнар йөрәкләренә гүя жеп суздылар, алар гүя бер тән, бер җанга әверелделәр. Юк, йөрәкләр сөйләшкәндә сүз артыктыр. Бер тапкыр аңа мөгаллиме кәтиб Хафиз: «Саф мәхәббәт йөрәккә кадалган уктыр»,— дигән иде. Сүз исә бу очракта йөрәккә кадалган укны тагын да тирәнгәрәк тартырга мөмкин. Туктадылар. Кыз аңа таба борылды, йөзенә бакты. Караңгы булса да, ул аның йөзендәге һәр үзгәрешне күрде, хәтта елмайган иреннәрен тойды. Кисәк ул чарасыз калды, кызның алдына тезләнде һәм аякларыннан кочты. Сөмбел тәмам гасабиланды, ни кылырга белми аның башына кулларын куйды һәм үзе дә тезләнде. Хансөяр аның ике битеннән алды, кулында, уч төбендә кайнарлык тоеп:

— Мин сине яратам, Сөмбелем,— диде.

— Мин дә сине яратам, Хансөяр, мин сине көттем. Мин чарасыз, йә син мине бүген ал, йә суга ташла.

Ул елмайды, син әкият китабы битеннән төшкән хыялый җан, диясе килде. Ләкин алай дип әйтергә кыймады, кызның рәнҗүе, үпкәләве бар иде. Кинәт ул аны янә кулына күтәрде. Мәгәр кыз җылан кебек сузырылып чыкты һәм елга буйлап йөгереп китте. Хан оныгы Хансөяр: «Егылырсың!» — дип әйтәсе иткән иде, исенә килде һәм аның артыннан ташланды. Куып җитте, кулыннан эләктерде һәм җиңел генә кулына күтәрде.

— Мин сине хәзер дию пәрие сораса да бирмим. Бераүгә дә.

— Борын-борын заманда кардәшләребез Таман ярымутравында көн күргәндә, Бөек Болгар дәүләте тәхетендә олуг Кубрат хан утырганда, Фәнәгүр каласында кызларны шулай кияүгә биргәннәр. Кыз елгага таба йөгереп китә, ә егете аны куып җитәргә тиеш. Куып җитсә, кыз аныкы, инде куып җитә алмый икән — кичерә күрсен, димәк, кыз аны теләмәгән, йә егете дәртсез булган. Син мине куып тоттың, хан оныгы Хансөяр.

— Ләкин, Бачман кызы Сөмбел, кагыйдә буенча, кыз суга кереп аягын чылатырга тиеш булган. Син аягың чылатмадың мин сине тоттым. Димәк, син минем хатыным?!

— Хатының, хан оныгы Хансөяр. Мин синеке. Алып кит мине моннан. Сөмбелне үзеңнеке итәсең килсә, бер шарт сиңа, хан оныгы Хансөяр: атам-анама кереп, фатихаларын аласың.

— Без икәү керәбез алар каршына, Сөмбел. Кулга-кул тотынышып. Гәрчә дошман борын төбендә генә булса да, мин сиңа өйләнәм, Сөмбел.

Хан оныгы Хансөяр кызны аягына бастырды, асыл ташлар белән бизәлгән беләзекле беләгеннән тотты.

— Анам бүләге, мәхәббәт беләзеге,— диде кыз кулын алырга теләп.— Бу беләзекне аңа беренче ире Әмир Хаҗи бүләк иткән. Әнием бу беләзекне, тылсымга ия, дип бара. Бермәлне Шайтан каласына баргач, анам шул беләзекне югалта. Шунда анам ант иткән: беләзегемне тапкан кешегә ирем ташлап кияүгә чыгарым, дигән.

— Кем тапкан соң беләзекне?

— Бачман баһадир.

— Бермәлне син дә аны югалтырсың, син дәме мине ташлап китәрсең?.. Каяле, карыйм әле шул тылсымлы беләзекне...

Салдырып алды, әйләндереп-тулгандырып карады-карады да елга читенә ташлады. Сөмбел аһ! итте.

— Анам бүләге ич, Хансөяр! Нишләвең инде бу?!

Хан оныгы аны кочагына алды, күкрәгенә кысты. Ай калыкты, елга өсте көмеш төсенә керде.

— Мин аны хәзер табып алып чыгам.

Чишенә башлады. Чишенде. Сөмбел аңа шаккатып карап торды.

— Куй, Хансөяр. Булмаганны. Мин аны болай гына әйткән идем.

— Мин сиңа беләзегең табып бирәм, син бүген үк вәгъдә бирәсең.

— Мин сине болай да яратам, мин сиңа болай да кияүгә чыгам, хан оныгы Хансөяр.

Кыз аны туктатмакчы итте, ләкин ул елгага кереп бара иде инде.

— Монда комлык, сай. Табам мин аны, табам. Иртәнгә чаклы эзләсәм эзләрмен, барыбер табармын.

Чума-чума бик озак эзләде. Чыкты, тезләрен кочаклап бертын дәшми генә утырды. Сөмбелнең кәефе кырылган идеме, бер сүз дә әйтмәде. Тик бераз торгач кына:

— Туңдың бит инде, зинһар, киен. Мин аны юри генә әйттем, Хансөяр,— дип ялварды кыз.

— Мин өшемим, Сөмбел. Минем йөрәгем ут яна. Мәхәббәт уты. Үзең кабыздың, үзең үк аласыңмы? Табам мин аны.

Кереп китте, чумды чыкты, чумды чыкты. Сөмбел ни кылырга белми арлы-бирле йөренергә кереште. Анасы хикәятенә ышанып, җитмәсә аны гашыйк булган кешесенә сөйләп, башына бәла алды. Ә бит анын беләзекне тапмавы да бар иде. Шуннан беләзеккә сылтап... Йа Хода! Бу турыда уйларга да куркыныч иде.

— Хансөяр, Хансөяр дим, ташла инде, чык. Мин сиңа болай да кияүгә чыгам. Анам да, атам да риза булырлар, алар миңа каршы килмәсләр. Ышан! Хансөяр дим!

Кыз су читендә басып тора, өзгәләнеп ялвара, ә ул һаман чума да чума. Сөмбел каударлана башлады, итекләрен салып, суга кермәкче итте, ахыр чарасыз калып, чишенергә тотынды. Әмма икенче мәлдә ояты килде. Эчке күлмәктән генә калгач, куллары белән үз-үзен кочаклап, беравык икеләнеп торды. Хансөяр аны әллә күрми, әллә юри күрмәмешкә салына, һаман чума, һаман беләзекне эзли. Кыз суга ук керә башлады. Су салкын түгел икән, һавадан җылырак. Менә су биленә җитте, кемдер татлы итеп күкрәкләрен кытыклаган кебек тоелды. Рәхәт тә, куркыныч та иде. Бөтен гәүдәсе суга күмелгәч кенә, йөзеп китте һәм егет янына ук килеп чумды. Су төбенә төште, капшанып, кулына каты әйбер тимәсме дип йөрде. Өскә калыкты, судан чыкты. Нишләве инде бу хан оныгы Хансөярнең? Тагын керде, биленә кадәр суга кергәч, аягына нидер кагылып киткәнне тойды да чыр-йылап җибәрде. Ул да түгел, судан Хансөяр килеп чыкты.

— Хансөяр җаным, котым алдың ич! Ташла, әйдә чыгабыз.

Хан оныгы Хансөяр дәшмәде, су читенә баскач кына уч төбен ачты.

— Менә мәхәббәт беләзеге. Таптым!

— Хансөяр җаным, таптың, таптың! Мин синеке, синеке!

Хан оныгы Хансөяр аны кулына күтәрде, яр башына алып менде, аякларына бастырды. Әйтер сүз таба алмады. Киемнәре өстенә утырды, Сөмбел янәшәсенә чүмәште. Ярымялангач тәннән калгач, бер-берсенә күз салгач, гүрчә караңгылык булса да, өнсез калганнар иде. Сөмбел аның муенына сарылды, озын юеш толымнары ике күкрәк арасында калды, аларны артка чөйде, кайнар сулышы белән егетнең тәнен пешерде. Егет калтырана башлады.

— Син өшисең, Хансөяр?

— Юк, өшемим, янам.

Кыз карусыз аңа буйсынды, аның һәр теләгенә бирелде.

— Сөмбелем, сандугачым-былбылым минем, Сөмбелем!..

— Хансөяр, Хансөяр, мин сине яратам, яратам...

Аның ошбу татлы сүзләре егетнең күңел түрендә генә тукталып калмады, йөрәгенә үтте, ул бөтен тәне-җаны белән аңа тартылды. Һәм кызны назлый-сөя башлады. Ачылып киткән күкрәкләреннән, битләреннән, кендек чокырларына җитеп үпте. Сөю-назга тансыклаган, ана сөюеннән башканы күрмәгән, мәгәр ана мәхәббәтеннән күп тапкыр өстен булган иркәләүгә вә назга кисәктән тап булган кыз соңгы мәлдә Аллаһыга ялварды: «Йа Аллам, кичер мине. Мин гөнаһ кылмыйм. Мин аны бөтен җаным-тәнем белән яратам. Ул мине ала һәм мин чарасыз калып, аңа тартылам. Үзем, үз теләгем белән...»

Аллаһы тәгалә дәшми, чөнки пәйгамбәребез дә ошбу изге эшне гөнаһка санамаган. Изге эш гөнаһлы була алмый, дигән. Ләкин бит шул ук Аллаһы тәгалә биргән адәм баласындагы акыл, ярсу хистән күп тапкыр өстендер. Әйе, өстен. Алай булгач, ошбу яшьләр туктасыннар иде, нигә гөнаһ кылалар, чөнки никах укытмаганнар ич! Әйе, укытмаганнар, ләкин кавышулары эчкерсез, саф, илаһи, шуның өчен Аллаһы тәгалә аларны гафу итәр. Мәхәббәт ташкыны икесен дә чарасыз итте. Татлы дулкыннар әле йөгереп килеп йөрәккә тулды, әле зиһенне томалады. Тикмәгә генә борынгы балаларыбыз мәхәббәт алласын диңгез күбегеннән яралган дип әйтмәгәннәрдер, күрәсең.

Мәхәббәтнең татлы дулкыныннан соң гаҗизләнү хисе килде, кыз кайнар иреннәре белән аның йөзенә сыенды.

— Син курыкма, Сөмбелем.

— Мин курыкмыйм, Хансөярем, курыкмыйм. Мин сине яратам.

Ул янә аның битләреннән, кашларыннан, керфекләреннән, күзләреннән үбә-үбә иреннәренә күчте, кайнар күкрәкләренә сыенды. Сыгылып килгән зифа сын, күк йөзендәге ялгыз ай, елга шавы, балыклар чупылдавы, тирә-яктагы шомлы авазлар бөтенләй башка төс, башка моңга әверелде. Алар икесе дә моңа кадәр саңгырау йөреп, яңа гына аваз ишеткән кешеләрдәй исәңгерәп калганнар иде. Ошбу бәхетне, ошбу татлы назны икесенең берсе һични белән дә чагыштыра алмады. Тиңе булмаган бәхет ишелгән иде иңнәренә, күтәралмастай бәхет...

Соңыннан, икесе дә таралып, мәгәр кулларын-кулга куеп, бер-берсенең сүрелеп җитмәгән тән җылысын тоеп, сүзсез яттылар. Икесе дә күккә баккан, гүя зәңгәр-күгелҗем күктән үз йолдызларын эзләп-эзләп тә, җирдән, әнә шул якынлыктан табуларына таң калганнар иде. Күр инде, ул йолдыз җирдә икән ич, янәшәсендә ята. Ә бит икесе дә сабый вә үсмер чакта ул мәхәббәт йолдызларын гелән күктән эзләделәр. Һәр атылган йолдыз аныкы, аңа төшәр кебек иде, һәр атылган йолдыз аның язмышы кебек иде. Тикмәгә генә изге китапларда Аллаһы тәгалә һәр җан биргән кешесенә үз тиңен эзләтер, тапканы бәхетле булыр, тапмаганы бәйгыш кебек гомер буена иңрәр, димәгәндер.

Алар табыштылар, инрисе юк. Алар кавыштылар. Ә инде имаммеллалар уйлап тапкан никахны соңрак та укытырлар, өлгерерләр. Гашыйклар өчен бүгенгесе кыйммәт, бүгенгесе кадерле иде.

## 13

Икенче көнне искитмәле хәл булды. Болгардан килгән мелла Хакимҗан каршына йөздән артык азамат егет сөйгән ярын җитәкләп килде. Меллага атакай Артыктан һәммә кавышкан яшьләргә никах укырга әйтелгән иде инде. Ул өйләнешергә теләгән яшьләрне нәүбәткә куйды һәм үз эшенә керешге.

Хан оныгы белән үз кызына Бачман баһадир никахны имамыннан укыттырды. Ләкин аларга никах укылуга, Артык баһадир килеп керде, баһадир артында кулга-кул тотынышып, Айгөл белән Ташбай углан торалар иде. Имам аларга да никах укыды. Шулай итеп, тупчыларның күбесе Саксин кызларына өйләнеп, хатынлы булдылар. Артык баһадирга тупчыларын кызларның ата-аналарына җибәрергә туры килде. Әмма кисәтте: иртән-иртүк җыен төбәгендә булырга тиешләр.

Никахлашу мәсьәләсенә килгәндә, Акбикә бигрәк тә канәгать иде. Ул бертуктаусыз елмайды, Артык янына килеп:

— Кинәнәсе ит, атакай, кинәнәсе ит. Угланың каламдагы иң гүзәл вә акыллы кызга өйләнә. Күрәмсең, киленең язгы тамчы судай чибәр. Карлыгачыңа да ошар.

— Бикәм, бикәм дим. Рәхмәт сиңа, мең рәхмәт. Тик минем күңелемнән корыч баһадир Сүбәдәй китми...

— Бар, баһадир, котла балаларың, котла-котла.

Артык баһадир угланы Ташбай янына килде, Айгөлнең кулын үз учына алды, йомшак иде кызның кулы, әйтерсең, сөякләре дә юк иде.

— Төкле аягың белән, балакай.

— Рәхмәт, әтием,— диде кыз. Нәкъ шулай диде, «әтием», диде.

Артык баһадирның янә күзе дымланды. Колак яфрагы аша йөрәгенә үтеп кергән бу сүз баһадирны тәмам гаҗизләндерде. Бу сүзне аның кыз бала авызыннан беренче ишетүе иде. Моңа кадәр хәтта Ташбай угланы да аңа: «Атам, атакай»,— гына дип дәшәр иде. Ә бит ул үскән төбәктә аталарына нигәдер «әтием», диләр. Шуңамы гаҗизләнде, шуңамы күңеле нечкәрде. Хәтта Ташбайга: «Углан, миңа әтием дип дәшсәң икән»,— дип тә әйткән иде, әмма моңа нә хатыны Карлыгач, нә углан үзе игътибар итмәделәр. Углан Ташбай аңа «атакай, атам» дип дәшүен дәвам итте. Ә монда бу кыз бала авыз тутырып: «Әтием!» — диде.

Артык баһадир чарасыз калып, килененең битеннән үпте һәм янә:

— Төкле аягың белән, балакай,— дип кабатлады.

Шул җайдан Артык атакай һәр өйләнгән егетенә фатиха биреп, аларга изгелек теләп, йөреп чыкты. Шуннан соң гына ошбу йоладан мәхрүм калган тупчы егетләренә юнәлде. Һәм аларга әйткән беренче сүзе:

— Ә сез нәрсә карадыгыз, Саксинда кыз беттемени? — дигән сорау булды.

Атакайдан бу сүзне ишетүгә, бериш тупчы егет койма аша карап торган кызлар янына ашыкты. Артык меңбаш Юлдаштан:

— Болар кая киттеләр тагын? — дип сорады.

— Ярәшкән кызларын дәшкәннәр иде, сездән фатиха алырга куркып торалар иде, атакай.

Артык кашларын җимерде. Хак, ул каршы булмады. Ләкин бит болай ук булыр дип уйлап та карамаган иде. Ул бер сүз әйтми сарайга таба кузгалды, үзенә ияргән җансакчыларына исә:

— Мелла Хакимҗанны табыгыз, егетләргә никахны монда килеп укысын,— диде.

Сарай болдырында кала бикәсе аны көләч вә якты йөз белән каршы алды.

— Бикәм, минме акылдан шаштым, әллә тупчыларыма ул-бу булдымы. Әйе, тагын ун егетем өйләнә. Чеметегез әле үземне, төшемдә түгелме бу хәл, чынмы?

Акбикә Артык баһадирның беләгеннән алды, кеткелдәп көлә-көлә, сарайга алып кереп китте.

— Куанасы ит, куанасы ит, кардәш Артык,— диде аңа тәхет ягында утырган Бачман даһадир.— Мелләң балаларга бәхет өләшә. Куанасы ит.

— Бәхет!?

— Соң, бәхет булмый ни булсын, баһадир. Бак әнә йөзләренә, кояш чыкса да болай булмастыр. Ташбай угланың күктә, җиргә төшә алмый интегә.

— Бөтен булган, Илһам хан биргән байлыгым тупчыларым өйләндерүгә китте, баһадир. Бүген-иртәгә орышка керәсе. Ә син, куан, дисең.

Шулай дисә дә, Артык өйләнешкән тупчыларына күз төшереп алды. Йа Хода, соңы хәерле булсын, яхшыга юрыйк. Барысы да бәхетле була алмас, Ходай тәгалә, бер бәхетсезгә бер бәхетләне бирермен, дигән. Ихлас күңелдән яратышып өйләнешкән булсалар, иншалла, арадан исән калучылары да булыр әле.

—...Өйләдән соң туй башлана, баһадир. Акча сибәрбез, мин үз өлешем керттем.

— Мин дә Габдрахман картка әзерләргә кушкан идем.— Өйләнеп артына карады, беренче күзенә ташланган егетенә:— Бар алып кил тиннәрне, Садрыйҗан,— диде.

— Сүбәдәй дип борчылма, баһадир,— диде Бачман түрә.— Ашыкмый әле ул.

— Димәк, бездән төгәл мәгълүматлар көтә, карт төлке,— диде Артык.

— Багучыларым җиткереп торалар, иртәгә-берсекөнгә генә килеп җитмиләр әле.

— Ай-һай, Бачман кардәш, ул кыргый җанга ышану ярамастыр. Хәйләкәр төлке бит ул. Бер-бер хәйлә корып ятмыймы икән. Һич булмас димә, кинәт кенә ябырылуы да бар. Багучыларың ышанычлы кешеләрме соң? Сүбәдәй баһадирның алдынгы алае белән кинәт кенә һөҗүм итүе дә бар. Аңардан барысын да көтәргә була.

— Чарасын күрербез, баһадир. Бүген туй итик. Сүбәдәй турында куеп торыйк. Өйләнгән егет ике йөрәкле булыр, диләр. Ә Сүбәдәй турындагы шигең белән килешәм. Бик тә хәйләкәр кеше. Хәер, синең шигең, минем шигем дип кабул ит, баһадир. Туйлар башланганчы сөйләшеп алыйк әле, кардәш. Уз әйдә, утыр. Анасы, чәй хәстәрләтсәң иде.

— Минем күңелдә борчу бар, баһадир,— диде Артык, утыра-утыра.

— Алдагы орышны мин болайрак күз алдына китерәм, кардәш. Сәнең тупчыларың алга куярбыз. Ләкин туплардан аткач та аларны качырасы булыр, ә алгы сафка минем укчыларым чыгар. Сәнең тупчыларың исә ыстанга кайтып, тиз генә тупларын коралар һәм алгы сафка киләләр. Мин исә үз укчыларым җәя итеп, ике якка җәярмен, сәнең тупчыларың янә дошман каршына килеп басарлар.

— Әйбәт уйланган, баһадир, килешәм. Аллага тапшырыйк.

— Әйе, имам хәзрәтләреннән дә фатиха алыйк та, кардәш. Әйе, сөйләшкәнчә итәрбез. Инде хәзер туйны башлыйк...

## 14

Артык атакай нәүмизләнеп, җыелган халык вә бала-чаганың аяк астына тәңкәләр сипте. Мәликә бикә аның янәшәсендә. Артык баһадир горур кыпчак хатынына рәхмәтле иде. Нәкъ менә шул хатынның әнисенең әнисеме, тагын да арыракмы, Саксин каласына пәрәнҗә керттермиләр. Шәрекъ мәмләкәтләренең күбесендә хатын-кызларны

ир-ат күзеннән саклап, пәрәнҗә бөркәндереп йөргәндә, Саксин хатын-кызлары нурлы йөзләрен ачып йөрүләрен дәвам итәләр. Саксин хатын-кызларын акылга утыртырга килгән гарәп имамнары да һични кыла алмыйлар. Саксин хатын-кызы ир-аттан йөзен яшерми вә капламый. Ә менә ир-ат алдында яулык очы белән авыз каплау борынгыдан килә — болгарларда да бар. Гарәп-фарсы тәкъваларына хатын-кызларының йөзләрен яшертү нигә кирәк булды икән? Ташлап китәр дип куркуларымы? Алай дисәң, сине яратмаган хатын белән торганчы, аның сине ташлап китүе мең тапкыр хәерлерәктер, мөгаен. Диванага башын салган хасис вә хөсет кеше генә ваз кичсә кичәр гүзәллеккә багудан.

Бүген барысына да шат иде Артык баһадир. Барысы белән дә килеште, мәслихәтләште — тупчы егетләрен өйләндерүгә каршы төшмәде, тәкъваланмады. Ә бит каршы да төшә ала иде. Әйтик, әүвәл олуг хан Илһамга чаптар җибәреп, аның фатихасын алыйк, дип киреләнә ала иде. Сыныкка сылтау табылмыймы? Борын төбендә орыш тора, дип тә әйтә ала иде. Әйе, ахыр чиктә. Юк, алай итмәде, кайбер килен төшәсе кызларга, бирнәләре житмәсә, үзе булышты, үзе кайгыртты, рәхмәт базардаш Габдрахманга, ул да ярдәмләште. Изгелеген онытмас. Базарбаш Нисбах картны белә икән, исемен ишетү белән, йөгереп йөри башлаган. Менә ул изге зат даны, чиге бармы данның, чиге юк икән ич. Ә бит ошбу дөньяда тән-гаурәтләрен капларга бер кисәк киндер тапмаган адәмнәр дә бар. Саксин халкы ул хәтле Аллаһы тәгаләнең кашка тәкәсе түгел, бакты, күрде Артык: бер байга ике дистә ярлы, дигәндәй. Иллә насәрә-кяфер халыкмы әллә алар, бер-берсенә кул сузмагач. Саксин халкы да, һәммә шәрекъ кебек, ислам дөньясына йөз тота, кыйбласы да Мәккә вә Мәдинәдер. Гарәп-фарсы ирләре хатын-кызларының нурлы йөзләрен челтәр астына яшергәндә безнең бабаларыбыз моңа бармаганнар, аларга рәхмәт әйтергә генә кала, бигрәк тә ошбу мәликә хатын кебек Акбикәләргә. Болгар-Кыпчак халкының йөзе ачык, күңеле киң, җанга рәхәт телләре, иман-кыйблалары бар. Мысыр вә Бохара, Багдад тарафларыннан килгән имам-хәзрәтләр хатын-кызга карата катырак булырга өндәп, нотык-вәгазь укып торсалар да, коткыга бирелмәгәннәр, ир — ир рәвешендә, хатын — хатын рәвешендә көн күрәбез, гәрчә бездә дә ирсаннар арасында ир санында йөреп, яулык бәйләгәннәре дә очраштыргаласа да. Иншалла, ошбу өлкәдә Идел буе төркиләре арасында хатыннары пәрәнҗә бөркәнмәгән өчен орап-шаран салып йөрүчеләр булмаган. Тыям дигәне — тыярмын, бирәм дигәне — биререм, дигәннәр бит. Күңеле азгынга бездә дә җай юк түгел, иш янына кушы табылып тора. Ул бүген Идел буендагы мәһабәт калаларның берсендә Чин һәм Һинд мәмләкәтләренә йөрер юл өстендәге калада. Саксин каласын Сүбәдәй юлбасарга бирү Болгарны бирүгә тиң булып куюы бар. Тик менә Саксин кирмән-кальга буларак Болгар һәм Казан калаларыннан күпкә калыша. Сәер хәл, нигә олуг хан Үгәдәй үзе яу йөрми икән?

— Баһадирым, — диде аңа җансакчысы Сәмигулла, янына килеп. — Бачман баһадир туйны башларга кушты. Менә тәңкәләр, сибәрсез.

Сәмигулла аңа табак белән тиеннәр сузды. Бакыр тиеннәр арасында сирәк-мирәк көмешләре дә күренә иде.

— Киләләр, киләләр! — дип кычкырдылар.

Болдыр янынннан көймәле арба белән хан оныгы Хансөяр үтеп китте, бикә белән баһадир алар өстенә тәңкәләр сиптеләр. Аннары угланы Ташбай, аның артыннан шундый ук арбаларда башка тупчылары. Артык табактагы акчаларны сибеп бетерде дә артына әйләнеп, җансакчысына карады.

— Тагын юкмы?

— Бикә сибә ич! — диде Сәмигулла.

Ул арада арбалар узып та киттеләр. Һәр кыз сайлаган егетен кияүләргә үз җаена алып китте. Хан оныгы Хансөяр белән Ташбай арбалары сарай болдыры каршына килеп туктадылар. Хан оныгы Хансөяр кәлә-

шен күтәреп алды һәм йөгерә-атлый болдырга менде, аның артыннан бер тотам калмый Ташбай углан күтәрелде. Мәликә бикә каршына килеп туктагач, хан оныгы Хансөяр кәләшен аякка бастырды. Ташбай да Айгөлен Артык каршына куйды. Һәм икесе дә баһадирның аягына төштеләр.

— Инде рәхим итегез, балалар, эчкәре үтик! — диде Акбикә, Артык баһадирга күз сирпеп.— Алып кер балаларны, баһадир.

Туй табыны алдан хәстәрләнгән икән инде, кунаклар һәммәсе дә табынга утырыштылар, яшьләргә түрдән урын бирделәр.

Туй мәҗлесе башланды. Мәҗлес барганда Бачман баһадир Артык янына килде һәм аны үз бүлмәсенә алып чыкты.

— Кайбер нәрсәләр турында киңәшәсе бар, баһадир. Яшьләр күңел ача торсыннар. Без аларга комачаулыйбыз гына кебек. Һәе, баһадир, Сүбәдәй каладан ерак түгел, ыстан туктаган. Җай көтәме, башка бер-бер уе бармы, нигәдер кузгалмый. Чыңгыз ханның өлкән угланы Җүси үлгәч, аны үлтергәннәр дип тә сөйлиләр, хак булса кирәк, яшь хатыны тырышкан, диләр. Имеш, тегенең Җүси углан җирләрен угланына аласы килгән.

— Мин дә аны шулайрак дип ишеткән идем,— диде Артык баһадир, астындагы мендәрне җайлый төшеп.

— Чыңгыз хан чин галиме ярдәме белән атаулы карар чыгарып калдырган икән.

— «Яса», диләр аны.

— Әйе, шулай диләр. Шул «Яса»да унбиш яшьтән алып, җитмешкә чаклы ир-ат яу йөрергә тиеш, дип әйтелгән икән. Димәк, Сүбәдәй гаскәрендә картлар да шактый. Киңәш бир миңа, баһадир: калада калабызмы, чыгып орышабызмы?

— Борынгылар калама ябылганчы, даламда булсамчы, дигәннәр.

— Яхшы, баһадир. Инде әйт: каламызда кемне калдырабыз?

— Бикәне, баһадир.

— Гаскәр беләнме?

— Менә анысын үзең кара инде, баһадир. Калаңа да, далаңа да син баш. Нә әйттең — шул булыр.

— Мин болай уйлыйм, баһадир Артык. Калада бикә кала. Янында зур булмаган алай булыр. Чөнки орышның хәтәре далада булачак, Саксин язмышы шунда хәл ителәчәк. Аннары минем азатларым да кальгага бикләнеп орышырга өйрәнмәгән.

Шыпырт кына алар янына хан оныгы Хансөяр килеп утырды.

— Атакайлар, минем сезгә бер киңәшем бар. Хак әйтә, атакай, ил өстенә каза килгәндә калага бикләнеп яту килешми. Без бериш яшьләр белән мелла Хакимҗанны ияртеп, дошман ыстанына юл тотарга ниятлибез. Сәүдәгәрләр сурәтендә. Дөяләр, азык-төлек, товар булсын. Хак булса, Сүбәдәй баһадир сәүдәгәрләргә тими икән.

— Йә-йә, Хансөяр, дәвам ит...— диде сабыры төкәнеп Бачман баһадир.

— Без дошман ыстанында ни булганны белергә тиешбез. Нинди максат белән килә Сүбәдәй?

— Максаты бер аның — ил талау.

— Әрвахлар әтрафына минем барасым килә. Серләрен белгән хәлдә...

— Яңа күзле-башлы булдың түгелме, балакай,— диде Артык.

— Мин үзем белән ун егетне сайлап алдым.

— Ә Сөмбел? — дип сорады Бачман баһадир.

— Сөмбел дә минем белән сәфәр чыга. Иншалла, барысы да әйбәт булыр.

— Хатын-кызны йөретү ярамас, углан,— диде Артык баһадир.

— Хатын-кыз булмаса, аларның ышанмаулары бар, атакай.

Хан оныгы Хансөяр тезләнгән җиреннән торып басты.

— Фатихагызны бирсәгез иде, атакайлар?

Баһадирлар күзгә-күз карашып алдылар. Бачман баһадир бертын башын чайкап торды.

— Сөмбелнең анасы риза булырмы икән соң, кияү балакай?

— Булыр, атаем, сүз ил язмышы турында бара.

— Кһм,— дип тамак кырды Артык баһадир.— Кемнәр-кемнәр кузгалырга җыенасыз инде, меңбаш?

—Ташбай да бара. Дошман ыстанына үтеп, Сүбәдәйне үлтерәм дип әйтте.

— Кемне үлтерергә!? Сүбәдәйнеме?! Ташбаймы шулай диде, хан оныгы Хансөяр?! Ул бит...

— Беләм, атакай. Атага кул күтәрү зур гөнаһтыр. Вәләкин...

— Шәригать вә фикъһы гыйлеме буенча ул моның өчен ахирәткә кадәр тәмугта янар.

— Атакай, аның максаты башкадыр.

— Мин сәнең угланың дип аягына төшәргә исәбе юктыр бит?!

— Аның бу мәсьәләне сезнең белән мәслихәтләшәсе килә, атакай.

— Атага кул салу турында сүз дә булырга тиеш түгел. Ишетәсеңме, хан оныгы Хансөяр. Үзе кая соң әле, үзе?! Ничекләр дошман өенә үтеп кермәкче, ничекләр Сүбәдәй каршына барып басмакчы?! Нигә ошбу гөзернамә белән үзе килми?..

— Ташбай бу хакта берни дә белми, атакай. Бу бары тик минем башымда туган уйдыр, атакай.

— Каян килгән мәһди, күрче! — дип үртәлде Артык баһадир.

Артык атакай урыныннан купты, арлы-бирле йөреп килде.

— Уйлап карарга кирәк, баһадир,— диде Бачман түрә.

— Киңәшле эш таркалмас, дигәннәр бабаларыбыз.

— Әйткән идем аны Ташбайның моңа башы җитмәс дип,— дия-дия, әсәрләнеп йөрүен дәвам итте Артык.

— Бикә ни ди, сөйләштегезме?

— Бу хакта без аның белән бергәләп уйлаштык, атам.

— Кем баш монда, Бачман баһадир! — дип түрә каршына килеп басты Артык.

— Ә син, Артык баһадир, тынычлан, сабыр ит. Меңбаш углан безгә үз фикерен җиткерде, ә безгә ипләп кенә, бар ягын да уйлап хәл итәсе,— диде Бачман баһадир, аннары хан оныгы Хансөяргә карады:— Шулаймы, углан?

— Сез хаклы, атам, хаклы. Кызу канлылык орыш кырында гына әйбәт.

— Юк, углан, кызу канлылык беркайда да әйбәт түгел, орыш кырында бигрәк тә. Утырыгыз икегез дә. Минне тыңлагыз.

— Анам үз әмерен миңа бирде инде, атакайлар. Менә ул.— Хансөяр Артык атакайга бер төргәк бирде. Артык төргәкне сүтте, укыды һәм Бачман баһадирга текәлде.— Укыгыз, укыгыз әүвәл,— диде Хансөяр. Артык язмага күз йөртеп чыкты.

— Бәрәкалла, мәнем тупчыларыма атакай кирәкми дә башладымыни? Үзегез-үзегезгә башмыни?! Нә киңәш итү юк, нә уйлашу. Тәвәккәлләгәннәр дә вәссәлам! Белсәң иде, хан оныгы Хансөяр, Ташбай минем бердәнбер угланым. Бу хакта барысы да белә. Ә менә Сүбәдәй...

— Анысы кирәкмәс, баһадир, кирәкмәс,— диде Бачман баһадир.

— Сүбәдәй баһадир үзе белән Күлкән атлы угланын алып килгән. Орышта ул да катнашачак, ди. Ташбайның аны күрәсе килә,— диде хан оныгы Хансөяр.

— Ташбай яңа өйләнде.

— Мин дә, атакай. Без сәүдәгәрләр суратендә юл чыгабыз. Һәм без дошман ыстанына үтеп керербез. Анда язганы булыр.

«Менә кайчан чыга башлады аксөяк гайрәте угланда»,— дип уйлады Артык. Инде утыра гына башлаган иде, янәдән аягүрә басты.

— Кем монда баһадир, хан оныгы Хансөярме, әллә Бачман баһадирмы? Синнән сорыйм?

— Безне, атакай, Илһам хан Бачман баһадир кул астына җибәрде. Без аңа буйсынырга тиешбез. Ә баһадир безнең тәкъдим белән килеште, бикә гозернамә белән раслады. Дөяләр әзер, мелла риза, товарлар хәстәрләнә. Иртәгә торып, безгә сәфәр чыгарга кирәк.

«Менә сиңа меңбаш, менә сиңа хан оныгы Хансөяр. Барысын да сихерләде, Бачман баһадир кызын да, угланы Ташбайны да, бикә турында әйтеп тә торасы юк, хәтта нә сабыр кеше Бачман баһадирны да»,— дип уйлады урынга утыра-утыра Артык.

Әйтерсең, авызына шайтан төкергән, теле-телгә йокмый, меллаң бер якта торсын. Теге тел бистәсе тагын, ризалыгын биргән, Сүбәдәй ыстанын күрәсе килә. Күрсәтер әле ул күрмәгәнеңне. Корыч Сүбәдәй диләр аны. Уйнаштан туган җиде угланы каршына килеп басса да, үзенекен итәр.

— Синең бераз кыбырсылый торган гадәтең бар иде, хан оныгы Хансөяр, илләә мәгәр болай ук булырсың дип уйламаган идем. Багамкүрәм син гелән җирдә түгел икән ич, җиде кат күктә. Хак, ил куәте ирдә, мәгәр акыл куәте хәйләдә бит. Сүбәдәй баһадир сезнең бу хәйләгезне беренче көнне үк ачып салачак.

— Ул чакта без аның гаскәренә ялланырбыз.

— Аннары үз туганнарыңа каршы чыгарсың. Ялланган ятларны Сүбәдәй алдан куа, диләр. Артында аның укчылары, алдында безнекеләр. Нә кылырсың? Туганнарыңны уктан алырсыңмы?.. Шул хакта уйладыңмы бераз?..

— Уйладым, атакай. Җиңү корбансыз булмый. Ант итәм, мин үз туганнарыма атмам.

Артык атакай дәшмәде, дәшер әмәле калмады. Ул торды да хан оныгы Хансөяргә юл бирде.

— Бу уй-ниятең белән атакаең уттан алып суга салдың, меңбашым. Мин үземне дәресханә җыештыручысы назир хәлендә хис итәм. Азамат шәкертләрем үзбаш уй-ният йөртеп, илаһи дөньядан шәһит китмәкчеләр. Мине ошбу калада мәгыйшәт хафасы күмде, хан оныгы. Күргән төшем, юраган уем хак булды. Кичә иртәнге якта төш күрдем: имеш, кош икәнмен, тик бер канатым каерылган. Канатларым җилпеп күтәрелеп китмәкче генә итәм, юк кына, күтәрелә алмыйм, бер канатым сынык. Җитмәсә кан исен сизепме өстемә дала төлкесе килә. Тәкатьсез калдым. Кычкырам — тавышым чыкмый. Шунда, Ходайның хикмәте, Җәбраил фәрештә күктән бау төшерде. Тотын ошбу бауга, Артык баһадир, ди. Ә дала төлкесе өскә сикерергә тора. Ул да сикерде, мине дә Җәбраил фәрештә күккә күтәреп алды. Шуннан кинәт канатым төзәлде. Оча алам икән ич. Кай тарафка — Болгарыма очам икән. Уяндым да тын алырга куркып яттым. Нә булыр, бер Хода белә.

— Төшең саташуга юрыйк, атакай,— диде хан оныгы Хансөяр.

— Әйе, әйе, Артык баһадир, төшкә ни кермәс. Саташуың гына булгандыр.

— Саташу гына булса икән ул. Иртән меллама әйткән идем... Әйтергә дә куркам инде...

— Дошман Саксинны алыр. Шулай дидеме мелла Хакимҗан, атакай?— диде хан оныгы Хансөяр.

Аның бу сүзеннән баһадирлар икесе дә аягүрә бастылар.

## 15

Туйның икенче көнендә бөтен Саксин халкы елга буена чыкты. Ак киез өстендә шәрәфәтле бикә, баһадир, атакай утыралар, алар кырында ук кала имамы, мелла. Табын тулы ризык-нигъмәт, кымыз-касәләр. Яшьләр чак кына арырак утырышканнар, җырлыйлар,

домбра зеңе, курай моңы ишетелеп китә. Туй җаенда яңадан табышкан яшьләр дә булгандыр. Тик өйләнешкәннәре дә буа буарлык иде инде. Саксин кызлары чәчәктәй киенгәннәр, күзләр камашырлык. Яшь кәләшләр, бер кичлек хатыннар сайлаган ирләренең күкрәкләренә башларын куйганнар да күз яше белән саубуллашалар. Иртәгә тупчылар каладан чыгып китәчәкләр, имеш, дошман белән далада орышмакчылар, шулай хәл иткәннәр.

— Кызык туй булды бу, Бачман баһадир. Кайгы өстенә кайгы гына өстәмәдек микән дим,— диде Артык баһадир.

— Кайчак, баһадирым, бер-ике кичлек мәхәббәт гомерлек бәхетне алыштыра, диләр. Елашкан киленнәр күрсәм дә, мин бу яшьне шатлык яше дияр идем,— диде Акбикә.

Артык барысы белән дә килеште инде. Аның күзләре Ташбаенда, угланы тирәсендә уралган зәңгәр бала итәкле күлмәк кигән, башына акъяулык чөеп бәйләгән килене Айгөлдә. Яшьләр кулга-кул тотынышып, арлы-бирле йөриләр. Ә ак киезләрдә табын корып утырган ата-аналар тын гына аларны күзәтәләр. Ата-аналар арасында әче балдан сәрхүшләнеп киткәннәре дә бар. Ләкин ник бер җәнҗал чыгаручы булсын. Шул тирәдә уралган бала-чагага уен-көлке вә шатлык. Алар, сәрхүшләнеп йөргән агайларның ыштан бауларын чишеп җибәрәләр дә, вак балыклар кебек төрлесе төрле якка качалар. Ә кинәттән ыштаны төшеп киткән сәрхүш ни кылырга белми ыштанына ябыша, күтәрә, тирә-ягына карый һәм бәйләргә итә. Тик ыштан бавын бәйләү аңа җиңел түгел, бармаклар буйсынмый, ыштан кулдан ычкына, тагын төшә. Тагын уен-көлке башлана. Ахыр, чарасыз калган сәрхүш икекуллап ыштанына ябыша да таллар арасына сыпырта.

Туй бәйрәме кояш офыкка тәгәри башлагач кына тәмамланды. Халык көймәле арбаларга утырып, калага таба агыла башлады. Артык та Ташбай угланы арбасына менеп утырды. Кайттылар. Бикә яшьләргә иң хозур ятакларын бирде. Һәр ишкә күзәтүче карчыклар билгеләнде. Имеш, кыз сафмы, кияү тәгаен ирме. Һәм, гомумән, күз-колак булу өчен карчыклар куялар бугай төркиләр. Артыкка андый бәхет тимәгән иде, ул бер балалы хатынга өйләнде, аннары беренче төндә аны тешсез карчыклар да сакламады. Хәерле булсын, ястык карбыз түгел, икегә ярмыйлар. Бер ястыкка баш куеп яту үзе бер гомер. Гел ялгыз йоклаган егет янында алиһәдәй зат ятсын әле.

Мәгәр хан оныгы Хансөяр сүзендә торды: иртән-иртүк Үргәнеч капкасыннан кәрван сәфәргә кузгалды. Кәрван адәмнәре арасында кичә генә өйләнешкән ике-өч гаилә дә бар иде. Бачман баһадирга багучылары җиткерделәр: Сүбәдәй гаскәренең яртыдан артык сугышчылары төрки телдә сөйләшәләр икән. Бу хәбәрне китергән азатына рәхмәт әйтеп озатуга, Бачман баһадир Артыкны чакыртып алды. Күңеленнән карышып, әүвәл ризалыгын бирмәсә дә, Артык атакай угланы Ташбай белән килене Айгөлне озатырга үзе дә барган иде. Капкадан чыгып киткәндә атакай угланы Ташбайга:

— Оланнар, сез сәүдәгәрләр. Үргәнечкә ашлык, бал илтәсез. Мелла Хакимҗан, син алдагы дөягә утыр. Ашыкмагыз. Кала читенә сәйранга гына чыгу түгел бу, сез гаять җитди эш белән дошман ыстанына барасыз. Инде кузгалыгыз. Алла юлдашыгыз булсын! — диде.

«Углан! — диде ул китәргә кузгалган кәрванга борылып карап, атын тыя төште.— Углан!» — дип өзгәләнде, гәрчә гелән үзалдына гына өзгәләнсә дә. Угланын җибәрергә күңеле һич кенә дә тартмаган иде. Ләкин ахыр чиктә, үзе бик теләгәч, каршы төшәргә кыймады. Барысына да хан оныгы Хансөяр гаепле, ул сихерләде балаларны. Кәрван белән Сүбәдәй ыстанына керә, имеш...

Ни сәбәпледер Артыкның бугазына яшь төере килеп тыгылды. Ичмасам тел очына килгән саубуллашу, бәхилләшү сүзләрен дә әйтә алмады. Аннары менә ничә көн инде Ташбаена: «Син бит, углан, әнә шул

Сүбәдәйнең малае, мин сине тәрбияләдем вә бактым гына»,— дип әйтергә йөрде. Әйтмәде, сабыр итте. Аның ни әйтергә теләгәнен сизгән кебек, Ташбай үзе дә: «Атам, син борчылма, борчылма. Мин кайтырмын, кайтырмын, Аллаһы теләсә. Мин сине мәңге, мәңге онытмам»,— диде. Нәкъ менә шулай диде: «Онытмам». Эче сиздеме, кан атасының Сүбәдәй икәнен белүе идеме? Шул хакта сорарга дип авызын ачты, тик шундук тыелды, әйтерсең лә кайнар аш кабып, авызын пешергән иде. Аның каравы, күңелендә калганын хәзер тезде: «Ул сине үзенә охшатыр, балакай. Улым, дияр. Тик аңа карама. Син бит барыбер минеке, минеке. Мин сине бактым, мин сине кеше иттем!» — дип тәкърарланды ул эчке бер кайнарлану вә әсәрләнү белән. Хан оныгы Хансөяргә ачулы иде, шуңа карамастан, угланы алдында аңа карата яхшы сүзләр әйтте, гәрчә күңеле белән теләмәсә дә: «Хан оныгы Хансөярне тыңла, углан. Аңарда пәйгамбәр акылы бар,— диде бит әле. Ул гынамы:— һәр кылыр гамәлеңне, атлар адымыңны аның белән киңәшеп эшлә»,— дип үгетләде.

## 16

Дошман җайдаклары сузынкы яссы калкулыкта күренүгә, Артык атакай тупчыларына кисәү агачына ут алырга боерды. Аның һәр әмерен меңбаш Юлдаш йөзбашларга, тегеләре унбашларга җиткереп торалар. Бачман баһадирның укчылары алар артында. Тупчылар дошманга туплардан атуга, кире чигенергә, ә аларның сафын Бачман баһадирның укчылары алырга тиеш. Бачман баһадирның мәргәннәрен күреп сокланган иде Артык атакай. Тәз аталар. Тик бит Сүбәдәй баһадирның мәргәннәре дә дөнья арбасыннан төшеп калганнардан тормыйдыр. Корыч баһадирның мәргәннәре уннарча илнең гаскәрен тар-мар иткән сугышчылар. Гаҗәбе шул: корыч баһадир, гадәттәгечә, үзе белән хан токымыннан берәүне дә алмаган, хәтта абасы Җәбәй дә, аяклары сызлауга сылтап, ошбу яуга чыкмаган, диләр. Димәк, гаскәр башында берүзе. Тәвәккәл, тәвәккәл кеше, мәлгунь. Аның каравы унтугыз язына аяк баскан баш малае Күлкән үзе белән икән. Бәхәссез, ул угланын меңбаш иткәндер, бәлкем әле төмәнбаштыр да. Нигә әле гелән шул Сүбәдәй турында уйлый? Кем ул аңа? Кем?! Бажай. Менә кем. Карлыгачың Ташбаен кемнән таба? Шул корыч баһадир Сүбәдәйдән түгелме?! Хәзер әнә шул хатын Артыкның хәләл җефете, никахлап өйләнгән хатыны. Шуннан кем була инде сиңа Сүбәдәй? Бажай. Димәк, син, Артык баһадир, үз бажаеңа каршы орышка чыктың. Кайсыгыз алдырыр — анысы бер Аллаһы тәгалә кулындадыр. Ләкин син аның белән барыбер орышырга тиеш булырсың. Канкардәш түгел, бары тик бажай. Ә халык: «Кәҗә мал түгел, бажай кардәш түгел»,— генә көлеп әйтмәгәндер лә.

Сүбәдәйнең нинди дингә йөз тотуын Артык белми. Мәҗүси затмы, үзенә күрә илаһи дине бармы — ишеткәне булмады. Һәрхәлдә, табынган дине бардыр. Аллага дога кылмыйча сугышка кермиләр. Борынгы урысларның Перуны булса, борынгы болгарларның Тәңреләре булган. Тәңре белән орышка кергәннәр, Тәңре белән үлгәннәр. Әмма Артык атакайга җиткерделәр, Сүбәдәй мәрхүм ханы Чыңгыз төзеп калдырган «Яса»га табына икән. Имеш, баккан сурәте дә, табынган дине дә шул «Яса» икән. Тик алай гына түгелдер, җаны булган ир — хатынсыз, адәм баласы — алласыз яшәми, диләр. Тик бит Сүбәдәй Чыңгыз ханның баш угланы Җүси нойонның угланнарына атакай булып торган кеше, диләр. Ә тегеләр, Җүси угланнары, имеш, насарә диненә табынганнар һәм әле булса табыналар, ди. Чөнки мөгаллимнәре уйгур христианнары булган. Чыңгыз ханның баш угланы хатын-кыз яраткан, күрәсең. Унлап хатыны аңа ундүрттән артык углан табып бирә. Батый да, Урда да, Бәркә дә, Беркачыр да, Шәйбан да, Тангут та, Бәвел дә һәм калганнары да муеннарында тәре йөртәләр, дип әйтеп әйтәләр. Бу хакта Артык баһади-

рга Болгарда ук житкереп тордылар. Чыңгыз ханны, дошман ыстанына шымчы җибәрергә һәвәс булган, дип сөйлиләр, ул яккка килгәндә Илһам хан да Каракорымга шымчы артыннан шымчы җибәреп тора. Хак, Җүси угланының уйгур мөгаллимнәреннән сабак алуларын Чыңгыз хан ошатмаган һәм мөгаллимнәре кудырткан, дип тә авыз чайкаучылар бар. Тик моңа Артык ышанмады. Чыңгыз хан үзе надан булса да, ягъни укый-яза белмәсә дә, белемле кешеләрне хөрмәт иткән, аларга юртасы түреннән урын биргән. Ә инде Җүси угланына: «Без тамга танымый үстек, мин сезгә ярты дөньяны яуладым, тамга танучылар белән түгел, мәргәннәр белән»,— дип әйтеп әйткән, диләр. Димәк, Чыңгыз хан нә насәрә динен, нә ислам динен кабул итмәгән. Табынган динен бер Хода белә, ә менә үзенә күрә үз динен булдырган — «Яса». Мелласы Хакимҗан бу хакта сәгатьләр буена сөйли ала, әйтерсең, Каракорымда булып кайткан. Мелла Хакимҗан сүзенә ышансаң, бүген дә олуг хан Үгәдәй түрендә хөрмәткә ия имам Мәхмүд Ялави утыра икән. Кем аны ошбу имам изге кыйблага өндәмидер дип әйтергә кыяр икән? Тик бит олуг хан Үгәдәй христиан диненнән дә бер попны үз янында тота икән ич. Димәк, Магул ханнары бик еракка карап эш итәләр. Теге йә бу диннән хакыйкатьсез әзлиләр, ә мелла Хакимҗан үзе үк: «Хакыйкать бар нәрсәдән дә өстен»,— дип шапырына.

Кузгалдылар, киләләр... Йа Аллам, ярдәмеңнән ташлама.

Дошман җайдаклары бик үк шауламый гына тупчыларга якынаялар. Теге яктан да, бу яктан да берәү дә уктан алмый. Үз көчләренә ышаналар, беренче тапкыр гына һөҗүмгә ташланулары түгел.

Дошман укчылары тупчыларга якынрак килергә тиешләр.

Артык, йөрәге катырак тибә башлавын тоеп, күз алмый дошман җайдакларының хәрәкәт итүен күзәтте. Җайдаклар бер җәеләләр, бер җыелалар. Магулларда ат эре түгел, вак, мәгәр сәер адымы бар, төлке кебек юырта, шуңа ат өстендәге кеше зеркеми дә. Хәйләкәр, хәйләкәр Сүбәдәй, көтмәгәндә тупчыларның сул ягында йөзләрчә җайдак пәйда булды, ул да түгел, уң якта да дошман җайдаклары күренде. Димәк, Сүбәдәй Артыкның тупчыларын тулганага алмакчы. Артык баһадир артына әйләнеп карады: янәсе, Бачман баһадир моны күрәме? Күрә икән, мәргәннәрен ул да җәя башлады. Магул яугирләре: «һүррә-һүррә!» — дип кычкырырга тотындылар. Артык баһадир янында торган җансакчысына барс төшерелгән әләмен болгарга кушты. Шундук Артык атының аяк янына ук килеп кадалды, бөркет каурые белән җайланган ук бертын зеңләп торды.

«Мәртәтләр, нә тамаша кыю кыланалар»,— дип Артык, баһадир булуын онытып, җәясенә ук элде.

Ләкин көтмәгәндә магуллар кире борылдылар һәм калкулык артына кереп югалдылар. Артык баһадир Бачманга чаптарын җибәрде. «Нишлибез, магуллар кире борылды?» — дип. Чаптары әйләнеп килгәч: «Баһадир, урыннарыбызда калабыз. Сүбәдәй баһадир ермак яугирләрен җибәреп, безне сынап кына карады»,— дип әйтте, диде. Артык моңа ышанмады. Корыч баһадир мәргәннәрен тикмәгә генә кире бормас, дип уйлады. Алдады, мөртәт, бер дә бүтән түгел, алдады. Туплар атканны күргәч тә, кире чигенде. Димәк, Сүбәдәй туплар хакында белде чынлап та корыч баһадир,— Артык өчен сер иде.

Бәхәссез, хан оныгы Хансөяр дошман ыстанына үтеп кергәндер. Бәлкем дошман кулына эләккән егетләреннән берәрсе туплар турында Сүбәдәйгә әйтергә мәҗбүр булгандыр. Югыйсә алар нишләп әле туплар янына житәр-житмәс кире борылдылар? Әллә соң чынлап та багучы ермак алаен гына җибәреп карадымы Сүбәдәй? Бик ихтимал ич. Ярый әле туптан атарга өлгерми калдылар, юкса бөтен сер ачылачак иде.

Артык, маңгаена кулын куеп, калкулык артына кереп юк булган магуллар тарафына карады. Тып-тын, әйтерсең лә хәзер генә канлы орыш алдында да тормадылар. Язмыш диген син аны. Кай тарафларга килеп орышып йөри бу Сүбәдәй. Үз ханы васыятенә тугры калса калыр

икән кеше. Чыңгыз хан күптән гүр иясе, ә бу мәртәте аның уй-теләгән тормышка ашырып йөри.

Баһадир Бачман хаклы булып чыкты. Күп тә үтми, калкулыкта янә дошман җайдаклары күренде. Калкулыктагы тоташ ат-җайдак чылбырын күреп, Артык тупчылар алдыннан чаптырып узды. Янәсе, барысы да әзерме? Тупчылар аның боерыгын гына көтәләр иде.

— Тупчыларым, тупларыгыздан ату белән, ике якка аерылып, Бачман баһадир укчыларын алга чыгарасыз! Тагын кабатлыйм, бары тик аткач кына!

— Беләбез, беләбез, атакай! — дип кычкырды тегеләр.

Юлдаш меңбаш та ат өстендә Артык янәшәсендә бара. Аңа әйтелгән иде, тупчыларның бер канатын ул алып китә, бер канатын — баһадир үзе.

— Меңбаш,— диде Артык әйләнеп карамый гына.— Олауларга җитүгә, тупларны корырга һәм минем боерыгымны көтәргә. Олаулар янына мин үзем килермен.

— Яхшы, атакай, шулай итәрмен.

Кинәт дала уянды. Кылганнар арасыннан куркынып тургайлар, кошкорт күтәрелде, җәнлекләр өннәренә постылар. «Хр-р, хр-р!» кычкырулар, ниһаять, Артык баһадир колагына килеп иреште. Ул хәбәр салучы җансакчысына күз төшереп алды. Җансакчысы тупчыларга биреләсе билгеле хәбәрне бирергә әзер, тик иртә әле, иртә. Менә тоташ бер дивар булып килүче дошман җайдакларының йөзләре, киемнәре шәйләнеп күренә башлады. Артык сабыр итте. Магуллар ни сәбәпледер уктан алмыйлар, һаман киләләр иде. Бу юлы магуллар бер җәелеп, бер таралышып тормадылар, туры тупчылар өстенә киләләр. Каяндыр адашып калган карсак төлке җайдаклардан алдан чаба. Тик аңа игътибар итүче юк. Күзгә күренеп үлем килә иде. Артык кулын күтәрде, шундук әләм бер унга, бер сулга җилфердәде. Икенче мәлдә инде гөрст-гөрст килә-килә бер-бер артлы туплардан ата башладылар. Дошман белән ике араны төтен күмде. «Хр-р, хр-рр!» кычкыра-кычкыра һөҗүмгә килгән магулларның тавышы кисәк өзелде, аларны туплар шартлавы күмеп китте. Магулларның алгы сафы сүтелүен, яугирләр арасында ыгы-зыгы башлануын, төтен аша күренмәсәләр дә, Артык сизеп торды. Тупчылары ул әйткәнчә ике якка аерылып, артка чиктеләр, алгы сафка Бачман баһадир укчылары атылып килеп чыктылар. Төтен сүтелә төшкәч, Артык баһадир күрде, яугирләрнең кайберләре һаман һөҗүм итәләр. Артык баһадир егермеләп җансакчысы белән дошманга каршы кузгалды.

Аларны Бачман баһадирның мәргәннәре куып җиттеләр, узып, дошманга каршы ата башладылар. «Ур-ра!» тавышы яңгырады. Артык җәягә элгән угын алдан килгән дошманга атты. Ул күрде, теге башка арканга эләккәндәй артка каерылды, аннары ияреннәр ишелеп төшеп калды. Артыкка сугышчы дәрте вә гайрәте керде. Ул:

— Ур-ра! Ур-ра! — дип, атын дошманга каршы куалады.

Аны Бачман баһадир куып җитте һәм колакны яңгыратырлык итеп:

— Тупчыларың янына, баһадир, тупчыларың янына! — дип кычкырды. Артык шунда гына исенә килде һәм атын кире борды.

Үзәнлеккә чыптырып төшкәндә аны җансакчысы Ягъфәр куып җитте һәм:

— Баһадир, баһадир, дошман курыкты, кире чигенде! — дип кычкырды.

Тик хәйләкәр Сүбәдәй чынлап чигенде микән? Сүбәдәй тикмәгә генә чигенмәс, ул, мөгаен, Бачман баһадир укчыларын ияртеп алып китеп, тулганага алырга маташадыр. Тик Бачман баһадир да бирешмәс, аның да укчылары магуллардан ким сугышмыйлар.

Артык белми иде, Сүбәдәй иң батыр һәм иң кыю егетләрен атыкоралы белән һич югы бер тупчыны әсир итәргә җибәрә. Олы орыш кырында ачы сугыш барганда, магулларның батыр егетләре тупчыларга якынаеп киләләр иде инде. Нәкъ шул зур булмаган алай үзәнлеккә

тупчылары янына төшеп барган Артык баһадирга тап булдылар. Магул жайдаклары аларны бик тиз тулганага ала башладылар. Артык баһадир һичнин аңламый янындагы егермедән дә артмаган жансакчыларына карады.

— Божра булып басыгыз!

Ике як та бертын уктан алыштылар. Ахыр Артык кылычын суырып чыгарды, тулгана божрасын ерып чыгарга дип жансакчыларын ияртеп алга ташланды. Берничә егете ятып калды, әмма Артык магулларга житте. Китте кылычтан алыш, ук ташлау. Хәрби дәресханәләрдә алган бөтен сәләтләрен кулланырга мөмкинлек туды. Тик дошман аның егетләрен дә берәм-берәм чүпли торалар иде. Артык баһадир жансакчысы Ягъфәргә янәшәсенә килергә боерды. Һәм алар уңга-сулга селтәнә-селтәнә божраны ерырга ташландылар. Артык унлап дошманның башына житте инде, тик аны Ходай саклады.

— Бирешмә, бирешмә, Ягъфәр, уң ягыңа, уң ягыңа бак. Ук ташла үзенә, ук!

Жансакчысы Ягъфәр хәрби мәктәптә иң оста ук ташлаучы иде. Икегә сындырылган укны нәкъ кеше күзенә ташлый. Ул шулай итте дә, дүрт-биш дошманны уктан алды. Артык баһадир да кылыч белән ике дошманны иярennән ишелеп төшәргә мәжбүр итте. Шунда бер магул батыры сикереп ияр өстенә басты һәм Артыкка таба чаптырып килә башлады. Артык хәтта аның кысык күзен, кабак йөзен, кычкырганда күренеп киткән сирәк тешләрен күреп алды. Башында очлымы юк, бары тик камалы бүрек, күрәсез. Ул иярендә сикереп алды да бүре кебек Артык өстенә очты. Нәкъ менә очты, чөнки Артык аның башына, ат ялы өстенә килеп төшкәндә, кылычы белән чабып жибәрде. Чабу тимәде, чиртү генә булды, әмма Артык аермачык күрде, дошманның йөзе икегә ярылган иде. Дошман ат ялына тотына алмый калды, ат аягына төште. Куркып киткән ат артка чикте һәм яман итеп кешнәп жибәрде. Артык бөтен көчен куеп өзәңгесенә басты үзенә таба чаптырып килүче икенче батырга ыргылды. Янында Ягъфәр юк иде инде. Аның күзен кан басты, ул кылычын болгый-болгый әле берсенә, әле икенчесенә ташланды.

— Кем үлем эзли, кем! — дип кычкырды ул тамагы чатнардай итеп.

Нәкъ шул чакта, божраны ерып барганда, аның өстенә тагын бер яугир сикерде, бу юлы Артык чак кына кылычын аның корсак турына куярга өлгерде. Теге бичара «аһ» итте һәм үзен тишеп чыгарган кылычтан шуып төште. Әмма икенче берсе аны атыннан өстерәп төшерде. Жиргә төшкәндә үк хәнжәренә үрелгән Артык дошманның бөеренә кадады.

Аты беркая да китмәде, ул атланырга дип ияр башына тотынды, тик өлгерә алмады, чажлап килгән аркан элмәге аның беләкләреннән кысып алды. Аты әрнешеп кешнәп куйды, ә аны аркан белән сөйрәп алып киттеләр. Артык бер кулы белән арканга ябышты, икенче кулы белән хәнжәренә үрелде. Тик хәйләкәр жайдак атын кинәт сулга алды һәм ул әйләнеп төште. Артыкның битенә кылган, әрем бәрелде, тәненә шайтан таягы энәләре тулды. Ул янә уң кулы белән арканга ябышты, чак кына тартылуга, хәнжәренә үрелде. Кулы хәнжәр сабына житте, тотасы итте, тик шулчак кемдер аның кулына камчы белән сукты. Бармакларны гүя ялкын көйдереп алды, әмма хәнжәр сабын эләктергән иде инде. Ул һичнин күрми, ләкин аны таккан атның жан-фәрман чапканын бераз абайлый иде. Аңа тагын-тагын камчы белән суктылар. Артык ниндидер бер мизгелдә күзләрен ачты һәм яугирнең тагын сугарга кизәнүен күреп, бер көче белән аңа хәнжәрен ташлады. Хәнжәр тегенең бугазына килеп кадалды. Ул аны ары таба күрмәде, икекуллап арканга ябышты һәм әйләнеп китте. Бу ысул белән ул атта барган егетне егасы итте, тик ат кинәт туктады. Аны уннарча яугир божрага алдылар.

— Кабаланма, тупчы! — диде аңа саф төрки телдә сирәк сакаллы яугир. — Син болай да утыз сугышчымның башына житең. Бәхетең, синеҗ баһадирымыз үлтерергә кушмады. Юкса дала бүресенә каласы идең.

— Син кем? — дип кипкән һәм яргаланып, кан саркыган иреннәрен көчкә ачып сорады Артык.

— Кем булуым сиңа кирәк түгел, тупчы. Кайчандыр сезгә әсир төшкән татармындыр. Рәхмәт баһадирыма, мине сатып алды. Белеп тор, баһадир, минеп атым Котбый. Сине баһадир көтә. Хәзер без синең кулларына богау салабыз, кабаланма. Баһадирым Сүбәдәй миңа бер тупчыны булса да алып кайтырга кушты, мин сине алып кайтам. Егетләрең ятып калды. Син исән. Тор!

Сүбәдәй исемен ишетүгә, Артык алга сикерде һәм яугирнең ат астына керде, ияр тасмасына ябышты да ат корсагына типте. Ат үрле-кырлы сикерергә тотынды, яман итеп кешнәде, ахыр бер якка ауды. Яугир гөрселдәп берьякка төште, кулыннан кылычы ычкынып китте. Артык бер сикерүдә кылычка җитте, әләктереп алды. Әмма үрелеп күтәрелергә өлгермәде, әзмәвердәй гәүдәле берәү таш булып аның өстенә ятты.

Куллары каерылып бәйләнгәч кенә, Котбый дип таныштырган яугир аның янына килде һәм бар көченә корсагына сукты. Артык буш капчык кебек ишелеп җиргә ауды.

Ул күзләрен ачканда, кай җирдә ятуын абайлый иде инде. Аны әсир иттеләр, ул Сүбәдәй кулында. Артык җирдә ята, бераз колагы шаулый, кан саркыган иреннәре бер-берсенә ябышкан, куптарып булмый. Кемгә булса дәшәсе, су сорыйсы иде. Торды, аягына басты, шунда гына күрде — ыстан уртасындагы казыклар белән уратып алган божра эчендә икән. Божра тирәли сакчылар тора. Кымшанмыйлар да, әйтерсең лә тораташлар.

Артык теле белән ялый-ялый иреннәрен куптарды.

— Су бирегез миңа, су!

Тораташтай каткан сакчыдар кымшанмадылар да, әйтерсең лә аны бөтенләй ишетми иделәр. Артык тирә-ягына күз ташлады. Юрталарның исәбе-хисабы юк. Юрталарны авыл-авыл итеп куйганнар. Урта бер җирдә ап-ак киездән барысыннан да зур юрта. Сүбәдәй баһадир ныклы булса кирәк.

Юрта тирәли нүкерләр йөри, кишектиннәр. Аның кулларыннан богауны алганнар, күрәсең, ниһаять, качa алмавына инанганнардыр. Тәмам җеп өзәр хәле дә юк, һич югы су бирсеннәр иде, ичмасам азрак хәл керер иде. Әллә тагын ишеттеләр инде, хибесханәгә таба ике-өч кеше килә. Сакчылар аларга юл бирделәр. Өс-башлары килешсез, төкселәр, сары йөзлеләр. Берсе аңа агач чүмеч белән су бирде, икенчесе текәлеп карап тора — дәшми, гүя сыный. Артыкның баһадир булуына ышанмыйммы әллә? Хәер, ышанды ни дә, ышанмады ни, Артыкка ошбу адәм белән мал бүләсе түгел. Артык бер чүмеч суны йотлыга-йотлыга эчеп бетерде, кул аркасы белән авызны сөртте. Бу халык белән өлфәтләшергә язмасын, йөзләрендә нур юк. Бакты-күрде ич, һәр иләүдә каравыл-сакчы. Димәк, куркалар, чит-ят дала, куркырсыз да шул.

— Алыгыз үзен! — диде берсе. Ул шулай диюгә, Артыкны ике яктан култыклап алдылар да далага таба өстерәделәр. Шактый бардылар, юрталар артта калды. «Далага чыгарып, бугазлап бүреләргә калдырмакчылар», — дип уйлады Артык. Аның үләсе килми иде, ләкин чарасыз калуын да күптән аңлаган иде инде.

Туктадылар. Тирән булмаган баз, анда дистәдән артык мәет.

— Бирегез үзенә көрәк, — дип боерды кишектиннәрнең берсе.

Артыкның кулына көрәк китереп тоттырдылар.

— Менә бу базда синең азатларың ята, тупчы, әнә тегесендә син башларына җиткән безнең яугирләр. Күм шуларны. Күм-күм, югыйсә үзеңне терелэй күмәбез.

Артык азамат егетләрен киемнәреннән таныды. Тамагына яшь төере килеп тыгылды. Авыз эченнән генә дога укый-укый, яшенә тыгылатыгыла, азамат егетләрен күмә башлады. Хәле бетте, туктады, ләкин аңа шундук камчы белән сыптырдылар.

Үз азаматларын күмеп бетергәч, аргы базга күчерделәр. Әнә йөзенә кылыч белән чирткән яугир ята, әнә кылыч белән кадаганы, әнә Ягъфәр уктан алганнары. Каны катты, орыш мәлләре янабаштан күз алдына килде. Ниһаять, күмеп бетерде. Аны бер читкә сөйрәделәр. Шуннан бер көтү ат куып китерделәр дә өч-дүрт тапкыр кабер өстеннән уздырдылар. Шуннан соң Артыкны кире алып кайттылар. Аның хәле беткән иде, хибесханәгә керүгә, җиргә ауды һәм шундук йокыга талды.

Ул уянганда кояш баеган, җир өстенә салкынча һава төшкән иде инде. Артык торып утырды, тезләрен кочаклап җылынмакчы итте. Тәүге сакчылар юк, алар урынына башкалары килгән, болары хибесханә тирәли әкрен генә йөреп торалар. Ләкин ник берсе сөйләшсен, әйтерсең лә авызларына су капканнар. Ниһаять, аңа ашарга китерделәр. Зур булмаган түтәрәм сарык ите. Артык кабаланып ашый башлады, бер сакчының үзенә текәлеп, авыз чите белән елмаеп карап торуын күргәч кенә — үз кыланышыннан үзе уңайсызланып куйды. Ит артыннан бер касә кымыз бирделәр, Артыкка тәмам хәл керде. Эңгер иңеп килгәндә тагын ике кеше килде. Бу юлы аңа тәләкә астылар. Бу хәлне беренче тапкыр күргән Артык карышмакчы итте, ләкин берсе шундый иттереп аның эченә типте ки, Артык сыгылып төште һәм яңә көч-хәл белән генә тураеп баса алды. Инде теләсә нишләсеннәр. Борынгы болгарлар агач тәләкәне качкын сыерларга такканнар. Димәк, бу магуллар аны хайванга саныйлар.

— Минем тышка чыгасым килә.

Каравылчының берсе эчкәре керде, аны ияртеп, бер читкә әйдәде. Хәзер генә тәләкәнең ни өчен куелуын аңлады Артык, чәркәгә туры китереп куелган тәләкә бөтенләй атларга бирми, аякларны күчереп кенә барып була икән.

— Әйдә, әйдә! — дип ашыктырды сакчы.

— Шунда гына ярамасмы, яугир?

— Утыр алайсаң. Утыр шунда.

Ләкин тышка чыккач, сакчы аны бөтенләй башка якка алып китте.

— Мине кая алып барасың, яугир?

— Баһадирга, баһадирга, әсир. Син шактый зур тутый кош икәнсең бит. Тупчы диделәр үзеңне...

Артык дәшмәде. Аның бөтен дикъкатен Сүбәдәй белән очрашу мәле биләде. Кан кайный, җан иңри, йөрәк сыкрый. Тик нихәл итә ала. Ул әсир, ул кол хәзер. Җәбер-золымга йөз тоткан, орыш кырында күзгә-күз очрашырга теләгән Сүбәдәй каршына әсир исәбендә бара. Нигә тупчыларына ияреп китмәде, нигә калды, нигә Бачман баһадир әйтсә дә, кире борылып чапмады?... Кимсенү, үкенү, үз-үзеңне тиргәү бары тик чарасыз калудандыр. Ул чынлап та Сүбәдәй кулында — әсир. Әй, тәләкәдән вә әсирлектән арынасы иде дә ат менеп, бөтен төрки дөньясын җиһадка чакырасы иде. Нигә берләшми бу төрки халкы, нигә берсе тегеңә, берсе моңа ялланып хезмәт итә? Идел-Җаек төркиләренең терәге булган болгарларны да бугазлый башладылар бит инде. Һәм кем? Шул ук төрки халыклар. Кемгә ялланганнар диген? Теле-дине ят булган магулларга. Нигә аны әсир иткәндә, баһадир, диделәр? Кем белә аны монда? Алҗыган рәвештә, Ходай тәгаләдән мәрхәмәт сорый-сорый, иләү уртасында кукыраеп утырган юртага таба шуышты Артык. Нәкъ менә шуышты, атлый алмый иде, чак кына аякны киңрәк итеп атладыңмы, агач тәләкә чәркә сөягенә шундаен иттереп китереп ора, күз алларың караңгыланып китә. Хак, тәләкәне кулга тотып та була, ләкин сакчы бирми, шундук аркага камчысы белән сыдыра. Әсир икәнсең — кушканны кыл. Тикмәгә генә: «әсир кеше ким кеше, эт санына тиң кеше», дип әйтмәгәннәрдер, күрәсең.

Юрталарның исәбе-хисабы юк кебек. Ыстан тутырып казан астылар, ахрысы, күзгә әче тизәк төтене исе тула башлады.

— Нигә калада түгел, кордаш?

— Без бирегә кала алырга түгел, җәйләүләр яуларга килдек, әсир. Безгә кала кирәкми. Каладa син яшә. Хәер, син хәзер яшәр кеше түгел инде. Хәер, белеп булмый, туп серен бирсәң, баһадирның сине исән калдыруы да бар.

— Нинди туп сере?

— Болгардан килтергән туп серен, әсир. Сине мөңбаш диделәр, тик син мөңбаш түгел.

— Әйе, түгел,— диде Артык килешеп.— Меңбаш булсам, әсир төшмәс идем.

— Ә калаңызны бүген булмаса, иртәгә алырбыз, атаң коргыры зат. Сиңа минем бер дә күңелем ятмый. Син безнең унлап кешене шәһит иттең. Аягыңнан асып дала бүреләренә ташласы иде дә, баһадир сакларга боерды. Димәк, син аңа кирәк. Соңыннан безгә бирер ул сине, сорау алгач, теләгенә ирешкәч.

— Мин нигә баһадирга?

— Менә анысын үзеннән сорарсың инде, атаң коргыры җан. Тупчы ич син. Без сине тупчылар арасыннан аерып алдык.

— Кулымда коралым чакта туры килгән булсаң икән син миңа...

— Көрәшергә ниятең бармы әллә?..

— Ә нигә көрәшеп карарга да була. Тик башта тәләкәмне салдыр.

Сакчы сызгырып җибәрде, шундук хибесханәдәгеләр йөгерешеп килделәр.

— Ни булды, меңбаш?

— Менә бу өтекнең минем белән алышасы килә. Алыгыз тәләкәсен. Беркая да качмас, башы ике түгелдер.

— Йә,— диде каршында торган меңбаш.— Кил. Барысы да күренә, ай калкып килә. Курыкма. Кил-кил!

Кирәкмәгән олпат гәүдәле, кап корсаклы иде меңбаш.

— Безнең Болгарда сөлге белән алышалар.

— Бирегез үзенә билбау! — дип боерды меңбаш. Ул аякларын киңәйтебрәк басты, Артыкның якынайганын көтә башлады.

— Меңбаш, белеп торсаң иде, мин беркайчан да җәһилләргә баш биреп, бил бөгеп яшәмәдем. Эл сөлгең бөләгеңә.

— Әтәчләнмә, тупчы, әтәчләнмә. Бик маһир булсаң, кил.

Артык тиз-тиз атлап килде дә меңбашның биленә сөлгесен ташлады, арттан эләктереп алды. Меңбаш та төшеп калганнардан түгел икән, тиз үк Артыкның билен кысты.

Һәр ике батыр, ахылдый-ухылдый, әйләнә-тулгана, бил тартырга җай көтә башладылар. Сабантуй көрәшләрендә ничәмә-ничә тапкыр батырга чыккан Артык меңбаш сөлгесен биленә салуга ук аңлады — оста көрәшче бу. Җитмәсә әзмәвернең гелән биле дә юк кебек. Ул да түгел, Артыкның касыгына йодрыгын тыга башлады. Бу инде ким куйганда хәрамлау иде. Тик Артык та шул ук хәрәкәтне кабатлагач кына, меңбаш йодрыгын аның касыгыннан алды. Ә тамаша карарга яраткан халык җыелды да җыелды. Ай яктысы якты, әйтерсең лә көн үзе иде.

— Читкәрәк-читкәрәк китегез! — дип көрәшчеләрнең мәйданын киңәйтергә тотынды берәүсе.

Шулчак ике баһадирны уратып алган халык икегә аерылды һәм, бу тамашаны күрергә баһадир Сүбәдәй үзе килә, дигән пышан ишетелде. Артыкның сулышы кысылды. Чынлап та Сүбәдәй үземе? Үзедер. Озын буйлы, сыңар күзен кызыл чүпрәк белән бәйләгән, башында камалы бүрек, кәкре кылычы билендә, өстендә көмеш җеп белән тукылган сырмахалат. Артык аңа туры бага алмады, ул арада меңбаш аны тартып китерде һәм күтәрмәкче итте. Әйләнгәндә-тулганганда күрде Артык: Сүбәдәйнең ике ягында ике үзеннән дә җилкәлерәк кишектине[1], артында тагын берничә әзмәвер.

[1] Кишектин — баһадирның җансакчысы.

Баһадир кемгәдер аяк кагып кына ишарә ясады. Көрәшче меңбаш әллә Сүбәдәй баһадирны күрмәде, әллә күреп күрмәмешкә салышты, янә бер тапкыр Артыкның билен тартып китерде, күтәреп ормакчы итте, әмма Артык билен еландай боргалап, сөлгене аркасына шудырды. Алай да меңбаш аны күтәрде, мәгәр ора алмады, Артык гөрселдәп аның өстенә төште. Шунда меңбаш аны яткан килеш бер читкә ташлады. Моны Артык һич тә көтмәгән иде, тәгәрәп үк китте. Аягына басарга да өлгермәде, аның ике ягына ике кишектин килеп басты.

— Минем юртага! — диде Сүбәдәй коры гына һәм борылды да, җирдә яткан меңбашына күз дә салмыйча китеп барды. Сүбәдәй юртасына кишектиннәрен узып китеп керде, Артыкны алып кергәндә ул түр яктагы мендәренә кырын төшкән иде инде. Юрта эче шактый якты, өч-дүрт җирдә майлы ут яна.

— Син кем?

Артыкны ике кишектине баһадир алдына чүктерделәр.

— Син кем, дидем түгелме сиңа?!

Икенче тапкыр шактый саф төрки телдә аңа сорау бирде.

— Әйт, син кем! — диде өченче тапкыр, камчысын кулына алып, Сүбәдәй.

— Тупчы мин, баһадир.

Баһадир ишекъяры торган кишектиннәренә карады, янәсе, чынлап та тупчымы. Тегеләре, күрәсең, Артыкның сүзен куәтләделәр.

Барысын да көткән иде Артык, ләкин менә шулай Сүбәдәйнең юртасында күзгә-күз очрашырбыз дип күз алдына да китермәгән иде. Кеше әйтеп, кеше ышанмастай хәл — ул бажасы Сүбәдәй алдында һәм нинди сурәттә әле — әсир сурәтендә. Сүбәдәйнең йөзе озынча, өскә таба маңгае тараеп тора, киң кашлы, юка иренле. Сакалы юк, димәк, йә үзе йолка, йә йолкыта. Өстендә көбә күлмәк, кылычы вә кынысы Бохара әмиренеке булса кирәк, Бохара осталары шулай нәкышлый кылыч сабын, кылыч кынысларын. Аягында ак итек, димәк, чи тиредән, чөнки итек башы тырпаеп тора, итек куңычында хәнҗәр. Юртага яңа гына Артык белән көрәшкән меңбаш керде, Сүбәдәй аңа түрдән урын күрсәтте.

— Кай тирәдә эләктердегез үзен?

— Туплар аткан тирәдә. Туп куйган атлары тайганнар иде инде, бу нишләптер бериш азатлары белән укчыларга ияргән булды. Аннары без аны җай китереп бүлеп алдык. Тупчы гына түгел бу, баһадирым, йә меңбаш, йә йөзбаш. Егермегә якын яугиребезне теге дөньяга озатты. Менә очлымы, күрәсең ничек каттә итеп эшләнгән.

— Һәйбәт, — диде Сүбәдәй. — Үзеңә ал. Ә син әт, тупларны кем ясый?

— Болгар ясый, баһадир. Бездә күп ул, бик күп.

— Кымыз бирегез тупчыга.

— Баһадирым, орышканда азамат егетләре саклады-лар үзен.

— Меңбаш, — диде Сүбәдәй һәм мендәргә утырды. — Тупчылар меңбашы.

Сүбәдәй баһадир кымыз китерүче кулыннан чин касәсен алды, бер уртлауда эчеп куйды.

— Тупчыга да бирегез, — диде ул кымызчыга карамый гына. — Ул да сусагандыр.

Җаны тәмам кипкән иде, Артык та нәкъ Сүбәдәйчә бер йотуда касәне эчеп бетерде. Әчкелтем сыекча бөтен эчәк-әгъзаларын рәхәтләндереп, эчкә коелды һәм шундук башына дымлы кайнар һава агыла башлагандай булды. Иреннәре кипкән, җаны көйгән иде, кымыз эчкәч, хәле җиңеләйгән кебек булды. Ул башын түбән иде дә бертын утырды.

— Йә, тупчы, нә әйтерсең миңгә?

Артык туп-туры Сүбәдәйнең күзенә күтәрелеп карады. Сүбәдәйнең кан тамырлары күренеп тора, камчы сабы кебек муен сеңерләре калык-

кан, ишеп куйган аркан диярсең. Юртага төз гәүдәле яшь егет килеп керде. Өсте-башы әйбәт, үзен иркен тота.

— Кем бу, атам?

— Уз, утыр әйдә, углан. Син дә сорау ала аласың. Болгар меңбашы. Әсир алдык. Әүвәл, тупчы, диде, меңбаш икәнсең бит.

— Егермедән артык яугирнең башына житкән адәм бу, атам.

— Шул. Димәк, тупчылар меңбашы. Атың ничек, меңбаш?

— Атым — Болгар, баһадир.

— Болгар. Ил исемен йөртәсең, димәк. Күлкән углан, әллә син сорау аласыңмы үзеннән? Баһадирны әсир иткән яугирләргә бирәр бәлеш алтын бирергә. Казнабаш, ишетәсеңме. Һәр яугиргә.

— Һәр исән калган яугиргә, атам.

— Меңбаш кадәр меңбашны әсир итсеннәр әле,— диде Сүбәдәй горурланган бер төстә.

— Исән көйгә алырга кушмаган булсаңыз, баһадир, мин аның әллә кайчан җанын җәһәннәмгә җибәргән булыр идем.

— Игелек вә дан сиңа, меңбашым, игелек вә дан!

«Менә Күлкән белән дә очрашырга туры килде»,— дип уйлады Артык, аяклары ойый башлавын тоеп, бөкләнеп утырды. Күлкән бер ягы белән дә Ташбайга охшамаган. Ә менә атасында Ташбай углан чалымнары бар.

— Инде меңбашны нишләтәбез, атам? — дип сорады Күлкән.

— Ал син аны үзеңә. Сакла. Кирәк булыр әле ул безгә. Тик кара аны, нык сакла. Аның миңа кирәк булып куюы бар. Хәзер безгә, Котбый меңбаш, сиңа әйтәм, туплар куйган атларны кулга төшерергә кирәк. Үзеңә ошаган егетләрне сайлап ал да шул эшкә кереш. Мин Болгарны үзләре ясаган туплар белән алырмын.

— Башта Саксинны алыйк әле, атам.

— Саксинда без торабыз инде. Дала безнеке, каласы да безнеке булыр. Олан, барыгыз алып китегез әсирне!

Артык торды, ике кишектин арасында тышка чыкты.

Һава салкынчарак иде. Аңа тәләкә элмәделәр: димәк, Күлкән оланга ышаныч зур. Күр әле син Сүбәдәйне, угланына безнең кебек «олан» дип дәшә. «Әллә соң үзе дә шивәле татармы? Карлыгач та бик тиз безнең як шивәсендә сөйләшә башлады ич»,— дип уйланып атлады Артык. Сүбәдәйнең меңбашларына кадәр төрки. Котбый үзе ни тора. Араларында мөселманнар да бар, дигәннәр иде аны, хак икән. Хәер, борынгылар, яулаган халыкның телен белү — ярты җиңү, дигәннәр.

Артыкны зур булмаган юртага алып керделәр.

— Биредә торыр,— диде аны озата килгән меңбаш.— Бавырчы, әсирне ашат, эчер. Ә сез, яугирләрем, ошбу әсир өчен башыгыз белән җавап бирәсез.

— Без аны саклarбыз, Котбый меңбаш. Кача-нитә калса, аягын сындырмый булмас.

Сакчылар меңбаш белән үзләрен эре тоттылар, димәк, Күлкән углан кишектиннәре, дип уйлады Артык. Түр яктагы намазлык хәтле генә, телгәләнеп беткән киезгә утырды. Эчтә аны ике кишектин саклый, тышта тагын сакчылар бар. Бавырчы касә белән шулпа, ит китерде, соңыннан су бирде. Шуннан соң беләк юанлык каен агачыннан ясалган, бер кеше басып торырлык кына хибесханәгә алып керделәр. Сакчыларның берсе Артыкны шунда кертеп япты, икенчесе ишек яры мендәргә утырып, дикъкать белән күзәтеп торды. Кишектиннәрнең кулларында корал юк, билләренә таккан хәнҗәр генә, итек куныычларында пычак. Ләкин тышта торганнарда сөнге-кылыч бар. Артык хибесханәдә утыра гына ала. Утырды һәм шундук йокыга талды.

Уянды ул ат пошкырганга. Юрта янына кемдер килгән, кишектиннәр белән сөйләшә. Эчтәге кишектин сискәнеп китте, япма янында утырган ишенә төртеп алды. Артык юрта тишеге аша һавага карады. Кояш

чыгып килсә кирәк, һава зәп-зәңгәр, йолдызлар сүнгән. Бераз баш авыртып тора, әмма түзәрлек. Ә менә йөрәк әрнешүгә, бәгырь телгәләнүгә түзмәле түгел, чигәләрне шаулатып сыза да сыза ачу һәм үкенү гайрәсе. Әле ул Аллаһы тәгаләгә мөрәҗәгать итте, әле Бачман баһадирга. Килсен иде бөтен гаскәре белән, ябырылсын иде Сүбәдәйгә һәм аны коткарсын иде. Бачман баһадирны тыңлап, ул әйткәч тә, тупчылары артыннан киткән булса, бу көнгә дә калмаган булыр иде. Үзе орышта катнаша, янәсе... Катнаштың һәм менә килеп каптың. Кемгә диген әле — кан дошманы Сүбәдәй кулына. Туплар ясау серен белү өчен ул хәзер аның җанын алачак. Кайда хәзер Бачман баһадир, кайда тупчылары — бер Хода белә. Сүбәдәй калада түгел, димәк, каланы ала алмаган. Сүбәдәй тагын бер-бер хәйлә корып ята булса кирәк. Бачманны җиңәргә, каланы алырга аңа Артык баһадирның тупчылары ирек бирмәде. Бусы хактыр. Чөнки әсир төшкән бер генә кыпчак азаты да күзгә чалынмады. Аннары нишләптер Сүбәдәй, хәтта Бачман баһадирның гаскәр санын да сорамады. Димәк, хәбәрдар, барысын да белә. Хәер, гаскәр санын гына түгел, тупчылар санын да беләләр булса кирәк, чөнки үзләрен бик иркен тоталар.

— Һәй, кишектиннәр,— диде Артык.— Минем тышка чыгасым килә.

Янында йокымсырап утырган кишектин күзләрен ачты, аякларын сузып җибәрде.

— Сабыр ит, тупчы, сабыр ит. Хәзер мине алыштырырга киләләр. Алар сине тышка йөртерләр инде.

Чынлап та, күп тә үтми, юртага ике кишектин килеп керде, болары исә чыгып киттеләр. Алар үзара сөйләшеп алдылар. Артык аларның телен аңламады.

— Кишектиннәр, минем тышка чыгасым килә,— дип кабатлады Артык.

— Эт намастаның тышка чыгасы килә,— диде берсе.

— Юкса юртаңыз сасытам.

— Яныйсың,— диде икенчесе һәм хибесханәнең ишеген ачты.

— Чык,— диде беренчесе.— Чык, эт косыгы. Аннары тыштагыларга кычкырды: — Хулан, Хулан дим, әсир тышка чыгам ди, каршы ал.

— Әйдә, чыксын,— диде, япманы ачып, тыштагы кишектин.

«Күр әле боларны, кишектиннәре әллә гел төркиләр инде»,— дип уйлады Артык далага таба атлаганда.

Кылганнар арасына кереп утыргач, Артык кояшчыгышка бакты. Кояш нурлары хатын-кыз чәчедәй күккә үрләгән иде. Ул түшәктә сибелеп яткан Карлыгачының чәчләрен күз алдына китерде һәм тешен кысты. Нинди көнгә калды бит!..

— Җитте сиңа, оема! — дип ашыктырды кишектиннәрнең берсе.

Артык ашыкмый гына ыштан бавын бәйләргә тотынды. Каерылып артына карады һәм йөрәге мерт итеп китте. Ике юрта аша гына үзе озатып җибәргән сәүдәгәрләрнең дөяләре тора иде.

— Нәмә күреп каттың анда, әйдә! — диде кишектин.

— Сәүдәгәрләр дә туктайлар икән үзегезгә,— диде Артык кузгала башлап.

— Туктамасалар, туктатабыз аларны. Без аларга акчаны аз түләмибез.

— Болары кай тарафтан?

— Каян булсалар да безгә барыбер, товар гына сатсыннар. Йә, кузгал, нигә катып калдың!

Юртага кайтардылар, хибесханәсенә кертеп яптылар, ә Артыкка тынычлык килмәде дә килмәде. Нә Сүбәдәй угланы Күлкән килми, нә Сүбәдәй үзе кызыксынмый. Нинди мәгълүматлар алырга телиләр икән аңардан? Тупларны ничек ясауларын ул белми, хактыр. Ә менә аларны ничек атларга куярга, ничек атарга — ул осталарның остасы. Әгәр дә мәгәр дөяләр угланнарныкы булып чыкса, алар Сүбәдәй ыстанындалар.

Димәк, үз дигәннәренә ирешкәннәр. Ташбай угланы атасы Артык әсир төшкәнне ишетсә, харап — бер-бер ахмаклык эшләп ташлавы бар. Дөрес ул исемен Болгар дип әйтте, ләкин бит аны күрүләре ихтимал...

Менә бит ул — язмыш дигәнең, кичә кайда иде дә, бүген кайда ауный. Бәхәссез, Артык баһадирның югалуын тупчылары да, Бачман баһадир да белгәннәрдер. Хәтта аны коткару өчен иң кыю егетләрнең дошман ыстанына килүләре мөмкин. Менә анысы зур хата булыр иде. Аллам сакласын. Сүбәдәй баһадир тирәсендәге юрталарга үтеп керәм димә, һавадан очкан кошларны уктан алучылар бар. Моның өчен баһадир иң мәргән, иң елгыр егетләрне үзендә кишектин итеп тота. Килмәсеннәр, бәхетләрен сынамасыннар, дип хәбәр итәсе иде дә, тик кем аша? Меңбаш Котбыйга әйтеп караса? Әле сиңа шымчы кирәк булдымыни дип, ике дә уйламый кылычтан уздырыр. Болай да аның миңа ачуы зур, бәгъзесе утызлап азатының башына җиткәнбез икән ич. Юк сиңа, Артык баһадир, мәрхәмәт нә Котбыйдан, нә Сүбәдәйдән. Гомер бакыеңа, хәтта үлгәч тә кыямәт көнгә кадәр үк тәмугта янасы кеше син. Ниндәен егетләрең дошман кылычы астына алып кердең бит. Ягъфар үзе җиде мәргәнгә торыр иде. Ул да ятып калды. Җитмәсә, үз кулың белән күмдең үзләрен, күз яшеңә тыгыла-тыгыла, билге ташы да куймыйча, чөнки магуллар кабер өстеннән көтү-көтү ат уздырдылар.

«Йа Аллам, үзең ярлыка бән фәкыйреңне, ярлыка, ярлыка...»

## 17

Болгарда да, Саксинга килгәч тә, хан оныгы Хансөяргә берәү дә, тылсымга ия, сихерче ул, димәде. Сөмбелгә өйләнгәч, ул үзе дә бу хакта гелән онытты. Аның бөтен дикъкатен, көч-гайрәтен гүзәл кыз Сөмбел биләп алды. Меңбаш Ташбай да яшь кәләшкә таргач, дөньясын оныткан кешедәй халәттә иде. Ул карусыз бар нәрсә белән килеште, бер тапкыр да хан оныгы Хансөяргә каршы төшмәде, гәрчә дошман ыстанына сәүдәгәрләр сурәтендә үтеп керүгә, әүвәл каршы булса да, икесенең дә туйдан соң үткән төннәре йокысыз булды, җитмәсә таң белән диярлек сәфәр чыгасы иттеләр — сәүдәгәрләр, имеш. Бары тик юлда барганда гына меңбаш Ташбай: «Хан оныгы Хансөяр үзе генә белгән маһирлыкка бирелде бугай»,— дигән нәтиҗәгә килде. Ләкин соң иде инде, алар юлда, товар төялгән, дөяләр акрын гына атлый. Хәер, Ташбай хан оныгы Хансөяргә һәрчак ышанды, чөнки аның ялгышканы бик сирәк була, гүя күрәзәлек тылсымы бар иде үзендә.

Уй-теләкләре буенча татлы айлары сәфәрдә үтәргә тиеш иде. Кәрванда ун егет, унысы да өйләнгән, унысының да кәләшләре үзләре белән, бер мелла Хакимҗан гына ялгыз. Әмма аның да үз максаты: кыргый магулларны ислам диненә инандыру. Бар булган коралы: йомшак теле, сихри нотык-вәгазе йөрәк түрендә.

Тик алар ерак китә алмадылар. Сүбәдәй баһадирның багучыларына тап булдылар, ә тегеләрнең талканы коры булды, шундук үз ыстаннарына борып алып керделәр. Хәер, егетләрнең максаты шул иде ләбаса: ничек тә булса ыстанга үтеп керү. Хак, кәрванны туктаткач, ике яугир арасында бәхәс купты. Берсе: «Җибәрик сәүдәгәрләрне, туктатырга хакыбыз юк»,— дисә, икенчесе әллә сәүдәгәрләрнең яшь булуларына шикләнеп, аларны ыстанга таба әйдәкләде. Ыстанга җиткәч, аларны төрки баһадиры каршы алды һәм кай тарафка туктарга иләү күрсәтте.

Кәрван зур түгел иде, товарлары да ишелеп тормый, мәгәр, ыстанга сәүдәгәрләр килде, дигәч, килеп тамаша кылып китүчеләр шактый булды. Болгардан китерелгән итек-читек, муенса-беләзек, алка-бөти кебек затлы әйберләрне бик тиз сатып бетерделәр. Бал һәм бодай ярмасын бик алмадылар. Ул арада кич җитте, кунарга юрта куярга булдылар. Төннәре тыныч үтте, аларны берәү дә борчымады, әйтерсең лә дошман ыстанын-

да да түгелләр иде. Иртән-иртүк торып, ашап-эчеп кенә бетергәннәр иде, арпа-тары һәм бал алырга төрле яктан сугышчылар җыела башлады. Ярмаларны күпләп алмасалар да, өйлә тирәләренә алты дөядәге товар сатылып беткән иде инде.

Кояш баю ягына авышкан гына иде, бер төркем кәттә кишектиннәрен ияртеп, кәрван һәм сәүдәгәрләр янына Сүбәдәй угланы Күлкән килде. Углан янында саллы егетләр, киемнәре дә үзгә — ыспай киенгәннәр, үзләрен иркен тоталар. Бигрәк тә Күлкән аерылып тора. Өстендә кытай ефәгеннән тегелгән саргылт төстәге халат сыман кыска җиңле җилән, сәдәфләре алтын, башында камалы җиңел бүрек, көмеш белән нәкышланган кыналы кәкре кылыч сабында кулын тота, итек кунычында бер, билендә икенче хәнҗәре. Ни сәбәпледер Күлкән, килә-килешкә, күзгә-күз Ташбай белән очрашты. Ташбай сизелер-сизелмәс кенә аңа баш иде. Аннары Күлкән, киеменең затлы булуын күреп булса кирәк, хан оныгы Хансөяргә күз ташлады. Хансөяр кулын күкрәгенә куеп, кунак белән баш иеп исәнләште.

— Сәнме кәрванбаш? — дип сорады ул камчы сабы белән итек кунычына суга-суга. Хан оныгы Хансөяр соңгы батман балын сатып тора иде. Күлкән мөрәҗәгать итүгә, бар эшен ташлап, дикъкатен аңа юнәлтте. Ләкин игътибар итте, Күлкән карашын бөтенләй башка кешегә күчергән иде инде. Хан оныгы Хансөяр күрде, Күлкәннең хәтта күз карашында нәүмизлек хасил булды, әйтер сүзе тел очында калгандай, бертын авызын ябалмый торды. Күлкән беразаптырабрак, шул ук вакытта соклануын яшермичә, йөзен ачкан килеш дөя янында басып торган Сөмбелгә карый. Күлкән углан артыннан, хәрби боерык алгандай, кишектиннәре дә Сөмбелгә бактылар һәм, шик калмаган иде, алары да яшь хатыннан күзләрен ала алмас булдылар. Күлкән камчы сабы белән Сөмбел басып торган дөя тарафына күрсәтте.

— Дөя дә сатыламы? Кыз дамы?..

Хан оныгы Хансөяр зиһене аша мең төрле фикер-уй узды, ул хатыны ягына әйләнеп карамады, иллә сизде — Сөмбел бераз елмаебрак Сүбәдәй угланы Күлкәнгә карап тора. Вәйран батыр егет яшь хатынга бер күрүдә гашыйк булды, күрәсең. Моны Сөмбел үзе дә сизми калмады — күзләр барысын да әйтә ич, күзгә сүз кирәкми. «Нәркәз зәңгәр күзләрен, тулган ай күк йөзләрең... бер көн хаста, бер көн сау, үлә яздым, гүзәлем,— дигәнме әле шагыйрь, бер сылуны күргәч? Ни генә булмасын, Күлкән угланның Сөмбелгә күзе төшкән иде инде. Гүзәл затларны күрмәгән егет түгел иде ул. Әйе, күрмәде түгел, күрде, хәтта берничә тапкыр җылы кочакларын да татыды, иллә берәүсе дә аны болай бер күрүдә күз карашы белән сихерли алмаган иде әле. Сүз әйтергә теләп тә өнсез калуы шуннан иде — мондый гүзәлне аның күргәне юк иде. Хан оныгы Хансөяр кәрван башы булса да бер читтә калды, егетнең дикъкатын Сөмбел биләде.

— Каравыш кызмы, сатарга илтәсеңме? — дип сорады кабат Күлкән углан, хан оныгы Хансөяргә бөтенләй игътибар итми, ләкин ул аны ишетә-күрә иде, бары тик аның җавабына мохтаҗ түгел, телим икән, кызыңны каерып алып китәм, дип аңлатуы иде. Моны хан оныгы Хансөяр генә түгел, кәрван белән чыккан барысы да аңладылар. Чөнки Сүбәдәй баһадир угланы Күлкән хан оныгы Хансөярне бер читтә калдырып, Сөмбелгә таба атлый иде инде. Шунда гына хан оныгы Хансөяр каушый калды. Ул башта каударланып аңа аркылы төшмәкче итте, ләкин Күлкәннең кишектиннәре аны бик тиз бүлеп алдылар. Күлкән исә атлаган җайга ук күзләре белән яшь хатынның гәүдә-сынын капшый иде инде. Ни әйтергә тиеш аңа Сөмбел? Белмәде. Тик ул каушамады. Өйрәнгән иде ир-атның сөзеп каравына, бик исе китми иде. Тик монда бит Сүбәдәй баһадир угланы Күлкән һәм аның аша күп нәрсәгә ирешеп булачак. Моны хан оныгы Хансөяр генә аңласын иде. Юкка гасабиланмасын иде. Сөмбел үзен тота белер. Шик юк, Сөмбел ризалыгын бирсә дә, бирмәсә

дә, кәрванбаштан кызны үзенә сатуын сорар. Һәм бәһадә дә тормас. Нә кылыр шуннан соң хан оныгы Хансөяр, аның җан кисәге, ире, ниһаять? Сөмбелнең йөрәге калтырана башлады, курку түгел иде бу, үзе өчен ул курыкмады, бер-бер хәл кылыр дип Хансөяре өчен борчылудан иде. Күлкән аны аласы итсә, әлбәттә, Хансөярдән сорап тормас, бер дә булмас димә, тартып та алып китәр. Һәм хан оныгы Хансөяр һични кыла алмас.

Ә максаты аның ничек булса да дошман ыстанына үтеп керү ләбаса. Шуның өчен булса кирәк Хансөяр хатыны ягына карамады, ул күнел күзе белән күрде, Сөмбел карашы белән аны эзли, аның ризалыгын алырга тели, һич югы күзләре белән аңа нишләргә тиешлеген әйтсен иде! Күлкән тәмам аның янына килеп җитте, камчы сабы белән ияк астына кагылды, башын күтәрмәкче итте бугай, ләкин Сөмбел кинәт кенә дөя артына посты.

— Хөрмәткә ия, нойон, хатыным ул минем, каравыш кыз түгел,— диде, ниһаять, акылына килеп хан оныгы Хансөяр. Бу вакытта Ташбай, хатыны Айгөлнең йөзен каплап, дөя артына яшерде. Ләкин Сүбәдәй угланы Күлкән Сөмбелдән башка берәүне дә күрми иде инде.

— Син аны миңа сатарсың, кәрванбаш,— диде тәкәббер генә артына каерылып Күлкән.— Мин сиңа яхшы түләрмен. Бөтен саткан малың бәһасе алырсың.

Һәм Күлкән борылды да китеп барды, кишектиннәре аңа иярделәр, ләкин дүртесе калды һәм дөя артына поскан Сөмбелне күтәреп алдылар, берсе күтәреп җилкәсенә ташлыйм дип ымсынган иде, Сөмбел:

— Мин үзем барам, кагылма миңа! — дип кычкырды. Шуңа китеп барган Күлкән әйләнеп карады һәм кире килде.

— Үзе барса, бик әйбәт. Бирегез кәрванбашка биш бәлеш алтын. Шулчак Ташбай атылып чыкты, Күлкәннең кишектиннәре кылычларына тотындылар. Хан оныгы Хансөяр аны туктатты.

— Кирәкмәс, Ташбай. Туктал!

— Акыллы фикер,— диде Күлкән.— Акыллы фикер. Акыллы кәрванбаш. Ә синең белән очрашырбыз әле,— диде ул Ташбайга карап.— Болгарда.

Ташбай тагын ымсынган иде, Хансөяр аның җиңенә ябышты.

— Туктал диләр сиңа! — Аннары Күлкәнгә бил бөкте: — Гафу ит, нойон. Башы яшь әле аның.

Сөмбелне алып киттеләр. Ташбай меңбаш хан оныгы Хансөяр тирәсенә җыелган ишләренә карады.

— Нишлибез?!

— Коралланыйк та,— дип башлаган иде берәүсе, Хансөяр аны туктатты:

— Онытмагыз нинди максат белән килүебезне. Безгә аны Ходай җибәргән,— диде.

Барысы ла күзгә-күз карашып алдылар. Бу ни хәл инде, берәүнең хатынын алып киттеләр, а ул нәрсә ди?..

— Ташбай бажай,— диде хан оныгы Хансөяр.— Әллә сиңа Хода ике гомер бирдеме? Юкмы? Шулай булгач, тик тор. Алар безне күз ачып йомганчы юк итәчәкләр иде.

— Нишләргә соң безгә, кул кушырып утырыргамы! Бүген синең хатының алып киттеләр, иртәгә минекен таларга килсәләр? Мин хатынымны синең уч төбеңдәге биш бәлешкә генә бирергә ниятем юк, хан оныгы Хансөяр.

— Кем аңа йөзен ачарга кушты, үзе ачты, үзе! — дип үртәлде Айгөл.

— Булды, куеп торыгыз,— диде алар янына килгән мелла Хакимҗан.— Килешеңез, язмыштан узмыш юк. Иншалла, барысы да әйбәт булыр.

Хан оныгы Хансөяр меллага таба борылды, җилән якасыннан эләктереп алды.

— Максатымыз турында онытма, хан оныгы Хансөяр. Сөмбел үзен кимсетергә бирмәс. Безнең максат дошман ыстанына керү, диден ич. Үзең котыртучы. Без кәрван белән Үргәнечкә дә, Хивага, Бохарага да дип чыкмадык, без дошман ыстанына үтәргә тиеш идек, фәрештәләр амин дигәнгә туры килеп үттек. Инде кәтми хәлебез юк. Беренче адым ясалды, хан оныгы Хансөяр.

— Син хаклы, хаклы, мелла, тагын бер кат сорыйм, гафу ит. Мин кызып киттем,— диде хан оныгы Хансөяр.

— Иртәгә безнең хатыннарны да тартып алсалар, биш бөлеш бирепі!— дип атылып чыкты бер азат.

— Үзең сатмасаң, синең хатының берәү дә алмас, Сарбай азат. Сүбәдәй баһадир угланы хатын-кызга мохтаҗлык кичерә дип уйласагыз, бик нык хаталанасыз, балакайлар. Без ил өчен халкымыз өчен ихъя кыламыз. Хатын югалту — баш югалтумы! Әйтмәсәм әйтим. Җибәрегез мине Сүбәдәй баһадир каршына. Хан оныгы Хансөяр, үзең илт. Монда мин күрәм, ул ата, ул баш, ул хаким һәм ул хөкемдар. Сүбәдәй баһадир «Яса»га карап хөкем йөртә. Иншалла, Сөмбелгә берни дә кылмаслар.

— Хыянәт ич бу! Үз хатының үзең бирү...

— Биш алтынга түгел бит, биш бөлеш алтынга. Бер бөлешкә мин җиде дөяң товарың-нисң белән сатып ала алам, Ташбай меңбаш.

— Мелла хаклы,— диде, ниһаять, Сарбай азат.

— Тагын кабатлыйм, хыянәт түгел бу. Боерган итсә, Сөмбел безне дә Сүбәдәй катына дәштерер. Менә шунда инде без сөйләшеп карарбыз. Бер шагыйрь әйткән бит: «Тылсым аның күзе, уйнак аның сыны, тулган айдыр йөзе, яралады җанны»,— дип. Сөмбел яралады Сүбәдәй угланы Күлкәнне, яралады. Хәзер ул угланның йөрәгеннән кан тама. Сөмбел аның катына бармаса, ул безне җибәрмәс.

— Мелла, дим, оял бераз,— диде Ташбай, гасабилануын яшермичә.

— Оялырга мин сиңа хатын-кыз түгел, гәүрәтем күрсәтмим. Сабыр итегез, оланнар, сабыр итегез. Сөмбел бер дә акылсыз бала түгел, ул хәлнең асылына шундук төшенде, чөнки дошман ыстанына безгә башкача керү мөмкин түгел иде. Мин аңа серле дару бирдем. Ул даруны капкан кеше гайрәтсез калачак. Иншалла, барысы да әйбәт булыр. Яхшыга юрыйк, оланнар, яхшыга. Максатымыз онытмыйк, оланнар, максатымыз. Әгәр дә мәгәр Сөмбел артыннан без дә Сүбәдәй иләвенә үтеп керә алсак... анда без нә кылырга белербез. Мин ничекләр булса да Сүбәдәй баһадирны ислам диненә дүндерергә тырышырмын.

— Күлкән Сөмбелгә өйләнсә?— диде Ташбай, ни кылырга белмичә, йөренергә тотынды.

Мелла Хакимҗан кулларын җәйде.

— Нишләмәк кирәк, нишләмәк кирәк, Ташбай олан, әйе, өйләнеп тә куюы ихтимал. Ул чакта инде без баһадирга шарт куярбыз: мөселманнарча никах укытып һәм угланны да ислам диненә дүндергәндә генә кыз анык булыр.

— Мөмкин хәлме бу, мелла?

— Синең, хан оныгы Хансөяр, бер-бер башка тәкъдимең бармы? Булса, әйт. Нәчарасыз калдык ләбаса! Безгә, оланнар, баһадир Сүбәдәй кулыннан тыныч сәүдә итү өчен фатиха алу кирәк. Кайтып китсен ул иленә, Болгар белән тыныч сәүдә итсен.

— Ә Сөмбел?— диде Ташбай углан.— Кем сурәтендә бирегә килден?.. Сине бирегә Илһам хан җибәрде түгелме?! Иләү агасы корыч баһадир Сүбәдәйгә Болгарда нә кирәк? Ни өчен ошбу мәртәт өч-дүрт ел аңа яу йөри? Аңа ни җитми, ярты дөньяны яулады ич, һаман дала-көтүлекләр җитмиме? Җитә, җитә аңа көтүлекләр, оланнар. Мәрхүм ханы — Чыңгыз васыятен үтәп йөри ул. Бер диңгездән алып, икенче диңгезгә кадәр җирҗәйләүләр магулларныкы булырга тиеш. Менә аларның төп максатлары, төп теләкләре. Инде менә безнең Иделемезгә килеп төртелделәр. Бездән үтсә, урыс кала, урысны да узса — франклар, румнар. Йа Ходам,

нәнди кодрәт вә гайрәт бирдең син ярым кыргый, ярым дуамал халыкка. Мөслим-мөселманнарың шушы гыйбрәткә баш иеп торсынмы?!

— Сөмбелем, Сөмбелем, ахирәтем, кем кулына киттең? — дип, Айгөл ир-канаты Ташбай күкрәгенә капланды да елап җибәрде.

Кичә кич белән генә, хатын-кызлар үзләре генә утырганда Сөмбел аларга әйткән иде: «Илем-халкым өчен мин үземне корбан итәргә дә әзермен, ахирәтләр, ә сез?» — дигән иде. Котлары алынган яшь хатыннар ни әйтергә белми өнсез калганнар иде. Ничек инде кичәле-бүгенге генә кияүгә чыктылар ләбаса! Өзелешеп сөешкән, кочышып туймас чаклары ич!

«Абау, ахирәтем, тәүбә диген, як-ягыңа төкер, фәрештәнең амин дигәненә туры килүе бар», — дип үртәлде Айгөл.

«Килсен! — диде Сөмбел. — Килсен. Илем-халкым өчен калыпка утыртсалар да риза. Тик туган җиремне яугирләр, баскынчылар гына таптамасын».

Шаккатмалы хәл инде бу. Кулыннан тартып диярлек алып киттеләр, ә яшь ире уч төбенә салган биш бәлеш алтынга карап, торып калды. Мөмкин хәлме? Мөмкин икән ләбаса. Китте Сөмбел дошманга ияреп, калды өч-дүрт көнлек ире сөрәеп. Тагын бер хәл хәтеренә төште Айгөлнең. Сөмбелнең нә сөйләгәнен Хансөяр үзе дә ишетеп торган икән, моны күргән Сөмбел торды да ир-канаты аягына төште.

«Ир-канатым, ил-халкым хакына, нә кылсам да, сән бән хатының кичерерсең, нинди хәлдә дә кулыңа корал алмассың».

«Алмам-алмам, Сөмбелем. Ни сөйлисең син? Язмаганны...» — дигән иде. Язган булган икән ич!

Шунда хан оныгы Хансөяр хатынының битләреннән алды, күзләренә карады. Хатынның күзләре мөлдерәп яшь белән тулган иде.

«Мин синең колың, Сөмбелем. Раббым мине чарасыз итә. Алай димә, Сөмбелем, Ләйләм!..»

«Мәҗнүнем-Хансөярем. Ыстаннарына үтә алсам, мин корыч баһадирны калабызга керүдән ваз кичтерермен. Ил-гавамем хакына мин үземне корбан итәргә дә ризамын».

«Сине иблис котырта, Сөмбел, — дигән иде Хансөяр шунда. — Син намазга утыр, котыл бу уйдан, арын, Раббымыздан үтен».

Хатын-кызлар барысы да шыңшып елаша башлаганнар иде. Сөмбел аларны туктатты.

«Хатыннар, Аллаһы тәгалә безне рәхмәтеннән ташламас, иншалла, ил-каламыз кулдан язарга торганда кан-яшь түкмиләр, кулга корал алалар. Мән сайлаган корал — Сүбәдәй юртасына үтү. Ил югалганда мәхәббәт белән исәпләшмиләр», — диде шул чакта Сөмбел һәм елашкан хатыннарны гына түгел, тыңлап торган ир-атларны да шымга калдырды.

Җитмәсә шулчак Сөмбелне мелла Хакимҗан да яклап чыкты. Һәм аларга озын итеп нотык укыды.

«Ислам шәригате, балалар, иң әүвәл Алладан ярдәм сорый. Гавәм ничек аңлар, анысын без кайгыртырга тиеш, мөхтәрәм шәрәфле муллалар. Борынгылар: «Саф вә эчкерсез мәхәббәттә җәннәт төсе бар», — дигәннәр. Әйе, хәдистән белгәнебезчә, шулай, ләкин туган илгә, туган халкыңа мәхәббәт бәндәгә булган мәхәббәттән күп тапкыр өстендер. Мәхәббәт дөньялыкта нур булса — ахирәттә шатлык булыр, ди. Бачман баһадир кызы Сөмбел хаклы, балалар».

Ике-өч көн вә төн буена гыйшык табасыннан төшмәгән яшь хатыннар мелла нотыгыннан һәм ахирәтләре Сөмбел сүзләреннән соң иңкеминкә хәлдә калганнар иде. Йөрәкләре кушылган, чәчләре бәйләнгән ишләрне ничек тиз генә өзмәкче бу мелла. Моның өчен азмы ихтыяр көче кирәк. Бу көчкә ошбу сәфәргә чыккан барысы да ияме? Кушкан йөрәкләрне, бәйләгән чәчләрне үзе үк өзмәкче ич!

Шунда Ташбай меллага әйтте: «Мелла Хакимҗан, әйт әле, ниндәен илаһи көч мәне Айгөлдән аера алыр икән? Син, мелла, бәнем күңелемә шом вә хәвеф салдың».

«Хаклык синдә, углан Ташбай,— диде шунда мелла.— Никахлы ир белән хатын арасы Аллаһы тәгалә тарафыннан олуг сөннәт итеп карала-дыр. Үз туганына өйләнү хәрам булган кебек, никахлы хәләл-җефетеңне дошман кулына бирү дә зур гөнаһтыр».

«Бәс, мелла, шулай булгач, ниндәен маһирлыкка өндисең син безне?» — дип янә чәчрәп чыккан иде Ташбай.

«Тыныч тормышта гөнаһсыз юл сайлау кәттә сөнәттер, балакайлар. Иллә бүген без ил-гавәм язмышын хәл итү алдында торабыз. Сүбәдәй баһадир Саксин каласын кулга төшерергә дип килгән. Максаты яман. Каланы яулау белән гүзәл хатын-кызларымызны бауга тезеп, Каракорымга озатырлар, ир-атларымызны кылычтан уздырырлар. Ә инде даннары илләргә таралган һөнәр осталарымызны билләренә тәләкә тагып, йә булмаса калыпка утыртып, хезмәтче итәрләр. Чөнки, оланнарым, Сүбәдәй баһадир имансыздыр, аның инанган иманы — Чыңгыз хан калдырган «Яса». Ул бәндә нә ислам, нә нәсара диненә табынмый. Бән Сөмбел ярдәме белән аның кырына үтеп керә алсам иншалла, аны мөэмин-мөселман итәрмен һәм ул изге дингә кучүгә, калаларыбызны яулаудан баш тартыр».

Мелла Хакимҗан тынып калган иде. Ул бик озак дәшми торды. Нидер уйлады бугай. Ахыр: «Бүген һәммәгез, һәр гаилә үзегезгә чатыр корыгыз, иртәгә язганы булыр, оланнар. Иртәгә безнең тарафка Сүбәдәй баһадир улганы Күлкән килә, диделәр. Мин аңа ияреп китәргә тырышырмын».

Кичәге бу сөйләшү хан оныгы Хансөяр өчен бик күптән булган хәл кебек тоелды. Ул берәүгә дә дәшмәде, берәүгә дә күтәрелеп карамады, кичә төн уздырган чатырына таба атлады. Чатырга килеп керүгә, аның күңелен үткән төндә булган мизгелләр биләп алды. Чатырны корып, урын җәйгәч, Сөмбел аның кочагына кереп эреде. Мизгел эчендә бер җан, бер тәнгә әверелделәр. Сөю вә сөешү, назлау һәм иркәләү шул чиккә җитте ки, хан оныгы Хансөяр эченнән генә мелла Хакимҗанга рәхмәт әйтте. Ярый әле адәми затларга сөюгә вә сөешүгә чик-чама куймаган, юкса үз бәндәләрен иң кәттә бәхеттән мәхрүм иткән булыр иде. Ул Сөмбелен шул чикләргә җитеп сөйде вә назлады ки,хәтта җан-гайрәт тавышлары чыгарды. Әле ул үзен Мәҗнүн белән тиңләде, әле Сөмбеле өчен татлы сүзләр тезеп, былбыл булып сайрады. Сөмбеленә карата гыйшык дәрте шул хәтле көч-гайрәткә ия иде ки, гакылын югалтыр дәрәҗәгә җиткән чаклары булды. Аның һәр теләгенә җылы вә талгын дулкын булып ишелеп килгән зифа сын, йомшак назга сусаган тән, күперенке янбашлар, сыгылмалы бил җанын эретте, рәхәти тылсым кочагына ташлады. Шул кайнар тән, зифа сын, нечкә билме ил-халкы өчен үз-үзен корбан итәргә әзер?! Юк, ул андый түгел, түгел! Сөмбел аныкы. Аллаһы тәгалә тарафыннан аңа язган, фәрештәләр китергән бердәнбере, тиңе. Бу төндә хан оныгы Хансөяр ялкынлап янды, көйде вә көйрәде, гаҗизләнде, нәүмизләнде, мәхәббәт дәрьясына кереп чумды, бал күлендә йөзде. Һәм бертуктаусыз тәкърарлады: син чәчәктер, син сайрар былбылдыр, син алиһәдер, син җанымдыр...

## 18

Иртән ул бик иртә уянды. Хакимҗан мелла аякта иде инде. Ул инде намазын укыган һәм баскан да бар юрталардан да күркәмрәк булып күтәрелгән, түбәсендә ак кояш төшерелгән әләмгә карап тора. Хан оныгы Хансөяр аның янына килде.

— Син мине кичер, углан,— диде мелла Хакимҗан аңа карамый гына.— Кичер меллаң, үртәлмә вә үпкәләмә.

— Күлкән углан Сөмбелне көчләп үзенеке итсә, мелла?

— Углан Хансөяр, Сөмбелнең билендә хәнҗәр, ике агулы ук, муенча бөтиендә әҗәл агуы бар. Ул үзен рәнҗетергә дә, мыскыл итәргә дә ирек бирмәс.

— Ул аны үлтерергә тиешме?

— Юк, углан, ул аны үлтермәс. Ул аны Саксинга кермәскә үгетләр. Сөмбел бүген минем артымнан кеше җибәрергә тиеш. Мин калырмын. Ә сезнең китүегез хәерлерәк булыр. Ике корбан җитеп торыр. Булган товарларыгызны сатыгыз да китеп барыгыз. Сезгә калага кайтырга кирәк,— диде мелла Хакимҗан.

Шунда алар янына ике җайдакның чаптырып килүе күренде. Килеп җитүгә, аларның берсе:

— Мелла Хакимҗан сезме? — дип сорады.

— Сезне углан Күлкән дәшә. Атланыгыз атка.— Яугир аңа җайдак атын бирде. Хакимҗан баш иеп хан оныгы Хансөяр белән саубуллашты.

Мелла Хакимҗан атка атланды, артына әйләнеп карамый алдан киткән кишектингә иярде. Ыстанга җитәрәк, кишектин аңа:

— Мелла, туры Сүбәдәй баһадир юртасына! — дип боерды.

Нык саклыйлар иде баһадирны, өч бож̧ра аша узды Хакимҗан, өчесендә дә аны атыннан төшерделәр, коралларын карадылар. Мелла аларга телен чыгарып күрсәтте. Янәсе, менә минем коралым. Кишектиннәр һични аңламый бер-берсенә караштылар, ахыр кул селкеп, җибәрә тордылар.

Аттан төшкәч, Сүбәдәй катына җиткәнче аңа тагын ике җирдә тукталырга туры килде. Бу юлы аны капшап ук тикшерделәр, әмма хәнҗәр-корал түгел, чәч пәкесе дә тапмадылар. Ниһаять, юртага җиттеләр. Юрта ап-ак киездән корылган иде. Зур, биек һәм мәһабәт. Мелла Хакимҗан сакчы ачкан япмага таба атлады һәм гөрур төстә, башын чөя төшеп, мәгәр бусага-тупса аша зур атлап юртага килеп керде. Сүбәдәйнең сул кулында Сөмбел, уң кулында угланы Күлкән утыра, алар тирәли куштаннары, төмәнбашлар булса кирәк. Мелла Хакимҗан Сөмбелгә хәтта күз сирпеп тә карамады, туры Сүбәдәй каршына үтте, туктады, исән калган сыңар күзенә төбәлде. Чамалый иде мелла, ул биредә миһман түгел, корыч баһадир аны колач җәеп каршы алмас, шулай да күңеленә ачкыч табармын дигән өмет белән килүе иде. Бәхәссез, әүвәл Сүбәдәй Сөмбел белән кызыксыныр, аннары нинди дингә табынуын сорар. Болай гына, сүз юктан сүз табып, чөнки мелланың кем икәне корыч баһадирга күптән билгеле булса кирәктер — башындагы чалмасы ук әйтеп тора, нәсарә дине моңа ят. Меллага баһадир «Яса»га табына, диделәр., «Яса» — канун ич, «Яса» дин түгел. Мелла Хакимҗан иманы исә Коръән-Кәрим шартнамәседер. Аңлата алырмы сыңар күзен кызыл чүпрәк белән бәйләгән корыч баһадирга Хакимҗан — аның өчен сер иде. Шулай да ул өметен өзмәде. Иң әүвәл: «Ля Илаһә иллал-лаһ!» — дип авыз эченнән кабатлый-кабатлый, баш иде, аннары: «Мөхәммәдәр рәсүлуллаһ», дия-дия, Сүбәдәйнең аягына төште. Тик ул күңеленнән һич тә Сүбәдәй аягына төшмәде, ә Рәсүленә ялварды, аның хозурына баш иде.

Бары тик шул хәрәкәтеннән соң гына кояш нурыдай балкып утырган гүзәл Сөмбелгә карап алды, Күлкәнне күздән кичерде.

— Утыр, мелла,— диде Сүбәдәй тәкәббер генә, камчы сабы белән буш мендәргә ишарәләде.— Утыр, сиңа минем сүзем бар...

Сүбәдәй баһадир, Чыңгыз хан кебек, сәүдәгәрләргә һәм имам-муллаларга тимәде, аларны рәнҗетергә кушмады. Яугир егетләре бу хакта беләләр. Сүбәдәй баһадир ислам дине белән үзе дә кызыксына иде. Әнә шул ислам дине дәүләт нигезендә яткан Болгарны өченче тапкыр яуларга килә бит инде, тик әллә нигә теше үтми. Бәлкем, аңа менә шул мелладан башларгадыр? Кешенең җаны-тәне үзендә булса да, уе-хисе вә аң-акылы менә шушындый меллалар кулында ич. Ахирәт көнендәге җәза вә оҗмах белән куркытып һәм кызыксындырып, дөньялыктагы җисми хәлләрдән, матди тормыштан рәхәт эзләмәскә, күп нәрсәдән баш тартырга кушалар

имам хәзрәтләре. Бу хәл белән килешер дә иде баһадир Сүбәдәй, ул укый-яза белми, нотык-вәгазьләрне бары тик поп вә муллалардан гына ишеткәне бар. Аллаһы тәгаләнең берлеге һәм башка жан ияләренә охшамаган булуы турындагы имам-муллалар, поп-дъялар җырына бик үк ышанасы килми. Алай да аларны тыңламыйча да калмый иде. Әйдә, сөйләсеннәр, аларның үз кыйбласы, минем үз кыйблам, дип уйлый иде. Монда сәеррәк бер хәл булды, кичә аңа күзе-башы тонып угланы Күлкән килеп керде. Имеш, ниндидер сәүдәгәрләрдән гүзәл кыз сатып алган. Угланы Күлкән юртасына килеп кергәч үк, төшенде Сүбәдәй, углан ихластан гашыйк, сатып алган кызына гашыйк, чөнки шатлыгы эченә генә сыймый, йөзенә ташып чыккан иде, әйтерсең лә өлгереп житкән кымыз.

«Нә булды, углан?» — дип сорады Сүбәдәй.

«Атам, мин үземә бик тә гүзәл-сылу кәләш сатып алдым».

«Кәләшне сатып алмыйлар, кәләшкә өйләнәләр, углан»,— дигән булды Сүбәдәй, гамьсез калырга тырышып. Ул угланны ачулана ала иде. Аңа угланның: «...кәләш сатып алдым» сүзе ошамады. Әйе, кайчан магулның кәләш сатып алганы бар? Булмады ул хәл. Нә Чыңгыз чорында, нә хәзер. Кирәк дип тапканда хатын-кызны төркем-төркем Каракорымга кудырды. Кагыйдә-канун буенча һәр яугир ике-өч хатын-кызны әсир итә ала. Иллә Сүбәдәй баһадир үз яугирләренә үзләре белән хатын-кыз йөртергә рөхсәт итмәде. Шуңа күрә булса кирәк, угланның гүзәл кызны юртасына алып килүеннән дә бик үк канәгать түгел иде. Шунда Күлкән углан атасы каршына тезләнде, маңгаен аның итек башына орды. Угланның бу хәлгә житеп кылануы Сүбәдәйнең күңелен йомшартты, ул аны күтәреп алды, утырырга урын күрсәтте.

— Йә-йә, кирәкмәс алай, егет бул. Өйләнергә теләгенме әллә?

Күлкән кызарынып чыкты, башын түбән иде. Сүбәдәйнең хәтер кәтүге сүтелеп китте. Күп еллар элек ул үзе шушы якларда шашыр дәрәжәгә житеп бер асрауны яраткан иде — Карлыгачны. Ул хатын аңа малай табып бирде. Тик бәхет кошын бик тиз югалтты Сүбәдәй: болгарлар белән орышта жиңелеп, качарга мәжбүр булды, ә угланы белән хатынын әсир иттеләр. Бу хәлне Сүбәдәйнең гомер бакыена онытасы юк.

— Сәнең бу эшең миңа ошамый, углан. Ләкин мин сиңа...

— Ул бик тә сылу, мин аңа гашыйк булдым, атам, гашыйк булдым. Мин аны яраттым, атам,— дип Күлкән яшьле күзләре белән атасының күзләренә карады.

— Күрәм, чибәр,— диде Сүбәдәй, Сөмбел ягына күз ташлап, сүлпән генә.— Атаң сукыр түгел.

«Сукырсың, сукырсың,— диясе килде угланның.— Сукырсың, күрмисең. Күрсәң, шундук рөхсәт итәр идең»,— дип эчтән өзгәләнде Күлкән углан.

— Иртәгә яу кузгалабыз. Бачман баһадир тешле булды, бер селтәнүдә генә селкеп ташларлык түгел үзен. Әллә ниткән туплардан атып, иң көттә мәргәннәремне кырды. Һөжүм сүрелде, яудагы гадәти тәртип бозылды... Яуны туктатып торырга мәжбүр булдым. Шундый бер вакытта синдә кыз кайгысы, углан.— Сүбәдәй күз тасмасын төзәтеп куйды, янә мелла белән Сөмбелгә күз төшереп алды.— Ярый, тик озын-озакка сузма.

— Синең фатихаң кирәк, атакай...

— Туктале, олан. Кыз мөселман бугай бит? — Сөмбел урынына мелла Хакимжан: «Мөселман, мөселман, баһадир», дип еш-еш ияк какты.— Мелла, син нә әйтерсең? Мөселманнар кияүләп йөриләр түгелме соң?

— Йөриләр, йөриләр, баһадир,— диде янә ашыгыбрак мелла.

— Аннары никах укыйлар. Әүвәл ата-аналарыннан рөхсәт алалар бугай әле.

— Алалар, алалар, баһадир,— дип тәкърарлап, баһадирның сүзләрен куәтләп торды мелла Хакимжан.— Барысы да Хак Тәгалә кулында, баһадир.

— Менә миһман мелла да минем сүзне раслый, углан,— дип Сүбәдәй һаман нидер әйтергә теләп, шуны суза килә иде.

Мелла Хакимҗан кыюлана төште. Ул бит Сүбәдәйне явыз, кырыс, чын мәгънәсендә зобани дип белә иде. Бит, тикмәгә генә корыч баһадир атын бирмәгәннәрдер үзенә, ә монда исә барысының да хәленә кермәкче, житмәсә мелла Хакимҗан белән киңәшә. Шуннан соң мелла Хакимҗан кесәсеннән дисбесен чыгарды, тарта башлады, тәмам тынычланды.

— Баһадир, яшермим, сәнең хакта бик күп яман сүзләр ишеттек, илләә ялгышканбыз икән. Инандык: рәхмәтле, киң күңелле кеше икәнсең. Безнең Рәсүлебез Хак Тәгаләне адәм баласыннан яшереп булмый, дигән, чөнки аның рәхмәте үзендә, дигән. Тәңремез хакына кичер мине һәм ошбу балаларны. Мин аларга....

Сүбәдәй аягүрә торып басты, юртаны бер итеп, арлы-бирле йөрергә тотынды.

— Рәхмәт, Тәңребезне олыладың, мелла.

— Ля Илаһә илләл-лаһ рәсүллуллаһы мөхәммәд! — диде мелла Сүбәдәйнең салпы ягына салам кыстырырга теләп.

— Мин Тәңрегә генә табынам, мелла.

— Без дә, без дә, баһадир,— диде ашыгыбрак мелла Хакимҗан.— Безнең борынгы бабаларыбыз Тәңрегә табынган, Болгар төркиләре өчен Тәңре шул ук Аллаһы тәгаләдер, баһадир.

— Тәңре дә күктә, Алла да күктә, шулаймы, мелла?

— Күктә-күктә, баһадир, Аллаһысы да күктә, Тәңресе дә. Алар икесе бер ләбаса.

— Инде әйт, мелла, атың Хакимҗан диден бугай, әйт: нишлибез бу балалар белән?

— Баһадир Рәсүлебездә бер кол булган, атасы килгән дә Рәсүлемездән угланын сатып алмакчы иткән. Рәсүлемез аңа әйткән: бернинди дә акча кирәкми, угланның үз иркендә, тели китә, тели кала, мөселман динен кабул иткәннәр коллыктан азат ителәләр, дигән.

— Шуннан ни, мелла?

— Шуннан, баһадир, углан кол Рәсүлебездә калган, атасы белән китмәгән.

— Сатып алган малдан, сине ничек чаласы, дип сорамыйлар, мелла. Кол ул хайванга тиңдер.

— Сөмбел атлы бала — мөселмандыр, баһадир. Үзе хәтле алтын түләсәң дә, Аллаһы тәгалә аны кол итәргә бирмәс, иншалла. Ислам дине адәм баласын кол итеп сатуны катгый рәвештә тыя, баһадир. Саткан кеше ахирәткә кадәр тамугта янар, ди.

Сүбәдәй баһадир түр яктагы мендәренә барып утырды, сирәк сакаллы ияген учлап тотты, аннары артына әйләнеп карамый гына:

— Төптәңрем, чык әле бире,— диде.

Өстенә кат-кат чүпрәк каплаган, түшенә ялтырап торган бака кабырчыклары, җиз калкан таккан, табак битле, шәп-шәрә башлы төптәңре чыкты. Кыяфәте котың алырлык иде. Сүбәдәй баһадир аңа янәшәсеннән урын күрсәтте.

— Төптәңре, син миңа, болгарлар Тәңремездән ваз кичкәннәр, ислам диненә дүнгәннәр, Тәңремезне Алла итеп, Мөхәммәдне аның илчесе итеп кабул иткәннәр, дип сөйләгән идең. Шулаймы?

— Шулай, баһадир Сүбәдәй.

— Ә менә мелла Хакимҗан, сүз саен Тәңрене телгә ала. Бит Аллаһысы да, Тәңресе дә кеше күзенә күренмиләр...

— Күренмиләр, баһадирым.

«Авыртмаган башка тимер таяк булды бу төптәңресе,— дип уйлады мелла Хакимҗан һәм пыштын гына Сөмбелгә: — Угланны алып кит!» — диде.

— Атам,— диде тора-тора Күлкән углан.— Без китик инде.

Сүбәдәй баһадир угланына һәм кызга янә күз төшереп алды.

— Меңбашларны жый, углан, иртәгә яу чыгабыз.
— Ә-ә,— диде Күлкән Сөмбел тарафына ымлап.
— Кыз мондә калыр. Син миңа болгарлар кулындагы һич югы бер тупны алып кайт.
— Тупчылар ирсаны безнең кулда бит инде, атакай.
— Миңа тупчылар ирсаны түгел, туп үзе кирәк. Мин аны Чин белгечләренә җибәрәм. Бар! — диде Сүбәдәй коры гына.
Күлкән чыгып китте. Баһадир бертын кыз белән меллага карап утырды, ул сыңар күзе белән, әйтерсең, икесен тиң бораулый иде. Шуннан соң гына бавырчысына:
— Боларны әйбәтләп ашат. Табынны монда хәстәрлә,— диде.
Уртага ашъяулык җәйделәр, табынга түтәрәме белән ит куйдылар, куй ите, исе борынга килеп бәрелүгә, мелла Хакимҗан бисмилласын әйтә башлады.
— Кул чайкыйсы иде бит, баһадир,— диде мелла Хакимҗан.
Бохара, Үргәнеч, Сәмәрканд руханилары белән күп тапкырлар бер табында утырган Сүбәдәй каршы килмәде, бавырчысына җиз таз белән комган китерергә кушты. Мелла Хакимҗан бавырчы койган суда җиңен беләгенә кадәр сызганып, үзенә күрә битен юды, колак артларыннан бармаклары белән үткәреп, сөлгегә үрелде. Сөмбел дә кулларын юды. Боларның барысына да Сүбәдәй дикъкать белән карап торды. Әмма баһадир да, төптәңре дә кулларын да юмадылар, бисмилла да әйтмәделәр, Сүбәдәй түтәрәме белән ит кисәген алды да кимерә башлады.
— Әйт әле, мелла,— диде ул итне чәйни-чәйни,— нигә син аш алдыннан авызың чайкап, кулларың юдың?
— Авызыма иблис-шайтан кермәсен дип, баһадир.
— Һэ, мелла, шайтан синең кулыңда утырамыни? Синең ачык авызыңа керәсе итсә, көнозынга җаен тапкан булыр иде. Мин менә ун елдан артты инде каз каны эчәм. Шөкер итәм Тәңремә, тешләрем дә исән, кынам да коелмады.
— Мөселманга кан эчү хәрамдыр, баһадир.
— Мөселманга хәрам икән эчмәсен, мелла. Әмма миңа эчәргә ярыйдыр.
— Һәр кешенең үз ихтыяры, баһадир. Бисмилла әйтсәң, ризыгыңнан канәгать калсаң, эчә бир. Тик Аллаһы тәгалә генә кабул кылсын.
Майлы бармакларын чупыл-чупыл суыра-суыра Сүбәдәй баһадир ит ашады, итне бер дә симез дип тормады. Мелла исә ит кисәкләрен сайлап кына капты, аны да алга куйган кымыз белән озаткалады.
— Аллаһың кабул итмәсә, бу ит кая китә соң, мелла?
— Шайтан шайтанны чакырыр, ди, баһадир. Үләт чире килгәч, беренче булып кяферләр кырылдылар. Ә кул-авызын чайкарга гадәтләнгән безнең халык калды, бик азлары гына вафат булды.
— Хак, булды андый хәл,— диде әлегә кадәр бары тик ашап кына утырган төптәңре.— Аштан җирәнмәсәң, берни дә булмый, инде җирәнәсең икән — хәрам.
— Рәсүлемез кул юмыйча, авызың чайкамыйча табынга утыруны бер дә хупламаган, баһадир. Кул юмыйча, авызын чайкамыйча табынга утырган кешенең ашаган ризыгын шайтан йотып торыр, дигән.
— Шайтан йотып торгач, мин ничек туям соң, мелла?
— Димәк, тәнеңә файдага китми, баһадир. Аллаһы тәгалә барысын да күреп тора.
— Рәсүлеңез дәме? Ул да күзәтәме мине? — диде Сүбәдәй кымыз чүмерә-чүмерә.— Сезнең Рәсүлеңез, мелла, Мөхәммәд булса, безнеке Чыңгыз хандыр. Ул миңа «Яса» калдырды. Һәм мин шул «Яса»га үлгәнче тугры калырмын.
— Мелла Хакимҗан,— диде сирәк-мирәк кенә табактагы иткә үрелгәләп утырган Сөмбел.— Кирәкми, баһадир белән бәхәсләшмә. Монда сиңа хан табыны түгел.

Шунда гына Сүбәдәй баһадир Сөмбелгә игътибар итте.

— Нигә гүзәлебез ашамый утыра?

— Ашый-ашый, баһадир, ятсына төшәдер. Мөселман хатын-кызына ир-ат алдында авыз күтәреп ашау...— дигән иде мелла Хакимҗан, кисәк кайда утыруын абайлап алды.— Җитешеп утыр, бала, җитешеп утыр,— дип Сөмбелне кыстый башлады.

— Һы,— диде Сүбәдәй гаҗәпләнүен яшермичә.— Ашамаса, мин аны бавырчыма сыгындырырга кушам.

— Аллам сакласын, баһадир. Ашый ул. Карале, балам, җитешеп утыр, тартынма. Бисмиллаһ әйт тә алдыңа килгәнне аша.

Мелла Хакимҗанны әллә ишетте Сөмбел, әллә юк, ул тыенкысалмак кына капкалап утырды, касәдән шулпа эчте.

— Мелла Хакимҗан, миңа, ошбу бала белән икеңезгә бер юрта куйдыртам. Тәңремез язган итсә, иртәгә без каланы алырбыз, Бачман баһадирны каладан куарбыз. Кала түрәсе Бачманны мин алдыма тез чүктерермен. Кала миңа ошады, җиде юл чатында. Кай тарафка гына юл тотмасын, һәммә кәрван Саксинны урап уза алмый. Мәрхүм атамыз Чыңгыз хан Бохара рухание Галәветдинне ил башында калдырды. Минем кодрәтем яклап, Аллаңа ялварсаң, мин сине кала имамы итәрмен. Әлбәттә, сиңа күз-колак булырга мин гаскәремнең бер өлешен дә калдырырмын. Җәбәй нойон ошбу Болгардан баш тартты. Бер җиңелгән илгә яңадан аяк басмам, дип ант иткән, имеш. Олуг ханыбыз Үгәдәй мәрхүм атамыз Чыңгыз хакына аңа шактый җир-җәйләү бүлеп бирде. Мин исә, Чыңгыз хан васыятен үтәү нияте белән, Җүси углан җирләрен киңәйтергә дип килдем. Ошбу бай вә сәйран җирләрне яулау мәнем төп максатымдыр. Тиздән Җүси хан угланнары үсеп җитәр, мин алар белән ары таба китәрмен, Чыңгыз хан васыятен үтәрмен. Хөрмәткә лаек Чыңгыз хан, хатын-кыз коткасына ышанып, үз угланына кул салдырды. Ханның ата вә угланны үзара вәсвәсәгә калдыручы яшь хатыны Хулан булды. Бинахакка үтерелүен белгәч, Чыңгыз хан ул хатынын ил-җиреннән куып җибәрде. Мән ул юлдан бармам, мелла. Бирегә мин Күлкән угланым белән килдем. Аның башы яшь әле, минем аңа тиз генә орчык башын бирәсем килми. Мин өмет итәм, Күлкән угланга да өлеш чыгар. Син, мелла Хакимҗан, угланымны тугры юлга салырга ярдәм итсәң иде миңа.

Илаһи озын нотыкны тыңлау мелла Хакимҗанга авыр булса да, ул урыныннан купты һәм маңгаен бәрә-бәрә Сүбәдәй баһадирга рәхмәт укыды. Бу аның ризалыгы иде. Карышу, шиккә калу бөтен эшнең җеп очын гына җуеп куюу бар иде.

— Йә-йә, тор, мелла. Мән сиңа ышанам. Руханилар нинди дингә генә инанмасыннар, атамыз Чыңгыз хан теләген кабул иттеләр. Шуның өчен ул аларга тияргә кушмады. Төптәңрем, озат мелла белән кыз баланы яңа юртага. Сак куйсыннар. Яудан соң хәл итәрбез.

Юлбасар да, юлбуар да, сарбаз да түгел икән бит бу Сүбәдәй. Барымта йөрүчегә дә охшамаган. Яу килеп, максаты халыкны талап китү генә түгел, ил-җәйләүләргә ия булу теләге белән яна. Кинәт кенә куркыныч булып китте мелла Хакимҗанга. Ул Сөмбелне җитәкләде дә, берсүз әйтми, юртадан тизрәк ычкыну ягын карады. Ишеткәнен-ишетте, әйтәсен-әйтте бугай инде...

## 19

Бары тик өченче көн дигәндә генә Артыкны Сүбәдәй баһадирга алып килделәр. Тәләкәсен алдылар, кул-аягын да бәйләделәр.

Билгә таккан тәләкә, тышаудан да яман нәрсә, атларга да бирми иде. Менә язмыш диген син аны, кай тарафларга килтереп орды. Нә чара кыла ала соң ул хәзер? Аны уннан артык кишектин саклый. Качу турында

уйлама да. Үз-үзенә дә кул сала алмый, кулында һич нәрсә юк. Төнлә дә, көндезен дә күзәтү астында.

Сүбәдәй баһадир аны нәкъ, тәүге көнгәчә, түр якта күн мендәргә утырып каршы алды. Баһадирның юртасын йөзләрчә кишектин саклый, төнлә берәүләре, көндезен икенчеләре каравыл тора.

Артыкны ишек яры калдырдылар, озын ботларын чәнчеп утырган Сүбәдәй аңа бертын карап торды.

— Тупчы,— диде ул, ниһаять, тыныч кына.— Иртәгә мин каланы алырмын. Мәнем сәнең кем икәнеңне беләсем килә. Мәнем чирүемдә сәнең телдә сөйләшүчеләр бик күп. Меңбашлар да, йөзбашлар да. Ышанычлы, батыр кавем. Һәм Тәңрегә табыналар. Олуг хан Чыңгызның анасы да татар иде, үзе дә туталы-сеңелле татар кызларына өйләнде. Алар аңа җиде углан табып бирделәр. Барысы да үстеләр, батырлар, меңбашлар. Иллә хан булырга хаклары юк. Олуг хатыны Чыңгызга дүрт углан калдырды, әнә шуларның берсе бүген Каракорымда утыра.

— Аллаһы тәгалә барысын да күреп, барлап тора, баһадир. Үгәдәй хан турында мин дә хәбәрдар.

— Якшы, тупчы. Инде ары таба тыңла. Чыңгыз хан тангутларның пайтәхетләрен алган елны Сарысу елгасыннан ерак түгел җәйләүдә алтмыш биш яшендә вафат булды. Аны без туган җиренә, Өнән елгасы буена алып кайтып җирләдек. Әле булса хәтеремдә, Чыңгыз хан бик каты авырып киткәч, үз куштаннарын, баһадирларын, угланнарын юртасына дәште. Мин бахырыңыз да шунда идем. Ул авырлык белән булса да әйтте: «И-и сез, мәнем аркамдагы кабыргаларым кебек туганнарым, балаларым! Ишетеңез! Мин бүген шул дәрәҗәгә җитеп җәфаланам ки, үземнең олуг халкымны җыю турында никадәр җәфаланган булсам, шулай җәфаланамдыр. Мин халкым өчен тырыштым, шулкадәр тырыштым ки, өзәңге бауларым чыдамый өзелер иде, тимер каптырмалары сынар иде. Ләкин миңа бүгенге кебек кыен булмады. Халкымны җыяр вә туплар өчен капчыгыма кәҗә бәрәненең итен тагып чаба идем: ачыга, яна, сусый идем, ләкин бу кадәр кыен булмас иде. Адәм баласы гына түгел, яшен ташлары да ватыла, корыч та шартлап сына. Мин дә үләрем, безнең тәнебездә җаныбыз мәңгегә кала алмый...» — диде. Ханыбыз безгә мәмләкәтне ничек сакларга, аның күрсәткән юлыннан ничек чыкмаска, яулаган халыклар белән ничек идарә итәргә васыятьнамә әйтте. Без беразга тынып тордык. Авыр иде аңа. Шуннан баһадир Галәүтәй әйтте, «Һай син, безнең җаныбыз булган хан! Әлек очып барган карчыганың канатына утырган кеби йөри идең, инде шыгырдап барган арбага йөк булдың. Безне ятим калдырдың. Синең туган илең, сөекле халкың монда түгел, син хан булганчы ук хатының булган Бүртә дә, көй чыгаручыларың да, җырчыларың да, алтын тәхетең дә — барысы да монда түгел, сине без туган илеңә, гаделәтне дөньяга чыгарган җиреңә алып кайтабыз. Сиңа карап елълашабыз...» Ханым кебек, мин дә илемә китәрмен, тупчы. Мин монда угланым калдырырмын. Минем аны ышанычлы кешеләр кулына биреп калдырасым килә...

Ни дия ала ул? Артык беркайчан да телгә оста булмады, аңа мондый нотыкларны да тыңларга туры килмәгәндер, мөгаен. Ул сугышчы иде. Орышларда ул үз-үзен кызганмады, иң алдан кузгалды, һәрчак орыш күзендә булды, ә менә сүзгә саран булды. Әйе, нә әйтергә тиеш ул аңа? Баһадир дисә, күзе акаер, ат коерыгына тактырыр. Артык бераз уйланып утырды, әмма башына бер генә җай фикер дә килмәде. Һәй, булса икән аның урынында мелла Хакимҗан, йә булмаса хан оныгы Хансөяр, алар табарлар иде ни әйтергә сиңа, Сүбәдәй.

— Йә-йә, тупчы, мин җавап көтәм.

— Мин сугышчы, баһадир.— Артык башын күтәрде, туры Сүбәдәйнең күзенә карады.— Сугышчы, гадәттә, әмер көтә. Синең болгарлар белән беренче орышуың гына түгел, беләсеңдер.

— Мин ул чакта нә Җигүлеат таулар төбәгендә, нә Җаек буенда болгарларда туплар күрмәгән идем, тупчы.

— Туплар элек тә бар иде Болгарда, баһадир. Тик аларны кирмәнкальгаларга гына куялар иде. Хәзер әнә атларга куярга җайладылар.

— Ярый, тупчы. Нәмәгә син Болгардан ала Саксин каласын сакларга килдең?

— Саксин Болгарныкы, баһадир. Минс исә олуг хан җибәрде. Мин азат, ә хан әмере азат өчен аткан укка тиңдер, баһадир.

— Ул тупларны син ясый алыр идеңме?

— Юк, баһадир, тупларны осталар ясый. Мин тупчы гына идем.

«Минем баһадир икәнемне белми, белепме юри сораша?» — дип уйлады Артык, оеган аякларын кузгаткалап алды.

— Сиңа хан күпме түли, тупчы?

— Җитәрлек, баһадир, зарланасым килми.

— Мин сиңа ике тапкыр артык түләсәм, риза булыр идеңме?

— Туган илгә, Ватанга хыянәт итү — иманнан язу белән бердер, баһадир. Моңа синең гаскәриләрең дә бармас иде.

— Сәнең башы киселгән адәм гәүдәсенең уннан артык адым йөгереп барганын күргәнең бармы, тупчы?

— Бар, баһадир. Мин бик күп орышларда катнаштым. Без, гадәттә, күрше урыслар белән сугыша идек, хәзер әнә сезгә тап булдык. Адәм баласында дошманга карата нәфрәт хисе ташканда, башның гәүдәдән аерылып китүе дә ихтимал.

— Ә синең башың әлегә үз җилкәңдә, тупчы.

— Барысы да Аллаһы тәгалә кулында, баһадир. Без сезгә, сезнең җәйләүләргә яу йөрмәдек, сез килдегез безнең илемезгә. Ил-ватан өчен баш бирү мөселман кешесе өчен олуг дәрәҗәдер. Чөнки орыш кырында туган илне яклап һәлак булган кешенең урыны оҗмахтыр.

— Меңбаш Котбыйны дәш! — диде ишек яры торган кишектиненә Сүбәдәй.

Котбый меңбаш керде, бер тезенә төште.

— Утыр, меңбаш Котбый. Утыр, утыр. Инде баһадирың тыңла, меңбаш. Сән имам булган кеше, Котбый. Шулаймы?

— Имам түгел, баһадир, мелла булып йөрдем.

— Якшы, Котбый меңбаш, әйт әле миңа, орыш кырында ил-ватан өчен шәһид булган яугирнең җаны чынлап та туры оҗмахка керәме?

— Изге орышта шәһид булса, керә, баһадирым. Ислам динендә төрле мәзһапләрне, каләм шәрифне һәм шәригать кануннарын өйрәнү вә яттан белү заруридыр, баһадир. Һәр мөселман белемгә омтылырга, гафил булмаска тиеш. Мөселманның көнеле хөр, тамагы тук булсын өчен ул тырышып эшләргә, Аллаһы тәгаләгә рәхмәтле булырга тиеш. Илгә золым-богау китерүчеләрне ислам диненә иман иткән мөселманнар яратмыйлар, гавәм хөрлеген яулаучыларга ләгънәт укыйлар. Мөслим кеше һәрчак мәдәнилеккә, азатлыкка омтылырга тиеш. Изге китабымыз Коръән-шәрифтә, һәр адәм үз туган җирендә, үз утарында көн күргәндә генә рәхмәтле булыр, диелгән. Аллаһы тәгалә һәр халыкка да бертигез итеп өлеш чыгарган, ләкин яманлык аларны бер-берсенә яу йөрергә котырта, изге китап исә яманлык кылган адәмгә яманлыгы үз утарына, үз иленә, хәтта үз гаиләсенә кайтыр, дип әйтеп әйтә. Аллаһы тәгалә, ошбу дөньялыкта мөселманнарны рәнҗеткән адәмнәргә рәнҗү китермәсә, моның өчен аларның оныклары утта янарлар, ди. Хактыр, ислам динендәге кайбер руханилар шәригать кануннарын бозалар һәм шуның өчен дөньялыкта ук Аллаһы тәгалә каһәренә юлыгалар...

— Җитеп торыр, җитеп торыр, меңбаш Котбый. Күрәм, син олуг имамнарны да уздырасың. Беләм, син бик якшы мөгаллим. Әйе, бән начар шәкерт. Ярты сүзең аңлап бетермәсәм дә, кайберләренә төшендем: изгелек җирдә ятмаган кебек, кылган яманлык та сине куа йөрер икән. Тик җир йөзен ертып, анда икмәк чәчү, Тәңре яраткан хайван-җәнлекләр-

не ризыктан мәхрүм итү, суда йөзгән бер гөнаһсыз балыкны тотып ашау — изгелекме, меңбаш?

— Җир йөзендәге хәрам булмаган һәр хайван Мөхәммәд пәйгамбәр Аллаһы тәгаләдән сорап безгә тапшырган ризыктыр, баһадир.

— Бар кит, меңбаш,— Котбый чыгып китте, Сүбәдәй Артыкка таба борылды.— Орыш кырында әмәл-чарасыз калган чаклар була, тупчы. Берәүләр кала күтәрә, икенчеләре җимерә. Сез күтәрүчеләр, без җимерүчеләр. Без Тәңре яраткан һәммә нәрсәне җанлысын да, җансызын да үз хәленә кайтарып йөрибез. Адәм баласы бүре түгел, артыгын ашый алмый. Кыр-далалар, урман-сулар тереклек белән тулар, менә шунда оҗмах килер, тупчы. Мине синең теге дөньядагы оҗмахың аз кызыксындыра, тупчы. Кеше ошбу дөньяда бәхетле булырга тиеш.

Күр әле нинди фәйләсуф икән бу Сүбәдәй. Карлыгач тикмәгә генә яратмаган икән үзен, гәрчә очар казны тотып чалып, канын эчсә дә. Җәнлекләргә, хайваннарга җәйләүләр яулап йөри, ә үзе күзен дә йоммый адәм баласын урталай яра.

— Тупчы кымыз бирең,— диде Сүбәдәй, аннары тагын: — Минем, тупчы, һәр халыкның телен өйрәнәсем килә. Котбый минем өченче мөгаллимем инде. Башта ул да кулына кылыч тотарга кыймый йөргән иде, хәзер әнә меңбаш. Чыңгыз атамыз әйтә торган иде: бәхет ул яулаган халыкның хатыннары өстендә тәгәрәп йөрү, дип. Хатын-кыз мәсьәләсендә атамыз ялгыша иде, хатын ишәйтүдән бәхет тапмады ул. Бәхетне мин дошманны алдыма тезләндерүдә күрәм. Мин синең өчен юл өстенә төшкән күләгә түгел, илең өстенә килгән яңдер. Саксин каласын мин алырым. Кирәк дип табам икән, сине алгы сафка меңбаш итеп бастырырмын. Син миңа, меңбаш, тупчы буларак кирәксең. Мин ул тупларны барыбер кулыма төшерермен. Кичә без сәүдәгәрләрне туктаттык. Үргәнечкә сәфәр тоталар икән, ә монда минем яугирләремә ярма-бал кирәк. Акчаны мул түлибез. Без, тупчы, буйсынган халыкларны рәнҗеттермибез һәм үзебез дә рәнҗетмибез.

«Сорарга иде үзеннән: сәүдәгәрләр кай тарафтан? Тик ярамас, эшне бозып куюым бар. Оланнар гына була күрмәсен. Йа Ходa, оланнар булып, Сүбәдәй аларны үз каршына дәштерсә, угланы Ташбай белән киленен күрсә?.. Ләхәүлә вәләкуәтә, сакла фәкыйрең яман эштән. Ә бит синең угланың, Сүбәдәй, шул сәүдәгәрләр арасында. Тик син бу хакта беркайчан да белмәссең. Һәрхәлдә, миннән»,— дип уйлады Артык, баһадирга туры карарга куркып, әйтерсең лә Сүбәдәй бу хакта аның күзеннән укып белергә мөмкин иде.

— Йә, тупчы, ризамы меңбашым булырга?

— Мин ханыма тугры хезмәт итәргә ант иттем, баһадир.

— Ант итү баш бирүме, тупчы? Син аңа тугры калырсың. Ул да үз урнында калыр, миңа аның безгә буйсынуы, ясак түләп торуы гына кирәк. Уннан бер өлеш табышын Каракорымга илтеп торса, аңа зыянзәүрәт килмәс. Инде орыша, карыша икән... Үзенә үпкәләр ханың, тупчы.

— Мин уйлап карармын, баһадир.

— Озын-озак уйлама, тиздән яу чыгасы, тупчы.— Сүбәдәй кишектиннәренә ишарә ясады: — Алып китегез әсирне! — диде.

## 20

Артык өчен бик авыр мәл килде. Тәнозын уйланып чыкты, күзенә йокы кермәде. Баһадир орышка хәзерләнә, үзебезнекеләргә житкерәсе иде — Бачман баһадирга, ә ул хибесханәдә утыра. Сүбәдәй сакчылары үзеннән күзләрен дә алмыйлар. Калада чакта оланнарның максаты белән бик үк кызыксынмады да, шуңа күрә аяк терәп каршы да тора алмады. Әгәр дә мәгәр ул күргән сәүдәгәрләр алар булсалар, димәк, оланнар ыстанга үтә алганнар. Ары таба нә кылмакчылар? Ул

күргән дөяләр аларныкымы? Инде аңа нишләргә? Бер тезенә төшеп, Котбый кардәше кебек, Сүбәдәй каршына тезләнсенме?! Бәхетне шуннан күрә ич баһадир — дошманны алдына түндерүдән. Йа Хода...

## 21

Уңай гына урнашкан иде Сөмбел мелла Хакимҗан белән, аның артыннан углан Күлкәннең җиде кишектине килде. Җидесе дә яңа мыек чыгара башлаганнар, җидесе дә Сөмбелне күзләре белән ашарга торалар.

— Туташ,— диде берсе юртага кереп.— Сезне углан көтә.

Сөмбел, рөхсәт сорагандай, мелла Хакимҗанга карады, теге түр якта китеп укып утыра иде, башын күтәреп әле ишек яры торган кишектингә, әле Сөмбелгә карап алды да ризалыгын белдереп, ияк какты. Ул аңа кичтән үк барысын да өйрәткән иде инде. Сөмбелне алып китүгә, эчтәге кишектин бер сүз әйтмәсә дә, мелла белән кызны сакларга куйган кишектиннәр кызны туктаттылар.

— Кем рөхсәте белән алып китәсез кызны? — дип, бер сакчы Күлкән углан кишектиненә аркылы төште.

— Углан кушты.

— Ә баһадир! Баһадирдан рөхсәт бармы? — дип кылычына ук ябышты кишектин. Мелла Хакимҗан да сикереп торды, кыз янына килде. Һәм Күлкән углан кишектиненә:

— Безне бирегә баһадир үзе урнаштырды,— диде.

Аяк астында уралма дипме, Күлкән кишектине аның күкрәгенә төртеп җибәрде, мелла мәтәлеп диярлек утырган җиренә барып төште.

Сөмбел бер сүз дә әйтмәде, аңлый иде — әйтергә хакы юк, аны сатып алдылар, гәрчә мөселман булса да, мәгәр янагандай итте:

— Никах укытмыйча мин углан каршына бармас идем, кишектин,— диде ул сабыр вә тыныч кына.— Моны кылырга минем иманым кушмый. Аннары углан башта атасыннан фатыйха алсын иде.

Кишектиннәр икесе тиң кызга карап каттылар, тәмам телсез калдылар бугай. Моңа кадәр кулга төшкән кыз карусыз барысын да үти иде, ә бу ниләр сөйли? Мелла Хакимҗан тагын алар янына килде, тик бу юлы аны үзен саклаган кишектин шундаен итеп төртеп җибәрде ки, теге мәтәлеп үк китте. Ул торганда, юртада Сөмбел юк иде инде. Хакимҗан ишеккә ташланды, әмма кишектин аңа камчы белән сыдырды.

— Сөмбел, Сөмбел, балакаем,— дия генә алды ул, шундук аяк астына сыгылып төште. Китеп барган Сөмбел мелланың ыңгырашкан тавышын гына ишетеп калды. Шул чакта, Сөмбел бәхетенәмедер, юртасыннан Сүбәдәй баһадир чыкты һәм Сөмбелне алып китеп барган кишектиннәрне күрде дә, атына сызгырды. Аты килеп туктауга, сикереп атланды һәм китеп баручылар артыннан чапты. Бик тиз куып җитте. Бер кишектингә камчысы белән сыдырды.

Кишектиннәр күз алдында кечерәеп калдылар, баһадирның ат аягына төштеләр.

— Кая алып барасыз кызны?

Бер кишектин башын күтәрде, Сүбәдәйгә карамый гына:

— Углан кушты, углан боерыгы,— диде.

— Углан,— диде Сүбәдәй, авыл-авыл булып туктаган ыстандагы юрталарга күз төшереп.— Алып китми торыгыз әле кызны. Минем юртага кертеп калдырыгыз.

— Баш өсте, баһадир.

Чаптырып килгән берәү күренде, Котбый меңбаш икән, ул килеп туктауга, Сүбәдәй:

— Меңбаш Котбый, кызны үз кишектиннәреңә тапшыр. Кара аны, күз карасыдай саклагыз. Кызны минем юртага, нәрсә карап каттыгыз! —

дип камчысын күтәрде баһадир кишектиннәргә.— Орыш алдында торабыз, ә аларда кыз кайгысы. Югалыгыз күземнән!

Угланның кишектиннәрен гүя җил алды. Сүбәдәй баһадир атыннан төште, сорнай гәүдәсен икегә сындырып, Сөмбелгә баш иде. Һәм туптуры күзенә карады. Сыңар күзе күкле-яшелле иде, карашы куркыныч. Бик күп орышларда катнашса да, Сүбәдәй үзенә тиң батыр күрмәде. Нә уктан алуда, нә сөңгедә кадашканда, нә кылыч белән алышканда Сүбәдәй барысыннан да өстен чыкты. Углан Күлкәнне дә ул үзе кебек бар яктан да беренче итәсе килгән иде, угланның сенере сыек булып чыкты. Күбрәк юртасында ятты, китап укыды, хәрби уеннардан баш тартырга җай гына эзләп торды. Башта Сүбәдәй угланның бу хәленә ачуланды, аннары тегене үгетләп карады, янәсе, оят түгелме сиңа, кем угланы бит син, әмма Күлкән атасын әллә тыңлады, әллә юк, бер дә үзгәрмәде. Моннан жиде-сигез ел элек бу тарафларга килеп, Сүбәдәй баһадир Олуг Мөхәммәд шаһның атаулы гаскәрен туздырган иде, гөрҗи-әрмән сугышчыларын елганы буардай итеп чапкалап тутырды, алан-кыпчакларны, гайрәтле урысларны кыйнады. Ахыр килеп урыс кенәзләре өстенә юрта челтәрен вә киез җәеп, табын хәстәрләтте һәм шунда аларны тончыктырып үтерде. Чөнки каршы торып канын кайнатканнар иде. Шуннан соң ул Идел буенда болгарларга тап булды һәм бик каты кыйналды. Ул кыйналуны аның мәңге онытасы юк, болгарлар белән орышта ике төмән сугышчысы ятып калды, күзен чыгардылар, сөйгәне Карлыгачтан мәхрүм иттеләр. Менә шул болгарлар аны ике тапкыр кыйнадылар инде. Менә хәзер өченчесенә килде. Нинди хатыннар таба һәм тәрбияләп үстерә бу болгарларны? Менә шушы гүзәл кыз кебекләрме, шулармы батыр итә угланнарны?! Шулар. Менә шуның серен беләсе килә иде Сүбәдәйнең. Өченче тапкыр килә бит инде шул халыкны яуларга, һаман очына чыга алганы юк, ягъни ханнарын алдына тезләндерә алганы юктыр. Тик монысы соңы булыр. Җиңәр ул аларны, буйсындырыр. Бирегә яу килгән саен Сүбәдәйнең күңелен үзе дә аңлап бетермәгән гарьләнү хисе биләп ала. Бу хисне ул, ошбу якка килгәч тә, тоя башлады. Ул инде Болгарның илтабарлары, баһадирлары белән таныш диярлек, шымчылары барсын да җиткереп торалар. Беренчесендә аны Бачман баһадир белән Илһам хан кыйнаса, икенчесендә Җаек буенча Булат әмир белән Артык баһадир тәпәләде. Саксинда исә Артык баһадир белән Бачман баһадир гаскәр башында тора, диделәр. Бачман баһадирга Сүбәдәй баһадирның бигрәк тә ачуы зурдыр. Шул баһадир аны беренче тапкыр җиңүче һәм сыңар күзен чыгаручы... Мөгаллиме Котбый Бачман баһадир исемен телгә алган саен Сүбәдәйнең аркасы чымырдап китә. Ниһаять, ул аны кыйнар, җиңәр һәм алдына тезләндерер. Тик турыдантуры орышып түгел, бу юлы ул аны хәйлә белән җиңәр. Хәзер генә шымчылары җиткерделәр, багучылары исә расладылар: Бачман баһадир тупчылары һәм гаскәре белән ыстанга таба хәрәкәт итә икән. Әйе, ул ыстанга килсен, аны камасын, ә Сүбәдәй баһадир аның каласын барып алыр. Бу уй башына килүгә, Сүбәдәй тәмам йокыдан калды. Моннан да уңай җайны Тәңре аңа янадан бирмәс, йә хәзер, йә борылырга да кайтып китәргә һәм бирегә таба эз дә басмаска. Йөрсеннәр әнә Җүси угланнары, балигъ булдылар, хан сурәтендә йөриләр. Ә Сүбәдәй, абасы Җәбәй кебек, аяклары сызлауга сылтар. Теге вакытта Илһам хан белән Бачман баһадир төп гаскәрне ике тау арасына алдап кертеп тапаганнар иде. Юк, Сүбәдәй янадан андый кармакка капмас. Бу юлы ул үзе Бачман баһадирны тозакка эләктерер: гаскәре белән калага таба кузгалыр, ә юрталарын һәм карт-корыны калдырыр. Килсен Бачман баһадир, яуласын җәйләүне.

Менә шул хәбәрне алганнан соң һәм башында, калага яу чыгарга, дигән уй тугачтын, ул юртасыннан атылып чыккан иде. Әлеге кызга тап булды. Меңбаш Котбыйга рәхмәт, ул бирде кала тарафына яу йөрергә дигән фикерне. Котбый аның үзен генә түгел, угланны да укый-язарга өйрәтте. Заманында Чыңгыз хан угланы Җүсинең балалары уку һәм язу

белән бик мавыга башлагач, мөгаллим уйгурларны куып җибәргән иде, Сүбәдәй алай дип әйтергә җөрьәт итмәде. Гыйлемле кешеләргә ул һәрчак көнләшеп карый иде.

Сүбәдәй баһадир әүвәл угланы юртасына таба кузгалган иде, кызга күзе төшеп, кире үз юртасына таба борылды. Әйе, тиз арада түбәнбашларны чакыртырга һәм үз нияте белән таныштырырга. Тимерне кызуында сугып калырга кирәк!

## 22

Күлкән угланда бөтенләй яу кайгысы юк иде, ул түземсезлек белән Сөмбелне көтте. Аңа ул беренче күрүдә үк гашыйк булды, йокыдан калды, төшендә күрде, ә инде атасы мелла белән кызга аерым юрта куйдырткач, үз-үзенә урын таба алмый изаланды: кишектиннәре буш кул белән кайтып кергәч, ул чак кына күтәрелеп бәрелмәде.

— Йә, нәмәкәйгә карап каттыгыз. Кыз кая?

Кишектиннәр үзе белән бергә уйнап үскән егетләр иде, күзгә карашып алудан ары китә алмадылар, корыч баһадир атакай алып калды, дип әйтергә берсенең дә кыюлыгы җитмәде. Әйткән хәлдә, атакайның угланы кишектиннәре дип тормыйча, камчы белән яруы да бар иде. Аннары кишектиннәр беләләр иде. Күлкән углан үзе дә атасыннан шүрли, шунлыктан атасының ачуы килгәндә күзенә күренмәүне кулайрак күрә иде. Атасының камчысын аның да татыганы бар иде. Аннары ул Чыңгыз ханның Җүси угланын агулатып үтерүе тарихын да әйбәт белә иде, аның атасы да шул ук юлны сайламас дип кем әйтә ала? Әйе, каршы әйтсә, кушканны эшләми башласамы?..

— Йә, нәмәрсә телеңез йоттыгыз. Кыз кая? — дип кабатлады Күлкән углан һәм, терсәгенә таянып, күтәрелә төште.

— Кызны атаң алып калды, углан,— диде, ниһаять, кишектиннәрнең берсе.

— Әйе, алып калды...— диде икенчесе пышан гына.

Углан сикереп торды, кишектиннәргә берәм-берәм камчысы белән сыптырды. Ике углан аягына төштеләр.

— Без, гаепсез, углан, гаепсез!

Углан үз юртасыннан атылып чыкты, атына сызгырды, өйрәтелгән ат чаптырып иясе янына килде. Күлкән атка сикереп атланды да җанфәрманга атасы юртасына таба чапты. Юртадан йөгереп чыккан кишектиннәр атларына атланып, углан артыннан элдерделәр.

Йа Хода, кешеләрдәге яманлыклар кайта-кайта кабатланамы икән соң әллә? Кем тарафыннан котыртылып кабатлана икән ул яман хәлләр? Шайтан шулай котыртамы, һәр адым артыннан бер тотам калмыйча иблис йөримә? Бит Сәүдәгәр баһадир тормышында шуңа охшаш бер хәл булган иде инде. Һәм нәкъ шул төбәкләрдә, һәм күптән дә түгел бит әле. Дөрес, ул чакта гүзәл кызны абасы Җәбәй кулыннан меңбашы Хасдайга алып бирде һәм шул сәбәпле абасы Җәбәй белән дошманлаша язды, гүя ике туган арасыннан ташу суы узган иде. Тик монда бит үз угланы. Бүген төнлә яу кузгалабыз дип, түбәнбашлар белән сөйләшеп кайтуга, юртасында кызны күрмәгәч, Сүбәдәй ни кылырга белми торды. Ул гынамы, ярсынган углан ике кишектинен яралаган иде, тегеләрне табиб карап йөри. Сүбәдәй нигәдер күтәрелеп бәрелмәде, киресенчә, мендәргә кырын төште, өстәлчектәге тулы касә кымызны үрелеп алды һәм теш арасыннан гына сөзеп эчә башлады. Угланы Күлкән кыпчак кызына шулай башы аягы белән гашыйк булды микәнни?.. Шулай дип уйлап өлгерә алмады, күз алдына Карлыгачы килеп басты, әйтерсең хәтер күгендә күк капусы ачылды. Ул аны шундаен чын вә ихлас итеп күрде ки, татлы мәлләре күз алдына килүдән ихтыярсыз ыңгырашып куйды. Туган илендә калган хатыны Сөябелне ул беркайчан да Карлыгачны яраткан кебек ярата

алмады. Карлыгач аны гүя сихерләгән иде. Ятса — ул, торса — ул күз алдында булды. Ул аңа жаны-тәне белән тартылды, ниләр сөйсә дә, ниләр кыланып ратса да тансыклавы бетмәде, хәтта ул хатынның тавышы дәртен кузгатыр иде. Әгәр дә мәгәр углан Күлкән аның кебек үк ошбу кызга гашыйк булган булса? Нә кылырга тиеш ул?.. Углан дөрес эшләгән, кызны сәүдәгәрләрдән тартып алмаган, биш алтын бәлешкә сатып алган. Теге вакытта Сүбәдәй дә ак чәчле кыз өчен абасына биш алтын бәлеш биргән иде. Җансакчысы Хасдай тик ул чәчби белән озак тора алмады, тангутларга яу баргач, биек кирмән дивары буенда ятып калды. Тангутларны җиңү магуллар өчен каһәрле булды, чөнки Чыңгыз хан кирмәндәге бер генә җан иясен калдырмыйча суярга боерган иде, шуның каргышы төштеме, хан үзе дә шул тарафта дөнья куйды. Әйе, бер Хасдай кайгысы гына түгел иде Сүбәдәйдә. Хасдайны да ул Чыңгыз хан кебек арбага салып, туган ягына алып кайтты һәм хан кабереннән ерак түгел, үзләре уйнап үскән Диләгүн Булдак дигән тау итәгенә җирләде. Бу хәл милади белән 1227 елның унсигезенче августында булды, һижри белән 624 елның Рамазан аенда. Чыңгыз ханга үлгәндә алтмыш биш яшь иде, ә менә аның меңбашына, ягъни Хасдайга бары тик утыз тулып килә иде. Хасдайны күмгәч, Сүбәдәй кылган чәчле кызны ниндидер Бохара сәүдәгәренә сатып җибәргән иде. Гомер диген, әй!..

Инде угланы белән нишләргә тиеш ул? Иртәгә орыш, ул исә кыз белән мавыга. Барып камчы белән сыртын каезларгамы әллә?.. Тукта, тукта, нигә әле, Сүбәдәй, син кыздан берни дә сорашмадың? Бәлкем, ул калада ни булганны беләдер? Бик ихтимал ич. Бәлкем, үлеп гашыйк булган углан, үзе дә белмичә, ил дәрәҗәсендәге тутый кошны кулына төшергәндер. Иртәгә яу. Ыстанда карт-корыдан, бавырчылардан башка берәү дә калмас. Әллә соң яу җаен үзгәртергәме? Тик соң инде, Бачман баһадир бирегә таба хәрәкәт итә, ә ул төлкене алдавы җиңел булмас. Әйе, ыстанда калганнар төне буена һәрберсе өчәр-дүртәр учак яксыннар. Ә мин ул арада бөтен көчем белән калага ябырылам... Хых, хикмәт бит, әй! Саксин каласын алып, тархан вә имам билгеләп, Үгәдәй ханга сөенче җибәрергә... Кала сәүдә үзәгендә. Тора-бара бөтен кәрван биредән узар... Биредән исә Каракорымга байлык агар. Шул ук вакытта Болгарга юл ачылыр. Менә шулай, Бачман баһадир, син хәйләкәр, әмма мин дә төшеп калганнардан түгел. Тикмәгә генә Корыч аты бирмәде миңа мәрхүм Чыңгыз хан атамыз.

Башта Сүбәдәй кыз артыннан кишектиннәрен җибәрергә иткән иде, нигәдер үзе барырга булды. Кишектиннәре бер тотам калмыйча аңа иярделәр.

Юртага җиткәч, атыннан төште һәм ишеккә таба юнәлде. Башта ул туры эчкә керергә иткән иде, нигәдер тыелып калды, япманың бер почмагын күтәреп кенә карады. Бу ни бу!? Кызның инбашы ялангач, түр якта ни кылырга белми басып тора, углан исә аңа таба бара, ләкин килеп тотынырга да өлгерми, кыз елан кебек аның култык астыннан чыгып китә — кача. Алай да углан кызны эләктерде, ләкин кыз аны екты, сул кулын каерды да өстенә менеп утырды. Сүбәдәй ни кылырга белми яшьләрнең кыланышына исе китеп карап торды. Ярый әле алар аны күрмиләр, тышта сак торган кишектиннәр, баһадир күренүгә, шым булдылар, чөнки берсенең дә атакайның камчысын татыйсы килми иде. Сүбәдәй камчыны җиде көн куй маенда кайнатып иштерде, ишкәч тагы җиде көн кайнаттырды. Шуннан соң камчы тәмам еланга әверелде. Тигән җирне авырттырып кына калмый, көйдереп ала. Кыз бала углан өстенә менеп утыргач, ул тамак кырырга иткән иде, әйдә, шаярсыннар дип япманы җибәрде, чөнки кайчандыр үзе дә Карлыгач белән шулай ауман-тәүмән килер иде.

— Кагылмассыңмы бүтән Сөмбеленә! — дип сорый иде кыз. Сүбәдәй аның тавышын, үз итебрәк угланга дәшүен эче белән тойды.

— Юк-юк, Сөмбелем, кагылмам. Күпме әйтсәң, шул хәтле көтәрмен.

— Ничә көн?

— Ике көн, өч көн, бер атна, ун көн, бер ай...

Кыз угланны җибәрде, ахрысы, тавышлары бетте. Сүбәдәй түзмәде, тагын япма читен ачып, эчкә күз ташлады. Шунда хәйрани бер хәл булды, кыз чит бер кыз түгел, гүя аның Карлыгачы иде. Төсе-йөзе дә, күзләре дә, гәүдә-сыны да.

— Сиңа, Күлкән, янә бер шарт куям,— диде кыз.

— Куй, мин синең ихтыярыңда, Сөмбел, куй,— дип ялынды углан.— Син минеке, мин сине биш алтын бәлешкә сатып алдым.

— Тәнемне, ләкин җанымны түгел, Күлкән. Көч белән атны гына өйрәтәләр, Күлкән.

— Дөнья көчлеләр кулында, Сөмбел.

— Көчсезне акыл белән, көчлене корал белән җиңәләр, Күлкән. Син минем хәтта кем икәнемне дә белмисең ич.

— Юк шул, Сөмбел, белмим,— диде Күлкән торып утырды,— Кулны каердың, имгәткән булсаң,— дип зарланды.

Кыз акрын гына кузгалды да, килеп, угланның иңбашыннан сыйпады.

— Инде беттеме? Минем кулларым да шифалы.

— Юып алгандай булды, Сөмбел. Әллә чынлап та кулларың шифалымы, күр әле, бөтенләй авыртмый башлады.

— Минем кулым гына түгел, җаным-тәнем дә шифалы, Күлкән.

Юк, артык карап тора алмый. Үзләренчә, үртәшәләр. Үртәшсеннәр, әйдә, тик нигә: «Син кем баласы, атаң-анаң кем?» — дип сорамый икән. Күренеп тора ич, гади-садә гаиләдән түгел бу. Тукта, махсус җибәрелгән кыз булса? Бачман баһадирдан барысын да көтәргә була. Ничә тапкыр авызың пеште инде ошбу Болгарда.

Түзмәде, тагын япманы ачып карады.

— Беләсеңме, Күлкән,— диде кыз угланның чәчләрен рәтләп.— Синең монда туганың бар бит.

— Нинди туган, минем туганым Тайчин илдә калды, яшь әле ул. Атам аны киләсе яуга алырга итә.

— Бер әкият сөйлимме, Күлкән?

— Сөйлә, мин әкият тыңларга яратам.

— Кил, утыр янымарак, сал башың тезләремә. Сал инде, курыкма, тимим мин сиңа. Йа Аллам, мин синең колың дидем бит инде. Әйт әле, Күлкән, каян син безнеңчә бик оста сөйләшәсең?

— Чыңгыз хан исән чакта ук олуг ханның уң кулы мөселман Мәхмүд Ялавач Каракорым буласы калада мәктәп ача. Мин шунда укыдым. Чыңгыз хан да ислам диненә табынучыларны яраткан, аларга ярдәм иткән, Үгәдәй хан да Мәхмүд Ялавачны уң кулы итеп тота. Дөрес, Мәхмүд беренче вәзире булса, Үгәдәй хан икенче вәзире итеп Юләй Чүтсәйне тота. Кытайлы диләр үзен. Йә, сөйлә инде әкиятең.

— Тыңлыйм, тыңлыйм. Котбый мөгаллим дә, синең кебек, һәрчак: «Йә, тыңла! — ди. Төрки телне су кебек эчсәң, атам миңа, кала салдырам, диде.

— Борын-борын заманда,— дип башлады кыз һәм угланның маңгаена төшкән чәчләрен җайлады.— Ошбу якларга гаять көттә кодрәткә ия, курку белмәс, тәвәккәл бер баһадир күчеп утырган. Бу якның сулары вә елгалары, дала-урманнары аңа бик тә ошаган. Шуннан ул үзенә җәйләү эзли башлый. Тик кайсы төбәккә генә җәйләргә тукталмасын, иясе табыла. Янә ары китә баһадир. Көннәрдән бер көнне Кара Идел буена барып чыга. Кояш баеп килә икән инде, су буена туктап, кунарга була. Юртасын корып, кереп ятыйм гына дигәндә, моның кырына бер кыз килеп чыга. Кыз баһадирга хәтта борылып та карамый. Яр өстенә утыра да чәчләрен тарый башлый. Үзе кояшбаешка таба баккан. Баһадир кызның йөзен күрә дә гашыйк була. Башта ул аны су анасы дип белә. Чөнки кыз, дәшим генә дигәндә, йөгереп су буена төшә һәм киемен сала

да коена башлый икән. Баһадир тәмам өнсез кала. Әй йөзә, әй чума, әй су чәчрәтә кыз, үзе көлә, үзе егетне күрми. Йөзеп туйгач, судан чыга да киемнәрен кияргә дип яр өстенә менә. Бакса киемнәре юк, тагы да бакса янәшәдә генә юрта, тагы да бакса — каршында диярлек баһадир егет басып тора. Кыз чырыйлап кычкырып җибәрә дә йөгереп елга буена төшә һәм суга чумып күздән югала. И көтә, и көтә егет кызның судан чыгуын, төн көтә, көн көтә, ә кыз судан чыкмый да чыкмый. Шуннан юртасына әйләнеп кайта. Кайтып керсә, түр якта чәчләрен туздырып кыз утыра.

— Син кем? — дип сорый баһадир кыздан.

— Мин сине күптән көттем, баһадир,— ди кыз.— Тәңрем минс сиңа язды, ә син килмәдең дә килмәдең,— ди.

— Шуннан, шуннан, Сөмбел?

— Шуннан шул. Баһадир юртага керә дә кыз янәшәсенә утыра. Кыз аның башын тезләренә сала. Сала һәм: «Йокла-йокла, баһадирым, йокла таңнар атканчы»,— дип җырлый башлый. Баһадир шундук йокыга китә. Иртән уянса, берүзе икән, кыз да юк...

— Төшендә күргәнме?

— Юк кыз шунда булган, качып торгандыр. Аннары баһадирны хан чакыртып алган. Илгә яу килгән икән.

— Шуннан баһадир киткәнме?

— Киткән.

— Кыз шул юртада калганмы?

— Кыз аны әле булса көтә, ди. Тик баһадир килми дә килми икән. Ә бер көнне юртадан чыгып күккә бакса, баш очыннан бер кош очып бара һәм, аның турына җитүгә, кызга хат ташлый. Кыз хатны ала да сүтеп укый башлый. Һәм мондый юлларны күрә: баһадир орыш кырында ятып калган икән. Тик кызның шундый сихере бар икән, ул үлгән кешене терелтә ала, ди. Кыз атына атлана да орыш кырына китә, шәһит булган баһадирын эзләп таба һәм егетнең авызына зәм-зәм суын тамыза. Баһадир: «Бигрәк озак йокладым, нигә мине уятмадың, Карлыгач?» — ди. Кыз аңа: «Син каян белдең минем исемем?» — ди. Төшемдә күрдем, ди егет. Баһадир егет тора да Карлыгачын кулына күтәрә, атына сызгыра, аты килгәч, атлана да кызны юртасына алып кайта. Шуннан алар бергә көн күрә башлыйлар, тугыз айдан хатыны баһадирга углан таба. Аңа Ташбай дип исем кушалар. Ташбай ел үсәсен ай үсә, ай үсәсен көн үсә, ди.

Сүбәдәй түзмәде, оеган аягын күчерде, тамак төбенә килеп тыгылган яшь төерен йота алмый интекте. Шуннан япманы киң ачып, юртага атлады.

Күлкән углан корт чаккандай сикереп торып аягына басты, ә Сөмбел ничек утырган булса, шулай калды, тик яулык чите белән авызын гына каплагандай итте.

— Углан!

— Атам, кичер мине.

— Ни өчен? — дип сорады сыңар күзенә килеп тыгылган күз яшен кул аркасы белән сөртеп.— Ни өчен, балакай?

Атасының сыңар күзе мөлдерәп яшь белән тулганын күреп, Күлкән тагын да каушый калды. Корыч атлы, каты бәгырьле атасы күз яше белән елый, сүзен әйтә алмыйча интегә. Атасының күз яше сирәк сакалы буйлап агып-тәгәрәп төшә, бермәл каешланып беткән күбәсенә эләгеп тора, аннары икенчесе килеп җитүгә, ак киезгә тама иде. Сүбәдәй һичкемнән ятсынмый, күз яшеннән оялмый, борылып, Сөмбелгә карады.

— Син кем, балакай?

— Мин кол, атакай.

— Кол. Ташбайны каян беләсең?

— Әкияттәге Ташбайнымы, баһадир? Инәй сөйләгән иде.

— Инәң кая?

— Калада, баһадир.

— Аты ничек?

— Гөлбикә,— дип алдады Сөмбел үзе дә аңламаган уңайсызлану тоеп, Күлкәнгә күз ташлап алды.

— Атам, син барысын да ишеттең?— диде Күлкән.

— Ишеттем, олан, ишеттем. Син кем баласы, Сөмбел?

— Ятим бала мин, атам, шуңа мине сатып җибәрделәр. Кеше кулында үстем.

— Карлыгач та әкият иясеме?

— Карлыгач та әкият иясе, баһадир. Нигә ул сезгә, атакай?

— Сорауны мин бирәм, балакай, мин!

— Карлыгач атлы хатынны мин беләм, баһадир. Ул бер баһадирда кияүдә, Ташбай атлы углан үстерә.

— Угланга ничә яшь?

— Күптән бәлигъ инде, атакай.

— Угланның әтиләре вә әниләре исәнме?

— Исәннәрдер, мин белмим, баһадир. Әгәр дә мәгәр мине җибәрсәгез, мин аларны эзләп табар идем, баһадир.

— Сине җибәреп булмастыр, балакай. Сине Күлкән углан ярата. Ә мин Карлыгачны һәм угланым Ташбайны үзем эзләп табармын. Мәгълүматларың өчен рәхмәт сиңа, балакай. Белеп кал, мин сине яраттым, угланымны рәнҗетмә, яхшы хатын бул. Ә Болгарны мин алырмын, балакай, алырмын. Углан, инде атаңны син тыңла. Багучыларым җиткерделәр, Бачман баһадир бире таба килә икән, ыстанны тулганага алып, безне әсир итмәкче. Тик өлгерә алмый калыр, ул бире килер, мин урама юл белән аның каласына юнәлермен. Камасын ыстанны, әсир итсен карт-коры халкымны. Соңыннан мин аларны барыбер азат итәрмен. Ишетәсеңме, углан. Синең өстә тупларны кулга төшерү. Егетләреңне җый да һәйбәтләп аңлат. Таш яуса да туплар безнең кулда булырга тиеш, диген. Кызың торып торыр, өлгерерсең. Качмас ул, ышанычлы каравыл куй.

— Атам, атам,— диде Күлкән, Сүбәдәй алдына тезләнеп.— Атам, алма миннән Сөмбелне, тимә аңа. Мин аңа никахлашып өйләнермен.

— Һы,— диде Сүбәдәй, камчысы белән итек кунычына сугып алды.— Каланы алгач, күз күрер, углан. Егет бул. Җебемә! Кыз синеке, аңа берәү дә тимәс.

Юртадан чыккач, чигәсе чыңлаудан чарасыз калып, бертын ишекъяры торган сакчыга карап торды.

— Кызны күз караң кебек сакла. Кычкырса-фәлән дә кермә. Үз җаен үзе белер. Кыз аның кулында, үзе алды, үзе ия.

— Баш өсте, баһадир.

## 23

Сөмбел өчен зур сынау көн мәлләре башланды. Ул үз максатына иреште — дошман ыстанына үтте, Сүбәдәй баһадирны күрде, хәтта аның ниятен дә белде. Инде хәзер ничекләр бу хакта атасына хәбәр итәргә? Күлкәнне күктән төшкән бәхет итеп кабул итәсе иде дә, күңелен кытыклап, бимазалап торган вазыйфасы бар. Киңәшергә мелла Хакимҗаннан да аердылар. Аллага шөкер, Сүбәдәй баһадир аңардан мыскыл да шикләнмәде, бөтен булган хәрби серен сөйләп бирде. Тик моннан ни файда. Тиз арада атасына җиткерәсе иде — калага борылсыннар. Сүбәдәй бередән төнлә үк, урама юл белән калага таба кузгалачак. Сүбәдәй баһадирга рәхмәтле иде Сөмбел, бөтен серен сөйләп бирде. Тик ничек моннан ычкынырга, ничек Күлкән угланнан котылырга?

Күлкәннең тәгаен күзләре майланды, атасына биргән вәгъдәсен онытты да бугай, ялтыравык күзләре белән Сөмбелне ашарга җитешеп.

карап тора. Сөмбел бит-йөзенә иннек-кершән ягу нияте белән түр яктагы чаршау артына керде, бизәнү әйберләре куйган тартмасын ачты.
— Нә кылмакчысың, Сөмбел?
— Бизәнәм, Күлкән. Чыгып тор, мин хәзер.
— Мин бәхетле, Сөмбел. Син атама да ошадың. Ул миңа өйләнергә рөхсәт итте.
— Үпкәләмә, атаң сине санга сукмый, Күлкән. Каты бәгырьле кеше. Усал.
— Төрле чагы була. Усалга — усал, яхшыга — яхшы. Чын мәгънәсендә каты вә корыч баһадир ул, Сөмбел.
— Йә, чык инде моннан, Күлкән.
Күлкән теләр-теләмәс кенә чаршау артыннан чыкты. Сөмбел кечтеки генә хәнҗәрләр һәм агу яткан тартманың икенче катын ачты. Хәнҗәрләрне шундаен оста ата ул, кешенең йөзенә генә түгел, күзенә дә тигезә ала. Ләкин ул Күлкәнне үтермәс, аның бер гаебе дә юк. Ул аның бары тик кул-аягын бәйләп калдырыр. Аннары тышка чыгар, менә шунда инде кан коюы бар. Аны туктатырга тырышырлар, ләкин ул алдан ук Күлкәнгә атларны иярләп, юрта янына килтерергә кушар. Һич югы, далага чыгып йөрисем килә, дияр.
— Күлкән, атлар иярләп куярга куш әле. Далага чыгып керербез. Нигәдер атта йөрисем килеп китте.
— Әй, кем бар анда. Бүртә, дим, кер әле.
Кишектин керде, баш иде.
— Ике ат иярләп китер. Юрта янында торсыннар.
— Баш өсте, углан. Тик бит, атаң Сүбәдәй баһадир, яу чыгарга җыенырга кушты. Караңгы төшү белән, кузгалабыз, дип әйтеп әйтте.
— Ә син мин кушканны эшлә.
— Якшы, углан. Синең атың иярләнгән, тагын берне килтерермен.
— Сөмбел, Сөмбел дим. Мин ятып торам,— диде Күлкән.
Тышта эңгер иңеп килә иде инде, Сөмбел чаршау артындагы утын сүндереп, Күлкән янына чыкты. Урында ята, аны көтә Сөмбел ишекъяры узды, чөйгә эленеп торган кыл арканны алды.
— Нишлисең ул аркан белән?
— Яныма куям. Кыл арканнан елан курка, ди.
— Нинди елан булсын монда.
— Еланы булмаса, чаяны бардыр,— диде Сөмбел һәм арканны сүтеп, ятак тирәли сузып салды.— Менә булды да. Инде күзләрең йом.
— Күз йоммыйча да караңгы төште инде монда. Кил тизрәк!
Сөмбел җиләнен салды, ятак янындагы Күлкәннең хәрби киемнәренә игътибар итте һәм яулыгын салды, түш каплагычның бавын сүтте һәм Күлкән янәшәсенә ятты. Күлкән аңа үрелде, кочасы итте. Ләкин Сөмбел аның кулыннан эләктереп алды һәм артка каерды.
— Бир икенче кулыңны да, Күлкән.
Күлкән, шаярта дип булса кирәк, аңа икенче кулын да бирде. Сөмбел аның кулларын кыл аркан очы белән нык итеп бәйләп куйды. Гаҗәбе шул булды: Күлкән бер дә карышмады. Сөмбел тыенкы гына кычкыргандай итте, ай-вай килде. Тышкы яктагы кишектиннәр көлешеп алдылар. Сөмбел аһ-ух килде, әле Күлкәнне аркасына салды һәм өстенә менеп утырды, әле түше белән каплады.
— Җитмәсме? — диде, шикләнә калып, Күлкән.
— Юк әле, аякларыңны да бәйлим дә.
— Йә-йә, кыланып кал,— диде Күлкән көндәмләнеп.
— Менә шулай, Күлкән углан. Һәй-әй! — дип кычкырды Сөмбел.
Һәм тиз генә яулыгына үрелде, аны күлкәннең авызына тыкты.
— М-м, м-м-м,— дип ауман-тәүмән килергә итте Күлкән.
— Син тик кенә ят инде, Күлкән. Хәзер мин синең киемнәрең киям дә кишектиннәрең куркытам. Кеше куркытып, көлеп тормасыннар әле. Минем алардан төнем ояла.

— М-м-м-м,— дия-дия үрле-кырлы сикерергә тотынды Күлкән, мәгәр соң иде инде. Сөмбел тиз-тиз генә Күлкәннең хәрби киемнәрен киде, тышка чыкты һәм туры ике атны тотып торган кишектин янына килде. Бер сүз әйтми атларны алды да, берсенә атланды, икенчесенең тезгененнән алды һәм җилле генә юртып кузгалып китте. Нә сакчылар, нә ат янындагы азат аны танымады, күрәсең, углан үзе дип белгәннәрдер. Караңгы булса да бер сакчы:

— Угланны сыккан бу чибәр, аһ-ух килде, чырыйлады-чырыйлады да изрәп калды бугай. Ә углан атасына ашыктымы шулай?

— Нигәдер углан карсакланып калган кебек тоелды миңа, Үлҗәй. Сиңа дамы?

— Мин аңа бакмадым. Шундый кыз кочагында кечерәеп калса да гаеп түгел, Туктай.

— Сыгып ташларга сөлге түгел, менә кечерәеп калуы гаҗәп, Үлҗәй.

Бу вакытта Сөмбел атларын мелла Хакимҗан юртасына таба куалый иде инде. Аны ишектә туктатучылар да булмады, уздырып җибәрделәр, Күлкән углан дип белделәр бугай.

— Мелла,— диде пышан гына Сөмбел.

Мелла Хакимҗан түр якта, кечкенә ут янында утыра, тезендә— китап. Сөмбел аның янына ук килде.

— Сөбханалла-машалла, балакай, нәнди кием синдә? Төшемме, өнемме?

— Т-с-сс, мелла, тиз киен. Качабыз, мин атлар китердем. Мин сине, мелла, бередән чыгарып җибәрәм, калганын үзең кара. Атка атлангач, туры кояшбаешка таба кач. Мин аларны тоткарлармын. Инде дикъкать белән тыңла, мелла Хакимҗан: әтием бирегә таба яу килә икән, туктат син аны, туктат та калага алып кайт. Чөнки атам монда таба килгәнне белеп, Сүбәдәй баһадир урама юл белән калага юнәлде. Аңладыңмы, мелла Хакимҗан? Тиз бул!

Сөмбел мелла Хакимҗанны кулыннан тотып, юртадан алып чыкты.

— Мине моннан кучерәләр,— диде ул кишектиннәргә.

— Угланга кирәк булдыңмыни, картлач? — дип көлде бер кишектин.

Атлар янына килгәч, мелла атка менә алмый торды, аяклары оешкан иде. Сөмбел аны атка атландырды да тезгенен бирде.

— Сак йөр, мелла.

Сөмбел дә атына атланды һәм шундук караңгылык эченә кереп эреде. Мелла атын туры кояшбаешка тотты. Ләкин һаман юрталар арасыннан барды, бетәсе түгел кебек иде бу юрталар. Ул күрде, юрталар янында халык аз, карт-коры гына. «Димәк,— дип уйлады мелла Хакимҗан Сөмбел хаклы, Сүбәдәй баһадир сиздерми генә калага юл алган, ә баһадирымыз Бачман монда килә...»

Юрталарны чыгып китеп кенә бара иде, кемдер аңа кычкырды.

— Һай, туктап тор әле, туктап тор!

Нишләргә тиеш ул? Туктаса, кая барасың дип сорарлар, туктамаса уктан алачаклар. Мелла атын тыя төште.

— Учак янына тот, учак янына!

Капты болай булгач, бер чара кала — җан фәрман атны куаларга һәм качып котылып карарга. Сөмбел кая икән, кая югалды батыр кыз? Мелла туктамады. Магуллар коралларын җайлый, ат менә башладылар. Ыстанда ыгы-зыгы купты, шау-шу кузгалды. Мелла Хакимҗан ат корсагына типте.

— Йә, малкай, алдыр. Әйдә алып чык бу мәхшәрдән фәкыйреңне.

Арттан куа киләләр. Ярый әле төн караңгы, ләкин көнчыгыш тарафта ай калкып килә. Ай калыкканчы бу тирәдән ераграк китәсе иде дә.

Куучыларның кулларында кисәү агачлары, кычкыралар, яныйлар. Мелла Хакимҗан атын куды да куды. Калага кайту өчен чак кына уңга алырга кирәк. Болай туры Идел буена килеп чыгуың бар, анда инда харап, елга бередә киң, йөзеп чыгыйм димә. Ат та йөрәк кага башлады,

борынга тир исе килеп бәрелде. Ай тәмам калыкты. Хакимҗан артына әйләнеп карарга кыйды — куучылар юк иде. Ул атын тыя төште дә күз яше белән елап җибәрде. Бара-бара тынычлана төшкәч кенә, янә артына әйләнеп бакты. Ай яктысы якты — дала буш иде. «Сөмбел, балакаем,— диде ул ни кылырга белми үкси-үкси.— Син бит ир-егетләрдән дә асылрак булып чыктың. Сөмбел, дим!..»

Атын бераз атлатып баргач кына, малкай хәл алгач кына Хакимҗан кала тарафына юл тотты.

## 24

Күлкән угланның чит кулдагы кола айгыры кош кебек очты. Сөмбел чама белән атасы Бачман баһадирның кайда хәрәкәт итүен белә иде, шунда чапты. Офык чите күгелҗемләнеп тора, күзгә төртсәң күренмәстәй караңгы, вәләкин хайван кай тарафка барырга теләгәндәй кала ягына элдертә. Ай калка башлады. Сөмбел инде берәүдән дә курыкмый. Ул берәүгә дә тиз генә бирешмәс, гәрчә куып җитсәләр дә. Ләкин аны куучылар бөтенләй булмады, барысы да мелла артыннан ташландылар. Аны җиткән булсалар кызганыч, мелланың нә коралы, нә көч-гайрәте юктыр. Ахыр чиктә мелланың Сүбәдәй баһадир багучыларына барып кабуы бар иде. Мелланы тотсалар да, Сөмбелне эләктерсәләр дә, магуллардан шәфкать көтмә, йә ат коерыгына тагарлар, һич булмас димә, йә таш атып үтерерләр, йә кылычтан уздырырлар. Сүбәдәй үзе адәм баласын бер чабуда икегә ярып төшерә, дип сөйләделәр. Гомумән, бик күп гыйбрәтле нәрсәләр ишетте Сөмбел ике-өч көн эчендә. Сугышчыларының күбесе, баһадирның каны тоз, йөрәге таш, диделәр. Ул үз угланына карата да шәфкатьсез икән. Сөмбел үзе күрде. Ләкин баһадирны бөтенләй явыз дип тә әйтеп бетерәсе килми. Чынлап та, явызга — явыз, яхшыга — яхшыдыр. Керде бит әле угланы хәленә, керде. Имеш, ул шат, аларның икәүсен генә калдыра... Хәзер иң мөһиме — атасын табу. Дала таныш, гаскәр кадәр гаскәрне ничек тә табар. Иң мөһиме, ул иректә, атасы җитәкләгән гаскәргә каршы чаба. Бик кирәкле хәбәр илтә. Тик соңга гына кала күрмәсен иде. Атасы кайтып җитешмәсә, Сүбәдәй бөтен көче белән калага ябырылса, әнисе кулында калган азатлар гына Саксинны саклый алмаслар, капкаларны җимереп булса да калага керер.

Башта Сөмбел киемемә әллә ни игътибар итмәгән иде, өстендә магул меңбашы киеме булуын абайлагач, курка калды. Бит аны атасының мәргәннәре укка алачак. Иллә нишләмәк кирәк, башка чара юктыр, ни генә булмасын ул атасын кисәтергә тиеш. Кыпчак халкы да Саксинда азайды. Сарбай ханның гүзәл кызы Акбикә Болгар ханы Сәлим угланы Хаҗига кияүгә чыккач, бу халык кавем-кавем Кашан, Казан, Юкәтау якларына күчеп утыра башладылар. Анасы Акбикә, атасы Бачман белән кайтып, Саксинга ия булып, тулы тормыш белән яши башлагач кына, калага ит куна башлый. Кәттә гаскәр туплау да шунда гына башлана. Хәзер зарланасы юк, атасы Бачман баһадирда меңә дигән гаскәр, һәм ул каланы дошман кулына бирмәс. Бачман баһадир белән Акбикә, кайткач тернәкләнеп китсәләр дә, Болгар белән араны өзмәделәр, елга ике-өч тапкыр кунакка йөрделәр. Акбикә Болгар ханы Илһам белән дустанә һәм ярдәмчел шартнамә төзеде һәм бер капканы бары тик болгарларга бирде. Болгарлар калада үзләренә бер кәрвансарай күтәрделәр һәм үз базарларын булдырдылар. Болгар базарында иң кәттә алыпсатарлар сәүдә итте. Сүбәдәй баһадир Болгарга яу килә дигәч, анасы белән атасы киңәштеләр дә Җаек буена Булат угланга ярдәмгә бардылар. Сүбәдәй җиңелеп, борылып китәргә мәҗбүр булды. Боларның барысыннан да Сөмбел хәбәрдар иде. Ата-анасы кызларыннан сәяси серләрен беркайчан да яшермәделәр. Бәлкем шуңа күрәдер, Сөмбел сугыш һөнәрен бик теләп

үзләштерде. Тик хәйләкәр Сүбәдәй бу юлы атасы Бачманны төп башына утыртмакчы. Атасы аның ыстанына юнәлгәч, ыстанында җыен әтрәк-әләмне калдырып, урамалы юл белән калага юнәлгән. Хәйләкәр түгел диген син аны. Сөмбел куалады атын, ул аның янасын да белде, кызганды да, хәтта кызганудан күз яше белән елады, әмма ул чарасыз иде.

Кинәт мөлдерәп тулып торган ай кара болыт астына керде һәм гүя далага каракош канатын җәйде. Ул да түгел, бүреләр улый башлады. Бүреләр ач түгелләр иде, далада орыш бара, җир өстендә калган мәетләрне ашый-ашый алар кеше итенә өйрәнгәннәр. Кеше исе аларның канын кайната, үзен-үзе белештермәс халәткә китерә. Кеше итен ашап караганда дала бүресенең адәм затының исен тоюга, күзләре тона, үләсен белештерми кешегә ташлана. Шуның өчен кораллы яугирләр дә ялгызлары чакта дала бүреләре белән очрашудан сакла违налар иде. Дала бүресе, ялгыз җайдак күрүгә, иләмсез итеп улый башлый, ишләрен дәшә, ә инде бәгъзеләре ишәеп киткәч, җайдакны куарга керешәләр. Дала бүреләре улый башлагач та, яман хәл буласын күреп, Сөмбел атын куалый башлады. Аның исәбенчә атасының гаскәре шушы тирәләрдә булырга тиеш иде. Ләкин Аллаһы тәгалә, ике бәхеткә бер явызлык бирермен, диган бит, ай болыт астына керүгә, дала караңгыга күмелүгә, аннан да, моннан да дала бүреләре аңа таба килә башладылар. Сөмбел аларның гәүдәләрен күрмәде, ләкин аның артында йөзләрчә ут яна иде — корбанын күргән бүренең күзләре йолдыз кебек җемелди икән. Бераздан ай болыт астыннан чыкты, шунда гына күрде Сөмбел аның аты артыннан дистәләрчә бүре куа килүен. Сөмбелдә уннан артык хәнҗәр бар, өч-дүрт йолдызчык. Ул аларга болай гына бирешмәс, ләкин бит алар бик күпләр, шыксызлар, куркыныччлар. Әнә бүреләрнең берсе ат коерыгына ябышмакчы, инде куып та җитте, инде сикермәкче, авызы ачык, тешләре ыржайган, күзләре яна. Сөмбел аны тагын да якынрак җибәрде дә бер хәнҗәрен ташлады. Хәнҗәр бүренең әллә тамагына кадалды, әллә маңгаена тиде, җәнвар яман чинап тәгәрәп китте. Бериш бүреләр аңа ташландылар һәм ботарлый да башладылар. Әйе, дала бүресенең үз кануннары, кан исен тойдылармы, атасы-анасы вә туганы да дип тормыйлар, ботарларга керешәләр. Берничә бүре ян-якка чыкты, атның башына сикермәкчеләр. Сөмбелгә тагын ике хәнҗәрен ташларга туры килде, һәр хәнҗәр үз корбанын тапты. Ат мескен үзе дә курыккан иде, ниндидер инешне сикереп чыкты, Сөмбел чак кына һавада эленеп калмады, аяклары өзәңгедә булмаса, иярдән очып каласы иде. Ул куркудан ике куллап ияр башына ябышты һәм атын тыя төште. Бүреләр нигәдер инеш аша сикермәделәр, калдылар. Бүреләрдән тәмам котылуына инанганнан соң, Сөмбел тезгенен тартты һәм, төшеп, атының башыннан кочты да үксеп җылап җибәрде. Атның йөрәге дөп-дөп кага, аяклары калтырана иде. Сөмбел атның тезгененнән алды да сак атлап китте. Атны тик тотарга ярамый, мескен хайван хәрәкәт итмәсә, ятып җан тәслим кылуы ихтимал. Шунда ул алда үзенә таба чабып килүче азатларны күрде. Үзе дә сизмәстән атына атланды, ләкин бичара ат акрын гына тезләнде ятарга әзерләнде. Сөмбел чак кына иярдән төшеп өлгерде — ат ятты, аякларын тырпайтып, көзән җыергандай тартыша башлады. Сөмбел атның башын кочты һәм янә үксеп-үксеп еларга тотынды. Ат үлеме аның бөтен уй-хисен, теләген вә максатын юып аткан иде. Ул арада үзенә таба килүчеләрнең ат тояклары тавышы аермачык ишетелде. Кыз торды, бер хәнҗәрен кулына алды, букчасындагы йолдызсыман итеп ясалган, дошманның йөзенә ташлый торган коралын барлады.

— Син кем? — дип кычкырды алдан килгән багучы аңа җитәр-җитмәс.

Сөмбел якташын сөйләм моңыннан ук таныды.

— Мин Сөмбел, Сөмбел, Бачман баһадирның кызы! — дип кычкырганын сизми дә калды.

Багучылар аның янына чаптырып килделәр, килер җайдан атларыннан сикереп төштеләр һәм Сөмбел янына җыелдылар.

— Атың яндырдын мыни, балакай?

— Яндырдым, меңбаш Хәсән, яндырдым,— диде Сөмбел елыйелый.— Атам, атам кая? Мине тиз аның янына илтегез, меңбаш Хәсән.

Меңбаш үзе белән килгән азатларның берсенә атын бирергә кушты, Сөмбелгә атка менәргә булышты, һәм алар Бачман баһадир хәрәкәт иткән гаскәргә таба чаптылар.

Гаскәргә җитәрәк аларны янә бериш азатлар каршы алды, меңбаш Хәсән белән җилле генә килүче Сөмбелне таныдылар да, сорап-нитеп тормыйча, аларга иярделәр. Атасы, гадәттәгечә, алдан җансакчылары белән килә иде, Сөмбел атасы янына җитте дә сикереп аттан төште һәм атасының күкрәгенә капланды.

— Әтием, җаным, әтием...

— Йә, йә, Сөмбел, тынычлан. Ни булды, син кайдан? Кияүләр кайтты, син юк. Мин ыстанга һөҗүм итәм дип чыккан идем инде.

— Әтием,— диде Сөмбел һәм атасының күзләренә карады.— Әтием, Сүбәдәй баһадир син монда юнәлгәнне белгәч, урама юл белән калага китте. Тиз генә гаскәрең бор, әтием, аның каланы алып куюы бар. Мин бу хакта Сүбәдәй баһадирның үз авызыннан ишеттем.

— Ишеттегезме, җансакчыларым?— диде Бачман баһадир.— Тиз җиткерегез әмерем түмәнбашларга — калага таба борылабыз.

Бачман баһадирның җансакчылары килгән гаскәрбашларга баһадирның әмерен җиткерергә таралдылар, Бачман исә атына атланды һәм багучылар меңюашы Бурантайга дәште:

— Меңбаш, калага юнәл, күргән-белгән хәлләреңне җиткереп тор. Сак бул, Сүбәдәйнең калага кергән булуы бар.

— Баш өсте, баһадир!

— Ә без анаң коткарырга ашыгыйк, Сөмбел. Әйдә, балам. Тиз булыйк. Анаң янында бары тик бер меңбаш калган иде. Сүбәдәй баһадир өч-дүрт түмәне белән калага ябырылды, анаң мең азат белән генә каланы саклый алмас. Кузгалдык!

## 25

Буранбай багучылары калага җитәрәк Сүбәдәй яугирләренә туры килделәр. Ике арада каты орыш башланды. Ниһаять, Буранбай меңбаш яугирләрне тулганага алды, күбесе укка алсалар да, тулганада калсалар да, магул яугирләре бирешергә теләмәделәр, соңгы кешеләренә кадәр сугыштылар. Буранбай меңбашка калган җиде-сигез яугирне аркан ташлап әсир итәргә туры килде. Аркан ташлап, ияргәреннән суырып төшерелгән яугирләрнең кулларын богаулап, меңбаш Буранбай каршына китерделәр. Ай яктысы якты, һәр дошманның йөзенә багып була, Буранбай меңбаш әсирләрнең һәммәсенә дә карап чыкты, әйтерсең бер-бер танышын эзли иде. Тик бу кешеләр аның өчен ятлар иде, һәммәсе дә җәйпәк кабак битлеләр, шыксызлар шикелле тоелды. Мәгәр кайчан дошманның матур булганын күргәнең бар? Ил басарга килгән дошман матур вә күркәм була алмый. Илбасарга карата булган нәфрәт аны сиңа әшәке итеп күрсәтә.

— Кемнәр, кай тарафка юл тотасыз?— дип сорады Буранбай куллары артка каерылып бәйләнгән, барысыннан да бер башка калкурак гәүдәле яугирдән.

— Күлкән углан кишектиннәре без, меңбаш,— диде яугир.

— Сүбәдәй баһадир угланы Күлкән яугирләре, димәк. Кай тарафка юл тота идегез соң? Аннары углан үзе кайда? Сезнең белән түгел идемени?

— Ул ятып калды, меңбаш. Моннан ерак түгел булса кирәк, аңа ук тиде. Исән түгелдер ул.

Буранбай азамат егетләренә җир астыннан булса да, исәнме, мәетенме табып, Күлкәнне китерергә боерды.

— Тиз йөрегез, минем бу хакта баһадирга хәбәр итәсем бар! — диде.

Буранбай меңбашның берни егетләре далага таралдылар, мәет яткан төбәкләрдән Күлкәнне эзләргә керештеләр. Ул арада алар янына атасы белән Сөмбел килеп җитте.

— Ни булды, меңбаш Буранбай?

— Сүбәдәй баһадирның Күлкән углан җитәкләгән яугирләренә тап булдык. Тулганага алып, орышырга туры килде, качарга иттеләр, беришен дөмектердек, менә боларын әсир иттек.

— Ә Күлкән углан, Күлкән углан кайда! — дип атыннан төште һәм Буранбай меңбаш янына килде Сөмбел.

— Аңа ук тигән, диделәр, азатларым эзлиләр. Ятып калган.

— Мин китәм,— диде Бачман баһадир.— Угланның мәетен булса да алыгыз!

— Баш өсте, баһадир.

— Әтием, мин бередә калам. Минем Күлкәнне үз күзем белән күрәсем килә. Ул миңа... өйләнергә теләгән иде бит...

— Өйләнергә?!

— Соңыннан, әтием, соңыннан сөйләрмен. Бар, гаскәреңнән калма. Мин сине үзем эзләп табармын.

— Буранбай меңбаш, кызымны сакла. Үзеңнән калдырма!

— Яхшы, баһадир.

Буранбай меңбаш Сөмбел янына килде.

— Хәерсез төн булды бу, Сөмбел. Сүбәдәй баһадирның калага юнәлүе чынлап хакмы?

— Хак тәгаләдер, меңбаш Буранбай. Бәлкем, ул андадыр да инде.

— Димәк, без аңа юнәлгәнбез, ул калага?..

— Шулай булып чыга, меңбаш.

— Хәйләкәр, хәйләкәр, баһадир... Һы, күр әле ничек алдады. Инде хәзер боларны нишләтәбез, балакай? Мин багучы, минем аларны башыма бәла итеп йөретәсем килми. Бачман баһадир да бер сүз дә әйтмәде.

— Әйтте, Меңбаш Буранбай, әйтте, Күлкән углан шәһитме, исәнме, калдырмагыз, диде. Димәк, боларны да калдырмыйбыз, үзебез белән алабыз.

Ул арада Күлкән угланны табып китерделәр. Угланның иңбашына ук кадалган, ул аңын җуйган, ыңгыраша, су сорый. Буранбай меңбаш табиб артыннан җибәрде, ә угланны, чүпрәк җәеп, җиргә салдылар. Сөмбел аның янына тезләнде, маңгаена кулын куйды. Маңгае салкын иде Күлкәннең.

— Аның җан тәслим кылуы бар, меңбаш.

— Нишләмәк кирәк, балакай, орыш кырында үлем казык башыннан йөрми, алар минем дә дүрт азатымның башына җиттеләр, әнә күрәсеңме, ишләре кабер казып яталар?

— Яугирләрне кем җирләр?

— Без, без, балакай. Башта үзебезнекеләрне күмәрләр, аннары магул яугирләрен.

Сөмбел Күлкән угланның кулын тотып карады, салкын булуын тоеп, битен битенә куйды. Ләкин Күлкәннең бите дә боз кебек иде. Ул уч төбен угланның авызына куйды һәм келт итеп, күптән түгел генә авызына яулык тыгуы күз алдына килде, тәне калтырап китте, торып басты.

— Угын кем алды?

— Мин,— диде бер азат алгарак чыгып.

— Агулымы ук?

— Юк, Сөмбел, агусыз иде. Укның иясе мин.

Сөмбел меңбаш Буранбайдан кайнаткан кымыз серкәсе сорап алды һәм аны кулъяулыгына агызып, угланның ярасына каплады. Ул арада

табиб килеп җитте, беркемгә игътибар итми яралыны карарга тотынды. Табиб букчасыннан нәрсәләрдер алды, Сөмбел куйган яулыкны алып, Күлкән кесәсенә тыкты һәм яраны сихерләргә тотынды. Табиб ярага катырак кагылдымы, бу зәһәр дару белән көйдердеме, углан Күлкән ыңгырашып куйды, аякларын кузгатты.

— Ул терелерме, табиб?

— Упкынга очкан кешеләрнең бик сирәге чыга ала, балакай. Мин кулымнан килгәнен эшләдем, инде Аллаһы тәгаләгә калдырам.

— Без аны алып китәргә тиешбез, табиб. Сез безнең белән барырсыз. Мин баһадир Бачман кызы.

— Баш өсте, балакай. Мин сине таныдым, таныдым, Сөмбел, балакай. Яугирне минем арбага салыгыз,— диде табиб.

— Без китәбез, Сөмбел. Мин сиңа унбашым калдырам. Түләк унбаш син азатларың белән баһадир кызы Сөмбел карамагында каласың. Кара аны, сак йөрегез. Без калага киттек.

— Кала дошман кулында булса?— диде Сөмбел.

— Дошман кулында булса, Сөмбел, үз калабызны үзебезгә дошманнан азат итәргә туры килер.

Сөмбел атына атланды һәм ике тәгәрмәчле арба артыннан атлатып кына барды. Аның күңеле гүя икегә ярылган иде. Ул Күлкәнне кызганды да, шул ук вакытта нәфрәтләнде дә. Ни өчен ул монда килгән, кемне эзләгән? Сөмбел беренче тапкыр ир-ат затына карата күңелендә кызгану хисе уянуын тойды һәм үзалдына оялып куйды. Шундук күз алдына хан оныгы Хансөяр, меңбаш Ташбай, ахирәте Айгөл килде. Алар кайда икән хәзер?..

## 26

Күп тә үтми таң атты. Бачман баһадир түземсезлек белән кала тарафына карады. Менә-менә багучылары күренергә тиешләр иде. Әгәр дә мәгәр Сүбәдәй баһадир каланы кулына төшергән булса, баһадирга ыстан туктыйсы гына кала. Һәм шулай булды да, кояш чыкканда кала ягыннан килүче багучылары күренде. Күңелле хәбәр китермиләр иде багучылары баһадирларына — калага Сүбәдәй баһадир кергән иде инде. Гомер буена уң кулы булып йөргән меңбаш Буранбай килеп җитте, атыннан төште, баһадир алдына бер тезенә чүкте.

— Баһадирым, өлгерә алмадык, Сүбәдәй безне алдады, дошман калада.

Бачман баһадир кала тарафына карап беравык тын торды. Нә әйтә ала иде меңбашына? Һични. Шик юк, Сүбәдәй аны чынлап та алдады. Ләкин ихласи сугышып түгел, орыш кырында көчләр сынап түгел. Нишләмәк кирәк, хәрбиләр өчен дошманны алдау мактауга лаек лаземдер. Хәерле булсын, орышның гадел вә гадел булмавын Аллаһы тәгалә хөкем итәр. Син, Сүбәдәй, калада, мин далада, урыннарны алыштык, ләкин орыш барыбер булыр. Күзгә-күз очрашмыйча булмас.

— Тор, меңбаш. Шунда ыстан туктыйбыз. Җансакчыларым, корыгыз чатырым. Киңәшик.

Тиз генә баһадирга чатыр кордылар. Бачман аксакалларын чатырына дәштерде, түмәнбашлар да, багучы меңбаш Буранбай да кереп утырдылар. Аксакаллар арасында әле Сарбай хан Тын елгасы буйларында ук җәйләгән чакта түрдә утырган Тургай да бар иде. Ошбу аксакал йөзләрчә орышларда катнашкан, күп тапкыр яраланган, ләкин һәрчак сәламәт калган, ходай саклаган. Бачман баһадир тамак кырды, аксакалларга һәм түмәнбашларына булган хәлне аңлатып бирде.

— Баһадир Бачман,— диде беренче булып Тургай карт.— Сүбәдәй баһадир безне алдады, төпсез чанага утыртты. Безнең аның ыстанына таба юнәлүебез ялгыш булды. Баһадир, мин сине кисәттем бугай бит,

калаң ялгыз калдырма дип, кисәттем. Инде хәерле булсын, алга багыйк: нә кыла алабыз? Хак булса, бүген-иртәгә әмир Хаҗидан Җик Мәргән килеп җитәчәк. Мин сиңа, баһадирым, киңәш итәм: бүген үк калага ябырылмаска, сабыр итәргә. Яшермим, Илһам ханга мин ачулы, кайнар баш Артык баһадиры Сүбәдәйдә әсир, ә тупчылары яңа чирканчык алдылар. Орышмыйк Сүбәдәй белән, күчеп китик моннан.

Бачман баһадир кимсенү кебек хис тойды. Аксакалның, бик ихтимал, аны кимсетергә нияте дә булмагандыр, әмма барыбер шулайрак килеп чыкты. Бик борын заманда кыпчак ханы Әюп Болгарга килеп, Ибраһим хан белән солых төзергә тели. Имеш, Болгар сәүдәгәрләре Азак аша Судакка йөриләр, тик аларны урыс юлбасарлары бик еш талыйлар, тынгысызлап торалар. Әюп хан Болгар сәүдәгәрләренең исән-имин йөрүләренә иман итә һәм шул хакта сөйләшә. Тик бер шарт куя: азмыкүпме арпа-бодай биреп торыр Болгар, ди. Болгар ханы Ибраһим кызы Күркә Владимир кенәзе Юрий Долгорукта кияүдә булганга ышанмый, Әюп ханны һәм аның ишләрен агуларга куша. Әюп ханны һәм янә аның җиде әмирен зиратка илтеп күмәләр, чөнки Әюп хан мөселман була. Шуннан соң кыпчак кан-кардәшләр урыс кенәзләренә йөз тота башлый, хәтта Дәште Кыпчак тәхетендә утырган Янтак хан урыс кенәзе Андрей Боголюб белән Болгарга (1164) яу кылә һәм бабасы Әюп хан өчен үч ала. Бүгенге көндә кыпчак ханнары Болгарга йөз тота, алардан ярдәм көтә. Тик Илһам хан моны аңлый микән? Бит Сарбай хан заманында ук инде Дәште Кыпчак Болгар белән иңгә-иң килеп яши башлады. Соңгы елларда болгарлар белән кыпчакларны аерып та булмый инде, чөнки телләре, диннәре һәм гореф-гадәтләренә кадәр бердер.

Бачман баһадир тамак кырды. Һәм икенче аксакалга карады. Янәсе, әйдә, Габдулла карт, син дә үз фикереңжиткер.

— Әйе, орышмый булмас, баһадир. Минем әйтер сүзем шулдыр. Тик уйлашыйк әле башта, баһадир. Аллаһы тәгалә үзенең берәр бәндәсенә игелек теләсә. Ул аңа башкаларның да хаҗәтен йөкләр, ди. Миңа шунысы мәгълүмдер, баһадирның угланы Ташбай сылу кызымыз Айгөлгә өйләнде. Әнә шул ир бала баһадир Сүбәдәйнең угланыдыр. Ташбай биредә, әмма меллабыз Хакимҗан белән кызыңыз Сөмбел Сүбәдәй кулында тоткынлыкта...

— Сөмбел качып кайтты, аксакал, Аллага шөкер.

— Ә меллабыз Хакимҗан?

— Мелла Хакимҗан да күптән ыстанда инде,— диде түмәнбаш Коләхмәт.

— Ә Артык баһадир?

— Артык баһадир алар белән китмәгән иде, Артык баһадир үзсүзлелеге аркасында магулларга барып каба — әсир итәләр. Аның хакында берәү дә белми, аксакал.

— Минем әйтергә теләгән сүзем шулдыр, баһадир: угланы бездә икәнне Сүбәдәйгә җиткерергә кирәк. Ул каланы калдырсын, без аңа угланын бирербез.

Бачман баһадир ирен чите белән генә елмаеп, түбән карады. Чөнки бу чараны кылу һич мөмкин түгел иде. Ташбай — меңбаш, хан тупчысы. Аннары аның атасы бар — Артык.

— Аксакал, Ташбай углан бары тик бер атаны — Артыкны гына белә. Бу мөмкин хәл түгелдер. Аннары Сүбәдәй дә моңа бармас. Ә менә аның үзе белән алып килгән угланы Күлкән бүген безнең кулда. Угланны меңбашым Буранбай әсир итте.

— Менә монысы һәйбәт булган. Менә шуны шарт итеп куярга кәрәк Сүбәдәй баһадирга. Үзем барам баһадир каршына, үзем! — диде әтәчләнә төшеп өченче аксакал Әхмәтбай.

— Һэ, куандырдыгыз, куандырдыгыз, кардәшләрем, баһадирыгызны. Мәнем калада бикәм калды, ул бүген Сүбәдәй баһадир кулында. Таш яуса да, мин Сүбәдәй баһадир белән орышырмын. Җик Мәргән килеп

житсә дә, житмәсә дә. Иртәгә үк, иртәгә үк калага ябырылабыз. Йә калам азат итәм, йә изге юлда шәһит булам. Хәзергә исә киңәшегез өчен рәхмәт, аксакаллар. Ә сез, төмәнбашларым, орышка хәзерләнегез. Җиһад орышы, йә исән калабыз, йә шәһит булабыз...

Аксакаллар, төмәнбашлар дәшми-тынмый гына чыгып киттеләр. Баһадир Бачман чатырында берүзе калды. Җиз табактагы кавын телемнәренә кагылучы да булмады. Хәер, тамак кайгысы идеме халыкта. Кан коймый диярлек, көч түкми генә хәйләкәр Сүбәдәй каланы кулына төшерде. Ис китмәле хәл иде ич! Нә кылырга тиеш баһадир? Әллә соң багучысы Буранбайны Сүбәдәйгә илче итеп җибәреп карасынмы? Угланы Күлкән безнең кулда дип? Тик корыч вә бәдбәхет баһадир моңа барырмы? Батыр меңбашы Буранбайны кылычтан уздырмасмы? Уйланырлык иде баһадир Бачманга, уйланырлык иде. Аның әле беркайчан да бу кадәр уңайсыз хәлдә калганы юк иде. Каласын һәм бикәсен уч төбендә диярлек Сүбәдәйгә тоттырды ләбаса! Акылга сыймастай хата кылды.

Бачман баһадир аягына басты, чатыр чүпрәген ачып карады. Калкурак урынга чатыр корылган иде, шул төбәккә җилле генә ниндидер җайдаклар килә.

Бачман баһадир чатырдан чыкты, тураеп басты һәм җайдакларны көтеп алды. Алдан килгән егетләрнең берсе баһадирга житәр-житмәс атыннан сикереп төште, бер тезенә төште.

— Нә булды?

— Сүбәдәй баһадир калада, Акбикә мәликәбезне әсир иткән, үзе сарайга урнашкан. Баһадир, Түләк унбаш кызыңыз Сөмбел белән киткән ие, алар табиб белән Сүбәдәй угланы ярлы Күлкәнне дә алып киткәннәр ие, аларны магул яугирләре әсир иткәннәр, алар да сарайдалар. Орышканда унбаш Түләк егетләре белән ятып калган, батыр тик табиб, Сөмбел, Күлкән генә исән калган. Сүбәдәй аларның барысын да сарайга алган, беркая да чыгармый, чөнки угланы Күлкән бик тә авыр хәлдә икән.

— Ярый, бар, ял ит,— диде баһадир Бачман һәм борылып чатырына керде.

Хәлләр торган саен начарлана иде. Сөмбелнең янәбаштан Сүбәдәй кулына эләгүе, корыч баһадирның сарайда яшәве баһадирның тәмам кәефен бозды. Бачман баһадир һавага чыкты. Кояш баеп килә, иртәгә көн туар-тумас ул бөтен көче белән үз каласына яу йөрер. Һөҗүм шул хәтле дәһшәтле булыр, Сүбәдәй кая керергә белмәс. Каланың кайсы капкалары сыеграк икәнен Бачман белә, ул анда бик тиз үтеп керер һәм... Андагы кырышны, суешны күз алдына да китерү мөмкин түгел иде. Бит калага кимендә өч төмән дошман кереп тулган, моның өстенә кала халкы...

*Ахыры бар.*

# ШИГЪРИЯТ

## Салисә Гәрәева



### Нинди тын

Нинди тын!
Бу көзнең киче
сагышлы һәм... нинди тын!
Сары агачларның серен
тыңлыйм бүген ялгызым.

Йолдызларга оча сагыш —
салкынлык арасына.
Йолдызлар төшә... тоз булып
Йөрәкнең ярасына.

Әнә өзелгән бер яфрак
тирбәлеп төшеп бара!
Ялгызлык, Көз һәм Сагыштан
йөрәгем өшеп бара...

Нинди тын бу көзнең киче.
Өзелде кемнең тыны?
...Аяк астымда — суык җир,
өстә — йолдызлар чыңы...

### Рәхмәт!

Урманнарым!
Рәхмәт олы җаныгызга!
Агачларым, рәхмәт, рәхмәт барыгызга!
Җилләрдә сез яфракларны көйрәттегез,
Мине һәрчак уйланырга өйрәттегез...

---

Салисә ГӘРӘЕВА — *шагыйрә, «Уралым», «Тау сукмагы», «Офыклар» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Чишмәләрем!
Тавышыгыз көмеш-көмеш!
Йөрәгемдә татлы моң бар — сезнең өлеш!
Бала чактан миңа җырлар көйләдегез,
Халкым ничек яшәгәнен сөйләдегез.

Рәхмәт сиңа, үскән җирем!
Мең-мең рәхмәт!
Синең белән һәр очрашу — җанга рәхәт.
Йөрәгемдә — ялкын, сөю, моңнар — диңгез!
Бер балаң мин, туган җирем! Мин юк синсез!..

## Яшь бытбылдык

Үләннәргә ятып үбешмәгәч,
Ни рәхәте җирдә яшәүнең?!
Йөз елдан соң үлән арасыннан
Яшь бытбылдык булып дәшәрмен!..

Йөгертермен сине сукмак буйлап.
— Менә-менә тотам! — дигәндә,
Җәйге шәфәкъ алсуланган чакта
Саф җырыңны отам, дигәндә.

Югалырмын арыш арасында,
Урман аланында чүгәрмен.
...Сиңа охшатып, башка бер җир улын
Үлән арасында үбәрмен!

Яшь бытбылдык булып гүләрмен...

## Арыш бөртеге

Туган йортның кайттым кочагына —
Икмәк пешкән кайнар учагыма...
Гүя ташлар авырлыгын саклап,
Гади орлык ята учларымда!..

Нәни генә үзе, әмма салмак!
Кояш аңа көч-куәтен салды.
Арыш башагында үскән орлык:
— Нәни җир шары бу! — дип торырлык!...

Туфрак, Кояш, олы Диңгез тыны
Үзәгендә Арыш орлыгының!
Җир шары һәм салкын чык тамчысы —
Орлык! Минем җырның илһамчысы!..

Арыш икмәген ал — аша, сыйлан!
Аңа Җирнең бар тарихы сыйган!..

## Камыш

Кара башлы яшел камыш.
Кыяк чыжлаган тавыш.
Камышлар пышылдый кебек:
— Исмә, Җил! Очма, Сагыш!
Камыш чыжлаган тавыш...

Кыяклар яшел иде дә:
— Тирбәлеп яшим! — диде.
Камышлар бирде тавышын:
— Дулкынга дәшим! — диде.
Кыяклар яшел иде...

Болгана су, кага дулкын,
Ява яңгыр, су салкын...
Җилдә чайкалган камышның
Сагышы җанга якын...
Яңгыр ява, су салкын!..

Кара башлы яшел камыш.
Үрдәк кычкырган тавыш.
Моңнардан ташый күңелем,—
Кагыла күрмә ялгыш!
— Исмә, Җил! Очма, Сагыш!..

## Яңа көз

Өр-яңа Көз
Текә тауга менеп бара.
Май йомгагы —
Ягымлы Җәй сүнеп бара...

Тау битендә ят учаклар яна балкып:
Каеннарны
Чорнап алган сары ялкын!..

Торналарга карадым да,
Болгадым кул:
— Китәсездәмени инде?! Хәерле юл!
Килер язга
Кире кайтсын барчагыз да!
Сандугачлар
Кайтарыгыз бакчабызга!..

Оча яфрак
Җил иркендә талгын гына,
Сулып барган үләннәргә яулык булып.
Алда кышлар...
Без көтәбез яңа язны:
Күрешергә язсын кабат, саулык булып!..

Өр-яңа Көз
Тәрәзәмә яфрак сона:

Сары яфрак... тере ялкын төсендә ул.
Имин булсын Дөнья! Тормыш гөрләп торсын —
Янып яшәр,
Янып язар өчен дә ул!..

## Күз яшьләре дигән яңгыр бар...

Әнкәем юк инде. Кайгы килсә,
кем иркәләп мине юатыр?
Болыт, болыт! Әнкәм каберенә
ландыш чәчкәләре коя тор!..

Март җилләре! Ярсып искән чакта,
аның каберендә тынгыз!
Сайрар кошлар, яз җиткәнен әйтеп,
зират миләшенә куныгыз!..

Мин килгәнче газиз әнкәемне
борчымагыз, явар яңгырлар:
Әнкәм каберенә түгелер өчен
күз яшьләре дигән яңгыр бар,—
борчымагыз аны, яңгырлар!..

## Утыр әле яшел үләннәргә

Утыр әле яшел үләннәргә,
ак каенга терәп аркаңны! —
Тыңлыйк әле сөзәк яр читендә
ак ташларга дулкын какканны!..

Тыңлыйк әле икәү — кырмысканың
үлән сабакларын июен,
Ишетәсеңме, яшел яфракларның
бер-берсенә нәрсә диюен?!

Бу — Табигать. Тузаны да тере,
яшәү дымын илтә Терегә!
Бер уйласаң, вөждан — авырдыр күк
үләннәргә басып йөрергә!..

Җир астында яткан тамырларның
чәбәләнгән очы — дым тартып.
Алар саклый Җирне, язлар саен
яшел табигатьне яңартып...

Бала көткән матур яшь килендәй
безнең бу Җир — сакла, кадерлә!
Киләчәк тә анда, бүгенге дә,
без ятасы йомшак кабер дә...

Утыр әле яшел үләннәргә,
ак каенга терәп аркаңны:
тыңлыйк әле — Җирдә мәңге тере
гомер елгалары акканны!..



# Шәмсия Җиһангирова

## Ышанам

Бүген әле коеп яңгыр ява —
Мәңге туктамаска охшаган.
Иртәгәсен көлеп кояш чыгар —
Мин ышанам шуңа, ышанам.

Башка кайгы төшсә, дусларыма-
Ишләремә сөйләп бушанам.
Алар гына аңлый хәлләремне —
Мин ышанам шуңа, ышанам.

Киләчәгем якты булсын, диеп,
Сикәлтәләр аша юл салам.
Юлдашым үземнән яхшы булыр —
Мин ышанам шуңа, ышанам.

Яшәр өчен җанда өмет барда
Ышанудан бер дә туктамам!
Кемдер шулай миңа ышанадыр...—
Мин ышанам шуңа, ышанам!

* * *

Нигә күңелләрең боек —
Сагышлар эчтең мәллә?
Сөйгән ярың ташладымы —
Калдырып авыр мәлдә?

Нигә башың түбән идең —
Таяныр кешең юкмы?
Күзләреңдә яшь бөртеге —
Сагышмы, моңлылыкмы?

Имә башың, койма яшең —
Сизмәсен дошманнарың,
Дошманыңнан да бигрәк —
Дус дигән куштаннарың...

---

Шәмсия ЖИҺАНГИРОВА — *шагыйрә, «Төсле моң» (шигырь) һәм «Яшел гармун» (повесть, хикәяләр); «Бала чак кая китә?» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

* * *

«Язларында ялгыз йөрсәң,
Йөрәкләр яна инде...» — дип,
Җырлама миңа, җаным!
Минем менә күзләрдә дә
Йөрәкләр янган чагым.

Сары яфраклар санынча
Уйлар уйлаган чагым,—
Яфраксыз агачлар кебек
Шәп-шәрә калды җаным...

«Мәхәббәт — язларга тиң...» — дип
Кемнәр әйткән, ни сәбәп?—
Сагышыннан җан саргайган
Сары көз ул — мәхәббәт...

* * *

Бәхеттән әйләнсә башларың,
Шатлыктан буталса хисләрең,—
Сагышлы моң булып, төннәрдә
Мин синең исеңә төшәрмен.

Сагыштан саргайса йөзләрең,
Мин кабат исеңә төшәрмен,—
Иң кирәк, шифалы сүз булып,
Наз булып җаныңа күчәрмен.

Ахыргы сулышың алганда
Соң кабат исеңә төшәрмен,—
Гомерем учагын сүндереп,
Мин синең янына күчәрмен...

## Үзең килгәч күрерсең

Башкаемда — синең өчен
Агарган чәчләрем бар,
Күзләремдә — синең өчен
Коясы яшьләрем бар.

Бары синең өчен генә
Тибәсе бар йөрәкнең.
Белсәң иде ничек сыкрап
Өзелгәнен үзәкнең?!

Агын-карасын онытам,
Уйласам синең хакта.
Сөеп-сөелеп туймам кебек,
Ничә гомер торсак та...

Син дә шулай өзгәләнсәң,
Хәлемне белер идең.—
Агын-карасын уйламый
Яныма килер идең.

Әллә ниләр бирер булам
Сине бер күрер өчен...
Калганнарын әйтеп тормыйм —
Үзең килгәч күрерсең.

* * *

Мин күкләргә шундый якын идем:
Очып кына мен дә... үрел дә...
Җиде күкнең сихри бар балкышын
Мөлдерәмә тутыр күңелгә.

...Очтым, очтым хыял канатында,
Тик күкләргә житә алмадым...
Ялгыз канат көчсез икәнлеген
Шунда гына... шунда аңладым...

Мин күкләргә шундый якын идем —
Җиткән булыр идем югыйсә...
Бары да бетте... Күшек күңелемнең
Яраларын телеп җил исә...

## Син мине күрмәдең

Син минем иң гүзәл чагымны күрмәдең —
Яшенләп янганын күзләрем.
Син минем иң моңлы чагымны күрмәдең —
Еладым... еладым — түзмәдем.

Син минем иң назлы чагымны күрмәдең —
Аһ орып, ятларга сыендым.
Син минем иң иләс чагымны күрмәдең —
Нур булып күкләргә уелдым.

Син минем иң изге чагымны күрмәдең —
Фал ачып төшемне юраттым.
Хәзер мин гап-гади җир заты —
Югалттың син мине, югалттың...

* * *

Сикереп кенә атланыр да идең...
Атлары шул ап-ак бүз түгел.—
Кем беләндер бергә булу әле
Ялгыз булмау дигән сүз түгел...

Булса булсын атның тик акбүзе —
Башка атлар безгә үз түгел...—
Кем беләндер бергә булмау әле
Ялгыз булу дигән сүз түгел...

* * *

Әгәр минем хакта сорасалар,
Син башыңны түбән иярсең.
«Ярар инде, орышмагыз мине,
Ялгышлык булды ул...» диярсең.

Әгәр синең хакта сорасалар,
Мин башымны түбән имәмен.—
Орышу түгел, җаным алсалар да
«Язмышым ул минем...» диярмен...



Сәйдә Зыя

# ИКЕ ӘНИСӘ, БЕР МӘХМҮТ

хикәя

Беренче имтихан тарихтан иде. Ишек төбендә башкаларның чыгуын борчылып, куркып көтеп торырга Әнисәнең сабырлыгы җитмәстер кебек тоелды. Шуңа да имтиханга беренче төркем белән үк кереп китте ул.

Бу төркемдә алар бишәү иде: ике егет, өч кыз. Башлап билетны егетләр алды. Чем кара чәчле, каракучкыл йөзле, тәбәнәк буйлы егет билетын укый-укый тәрәзә буендагы өстәлләр рәтенә таба атлады. Ә озын буйлы, коңгырт чәчле ыспай солдат ишек янындагы рәткә, икенче өстәл артына килеп утырды. Әбисеннән өйрәнеп калган бар яхшы сүзләрен эченнән генә кабатлый-кабатлый, Әнисә дә билетка үрелде. Алды да, сөенеченнән чүт кычкырып җибәрмәде. Нинди бәхет — белгән сораулар чыкты бит! Беренче сорау: «Петр патшаның урыс дәүләтен киңәйтүдәге өлеше». Икенчесе: «РСДРПның II съезды». Әзерләнеп тормыйча да җавап бирергә була, димәк!

Билетына карап әле һаман урыныннан кузгала алмый торган Әнисәгә укытучы:

— Утырыгыз,— диде.

Кыз, солдат каршысындагы урындыкка килеп утырды. Сорауларны кабат укып, белгәннәрен күңеленнән барлап чыкты. Җавапларны тулысы белән язып тормыйча, бик мөһим дип тапканнарын гына кәгазьгә теркәде.

Озак та үтмәде, тәрәзә буендагы егетне — беренче булып билет алучыны җавап бирергә чакырдылар. Җавапка Әнисә дә колак салды: әйбәт, шома сөйли иде егет. Шулчак укытучыларның берсе икенчесенең колагына нидер пышылдады. Ничәдер секундлык пышылдау вакытында Әнисәнең өстәленә бөкләнгән кәгазь кисәге килеп төште. Ачып караса... Үз күзләренә үзе ышанмый торды, гаҗәпкә калды. Түп-түгәрәк хәрефләр белән язылган бик тә таныш кулъязма иде бу! Ул «ялт» итеп артына борылды. «Мәхмүт!» — дип сизелер-сизелмәс кенә кыймылдады иреннәре.— Менә син нинди икәнсең, Мәхмүт! Сержант Мәхмүт Саттаров!»

---

Сәйдә ЗЫЯ — *шагыйрә, проза әсәрләре дә яза. Берничә китап авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

Алар бер ел буе хат алышканнар иде. Ул — Апас районы егете, Әнисә — Мамадыш ягыннан. Адресны егет кызның авылдашы Хәбирдән алган булырга тиеш. Сержантлар әзерли торган курста алар бергә укыганнар. Адресны сорап алганмы Мәхмүт, әллә Хәбир аңа үзе тәкъдим иткәнме — бу кадәрлесе Әнисәгә караңгы. Курсны тәмамлагач, Хәбирне Биробиджанга җибәрделәр, Мәхмүтнең беренче хаты Төмәннән килде.

Читтән торып танышуны Әнисә өнәп үк бетерми иде, тик бу юлы тотты да Мәхмүткә җавап язды. Егетнең хатлары гади, тормышчан иде. Дуслары белән төшкән рәсемен дә җибәрде. Чаңгы ярышыннан соң төшкәннәр икән. Уч төбе хәтле кәгазьдә алты егетнең сурәте. Фоторәсемнең артына Мәхмүт: «Сулдан өченчесе мин булам, сагынганда карарсың», дип тә куйган. Шушы сүзләр Әнисәнең җенен чыгарды. «Ясмык хәтле чыккан йөзеңнең кай төшенә карарга кушасың соң син?! Кызларга шундый фото җибәрәләрмени!» — дип үпкәләп йөрде.

Берничә көн үткәч, тынычлангач, үзе дә рәсем җибәрүне кирәк тапты. Тик үзенекен түгел, апасының рәсемен. Сурәт тонык чыккан иде, томан эчендә торган шикеллерәк — өйрәнчекләр эше иде. Хатына: «Безнең авылда фотога төшә торган урын юк, гаеп итмә инде», — дигән сүзләрне дә өстәде.

Апасы белән Әнисә бер-берсенә һич охшамаган, белмәгән кеше аларның бертуган булуына ышанмый да. Апасының кара толымнары иңенә төшеп тора. Озынча йөз, сызылып киткән каш, килешле туры борын. Авылда аның турында: «Хәдичәнең матур кызы», — дип йөриләр. Әнисәнең йөзе түп-түгәрәк, күзләре зәп-зәңгәр, чәчләре бөдрә, җирән.

Фотодагы Әнисә Мәхмүт күңеленә хуш килде, күрәсең. Хатлар тагын да назлырак, тагын да җылырак була башлады. Ике арада шулай матур гына хатлар йөреп торганда, аралар өзелде... Анысы болай булды: укырга теләге барлыгын Мәхмүт гел искәртә иде. Әнисә аңа үзе белгән уку йортларының адресларын җибәрде. Кызның уенда да уку теләге көчле. Китапханәдә эшләп йөрүе вакытлыча гына. Менә шулай уртак уйлар, уртак хыяллар җылысына төренеп, күрешү көннәрен күз алдына китереп юанганда Мәхмүттән озын бер хат килде. Егет бу юлы әнисе, апалары, туганнары турында тәфсилләп язган. Әниләре тол калып өч бала үстергән икән. Олылары кызлар, Мәхмүт исә төпчек. Кечкенә апасы күптән түгел кияүгә чыккан. Әниләре хәзер ялгыз. Мәхмүтнең хәрби хезмәтне тутырып авылга кайтуын биш күз белән көтәләр. Ә аның укыйсы килә. Ул юллар чатында. Әнисен рәнҗетүдән дә курка, югары хәрби училищега керү теләге дә җанына тынгылык бирми икән. Нишләргә? Әнисәгә мөрәҗәгать итүе нәкъ менә шушы хакта. Аннан ярдәм сорый, аңлавын тели. «Кадерлем, бу хатым өчен ачулана күрмә. Һәр сүзем йөрәгемнән чыккан хисләрем белән сугарылган. Шунлыктан, төннәремне йокысыз иткән уйларымны сиңа җиткерергә җөрьәт итәм. Әнисәм, үтенәм синнән, чык миңа кияүгә. Мин укыган арада әни белән икегез торыр идегез. Беләм, син дә уку хыялы белән янасың. Апас белән Казан арасы ерак түгел, читтән торып та укырга мөмкин. Ризалыгыңны белдергән җавабыңны көтәм. Сине бик күрәсем килә, рәсемеңне үпмичә йокыга киткәнем юк».

Көтмәгәндә, уйламаганда килгән бу хәбәр тәэсиреннән Әнисә ни көләргә, ни еларга белмәде. Аңларга тырышып карады, тик нихәтле тырышмасын — аңлый алмады. «Күреп, күрешеп бер тапкыр да сөйләшмәгән кыздан ничек инде кияүгә чык дип сорарга кирәк? Моңа, әнисе белән торып торырга, аңа булышучы кеше кирәк. Укып чыккач, авылның беркатлы баласын аерып җибәрү читенмени? Бәлки, ул мине шулай сыный торгандыр? Ризалашкан сурәттә дә мин аның әнисенә түгел, үзенә чыгам бит! Бер эгоисттыр бу!

Бер-ике көн уйланып йөргәннән соң Мәхмүтнең дуслары белән төшкән рәсеме өстенә «җүләр!» дип язып, кире җибәрде. Рәсемне кайтарып бирү алар арасындагы элемтәнең өзелүе билгесе иде...

Әнә шул егет хәзер Әнисәнең артында утыра, сулышы аның чәч бөртекләренә кагыла. Алдында — берсеннән-берсе назлы хатлар язган кешенең кульязмасы. Анда бер генә сорау язылган: «Советларның II съезды турында ниләр беләсез?» Боларны, әлбәттә, белә Әнисә. Белгәннәрен язып та бирә ала... тик ул чагында Мәхмүт тә аның кульязмасын таныячак бит. Юк, язарга ярамый.

Ни сәбәпледер, имтихан алучыларның берсе бүлмәдән чыгып китте. Икенчесе, тәбәнәк буйлы егетнең җавабын тыңлый-тыңлый, тәрәзә каршына килеп басты. Шул берничә секунд, берничә сулыш арасында Әнисә сумкасындагы дәреслек Мәхмүт ягына таба шуышты...

Әнисәнең имтиханнан чыгуын Мәхмүт көтеп торган иде.

— Йә, ничек? — дип атылды ул аның каршысына.

— «Бишле», — диде кыз, сөенечен яшереп тормыйча.

— Шәп! Котлыйм үзегезне!

— Сезгә ничәле куйдылар?

— «Дүртле».

— Мин дә котлыйм!

— Рәхмәт. Сездә китап булмаса, көймә комга терәлгән иде.

— Алай ук түгелдер лә.

— Чынлап. Армиядә китаплар урысча иде. Хәзер тел ни урысчага, ни татарчага бармый.

Һәрчак шулай: имтихан биреп чыкканнан соң күңел күтәрелә, канатланып очасы килә башлый. Әнисә дә нәкъ шул халәттә: апаларына тизрәк барып, шатлыгын уртаклашасы килә аның.

— Мин китим, сау булыгыз, — диде ул.

— Ә мин сезне ашханәгә чакырмакчы идем...

Мәхмүтнең эчкерсез, самими карашы Әнисәне үзенә тартты.

— Мин каршы түгел, — дип ризалашудан башка чарасы калмады аның.

Университет бинасының дүртенче катыннан алар йөгерешеп диярлек төштеләр.

— Без таныш та түгел бит әле, — диде егет, урамга чыккач. — Мин Мәхмүт булам. Мәхмүт Саттаров.

— Әнисә, — диде кыз керфекләрен сирпеп.

Бу исемне ишеткәч, Мәхмүт барган җиреннән тукталып калды. Гаҗәпләнүдән түгәрәкләнгән күзләре туп-туры кызның йөзенә төбәлде.

— Фамилиягез Төхфәтуллинамы? — дип әсәрләнде.

Әнисәнең ирен читләре йомшарды: менә көләм, менә елмаям дип җәелеп китәргә тора. Тик нык булырга, ничек тә сиздермәскә, белдермәскә кирәк! Шуңа ул кашларын җыерды, йөзенә сәерсенгән кыяфәт чыгарды.

— Нигә әле мин Төхфәтуллина булырга тиеш, ди. Минем фамилиям Гаязова. Ә сезгә Төхфәтуллина кирәк идеме? — Хәзер бераз чытлыкланып, егетне үртәп алырга да була инде. — Исемемне ишеткәч, төсегез үзгәрде. Аңлавымча, Әнисә Төхфәтуллина сезнең котыгызны алган...

— Кызлардан гел куркам мин. Юаш, — диде Мәхмүт сүзне шаяртуга борып.

Кыз тыйнак кына көлемсерәде:

— Кызлардан курыккач, нинди сержант ди инде ул?

— Сержантлыкка укыталар бит. Кызлар белән сөйләшү фәнен беркайда да өйрәтмиләр.

— Ярар алайса, сезнең хәлегезгә керәм. Миңа хезмәтегез турында гына сөйләгез.

— Солдат тормышының кай җирен сөйлисең. «Тор!» — дисәләр торасың, «Ят!» — дисәләр ятасың. Үз иркеңдә түгел.

— Кайда хезмәт иттегез? Нинди җирләр күрдегез?..

— Амур өлкәсендә укыдым, Төмәнгә сержант булып килдем, — диде егет сүзен кыска тотып. — Үзегез кайсы яктан? Кайсы елгаларда коенып, нинди чишмәләрнең суын эчеп үстегез?

— Эчкән суым тау чишмәсеннән, коенуларым Мишәдәдер, туган төбәгем Шәле булыр,— диде Әнисә күзләрен уйнаклатып.
— Теге кызлар урлый торган Шәлеме?
Мәхмүтнең бу соравыннан икесе дә кычкырып көлеп җибәрделәр. Бу хәбәр Әнисәнең үзе өчен яңалык иде. Хәзерге егетләр кыз урлау түгел, кызлар өчен сугышмый да! Рыцарьлар заманы күптән узды. Шәледә нинди гадәтләр яши торгандыр — анысы Әнисәгә караңгы. Мамадыштан Казанга килгәндә юл буенда сузылып кала торган авылларның, мөгаен, иң зурысы Шәледер. Төзек, матур авыл. Шуннан артык мәгълүматы юк аның бу авыл хакында. Тик белмәгәнне белдерергә ярамый.
— Урлатсаң урларлар ул,— дигән булды кыз җитдиләнеп.
— Мин тагын шушы зәңгәр күбәләкне урламыйча, ничек Казанга җибәргәннәр дип торам. Мөгаен, сакчың нык тыр?
— Сакчыларыма сүз тиерерлек түгел,— дип елмайды Әнисә.— Иң элек әни. Соңга калып кайтсаң, кирәгеңне бирә. Чыда гына.
— Тагын?
— Тагын абый белән апам бар. Җиңги... Тагы да бер яшь сакчым үсеп килә иде,— дип авыр сулады Әнисә.— Ике айлык иде инде... Абыйның малае... Җирләдек... Өч ай була инде...
Мәхмүткә уңайсыз булып китте. Кызның сагышын, сабыйны юксынуын оныттырырга теләпме, армиядә булган бер хәлне искә төшерде.
— Шулай бер чакны Амур өлкәсендә подвал казыдык. Шунда кеше чыкты.
— Кеше! Нинди кеше?
— Скелет. Кеше скелеты. Борынгы кабер урыны булган күрәсең. Янәшәсендә кылычы тора.
— Бик куркынычмы?
— Юк. Тик, әллә ниткән уйлар килде башыма.
— Нинди уйлар?
— Менә без дә йөгерәбез инде... Тегесе кирәк, дибез. Монысы... Шулай йөри торгач, бөркөн үлеп тә китәсең.
— Табигать кануны катгый. Берни эшли алмыйсың. Туу — очраклылык, үлем — чарасызлык. «Үлемнән калмак юк»,— ди безнең әни.
— Әйе инде. Тик шунысы кызык бит: кеше дөньяга үз теләге белән килми. Әмма дөньяга килгәч, синең тууыңа без гаепле инде, дип берәү дә әйтми. Киресенчә, «син — тиеш, син — бурычлы», дип тинтерәтә башлыйлар. Мин, мәсәлән, үз теләгем белән туа торган булсам, гомумән, монда тумас идем.
Егетнең фәлсәфәсе кызга кызык тоелды.
— Кайда туар идегез? — диде ул елмаеп.
— Табар идем әле. Ә монда ягарыңа утын әзерләп, малыңа печән эзләп җан чыга. Әни колак итемне ашап бетерде инде. Син укырга киткәч, печәнне кем чабар, урманны кем кисәр, ди.
Мәхмүт әйбәт әңгәмәдәш иде. Кайбер егетләр шикелле сүз таба алмыйча интегеп тормый. Гади. Тормышны белә. Кыланчык та түгел, уйлаганын уртага салып әйтә. Бу сыйфатлары аның Әнисәгә бик ошады.
— Мин тагын, Америкада туасың калган дип торам.
Ул шулай Мәхмүт белән үз итеп сөйләшә торгач, син дип эндәшүен тоймый да калды.
— Америкада тусаң ярар иде ул. Американы куып җитәбез дә узып китәбез, дип күпме сөрән салдык ич.
— Анда сугышлар булмаган шул,— дип каршы төште Әнисә.
— Юк, юк! Мин бүген синең белән тарихтан бәхәсләшә алмыйм,— дип елмаеп, Мәхмүт ике кулын да югары күтәрде.— Син хаклы!
Түбән төшкәндә, җаен туры китереп, уң кулы кызның биленә кагылып алды. Тәннәр буйлап рәхәт дулкын йөгерде. Күңелләр бу дулкынның тукталмавын, берөзлексез тирбәлүен теләде. Егетнең хыялы назның татлы ширбәтендә йөзә иде. «Мамадыш Әнисәсе дә шулай чибәр микән?

Хәер, аның турында уйланунын кирәге юк. Очрашырга үзе теләмәде ич! Кайдан килеп башка керде соң әле... Янәшәмдә хыял үзе бүген...»

Хәрби хезмәткә киткәннән бирле кызлар беләнә кагылмаган куллар менә-менә кызны куенына кысар да, иреннәр иренгә кушылыр шикелле иде...

Тик кыз кырыс. Ул җитди булырга тырыша. «Бер озатудан үземә караттым, дип уйламасын әле. Егетләргә ялындырсаң яхшы...»

Әнисә егетнең тәкъдимнәренә ипле җаваплар таба торды.

Мәхмүт аңа:

— Әйдә кино карыйк бүген. Имтиханнан соң ял итәргә безнең хакыбыз бар,— диде.

— Икенче юлы инде,— диде кыз кабат очрашырга мөмкинлек калдырып.— Бүген вакытым юк.

— Ашыгасыңмыни?

— Каравайга ук барасым бар. Апаларга.

— Мин сине озатам.

— Юк, юк Мәхмүт. Рәхмәт. Мин ике көннән кайтам!— Әнисә рәтләп хушлашып та тормыйча, трамвай тукталышына таба йөгерде.

Әллә нәрсә булды Әнисәгә. Үз-үзенә урын тапмады. Читтән торып танышкан егет белән очрашырмын да, ул минем күңелемә керер, дип башкайларына да кермәде бит! Уйлап та карамады. Уйлап караса соң «Җүләр!» дип фотосын кире җибәргән булыр идемени! Йөрәкнең үрсәләнүенә каршы, ул арада, икенче «мин» башын күтәрә. «Тукта әле, ул хәтле вәсвәсәләнмә,— дип киңәш бирә.— Бәлки укырга керә алмассыз...»

Тулай торакка тагын ике көннән соң гына кайтасы Әнисә, апаларындагы беренче төнне үк көчкә үткәрде. Әйләнде-тулганды, керфегенә йокы кунмады, иртүк торып киенә дә башлады. Моны күргән апасы:

— Бу вакыттан кая барасың?— дип гаҗәпсенде.

— Өч көннән имтихан. Укыйсым күп.

— Алайса үзеңә кара.

Алар төш вакытында очраштылар. Бер шешә кефир белән газиткә төрелгән пәрәмәчләр кочаклаган Әнисә буфеттан чыгышлый Мәхмүткә килеп бәрелде.

— Кайттыңмыни!?— дип, егет сөенеченнән балкып кызның кулын тотты.

— Китабым калган...

Каушаудан Әнисәнең бит урталарына ут капты. Колак яфраклары чеметтереп кызышты. Мәхмүт исә сорап калырга ашыкты:

— Кич кая барасың?

— Бармыйм.

— Кич утыра керергә рөхсәт булырмы?

— Кер.

Нәрсә дисең инде? Кермә, дип әйтеп булмый... әйтә дә алмый. Аны күрер өчен ашкынды ич... Уенда һаман ул. Әллә... бер күрүдә гашыйк булу дигәннәре шушы микән? Моңарчы бер егет кулы да тотып карамаган кыз түгел ич ул! Авыл егетләре озатып карады, кунакка килгәннәре дә мәхәббәтләрен белдерде... Тик берсе дә аның күңелен ныклап яулый алмады.

Әнисә бүлмәгә йөгереп керде дә сиртмәле караватка ахылдап килеп утырды. Шул вакыт «кылт» итеп исенә төште: бәй, бүлмәдә бүген берүзе ич ул! Ашау онытылды. Ул ашыгып-кабаланып бүлмә җыештырырга тотынды. Артык-портык күлмәкләрен шкафка элде. Китап-дәфтәрләрен чемоданына тутырды. Мамадыш районы, дип язылган кәгазь-мазар күз алдында кала күрмәсен.

Кичке сәгать җиде тулганда Мәхмүт ишек шакыды. Гәүдәсенә сыланып торган хәрби кием, күкрәктәге значоклар аңа килешә, йөзенә җитдилек өсти.

Чәй эчкәндәй булып, өстәл артында озак утырылды. Караган кинолар, укыган китаплар, истәлекләр искә төште. Чәйнектәге су күптән суынды. Әнисә чәйнекне кабат кайнатып кирәргә ниятләп, өстәл янынннан кузгалганда Мәхмүт түзмәде, аның беләннән кочып үзенә тартты.

— Әнисә...

Кыз елмаеп, егетнең иреннәренә имән бармагын куйды:

— Я-ра-мый!

Кызның кулын Мәхмүт учына алды. Бармак битләрен берәм-берәм иреннәренә тидерә-тидерә пышылдады:

— Сөеклем минем... Кадерлем... Син бит хыялымда йөрткәнем...

Әнисәнең күзаллары пәрдәләнә, зиһене чуала... Ул аңа һаман ныграк елыша... Баш миенең үзәгендәге нәни бер күзәнәк кенә, өзек-өзек дулкыннарын җибәреп, йөрәк белән тартыша: «Кочакка керүгә эреде, йомшак кыз икән димәсме? Егетләргә сөюеңне белдермәү язшы... Аның хатларын көтеп алган Әнисә икәнлегеңне белми ич ул! Сиздермә... Сиздермә... Бәлки... хат алышкан кызлары да бер син генә түгелдер...»

Тамчы таш тишә, диләр. Тәки шул нәни күзәнәктән килгән дулкыннар, тирбәлә торгач чәйнекле кулны кузгатырлык, әз генә булса да, читкәрәк тартылырлык көч бирде. Билне кыскан егет кулы бераз йомшарды. Әнисә кочактан ычкынып, ишеккә атылды. Ярый әле аш бүлмәсендә берәү дә юк иде.

Чәйнегенә су агызып, плитәгә куйды, газын әз генә чыгарды. Салмак утта иркенләп кайнасын, дип уйлады. Әнисә ашыкмый. Аңа зиһенен тупларга, үзен кулга алырга кирәк. Җете кызыл тиз уңа, диләр. Кинәт кабыну, тәкатьсезләнү килешмәс.

Аш бүлмәсендә юанып Әнисә ялгышмады. Ул кергәндә Мәхмүт тә тынычланган иде. Кулында гәзит. Шуны караштыргалап утыра.

Сүз тагын уку турында башланды.

— Синең урыс теленнән дәресләкләрең бармы? Җөмлә тикшерүне мәктәптә укыганда да яратмый идем,— диде егет, гәзитен өстәл читенә куеп.

— Тарих-филология факультеты булгач, яратмасаң да өйрәтерләр...

— Мин бит диңгезче офицер булырга хыялланган кеше, Әнисә.

— Хыялыңа нишләп хыянәт иттең соң?

— Әни каршы килде. Теләгән кешегә Казанда да укырга була, диде.

— Үкенмәссеңме икән?

— Белмим,— диде ул. Күзләреннән бөркелгән сагышын яшерергә теләп. Егетнең эчке моңын бар тулылыгы белән сизде Әнисә.— Юк, үкенмимдер,— диде ул үзен кулга алып.— Ә менә сине очрата алмасам, үкенеч булыр иде!

— Очрашканыбызга үкенсәң, нишләрсең?— дип көлде кыз.

— Әнисәкәй, мин чынлап әйтәм. Әллә нишләдем мин. Сине күргәннән бирле исереп йөрим менә. Күңелемдәген аңлатырга сүзләр эзлим, табалмыйм.

— Егетләр гел шулай инде... Тасма телле...

— Алай димә, Әнисә...

— Һай, Мәхмүт! Яшенле яңгыр тиз уза...

«Яшенле яңгыр тиз уза...» Бу сүзләрне әлек тә ишеткәне бар аның. Таныш сүзләр... Кем әйтте соң әле?..»

— Ачуланмасаң, бер сорау бирер идем,— дип дәвам итте Әнисә.

— Рәхим ит.

— Имтиханнан соң... исемемне ишеткәч, нишләп йөзең үзгәрде?

— Үзгәрдемени?

— Ничек кенә әле!

— Бер кызык халәт булды ул...

— Сөйлә, ә?

— Әнисә исемле кыз белән хат алыштым мин. Сине шул дип торам.

— Ул кызны танымыйсыңмыни?

— Тонык кына фотосын җибәргән иде... Үзен күрмәгәч, ялгышырга да мөмкин...

— Армиядәге егетләр бер-берләренә кызлар адресы бирә икән дип ишеткәнем бар иде минем дә.

— Ул кызның адресын мин үзем алдым.

— Кайдан?

— Хәбир исемле егет белән бергә укыдык. Мамадыш егете.

Моңа авылдаш кызы хат яза. Йөргән кызы түгел, дус кызы. Сөйләшәбез шулай. Хәбир мактый моны. Акыллы, кешелекле, ди. Хәбирнең кайсы авылдан икәнен беләм ич мин. Сержантлар мәктәбен тәмамлап, Түбәнгә килгәч, хат яздым.

— Очрашырга теләмәдеңме?

— Ара өзелде безнең.

— Очрашсагыз, кызык булыр иде,— дип балаларча куанды Әнисә.

— Ну хәйләкәр дә инде син!—дип көлде Мәхмүт.

— Нишләп тагын?

— Миңа әллә ниләр сөйләттереп утырасың бит.

— Синең турында күбрәк беләсем килә.

«Тагын таныш җавап».

Кайчакта өйдә берәр нәрсәгә күзең төшә дә, шуңа исең китеп карап торасың. Әйтерсең, син аны беренче тапкыр күрәсең. Мәхмүтнең хәзерге халәте дә шулайрак иде. Әнисәнең һәр җавабы аңа нидер хәтерләтә сыман... Әллә укыган романнарындагы геройлар теле белән сөйләшә инде, дип тә уйлап алды егет, тик ачыклый алмады.

Үз бүлмәсенә кергәч, йоклый алмыйча озак уйланып ятты Мәхмүт. Бүгенге әңгәмәне күңеленнән кабат-кабат кичерде. Мамадыш Әнисәсе язган хатлар исенә төште. «Көннәр шундый әкрен уза. Хезмәтне бүген үк тәмамлап, туган якларга кайтасы килә. Ичмаса кыска ял да бирмиләр. Тавык төшенә тары керә, диләр. Мин дә синең белән күрешү мизгелләремне күз алдыма китереп хыялланам. Имеш, миңа ял бирәләр дә, тиз генә сиңа хәбәр салам: «Түбән—Мәскәү поезды белән шул көнне Казанда булам. Каршы ал!»—дим. Әмма бу бары тик татлы хыял гына»,— дип язган иде ул бер хатында. Аңа каршы Әнисә: «Яшенле яңгыр тиз уза. Мин дуслыгыбызның озын булуын телим»,—дип язган иде. Фикерен шигырь белән дәлилләп тә куйган.

> Олы хисләр — күңел түрләрендә,
> тел очында йөрсә, җил алыр.
> Яратуың артык тирән булса,
> «яратам» дип әйтү бик авыр.*

Мәхмүт кинәт маңгаен тотты. «Соң, тиле баш! Икесе бер Әнисә ич инде! Вәт җүләр! Шә-ә-әп! Кызык итте бу кызыкай мине...»

Имтиханга әзерлек көннәрен алар бергә үткәрделәр. Тик бер-берләрен белүләре турында икесе дә ләм-мим.

...Урыс теленнән имтиханга Мәхмүт соңга калып килде. Әнисә «дүртле» алып чыккан, борчылып Мәхмүтне көтә иде.

— Имтихан бетә ич инде,—диде ул Мәхмүтнең килгәнен күреп алуга, каршысына чыгып.—Өч кенә кеше калды. Менә дәфтәр. Бәлки, кирәге чыгар.

Имтиханны егет «өч»кә бирде. Болай булгач конкурстан үтүе икеле иде аның. Ул үзе дә моны чамалады. Әмма ни өчендер аның моңа исе китмәде. Әллә инде чынлап та гуманитар фәннәр өйрәнергә күңеле тартмады. «Бишле»гә биргән кешедәй шаярды, көлде. Алар кич буе Казан урамнарын урадылар. Тик, егет теленнән «яратам» дигән бер кәлимә сүз төшмәде. Куллары Әнисәнең беленнән кочмады. Кызларның төшенә генә керердәй гаҗәеп егет иде ул бүген. Әйе, арып-талып тулай

---

* Сажидә Сөләйманова шигыре *(автор искәрмәсе)*.

торакка кайткач, ишек төбендә бер тапкыр тәмен белеп, суырып үпте ул аны. Аннары «кырт» борылып, үз бүлмәсенә китте. Ярату теләгенең татлы газабыннан котылу өчен, аның үз өстенә салкын су коярга ашыгуын Әнисә башына да китерә алмады...

Иртәгесен, Әнисә нихәтле генә көтсә дә, егет ишек шакымады. Аптырагач, кыз үзе аларга керергә уйлады. Бүлмәдәшләре аның китүен әйттеләр. Кызның күзләре мөлдерәмә тулды, тамагына төер утырды. Кеше алдында сытылудан куркып, тизрәк чыгып киту ягын карады. «Димәк, киткән... киткән...» Теле һаман бер сүзне тәкърарлады.

Тулай торак диварлары аның йөрәген кыса шикелле. Сулыш җитми, тын алуы авыр... Әнисә тизрәк урамга чыгарга уйлады. Бәлки, хәле анда бераз җиңеләер, авыр уйлары бераз таралыр...

Чыгышлый, хатлар куела торган киштәгә күзе төште. Анда Төхфәтуллина Әнисәгә дип адресланган хат ята иде. Түп-түгәрәк хәрефләр белән энҗедәй тезелгән матур, тигез кульязма. Әнисә ашыгып-кабаланып ачты хатны. «Кадерлем, болай китеп баруым өчен мине гаепләмә. «Өчле» белән мин конкурстан уза алмаячакмын. Хезмәтемне тутырып, тизрәк кайтырга кирәк миңа. Язмыш синең белән күрештерде. Иң мөһиме шушы. Көт. Тагын ике айдан яныңа бөтенләйгә кайтам. Мәхмүт.»

Бу юлы Әнисәнең башы әйләнеп киткәндәй булды. Ә бераздан теленә җыр килде, күңеле кош сыман җилкенеп зәңгәр күккә күтәрелде, хисләре диңгез дулкыннарыдай чайкалды... Кыз күңеле шул!

## ШИГЫРИЯТ



**Фирдәвес**

**Әһлия**

### Ашкынулар юшкыны

Машиналар ташкынында
Сөйгәненә ашкынды...
Ашкынуы үтте дә бит,
Үтми икән юшкыны.

Шәһәренең урамында
Үлеп тыны кысыла.
Җаннары белән тартыла
Хыялдагы кызына:
Еракларлан, томаннардан
Нәние кулын болгый.
Очар иде яннарына! —
Булмый шул.
                Булмый!
                        Булмый...

Бала киемнәрен карый
Кереп кибетләренә...
Йөрәккәен ялкын ала,
Каба ул битләренә.

Аяклары үзе илтә
Бала табу йортына...—
Бала төшертергә чират
Тора йөкле хатыннар.

Күрәсең, балага узу
Алар өчен «зур бәла».

---

Фирдәвес ӘҺЛИЯ — *«Актриса» (документаль повесть һәм хикәяләр), «Ак күгәрчен» (әкиятләр) исемле китаплар авторы. Шигырьләре көндәлек матбугатта басылып килә. Казанда яши.*

Ә ул ходайдан ялвара:
«Бирче, ди, бала, бала!..»

...Үксез песи дә бәхетле,
Ул да бит, әнә, ана.
Балалары имеп ята...
Көнләшеп куя аннан.

Бала имезгәнен күреп,
Төшләрендә юана.
Ә аннары уяна да,
Яше белән юына...

Машиналар ташкынында
Сөйгәненә ашкынды.—
Ашкынулар ялгышының
Үтми икән юшкыны.

## Сөям сине!

Сөям сине — тыпырчына йөрәк
Сабый сыман дөнья карнында.
Мине сөймәгәннәр хурга калсын
Олуг мәхәббәтем каршында.

* * *

Синең сурәт инде ераклаша:
Томаннарга кереп адаша.
Ә мин калам — яшьле күзләремдә
Нәфрәт белән сөю алыша.

## Йокысыз төн

Күзем кызыл.
Күгем кызыл.
Кемдер миңа
Кабер казый...
Баш очыма
Как бер казык:
Бәлки, чәчәк
Атыр язын.

Синең яшьлек —
Минем яшем.
Күзләремдә
Ачы яшем.
Еллар буе
Синсез яшим.
Сөясең ич!
Яшер... яшер...

...Күгем кызыл:
Таңмы?.. Канмы?..
Йөрәк каным —
Сиңаданмы?

* * *

Калдыр мине! Калдыр гомерлеккә,
Алай гына түгел — мәңгегә...
Ак аракы гына — синең кыйблаң,
Өстерәмә, зинһар, мине дә...

Корбан итиммени үз-үземне
Шул агулы шешә хакына?
Көнең-төнең синең саташулы,
Назыма да җаның... абына.

Мин кызганам сине үлә язып,—
Синең каның гына кызадыр...
Мин кызганам сине, бәгырькәем,
Ә мине соң кемнәр кызганыр?..

## Тынлык

Әллә нәрсә булды әле:
Күңелем кинәт сынды.
Шигърият дигән чишмәнең
Моңлы җырлары тынды.

Тынды гавәм, тынды галәм:
Куркынычмы, рәхәтме?..
Рәнҗүләрең төште микән?
Әллә... синең рәхмәтме?..

## Елау

Сөйгәнемне кайтар миңа,
йа раббым!..
Ялгыш юлларда йөрмәсен,
йа раббым!..
Гомерлеккә ярым булсын,
йа раббым!...
Бәбкәемә әткәй булсын,
йа раббым!..

Сөйгәнемне кайтар миңа,
йа раббым!..
Аны миңа күкләр бирде,
йа раббым!..
Әрвахлар да риза булды,
йа раббым!..

Төшләремә кереп әйтте,
йа раббым!..

Сөйгәнемне кайтар миңа,
йа раббым!..
Мин бит аның бердәнбере,
йа раббым!..
Иманына кайтар аны,
йа раббым!..
Күңеленә сал шуларны,
йа раббым...

## Сагышлы җыр

Кара урманнарга керсәң,
Кыен була кайтырга.
Инде беркемем калмады
«Җаныем!» дип әйтергә.

Күз яшьләремне юарга
Төшәм әле күлләргә.
Ярың җуйсаң, мөмкин икән
Мәхәббәттән үләргә.

Ерак коеларга барам
Тирәннән су алырга.
Теләмәс идем беркемгә
Япа-ялгыз калырга.





# Фирдәвес Бәширова

## Хатын-кызларга

Вакланмагыз әле, хатын-кызлар.
Бәягезне бераз белегез.
Табигатьнең сез бер табышмагы,
Бәлки, чишелмәгән — билгесез.

Ул нәфислек, илаһи көч сездә! —
Урал тауларына торырлык.
Бер сирпелеп каравыгыз кайчак
Гаскәрләрне кире борырлык.

Ә сабырлык?..
Кайдан килә дисең?
Ташкыннардай ярсу мәхәббәт?
Мин кешемен дигән һәркемгә дә
Насыйп булсын сездән мәрхәмәт.

Йомшак, бәрхет тавыш агылганда
Сандугач та тына җиңелеп.
Кирәк чакта сез тартырга әзер
Ил арбасын, аттай җигелеп.

Күзләреңдә сары ай сагышы
Анасыннан калса баласы.
Бөгеп салмас димә ир-егетне
Хатын-кыздан алган ярасы.

Акыл да бар сездә, хәйләсе дә,
Сөелергә тулы хакыгыз.
Ирне ир иткән дә, җир иткән дә
Сез бит инде, шул ук хатын-кыз!?

Вакланмагыз әле, хатын-кызлар!
Яшәү мөмкин зиннәт, алтынсыз...
Кешелекнең иң зур зиннәте — без.
Яшәү мәгънәсе дә — хатын-кыз!

Вакланмагыз!

---

Фирдәвес БӘШИРОВА — *шагыйрә, «Сезнең өчен тибә йөрәгем», «Җылы сүз көтәм» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

## Чишмәм

Урал тауларының моңы, җыры —
Чишмә агып ята ялтырап.
Җир җылысын куенына төреп
Әнә бара чыңлап, чылтырап.

Кайда кабаланган була икән? —
Тәвәккәлләп төштем артыннан.
«Идел белән кавышырга бара...»
Дип ишеттем авыл картыннан.

— О мәһабәт Идел!
Илне иңләп
Килеп җиттем айлы бер кичтә.
Кургаш төсле тыгыз агымнарың,
Меңәрләгән тәңкә өстеңдә...

Әйтче миңа: кайда минем чишмәм?
Кайсы тәңкәң аннан яралган?
— Төш тә эзлә! Алар хәйран миндә.
Әнә, сары күпер. Ай салган.

— Суың, Идел, мин буйларлык түгел,
Мин буарлык түгел агымың.
Көмештәй саф, боздай сулы чишмәм
Җыйган моңын Урал ягының...

— Минем өчен бар чишмәләр дә бер:
Йотам! Килеп кенә җитсеннәр.
Гайрәт чәчеп ятам! Минем белән
Кушылганга шөкер итсеннәр!..

Һәм шаркылдап көлгән кебек Идел
Борылышта зәһәр шаулады.
Котылмакчы тамчы... атылды да...
Тик тамчыны Идел аулады.

Һай бу дөнья! Сикәлтәле дөнья.
Ак төсенә янәш карасы.
Тамчы белән тамчы язмышлары —
Зәңгәр күк һәм Җирем арасы...

Идел төпләренә уй уелды,
Кырчынташка бәрелеп чәчрәде.
Кургаш дулкын ярдан ялап алды
Кулымдагы тере чәчкәне...

## Беләсеңме?

Бер кеше дә эзсез китми Җирдән:
Мәгърур сыннар, затлы әйберләр,
Чүлдә чәчәк аткан гөлбакчалар,
Җиргә суккан мөһер-каберләр —
Болар бар да кеше эзе Җирдә.

Һәркем шулай үз мөһерен суга:
Иҗат итә, төзи, җимерә.
Җинаятьне изге саганнар
Кара эзен сала Җиренә.

Гөнаһым юк Җир каршында минем,
Дигән әүлия дә гөнаһлы.
Бер гөнаһсыз булу мөмкин түгел —
Шулай инде аның дөньясы.

Эзен сала Җиргә яхшысы да,
Яманы да суга мөһерен.
Үз-үзеңнән сора: — Беләмме, дип,
Үз әнкәмнең — Җирнең кадерен?





**Индус Сирматов**

# СҮНГӘН УЧАК

хикәя

Шаһимөхәммәт карт белән Гаделбану карчык бер атна инде утны учакта гына саклыйлар. Ә менә ул көнне, соңгы шырпыны сызып ут тергезгәндә, карчыгын кисәтеп куйды карт:

— Карале, сиңайтәм, ишетсен колагың, шырпы бетте. Утны сакларга кирәк!..

Утны саклауның ни икәнен Гаделбануга аңлатып торасы юк. Сугыш елларында гел шулай булды. Кичтән казан астына кисәүләре-ниләре белән бергә күп кенә итеп утлы күмер өясең дә өстен кайнар көл белән томалыйсың. Мич юшкәсен аз гына ачык калдырасың. Һава алышынып торгач, казан астындагы күмер иртәнгә чаклы салмак кына пыскып ята. Иртән иртүк, көл арасыннан актарып, чикләвек кадәрле генә бер-ике утлы күмерне табасың да самавырга саласың.

Аннары инде син көне буена утлы булдың дигән сүз.

— Шушы араларда берәрсе килеп чыкмаса, Исәмәткә төшеп менәсе булыр. Тозың да бетеп бара бугай. Шырпысын да алып кайтырмын.

— Кем генә килер икән, сиңайтәм. Мирзанур гына әйләнеп чыгасы итмәсә инде...

— Иртәгә үзем төшеп менми булмас, ахры. Кеше килгәнне көтеп ятканчы...

— Төшеп менәм дигәч тә, якын җир түгел бит әле ул, сиңайтәм. Баруы-кайтуы унбиш чакрым... Туксанга җиткәч сиңа... учак кабызу эше генә түгел...

Икенче көнне Шаһимөхәммәт күрше авылга дип чыгып киткән җиреннән тиз генә кире әйләнеп керде.

— Әллә нигә хәл бетеп тора, сиңайтәм. Көннең кыздырганы...

— Ярар, ярар, йөрмә интегеп, сиңайтәм. Берәрсе күренер әле. Килми калмаслар.

---

Индус СИРМАТОВ (1937)—*язучы, журналист. «Еллар шаһит», «Әткәй сәгате» китаплары һәм республика матбугатында чыккан повесть, хикәяләр авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

Ләкин икенче көнне дә, соңрак та бу сыңар йортлы авылга килүче булмады. Карт белән карчык атна буена тагын өй сакладылар. Дөресрәге, учактагы утны сакладылар.

— Бүген җомгамы әле? — диде Шаһимөхәммәт, иртән торып самаварга янә утлы күмер салгач. — Болай булмас, ахры. Барып кайтыйм чәй эчкәч...

— Әллә йөрмисеңме, сиңайтәм. Нигәдер җилкенсенеп торам.

— Әйтәм аны төн буена саташып чыктың. — Шаһи карт уч төбен карчыгының маңгаена тигерде. — Бәй, ут кебек янасың бит син. Мәтрүшкә кайнатып биримме соң әллә? Туктале, иң элек кәҗәне савып керим булмаса...

Ирләр эше дип санамаса да, карчыгы авырып-нитеп куйганда шулай кәҗә сауганы бар аның. Сөт тулы җиленен бушатмыйча интектермәссең бит инде малны.

Сөтен савып алгач, кәҗәне тыкрык киртәсенә муеныннан бау белән бәйләп куялар да, көн буена чемченеп йөри ул шунда мәхлук. Бүген исә Шаһи карт кәҗәне бәйләп тә тормады. Ләкин абзар ишеген ачык калдырды. Йөрсен шунда, вакыты җиткәч, үзе кайтыр әле, янәсе.

— Мә, сиңайтәм, сөтле мәтрүшкә эчеп җибәр әле... Бәй, йокладыңмыни? Йокла, алайса. Йокы иң әйбәт дару ул. Уянгач эчәрсең, алла боерса...

Шаһи карт шулай сөйләнә-сөйләнә өй эшләрен караштыргандай итте. Ишек алдына чыгып кәҗәгә күз салды. Кәҗә, кемгәдер үпкәләгәндәйме, башын югары күтәреп басып тора иде. Карт шунда бер уңгайдан бакчадагы ике баш умартаны күзәтергә дә онытмады. Умарта күче үз эшендә, тыз-быз киләләр. Әтәчкә ияргән тугыз тавык исә ишек алдында тырмана. Унынчысы аның чебеш әнкәсе булырга җыена — күкәй өстендә утыра.

Шаһимөхәммәт өйгә әйләнеп кергәндә карчыгы әле дә булса йокыдан уянмаган иде.

— Өйлә җитә, сиңайтәм, әллә чәй эчеп аласыңмы?

Карчык җавап бирмәгәч, Шаһимөхәммәт якынрак килеп, кулын аның маңгаена салды. Карчыгының тәне иртәнгедән дә кайнаррак тоелды аңа.

— Кем ие ул анда? — дип сорады Гаделбану, күзләрен ачмыйча гына.

— Син нәрсә, кем булсын...

— Кем белән сөйләштең? Мирзанур килдеме әллә? Әнә бит сөйләнә...

Саташа, дип уйлады Шаһи карт. Көпә-көндез саташу, һәрхәлдә, хәерлегә түгел. Ул, колхозга кергән елны имән тактадан үзе ясаган артсыз урындыкны алып, карчыгы яткан карават янынарак утырды.

— Берәү дә сөйләшми. Ишетелә генә ул сиңа. Тәнең авыртамы әллә?

— Шырпыны саклап тотарга кирәк шул аны... Кучкарга алып куй әле боларын... Сыер көтүе кайтмадымы әле?..

Бу соңгы сүзләрен ишеткәч, карчыгының саташуына тәмам ышанды Шаһимөхәммәт: авылда сыер көтүе беткәнгә егерме ел бит инде!

«Йа илаһем! Миннән алдарак китәрсең микәнни? Әллә иң әүвәл үзең мине җыярсыңмы дигән идем...»

Чынлыкта, үз уйларыннан үзе куркып калды Шаһимөхәммәт.

Хәер, моңа алар икесе дә әзер иде инде. Алтмыш-җитмеш йортлы авылдан үзләре утырып калганга да унбиш еллап бардыр инде. Аңа чаклы исә ничә еллар биш-алты йортта гына кеше яшәде. Элек урам дип саналган урамның теге башында сыңар йортта ялгызы яшәгән Бибигайшәне дә җирләгәч, авылда менә шулай үзләре генә утырып калдылар. Калсалар калдылар, әмма тирә-юньдәге авыллар Шаһимөхәммәт белән

Гаделбану яши торган шушы бер йортлы авылны барыбер элекке исеме белән Яңа Әнәле дип йөртәләр иде.

Ә бит нинди күкрәп торган авыл иде! Халык дус яшәде. Берберсен чагу, күрше күршегә зыян-зәүрәт салу, олылар арасында гауга куптару, яшьләр арасында зина кылу дигәннең нәрсә икәнен белмәделәр диярлек.

Колхозлары гел алдынгы булды. Игеннәре уңды. Абзар-кура тулы мал-туар, урам тулы бала-чага дигәндәй... Сугыштан соң, шөкер, электр керде, радио сөйли башлады.

Шулай матур гына яшәп ятканда әллә каян килеп колхозларны эреләндерергә керештеләр. Эреләнгәч тә башта иң элек кәнсәләрне сүтеп Исәмәткә алып киттеләр. Барыбер анда да юньле эшкә ярамады идарә йорты. Терлекчеләргә кызыл почмак итеп кормакчылар иде, бүрәнәсе тегендә-монда таралды да бетте. Аннары амбарлар сүтеп алынды. Яңа йорт салучыларга да Исәмәткә төшәргә куштылар. Авыл күзгә күренеп кими башлады. Яртылашка калгач, бөтенесенә дә Исәмәткә күчәргә, диделәр. Күчкәне күчте, күчмәгәне йорт-җирен сатыпмы, тәрәзәсенә аркылы такта кадаклапмы, әллә кая читләргә тарала башлады. Тегендә яңа шәһәр салалар — эшче куллар кирәк, монда нефть чыгаралар — эшче көче кирәк. «Ә» дигәнче таралды да бетте Яңа Әнәле. Шәһәргә китәргә көче-куәте булмаган, Исәмәткә күчүдән баш тарткан карт-корылар яши торган өйләрнең генә морҗаларыннан төтен чыга торган булып калды.

— Сиңайтәм, нигә кергән ул?

— Кем кергән, берәү дә кермәгән. Саташмале, сиңайтәм. Уян әле.

— Бибигайшә, мине көтәсеңмени? Хәзер, хәзер... Быел җиләк бигрәкләр дә уңган. Хәзер китәбез. Чык кипкәнче...

«Әллә кайчан үлгән Бибигайшә белән күрешкәч, озак калмагандыр шул инде»,— дип шөбһәләнде Шаһи карт.

Бу куркыныч уйлардан картның үзенең дә кинәт башы әйләнеп китте.

Анысын инде тагын да куркынычрак икенчесе алыштырды: «Үзем дә үлеп китмәгәем әле. Юк, юк, әлегә үләргә ярамый. Мин гүр иясе булсам, Гаделбану кем кулларында калыр?..»

Их, Гаделбану, Гаделбану! Бигрәкләр дә туры китереп кушканнар шул исемеңне! Бигрәкләр дә гадел булдың шул! Кыз чагыңнан ук. Беренче тапкыр күзгә чалынганда сөлеккәйләр кебек зифа буйлы кыз бала идең! Уникедәме соң ул чакта, унөчтәме? Печән өмәсендә сиңа күзләремне тутырып карап торуымны сизгәч дә йөзең пакуста посып яткан җир җиләге кебек кып-кызыл булды. Әле шуннан соң да ни гомерләр сиңа сүз катарга җөрьәт итмичә йөрдем. Үзебез очрашканда күзләребез дә очраша иде дә, гаепле кешеләр сыман һәрвакыт кызара идек. Ничә еллар үтеп, беренче Герман сугышына киткәндә генә: «Мине көт, Гаделбану, яме»,— дип пышылдадым. «Көтәрмен, Шаһимөхәммәт»,— дидең син. Көткәнсең дә, рәхмәт. Герман пленында йөргәндә дә көткәнсең. Аннан котылып илгә кайткач, Гражданнар сугышында йөргәндә дә көткәнсең. Анда муеным, эчем-башым дигәндәй яраланып кайтуыма карамастан, и-и сөендең дә инде! Шөкер, бер-беребезгә насыйп булдык. Улларыбыз-кызларыбыз туды. Гадел булдың. Аларның бүген берсенең дә бу дөньяда калмавына син дә, мин дә гаепле түгел бит. Бик гадел булдың. Ике улымны ияртеп икенче Герман сугышына киткәч тә көттең. Анда әсирлеккә эләккәч тә көттең. Кырык алтыда әсирлектән кайтып, яңадан кавышкач та бик гадел булдың. Озак куанырга гына туры килмәде шул. Ике ярман сугышында да плен төшкәнсең дип, тегендә илтеп тыккач та көттең. Әйләнеп кайтуыма, төпчегебез Зөләйха менә дигән иттереп мәктәптә укып йөри иде инде.

— Шулчаклы пар атлар җигеп килмәсәгез тагын, адәм тәганәсе! Бер кәҗәне алып китәргә сыңар ат җитмәс иеме!..

— Ни сөйлисең, сиңайтәм. Уян әле... Куркытмале мине. Кем ул пар ат белән килгән?..

— Әнә бит, бүрәнә ярыгында... Кермәгез, көшегез, көш-ш!..

Гаделбануының агарып киткән йөзенә карады да катты Шаһимөхәммәт. Үзенең инде әллә кайчан тоныкланган күзләреннән энже бөртегедәй яшьләр тәгәрәвен, ул яшьләрнең җыерчыклар аркылы ага-ага сакал очына килеп җитүен һәм «тып-тып» итеп идәнгә тамуын сизмәде дә карт. Томаланган күзләре аша бары тик Гаделбануның әрнүле йөзен генә шәйләгәндәй булды.

Бигрәк тә әрнегән иде шул ул чакта да карчыгы. Дөресрәге, Бибигайшәне җирләп кайткан көнне иде ул.

— Безгә дә чират җитте, сиңайтәм,— дигән иде ул чакта Шаһимөхәммәт.— Әллә соң Исәмәткә генә күчәбезме? Әнә бит Мирзанур ни дип тора. Йортыгызны машинага төйим дә үзем алып китәм, ди. Бибигайшә җиңгәчәйнеке белән икесен бер итеп үзем өр-яңадан салып бирәм, ди. Төшәбезме әллә, сиңайтәм. Монда безне күмәргә кеше дә калмады ич инде.

Әй әрнегән иде дә соң ул көнне Гаделбану!

— Алай бик китәсең килсә, кит,— диде.— Мин, әнә, кәҗә белән абзарда калырмын,— дигән иде.— Мин сине гомерем буе шушында көттем, үлememне дә шушында каршылармын,— дигән иде.

Үз гомерендә беренче тапкыр картына үпкәләве шул булды Гаделбануның. Беренчесе, әмма соңгысы түгел.

Ике-өч көннән Мирзанур яңадан шул тәкъдиме белән килгәч:

— Зинһар, Гаделбану җиңгәчәнә ишеттерә күрмә,— дигән иде Шаһимөхәммәт.— Без шунда гына калырбыз инде. Үлгәч, иншалла, күмәргә килерсез әле.

Баштагы елларда Мирзанур тагын берничә кат әйтеп карады ул сүзләрен. Берсендә колхоз рәисе белән икәүләп килделәр.

— Син бит, Шаһи бабай, ветеран,— диде яшь-яшь рәис. Кече улың әнә Мирзанур абый белән яшьтиләр дә булган икән. Сезнең өчен берни дә жәл түгел. Өр-яңа нарат бүрәнәдән салынган йорт буш тора. Төшегез дә утырыгыз. Бер тиен түлисе юк!

— Монысын нишләтербез?

— Боларын, сүтеп, үзегезгә утын итәрбез. Авыл урынын сөреп, иген чәчәрбез...

Авыл урынын сөреп, анда иген чәчүнең «ветеран» өчен йөрәген сабан белән сөрүгә тиң икәнен ничек аңлатасың яшь-яшь егеткә.

Инде шуннан соң бүтән борчымый башладылар. Тик Мирзанур ташламады. Утынын китерә торды. Тоз-шикәр, сабын-шырпыдан өзмәде. Ә бәрәңге бакчасын үзе карады Шаһимөхәммәт. Кәҗәсенә кышлык печәнне үзе хәстәрләде. Борынгыча итеп эче чокылган ике баш бүрәнә умартасы белән мәш килде. Ат кузгалагының өлгергән орлыкларын да Гаделбану белән бергәләп җыйдылар, көлтәләп киптерделәр, кыш буе шуны тавыкларына җим итеп тугыладылар.

Бер елны Мирзанур Бибигайшә йортын сүтеп туpады да Шаһи карт капкасы янына килеп туктады.

— Менә сезгә утын,— диде ул.— Рәхәтен күрегез. Биш елга җитәрлектер.

Ләкин Гаделбану ахирәтенең йортын утын итеп мичкә ягудан баш тартты.

— Кулым-аягым корыр, әстәгъфирулла тәүбә,— дигән иде ул көнне Гаделбану.

Киселгән-ниткән әзер утынны Мирзанур Исәмәткә алып китте. Кайсыдыр бер яңгырлы көнне машинасы авып үзе озак кына шифаханәдә ятты. Ул елны Шаһимөхәммәтләр янына юньләп килүче дә булмады. Рәис алышынган. Яңасы сыңар йорттан торган Яңа Әнәле авылы турында белми дә, күрәсең. Элекке чаклардагы сирәк-мирәк күренүче пионер-

лар да килми башлады. Оешмалары беткән диме шунда... Җитмәсә, кайдадыр багана авып, электр өзелде. Радио да сөйләүдән туктады. Хәер, электрның бик әллә ни кирәге дә юк иде бугай инде. Җәйме-кышмы, көн караңгылануга, юрган астына керергә, кояш чыкканчы торып басарга күнеккән карт белән карчыкка электр яктысы кирәкмени! Көн яктысы да бик җиткән. Баштарак радио сөйләмәвенә генә борчылганнар иде дә, тора-бара ансына да күнектеләр. Мирзанурның да үз мәшәкате мәшәкатьтер, һаман саен сирәгрәк күренә башлады. Шулай итеп, гомерләренә эштән башка берни белмәгән карт белән карчык кешеләрдән тәмам бизенделәр.

— Сиңайтәм, мәтрүшкә кайнатам, дигән идең түгелме?..

Карчыгының бу сүзләрен ишетү Шаһимөхәммәткә, үз гомерендәге иң зур шатлыкларның берсе булгандыр. Димәк, үз аңында! Карт сикереп торып диярлек аягына басты да самавырын яңартып җибәрде, мәтрүшкәсен пешекләп, аңа кәҗә сөте кушты. Бал әзерләде. Өстәлгә килерме соң бу, караватына утырган көе генә эчәрме, дип икеләнеп торганда янадан Гаделбануның хәлсез тавышы ишетелде:

— Ясин чыгар идең, ичмасам, сиңайтәм...

— Кит әле моннан! Ниткән ясин чыгу ди ул. Менә кайнарлата чәеңне эчеп җибәр. Бал белән. Шыбыр тиргә батып...

— Безгә нидоимка тиеш түгел. Безнеке түләнгән. Заем да түләнгән. Түләнгән бит, сиңайтәм?..

— Ниткән заем тагын? Ни сөйлисең син?

— Әй, юк, саташам гына бугай.

Гаделбану бер чокыр кайнар мәтрүшкә чәен эчеп тә бетерде. Балны Шаһимөхәммәт аңа үзе каптырып торды. Озак та үтми, карты әйткәнчә, шыбыр тиргә батып йоклап та китте ул.

Ул йоклагач, Шаһимөхәммәт үзе дә тынычлап бер чынаяк чәй эчте. Урамга чыкса, инде караңгыланып килә икән. Гадәттә, абзарга кереп ята торган кәҗә бүген ни өчендер болдырда басып тора. Шаһи карт үз гомерендә беренче тапкыр хайванга хилафлык эшләде: савып-нитеп тормыйча гына, кәҗәне абзарга кертеп җибәрде. Мунчадан куыксыз керосин лампасы алып өйгә керде дә филтәгә ут элде.

Гаделбану тигез сулап йоклый иде.

Карт, лампаны өстәлгә куеп, шүрлектән китаплар алды. Кайсы киндер белән тышланган, кайсының инде тышларлыгы да калмаган бу китаплар арасыннан ул курка-курка гына ясинлесен эзли башлады. Әмма ни өчендер ясин китабы юк иде.

— Әй, юләр,— дип куйды ул үзалдына.— Ясин китабы теге чакта Бибигайшә йортында калды бит. Шуннан ары кирәге булмады ич...

Аннары мәдрәсәдә укыган чакта ятлаганнарын искә төшерергә тырышып карады — барып чыкмады. Теге чакта, үзләре үк актив булып, мәчет манараларын кисеп, халык күңеленнән динне кысрыклап йөргәндә ясин догасы да истән чыккан, күрәсең. Ә менә колһуалла истә калган. Ләкин колһуалла ясинны алыштыра ала микән соң?

Гаделбану аны тагын уйларыннан бүлдерде.

— Әнкәй, әнкәй, олы түтәй чулпысын миңа бирсен әле. Утырмага барып кайтканчы гына... Кирәкмәс, кирәкмәс, арыш урагы бетми торып, кая ул борайга төшү... И-и Зөләйха кызыкаем, абыеңнан хат бармыни?..

Шаһимөхәммәт карчыгына таба борылып карады: Зөләйханың суга батып үлгәненә биш былтыр бит инде. Карт, имән урындыгына көчеп, карчыгының баш очына утырды да, булмаса булган икән, дигәндәй, белгәннәрен укый башлады:

— Бисмиллаһир-рахман ир-рахим. Колһуаллаһе әхәде, аллаһе сама-де, ләм җәлиде вә ләм җүләде вә ләм җәкүн ләһү көфүүән әхәде...

Гаделбану саташа да саташа... Шаһимөхәммәт инде дога укуын да онытты, карчыгының сөйләгәнен дә ишетми башлады, уйлары белән генә кемнедер каһәрләп утырды.

Кемгә кирәге булды соң монын? Кемнәргә генә кирәге булды авыл бетерүнең, авыл күчерүнең? Кешедән аерылган кеше — кеше була димени! Адәм балалары гомер-гомергә бер-берсенә елышып яшәгәннәр бит. Кабилә белән кабилә, ыру белән ыру бер тирәдә булган. Сәбәпсезгә ата-баба иленнән аерылып китүчегә мәңгегә дә фатиха бирмәгәннәр. Кире әйләнеп кайтып тезләнмәсә, гафу да итмәгәннәр. Әнәледән киткәннәр кем алдына кайтып тезләнер? Кемнән гафу үтенерләр дә кемне гаепләрләр?...

Шулай уйлана-уйлана, Шаһимөхәммәт карт калак сөяге астында нидер чәнчешкәнен һәм үзенең дә аңы томалана башлаганын сизде...

Керосин лампасы бер-ике тапкыр «леп-леп» итеп алды да сүнде.

Төн буена шыбыр тирдә яткан Гаделбану карчык икенче көнне кояш төшлеккә житкәч кенә йокысыннан уянды.

— Бигрәкләр дә озак йокланылган икән, сиңайтәм. Баллап эчкән чәйнең шифасы бигрәкләр дә бар шул, аллага шөкер. Сиңайтәм, син өйдә юкмыни?

Гаделбану карчык, караватыннан төшүгә, идәндә сузылып яткан картын күрде.

— Әстәгъфирулла тәүбә, сиңайтәм!

Карчык бүтәнчә берни дә әйтә алмады. Идәнгә утырды да кулын картының башына салды. Аннары, сак кына итеп, картының ачык калган күзен йомдырды, кулларын күкрәк турысына күтәрде. Шунда гына әрнеп, яшь аралаш:

— Көтмәдең, киттең...— дип пышылдады.

Бу аның картына үз гомерендә икенче һәм соңгы тапкыр үпкәләве ләбаса. Ләкин учагы сүнгән бу йортта аның сүзләрен ишетер кеше юк иде инде...

# САГЫНУ ТУДЫРГАН ҖЫР



**Фәрдия Сәфәргалиева — Арча якларында туып үскән кыз. Әмма язмыш аны озак вакытлар туган җиреннән аерып, «читтә йөртә»: ул Ульяновскида яши, урыс мәктәпләрендә — математика, әмма үз балаларына туган җиргә, Татарстанга мәхәббәт һәм ана теле дәресләре бирә. Туган телдән читләшкәннәрне дә кабат уяныргa, җыр-моңга чакырып яши: татар теле түгәрәкләре оештыра, Сембер ягында узган җыр конкурсларында катнашып, җиңүче була. Аннары хисләре шигырьгә күчә — көндәлек матбугатта күренә башлый... Бүгенге көндә ул — газиз мәркәзебез Казанда. Фәрдия хәзер — Милли мәдәният үзәгендә, гомер буе омтылган — үз халкына, туган телгә хезмәт итү мәйданында.**

**Шигырьләре турында шуны гына әйтеп буладыр: туган җирне сагыну, мәхәббәт хисе уяткан сурәтләр. Аларда читтә яшәгәннәр халәте! Гыйбрәтле язмыш сәхифәләре, бәлки...**

**Бу — аның шигъри юл башы.**

**Ә дәвамы — хәзер яшь шагыйрәнең үз кулында. Ныклы адымнар өчен дә Фәрдиянең тумыштан сәләте бар дип саныйм. Шул ышаныч белән язам бу кереш сүземне.**

**Рәдиф ГАТАШ.**

## Фәрдия

### Бәлки...

Мин дә юк буласы — мәңгелектә...
Мин дә кушылырмын — Җиремә.
Тик, нигә соң, кабат яшәр кебек,
Киләчәккә күңел җилкенә?
«Бүгенгесе әле чын түгелдер,
Ямьлерәге әле алдадыр», —
Әнә шундый яшерен уй-хыялга
Гомер буе күңел алданыр.
Мин дә юк буласы. Җирдә — гөлгә
Әйләнермен аннан, кем белә?
Бәлки әле башка бер сурәттә

Кабат кайтырмын мин илемә?...
Кабат йөгерермен тар сукмактан,
Ялан тәпи, инеш буена.
Кабат шашып-шашып сөенермен
Таң атуга, сабан туена...
Кабат сокланырмын. Төнге күкнең
Шаян йолдызларын санармын.
Язын кабат талның «песиләрен»
Гаҗәпләнеп, үбеп назлармын...
Бәлки, кабатланыр яшьлек язы,
Бәлки, кабатланыр ул таңнар?...
Бәлки әле минем шатлыгымны
Кабат уртаклашыр бу таулар?...

## Белеп яшә

Болыннарга күз сал,
шатлана бел.
Чәчәкләргә карап
соклана бел.
Кош сайравын тыңлап
моңлана бел,
Гомеркәйләр уза,—
кадерен бел.
Ялгыз картлык күреп
кызгана бел,
Сабыйларга карап
уйлана бел.
Тормыш яме гел өстәлеп торсын,—
Шатлана бел,
сөя-соклана бел!

## Туган якта

Үләннәрнең иң яшеле — анда.
Чәчәкләрнең иң гүзәле — анда.
Таңнары да аның башкачарак,
Язларның да ямьлерәге — анда.
Җилләрнең дә иң җылысы — анда.
Көйләрнең дә иң моңлысы — анда.
Төнге йолдызлары да яктырак,
Сандугачлар өздереп сайрый анда.
Татлы сулы чишмәләр дә — анда.
Җыр-биюле кичәләр дә — анда.
Серле күзләр карашы да — анда.—
Туган җирне сагыну — безнең канда.

## Адаштырды

...Адаштырды әллә синең күзләр,
Киттем мәллә юлдан читкәрәк?
Йә сукмакларыңмы таррак булды,
Узалмаслык булды бергәләп?!

## Сәламемне тапшыр

Ай йөзә, аны болытлар
Иркәлиләр, ярышып...
Ай гынам, син сәламемне
Тапшыр, үтеп барышлый,
Минем туган авылыма,—
Аның урамнарына.
Туган йортның тәрәзәсен
Төр син ак нурларыңа?!
Минем сәламемне тапшыр,
Сагыну-сагышларымны...
Мин сиңа өзелеп карыйм,—
Җиткер карашларымны?!

## Елларымны югалтма

Аптырама ни булды дип,
Бик сагышлы көннәрем:
Гүзәл җәйләр үтеп бара,
Шиңәр инде гөлләрем.

Гаҗәпләнмә уйларыма,
Тынычлан, дип юатма.
Тик... сиңа бүләк ителгән
Елларымны югалтма!..

## Читкә киткәннәр сүзе

Таңнарында моңаябыз,
Карап туган якларга.
Тын кичләрдә дә ямансу
Бик сагынган чакларда.
Туган-үскән җиребезгә
Без мәңге бурычлылар.
«Кайтырбыз»,— диеп яшибез
Без, читтә торучылар...
Шул өмет чаткысы безнең
Җылыта күңелләрне.
Кичер, туган-үскән җирем,
Бездәй читтәгеләрне...

# ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ XII СЪЕЗДЫ АЛДЫННАН

Инде хәбәр иткәнебезчә, 1994 елның май аенда Татарстан язучыларының XII съезды җыелачак. Шул уңайдан редакция язучыларга түбәндәге сораулар белән мөрәҗәгать иткән иде:

*1. Язучыларыбызның XI съезддан соң үткән биш елдагы иҗатына һәм аерым әсәрләргә карата Сез нинди фикердә?*

*2. Әдәби процессны оештыру ягыннан бу елларда Татарстан Язучылар берлеге һәм әдәби басмалар башкарган эшләрдән Сез канәгатьме? Сезнеңчә, XI съезд карарлары ни дәрәҗәдә үтәлде?*

*3. Әдәби фондның алдагы эшчәнлеге нинди булырга тиеш?*

*4. Алда торган съездда Сез нәрсәләр көтәсез?*

*5. Иҗат берлегебез татар әдәбиятын тагын да үстерү өчен нинди мөһим чаралар үткәрергә тиеш дип саныйсыз?*

Түбәндә редакциягә килгән кайбер җавапларны урнаштырабыз.

## Гөлшат Зәйнашева:

1. Татар язучыларының ике съезды арасында иҗат эшләренең ничек баруы турында сүз әйтү өчен, иң элек ике съезд арасында дөньяда булып узган төрле үзгәрешләр турында әйтеп китәргә кирәктер. Дөнья астыөскә килгән шикелле төрле үзгәрешләргә дучар булды. Элеккеге СССР сәяси яктан бөтенләй башка юнәлеш алды, социалистик идеология инкарь ителде. Коммунизм төзү өчен көрәш идеологиясенең купшы хыял гына икәнлеген аңладык, бу көрәштән баш тарттык. Социализм, коммунизм идеологиясеннән баш тарткан бу елларда, гомумән, идеологиясезлеккә килеп чыктык шикелле. Хәзерге көндә нинди идеологиягә нигезләнгән безнең яшәү рәвеше?.. Бу җәһәттән кешеләр аңында билгесезлек көчәйде кебек. Иҗат кешеләре алдында да шундый билгесезлек тора булса кирәк. Нинди идеал өчен иҗат итәргә?.. Бу хәл язучыларның иҗат эшенә шактый комачаулый. Әмма ләкин, миңа калса, иҗат кешесенең йөрәгендә үз идеалы, үз иманы булырга тиеш. Нинди генә система булмасын, нинди генә идеология җитәкләмәсен, халык тормышында һәр заманны һәм һәр ил халкы өчен уртак булган мәңгелек әхлак кануннары бар: кешеләр арасында дуслык, татулык, бер-береңә хөрмәт, ата-анага, өлкәннәргә мәрхәмәтлелек, үзеңнән көчсезләргә ярдәм-шәфкатьлелек, намуслы хезмәт белән яшәү һ. б. Кешелек кануннары — иҗат кешесенең идея юнәлешен билгели торган кыйммәтләр. Шул кыйммәтләргә таянып иҗат иткән һәр иҗатчы үзенә идеал таба ала һәм дөньяда сәясәтләр үзгәреп, әллә нинди системалар барлыкка килгәндә дә югалып калмый. Безнең татар әдәбиятында күпчелек язучылар югалып калмыйча, үзләренең иҗат эшләрен дәвам итәләр. М. Хәбибуллин, Р. Батулла, А. Гыйләҗев, Р. Мөхәммәдиев, К. Тимбикова, Г. Тавлиннар яңа роман-

нарын язып, укучыга тапшырдылар. Рәшит Әхмәтҗанов, Р. Фәйзуллин, Л. Шагыйрьҗан, К. Сибгатуллин кебек шагыйрьләр ялкынлы шигырьләре белән шигърияттә мәйдан тоталар.

Бу елларда татар әдәбиятының элек күп еллар дәвамында ирешкән уңышларын шик астына кую, кайбер әдәби кыйммәтләрне тарихтан сызып ташлау кебек омтылышлар булды. Мондый омтылышларны мин хупламыйм. Һәр чорның әдәбиятта үз чагылышы булган. Бер селтәнү белән үткән еллардагы әдәби байлыкны чүплеккә түгәргә омтылу — коендырган суың белән бергә баланны чыгарып ыргыту шикеллерәк. Әдәби мираска караш кешелекле һәм гадел булсын иде.

2. Оештыру эшләренә килсәк, ике съезд арасында әдәби хәрәкәт шактый сүлпәнәйде дип уйлыйм. Язучы халкы әлеге дә баягы идеологик әйдәп баруга күнеккән. Соңгы елларда аны әйдәп баручы идеологик оештыручылар юк. Язучылык хезмәте үз агымына куелган. Бу бер караганда яхшы, язучы үзбаш хәрәкәт итә. Икенче яктан караганда, әдәби хәрәкәтне оештыру язучыны активлаштырыр иде. Әйтик, жанрлар буенча секцияләрнең эшләве, башлап язучылар өчен семинарлар үткәрү, теге яки бу әсәр буенча конференцияләр үткәрү файда гына китерә бит. Ә ике съезд арасында бу эшләр сүрелде. Секция утырышлары сирәк уздырыла. Башлап язучылар, яшьләр белән эшләү дә сизелерлек сүлпәнәйде.

3. Әдәби фондның киләчәге ничегрәк булырга тиештер, мин өзеп әйтә алмыйм. Ләкин шунысын әйтеп китәм, кайбер язучылар: «Литфонд нигә кирәк, Язучылар союзы нигә кирәк?», «Таратырга кирәк аларны»,— дип тә әйткәлиләр. Булганны тарату җиңел ул. Гомумән, тарату, җимерү җиңел эш. Ә менә булдыру, оештыру, төзү җиңелдән түгел. Кемнәрдер ул оешмаларны төзегән, булдырган, бүген тот та җимер, имеш!.. Җимерергә остарып китте адәм баласы!.. Җимерүен җимерә, ә җимерелгән урынына нәрсә булдыра!?. Мин Әдәби фондны да, Язучылар союзын да сакларга кирәк дип табам. Сакларга һәм яхшы юнәлештә аларны үстерергә, камилләштерергә кирәк. Әдәби фондтан файда күрдек, зыян күргәнебез юк бит әле. Күреп торабыз, күмү дигән йоланы үтәү нинди кыен, нинди зур чыгымнар сорый. Үлмик әле, анысы, яшик. Мин бу сүзне Әдәби фонд эшенең әһәмиятен аңлату өчен мисал итеп кенә китердем.

4. Киләсе съездан нәрсәләр көтәм?.. Алда әйтеп киткән таркаулык бетсен иде. Әдәби хәрәкәттә җанлылык булсын иде. Идарә составына бүген иҗат итеп килгән иң актив язучылар, эшлекле кешеләр сайлансын. Китап чыгару эше җайга салынсын иде. Юкса, соңгы елларда язучыларыбыз китапларын дөньяга чыгара алмыйча җәфаланалар. Язучылар идарәсе бу эшкә игътибар итәргә бурычлы. Нәшрият җитәкчеләре белән бергәләп, китап чыгару эшен тиешле югарылыкка куйсын иде. Китап «базар мөнәсәбәтләре» дигән давыллы-җилле диңгездә йомычка хәлендә калырга тиеш түгел, китапның рухи тормышыбызда үз урыны булырга тиеш. Китап — милләтне тәрбия итү коралы. Шушы хакыйкатьне онытмыйсы иде. Бу эшкә яңа съезд төпле юнәлеш бирер дип өметләнәм.

5. Җавабым бик гади: яхшы әсәрләр язарга кирәк! Халкыбыз яратып укысын, үзенә рухи азык алсын — менә шундый әсәрләр иҗат итәргә!..

## Мәгъсүм Хуҗин:

1. Ике съезд арасында татар әдәбияты, минемчә, өч хикәягә баеды. Мин хикәяләр турында гына искәртәм. Менә алар: Зиннур Хөснияр — «Трагедиягә ике билет» («Ватаным Татарстан» газетасы), Ләис Зөлкарнәй — «Ак карга» («Ялкын» журналы), Ркаил Зәйдулла — «Шаһгали» («Идел» журналы). Биш елда әдәбиятның байлык шүрлегенә өч хикәя тезү аз түгел. Һич тә аз түгел! Әлеге хикәяләрне яшь буын язучылары иҗат итте. Димәк ки, диик, алар китап киштәсенә исемен алга каратып

куярлык әсәрләрне тагын да язарлар әле. Өч егетнең дә кулларындагы кавырсын каләмнәр гел асыл кошларныкы булсын!

2. Бу сорауга съездда хисап тотучы иптәшләр җавап бирерләр, шөт. Һәм алар сөйләр сүз табарлардыр. Шулай да узган съездда язучылар белдергән кимендә ике теләк-таләп тәгаен җавапсыз калмасын иде. Мин съездның язучылар нәшрияты булдыру һәм әдәби газета чыгару турындагы карарларын күз алдында тотам. Шушы ике эш кенә тормышка ашкан булса да, әдәбиятның үсеше турында күкрәк киереп, борын чөеп, күккә текәлеп мактану да гафу ителер иде.

...Борчылырлык хәлләр күп шул...

Шушы арада гына Михаил Пришвинның 1937 елгы көндәлекләрен укыдым. Сталин конституциясенә гаҗәеп төгәл бәя бирә ул һәм моны М. Пришвин, кем әйтмешли, көн кадагына сугып эшләгән. Безнең көннәрдә дә конституцияләр кабул ителә. Әмма безнең аларга җентекле бәябез юк. Шуны көндәлеккә генә булса да нигә язып куймыйбыз икән? Ялкаулыкмы бу, әллә куркаклыкмы? Икенчесе икән — монысы инде коточкыч хәл...

Соңгы елларда күп әдәбиятлар элек язылып та бастырылмаган әсәрләр исәбенә дә баеды. Бездә исә андый әсәрләр юк дәрәҗәсендә икән. Әллә аларны, егетлек күрсәтеп, вакытында бастыра барганбызмы? Нигәдер андый әсәрләр искә төшми...

Борчулы хәлләр турында Язучылар берлеге идарәсенең әңгәмә корулар оештыруы зыян итмәс иде, әлбәттә. Әдәби хәрәкәт дилбегәсе шул идарә кулында булырга тиеш, ләбаса.

3. Әдәби фондның үз Уставы бар. Аның бурычлары-вазифасы төгәл күрсәтелә анда. Шулар үтәлсә, Татарстан Әдәби фондын мактарга сүз таба алмыйча аптырарсың, әкәмәт...

4. Ыбыр-чыбырны онытып, эшлекле сөйләшү-киңәшү нигезендә, әдәби хәрәкәтне ташкын кодрәтенә ия итәрлек карарлар кылынуын көтәм.

5. Сез әйткән «мөһим чаралар үткәрү» турында съездда барлык язучыларның бергәләп фикерләшүе хәерле.

## Роберт Әхмәтҗан:

1. Сәясәттә дә, икътисадта да бик тынгысыз, өермәле еллар булды. Барча халыкның башы әйләнеп бетте. Бу хәл безнең әдипләргә дә бик нык тәэсир итте. Күпләрнең күңеле төште, байтак каләм иясенең кыйблысы, ышанычы югалды. Шуңа күрә иҗади активлык та нык кимеде. Мин дә соңгы биш ел эчендәге иҗади казанышларны аерым әсәрләргә конкрет тукталып дәлилли алмыйм. Әмма шигърият өлкәсендә булган табышларыбыз бәхәссез. Ә исемнәргә килсәк, шул ук безгә таныш, башта ук «алдырып киткән» исемнәр... Ә конкрет вакыйга булган әсәрне белмим. Иҗади активлык «көтү» рәвешен алды — көтү бара, тузан күтәрелә...

2. Оештыру эшеннән мин канәгать түгел. Бездә таркаулык ел саен үсә бара кебек. Ә бит берләшергә, туплана төшәргә иде безгә! Әлбәттә, мөстәкыйльлегебезне яклауда, чын иҗатны төрле шаблон-суррогатлардан аеруда безнең чын милли журналыбыз «Казан утлары» зур көч куя. Бүгенге иҗади хәрәкәттә, шөкер, ул әле дә булса әйдәп бара.

3. Әдәби фондның офыгында, һичшиксез, өмет яктысы ачылсын, сейфы күгәрмәсен, аны үзара тутырышып яшәргә язсын иде.

4. Алда торган съезд иң элек иҗат эшен — коммерциядән, акны карадан аерырга ярдәм итсен. Ул безгә һәр ялтыраганның алтын түгеллеген һәм чын талантның да кәсепче түгеллеген аерып бирсен иде.

5. Хәзер безгә талантларны үз тирәбезгә күбрәк тупларга, бүгенге анархия шартларында «язучы» исеменең абруен күтәрергә, яхшы әсәрләрне вакытында күреп алырга һәм аларны тиешенчә бәяли барырга кирәк.

**Камил Кәрим:**

1. Минемчә, татар язучыларының байтак әсәрләре дөнья күрмичә, авторларның үз кулында калды. Соңгы биш ел яңа иҗат шартларына күнегү (адаптация) чоры гына булып саналыр төсле. Җитмеш ел буена өстән әйткәнне генә язарга күнеккән язучыга биш кенә ел иректә йөрү азрак шул. Әгәр алга таба да иҗат иреге сакланса, укучыларның бездән яхшы әсәрләрне аяк терәп таләп итәргә хакы бар. Мин газета-журналларда һәм радио-телевидение аша мактап телгә алынган, сыйфат тамгасы сугылган әсәрләргә табынмыйм. Шулай да, ике съезд арасында чәчмә һәм сәхнә әсәрләре ныгыбрак калды дип исәплим.

2. Әлегә язучылар армиясен туплау гына бара. Ул армиядә солдатларыбыз да, генералларыбыз да бер киемнән йөри. Язучыны дәрәҗәсенә карап сәламләү дә җитенкерәми хәтта — чөнки һәркем үзен бөек дип саный. Бу армия базар лидерлары тарафыннан сайлау баталияләре өчен тупланды. Шуңа күрә Язучылар оешмасы күпмедер дәрәҗәдә декоратив оешмага әверелеп калды.

Безнең бик күп идеалларыбызны перестройка тәгәрмәче таптап үтте. Шулай да, бүгенге тәртипсезлекнең бер уңай ягы бар: язучыга хәерчелек янаса да, эшсезлек янамый! Ике съезд арасында «профессиональ язучы» дигән төшенчә юкка чыкты. Пенсиядәге язучыларыбыз да журналист булып эшкә урнашып беттеләр! Элек язучы кешегә эш табуы бик кыен иде бит...

Унберенче съездда нинди карарлар кабул ителүен хәтерләмим инде... Язучылар оешмасының нинди эшләр майтарганын да идарә әгъзалары яхшырак беләдер, чөнки соңгы елларда гомуми җыелышларга чакырылганыбыз юк.

3. Язучылар оешмасының киләчәген, гомумән, Әдәби фонд буларак күз алдына китерәм. Язучыны социаль яклау белән элек-электән Әдәби фонд шөгыльләнде. Ә идарә һәм аның рәисе Әдәби фонд өстеннән идарә итүче, абруй өләшүче даирә булып калды. Ике съезд арасындагы болгавырда Әдәби фондның бердәнбер кирәкле һәм эшлекле оешма булып калырлык мөмкинлеге бар иде. Кызганычка күрә, Әдәби фонд үзенең ныклы сүзен әйтә алмады.

Телибезме, теләмибезме — язучыларга, барыбер, берәр оешмасыз яшәү мөмкин түгел. Сыра сөючеләрнең дә партиясе төзелгән бу заманда берләшмичә, таркау хәлдә ничек дөнья көтмәк кирәк?!

4. Дөресен генә әйткәндә, мин алдагы съезддан әллә ни көтмим. Съезд ул, миңа калса, Язучылар берлегенең идарәсен һәм рәисен сайлау буенча бер баталия гына (махсус кабатлыйм). Съездны аны үткәрергә була, үткәрмәскә була. Вакытыннан алда җыярга һәм куып таратырга да мөмкиндер. Язучының иҗат мөмкинлеге, сәләте исә съезд карарларына гына бәйләнмәгән. Кулыңнан килә икән — яз, сәләтең бар икән — укучыңны тап, яшисең килә икән — базарга кер...

5. Бүгенге үзгәрешләр белән килешкән дәвердә Ходайдан һәм Президенттан бер генә нәрсә сорарга туры килә: инде язучының яшәү шартын, фатирын, гонорарын арттыра алмыйсыз икән, һич югы үзебезнең җөмһүрияттән ерак китмичә генә бер Иҗат йорты булдырылса иде...

## ПУБЛИЦИСТИКА



**Флүс Латыйфи**

**Ринат Якуш**

# ШЫГЫРДАН ФЕНОМЕНЫ

**Тел авылда туа,**
**Шәһәрдә үлә.**

Татар теле өчен бүгенге көндә шәһәр үлем белән бер. Ул монда бер буыннан артык бара алмый. Икенче буын инде ярым-йорты телле. Татарчасы өйдә аңлашырлык кына булыр. Алардан туган буын исә тулаем диярлек телсез. Тел яшәсен, үссен, тәрәккый итсен өчен шул телдә аралашучы, шул тел кануннары белән яшәүче тотрыклы бер җәмгыяви уртаклык булу кирәк. Ә татарда бармы соң ул? Шәһәрләребез тоташ урыслашкан. Татар шәһәрләре юк. Әле бүгенге көнгә хәтле телебез үлмәгән, терелергә, аякка басарга азапланып ята икән, моның өчен без тулаем авылга бурычлы. Татарның йолалары да, гореф-гадәтләре дә — барысы да авылдан. Тамырларыбыз безнең тирәндә, еракта. Аларның очы Себердән Әстерханга сибелгән татар авылларында.

Ләкин, ничек кенә булмасын, әйткәнебезчә, тел яшәсен өчен, үссен, баесын өчен шул телдә сөйләшүче һәм сан ягыннан җитәрлек дәрәҗәдәге тотрыклы җәмгыять, кешеләрнең этник яктан чиста уртак бер яшәү урыны булырга тиеш. Менә монда да безгә тагын карашыбызны авылларга юнәлтергә туры килә. Үзләренең географик тоткан урыны, кеше санының күплеге һәм этник чисталыгы белән культурабыз үсешендә, телнең, гореф-гадәтләребез һәм йолаларның саклануында татар дөньясында шәһәрне алыштырырдай авыллар бар. Һәм, сөенечебезгә, алар шактый күп. Биредә без рәсми культура үзәге саналучы район үзәкләрен күздә тотмыйбыз. Аларда читтән кертелгән советча йолалар да, һәм шул ук вакытта кайсы каян килгән, бер-берсенең тамырын, нәсел-нәсәбен белмәгән кешеләр дә җитәрлек. Алар гасырлар төпкеленнән үк килүче йолалар нигезендә берләшкән гомуми уртаклык хасил итә алмыйлар.

Сүзебез Чувашстанның Шыгырдан, Татарстанның Шәле, Пенза өлкәсенең Әләзән кебек авыллары хакында. Нәкъ менә шушы авыллар тирә-як төбәк өчен шәһәр хезмәтен үти башлаган да инде. Алар татарлар күпләп, тупланып яши торган җирләр.

## Иске карта хатирәләре

Шыгырдан — шактый борынгы авыллардан. Картлар сөйләвенә карагында, аңа 16 гасыр башларында нигез салынган булса кирәк. Авылда җиде-сигез буын бабасын хәтерләүчеләр дә, аларның исемнәрен кадерле бер истәлек итеп саклаучылар да җитәрлек. Аларның шәҗәрәсен исәпләгәндә генә дә гасыр төпкелләренә байтак тирән төшәргә туры килә. Һәрхәлдә, болар килмешәк түгел, ә борын-борыннан шушы якларда көн итүчеләр. Казан дәүләтенең шаулап чәчәк атып утырган еллары да, Казан каласының егылуы да шыгырданлыларның бабалары хәтерендә, буыннан-буынга тапшырылып килгән. Шуңа күрәдерме, мондагылар авыз тутырып, «хан заманыннан ук», дип сөйлиләр. Моның белән кайчагында нәрсәнеңдер борынгылыгын, искелеген аңлатырга теләсәләр, кайсыбер очракларда исә бу җирләргә безнең хокукыбыз хан заманыннан ук килә, дигән мәгънәне дә салып җибәрәләр.

Әле безнең татар авыллары тарихын ачыклыйсы, архивларда казынасы, картлар телендә генә йөргән риваятьләргә, сандык төпләрендә кадерләп саклан-ган документларга фәнни нигез бирәсе, тирәннән анализлыйсы бар. Алары киләчәк эше.

Ныклап эзләнсәң алар һәр авылда бар. Шыгырданда безгә моннан нәкъ 110 ел элек төзелгән землемер картасын күрсәттеләр. Яңа утарлар өчен җир бүлеп бирү турындагы бу документка, шаһит буларак, авыл укымышлыларыннан ике кеше кул куйган. Аларның берсе — заманында урысча да укый-яза белгән Ибрай Алие дигән кеше булган. Бу карта исә шул Ибрай Алиенең шәҗәрә җебен бүген дәвам иттерүчеләрдә — аның нәселендә кадерле бер ядкарь итеп саклана. Аны безгә бу нәселнең төпчек улы Наил бик кадерләп, уалырдай әйбер тоткандай сакланып кына күрсәтте.

Үткәннәргә, истәлек-хатирәләргә шундый сак караш булганда гына бүгенгенең борынгыга барып тоташканлыгын аңларга, борынгылыкның бүгенгедә дәвам иткәнен төшенергә була торгандыр да. Ә мондый сыйфат, гадәттә, үзен нәселенең дәвамы итеп санаучы, борынгы бабалары кылганнар белән горурлана алучы укымышлы затларга гына хас. Халык буларак халыкны шундый сыйфатлар саклый.

Еллар үтү белән инде саргая башлаган калын кәгазьгә Шыгырдан авылының ул чорда ничек урнашуы бик тәфсилләп төшерелгән иде. Аның җыерылган җирләрен учларыбыз белән тигезләп, бик сирәк очрый торган документны өйрәнергә керештек. Аның югары өлешенә каллиграфик почерк белән «Землеустроительная схема села Шихирдан Буинского уезда Симбирской губернии» дигән сүзләр язылган иде. Акка кара белән авылда 400 хуҗалык булуы теркәлгән, тагын унбишләп кешегә җир бүлеп бирелүе күрсәтелгән. Һәр кишәрлеккә номер сугылган, иясенең фамилиясе язып куелган иде.

Дүрт йөз хуҗалык! Үз чоры өчен генә түгел, бүгенге көн өчен дә шактый зур сан бу! Әгәр ул заманнарда һәр гаиләдә кимендә биш-алты бала үскәнне, әби-бабаларның бер түбә астында яшәгәнлеген искә алсаң, инде моннан йөз еллар элек үк Шыгырданның тирә-яктагы иң зур авыллардан булганлыгын ачыклау кыен түгел.

Бүгенге көндә хәл ничегрәк? Бүгенге Шыгырдан башка авыллардан кайсы ягы белән аерылып тора? Ни өчен ул безнең игътибарны җәлеп итте соң әле? Шыгырданның үзенчәлекләре исә, чыннан да, байтак. Шуларның беренчесе, әйткәнебезчә, аның татар дөньясында иң зур авыллардан булуы. Хәзерге вакытта Шыгырданда 5116 кеше яши, 1310 хуҗалык исәпләнә. Ләкин авыл үсүдән туктамый. Әле быел гына да тагын 116 хуҗалыкка нигез салынган. Авылның һәр тарафында яңа йортлар күтәрелә. Шыңгырдап торган нарат бүрәнәләрдән дә, ап-ак кирпечтән дә шәһәр коттеджларына биргесез менә дигән йортлар калкып чыга.

Авыл Советында безгә тагын бер сан әйттеләр: Шыгырданның бөтен биләгән җирләре — нибары 4016 гектар. Шулардан авыл хуҗалыгы өчен яраклылары өч мең гектар чамасы. Тагын 27 гектарда урман, ике буа, күлләр, авыл аша агып ятучы Юхма суы һәм якында гына Бола елгасы бар. Боларны санауның аерым мәгънәсе бар: кеше башына күчереп исәпләгәндә, хәтта бер гектар да җир туры килми. Ә Шыгырдан һаман үсә, матурая һәм... шактый мул тормышта яши дә. Сәбәпләре нәрсәдә? Шыгырданлыларны авылга нәрсә бәйләп тора? Яхшы һәм житенкелекле тормышны алар кичек кора.? Безгә мәгълүм түгел нинди серләре бар?

Менә шушында Шыгырдан табышмагы башлана да инде.

Жирсезлектән, ярлылыктан туйган халык күпләп-күпләп, оялап-оялап читкә китми, тырышып-тырмашып дөньясын шушында корырга омтыла, авылга ябышып ята. Авыл башлыклары, колхоз житәкчеләре белән сөйләшкәндә дә, инде ашыйсын ашаган, яшәсен яшәгән, ялга чыгып, балалары тәрбиясендә генә ятасы картлар белән очрашканда да, дөнья йөген жигелеп тартучы яшьләр белән күрешкәндә дә, Шыгырдан табигатен, аның чишмәләрен, елгаларын-күлләрен карап йөргәндә дә без менә шуларны ачыкларга тырыштык.

Нәрсә тарта авылга шыгырданлыларны? Кабатланмас табигатеме, әш сөючән кешеләрнең бер-берсенә ярдәмчеллегеме, әллә берәр башка сәбәпме?

## Чишмәләр ни сөйли?

Читкә китеп гомер уздырган кешеләрнең олыгаеп, тән-сөякләре, кан тамырлары таушалып тузгач: «Үз чишмәмнең суын эчсәм, тәнем сихәтләнер иде»,— дип ерактан йөрәк авазлары салуы бер дә гаҗәп түгел. Үскән чакта ул кешенең тән күзәнәкләре әнә шул чишмә суының микъдарыннан ясалган, формалашкан. Әнә шуңа күрә борын-борын заманнан алып чишмә халык җырларына керә килгән.

Тау астында салкын чишмә
Челтер-челтер агадыр,—

дип җырлаган халыкта чишмә инде, әлбәттә, матди байлык — эчәр өчен су чыганагы гына түгел, ә рухи, поэтик байлык чыганагы да. Кайбер чишмәләрне гомере буена бер кеше караган, бу шөгыль атадан улга, оныкка күчә килгән. Шулай чишмә исемнәре туган: Гали чишмәсе, Сафый чишмәсе, Фазыл чишмәсе ...

Язучы Мөхәммәт Мәһдиевнең бу сүзләре әйтерсең нәкъ менә Шыгырдан турында. Шыгырдан чишмәләре хакында.

Табигать Шыгырданны рәнҗетмәгән. Кайчандыр атлар йөздерерлек булган Бола суы да, авылны урталай ярып агучы Юхма инеше дә, бихисап чишмәләр дә аларның мактанычы, авыл бизәге. Юхма суы ярындагы тауда кайда төртсәң, шуннан чишмә килеп чыга. Әйтерсең табигать үз балаларына мәрхәмәтен шулай күрсәтә. Чишмәле авыл — бәрәкәтле авыл.

Яз көне иде. Асфальт юлдан чыгып, әле кибеп бетмәгән юеш җир өстеннән корырак урыннарны сайлый-сайлый, тар сукмактан тау астына төшәбез.

— Монысының суы йомшак. Чәйгә шушыннан алалар. Яшь кызлар-киленнәр дә, карт-карчыклар да шушыннанрак алырга тырыша.

— Әнә тегесенең бурасын безнең әти ясап куйган иде,— дип куйды әңгәмәдәшебез, Шыгырданда туып-үскән яшь шагыйрь Рөстәм Сүлти.— Бездә һәр чишмәнең үзенә күрә хуҗасы бар.

Рөстәмнең әле күптән түгел генә Казанда беренче шигырь китабы басылып чыккан көннәр иде ул. Аның беренче иҗат үрнәкләрен туплаган китапның нәкъ менә «Мин шигырьдән» дигән юллар белән ачылуы да очраклы түгел.

Чын мишәрең булалмадым инде,
Моңсу мишәр шул мин, Шыгырдан.
— Син кайдан? — дип сораганнар өчен
Тик бер җавап миндә:
— Шигырьдән!
Изге сүзнең яңгырашы синдә —
Үпкәләмә мина, җан парәм,
Синнән кичсәм — шигырь хәрәм булсын,
Шигырьләрдән кичсәм — син хәрәм ...

Әйе, яшь шагыйрьнең авылына, авылдашларына биргән шушы шигъри антыннан да яхшырак итеп әйтеп булмый торгандыр. Бер тамчы суга бөтен җир шары сурәте сыйган кебек, Шыгырданга да барысы да сыйган: дөнья йөген җигелеп тартучы ирләр дә, эшкуар егетләр дә, лирик шагыйрьләр дә, математиклар да, хыялый һәм назлы кызлар да, нечкә күңелле, мәрхәмәтле аналар да... Барысының да язмышы җепләре шушында тоенләнгән.

Кизләү-чишмәләр карап йөрибез. Ә уйлар өермәдәй бөтерелә. Чувашстанның урманлы-таулы бер төбәгеннән татар мәдәниятенә, фәненә килгән шәхесләрне барлыйбыз. Шыгырданлылар авылдан 28 фән докторы һәм кандидаты чыгуын горурланып сөйлиләр. Ә аларның берсе — Ригадагы хәрби һава көчләре академиясендә профессор булып эшли, ныклык теориясеннән белем бирә. Гомумән, авылдан чыккан галимнәрнең нигездә физика, математика һәм медицина өлкәсендә эшләүләрен әйтеп узарга кирәк. Боларның да нигезләрен ачыклыйсы бар.

Яшьләрнең нәкъ менә шушы фәннәргә тартылуында татарның дөньяга аек күз белән каравы, эшчәнлеге һәм борынгыдан килгән сәләте дә ятмыймы икән?! Аларның тууына, бу төбәкләрдән әдәбиятыбызга яшь шагыйрьләр килүендә шушы чишмәләр, кеше кулы җылысын тойган шушы агачлар, туган телдә, ата-аналар рухын саклап эшләп ятучы шушы мәктәпләр сәбәп түгелме?!

Һәм, ниһаять, шушы чишмә сулары да тартмый микән Шыгырдан кешеләрен туган якка! Шулайдыр! Бер авыз иткән су үз янына кабат чакыра торгандыр.

## Чкаловтан Шыгырданга, Ждановтан «Байрак»ка

Колхоз идарәсендә сөйләшеп утырабыз. Хуҗалык җитәкчесе басса бакыр изәрлек, типсә тимер өзәрлек баһадир ук булмаса да, нык бәдәнле, кыяфәтеннән көч һәм дәрман ташып торган ир уртасы булып килүче Ринат Сыраев сорауларыбызга сабыр гына җавап бирә.

Аның ашыкмый, кабаланмый, һәр сүзне үлчәп, белеп сөйләгәннәреннән Шыгырданның татар дөньясыннан бер генә мизгелгә дә аерылып тормавын, монда дөнья рәтен белүче кешеләр яшәгәнлеген аңлыйсың.

Шыгырдан — чуваш илендә, чуваш арасында татар утравы, татар дөньясы. Монда Татарстандагыларга караганда да татаррак булып яшиләр. Колхоз идарәсе, авыл советы янындагы барлык язмалар үзебезчә, татарча. Сап-сары бүрәнәдән, кирпечтән зәвык белән салынган пулат-пулат йортлар өстеннән дә күтәрелеп, тирә-якка ямь биреп утыручы мәктәпләр дә татарча эшли. Авылдан чыгу юлында исә туган телебездә «Хәерле юл» теләгән язма озатып кала.

— Безнең колхоз элек Жданов исемендә иде. «Байрак»ка алыштырганга инде ике еллап булыр,— дип башлап китте Ринат Сыраев.— Ә быел референдум вакытында авыл исемен дә кайтардык. Җитмеш сигез процент халык исемне кайтаруны яклап тавыш бирде. Хәер, Чкалов авылы дигән исем рәсми язулардан башка беркайда да кулланылмады. Ничек Шыгырдан булса, шул Шыгырдан көйгә йөри бирде. Безнең халык бер гадәткә кергән нәрсәдән тиз генә аерылмый. Алтмыш еллап вакыт узса да Чкалов исеме ябыша алмады.

Сүзебез тагын үз агымы белән дәвам итте.

— Пенсионерын да, сезонлы эшчесен дә кертеп колхозда 816 кеше исәпләнә. Төп эштә шул 500—600 чамасы.

— Ә башкалар кайда эшли? Алар нәрсә белән шөгыльләнә?

Сүзне авыл администрациясе башлыгы Наил Вәлитов ялгап китте:

— Безнең авыл олы юл өстендә, бик җайлы урында,— диде ул алдындагы кәгазьләрне аралый-аралый. Аннан соң стенада эленеп торган картага күрсәтте.— Әнә, карагыз, Шомырша районы үзәге утыз биш чакрымда, Комсомол районы егерме биш, Яльчик тагын егерме биш чакрымда гына. Күпләр шунда эшли. Аннан соң зур шәһәрләр дә ерак түгел. Ульяновскига йөз чакрым. Чабаксар йөз егерме чамасы, Канаш илле, Йошкар-Ола ике йөз егерме чакрым булса, иң ерак дигән Казанга да нибары икө йөз илле чакрым. Юллар әйбәт. Утыр да чык та кит. Күбесе әнә шул район үзәкләрендә эшли. Якын-тирә шәһәрләргә барып эшләү дә гадәти күренеш. Үзе шәһәрдә эшләр, ә гаиләсе, йорты, хуҗалыгы монда булыр.

— Ләкин берсе дә анда төпләнеп калмый. Бездә ничек бит, читтә йөрсә дә, байлык туплап авылда йорт салуны абруйлы эш саный. Шуның белән авыл халкында хөрмәт казанырга тырыша,— дип өстәп куйды Ринат Сыраев.

Авылның җир бүлүчесе, ягъни землеустроитель булып эшләүче Дамир Нигъмәтуллов та үз фикерләрен өстәргә ашыкты:

— Менә сез карагыз, Шыгырданда машинасыз йорт сирәк. Әле быел гына да 118 йөк машинасы сатып алдылар. Үзе бер автоколонна хәтле! Һәр икенче өйдә трактор. Йә «Беларусь», йә, ДТ, йә Т — 16. Халыкның 30—40 проценты ат асрый. Әле шуның өстенә байтак кына кешедә үзе ясаган тракторлар бар.

Дамирның сөйләгәннәрен сабыр гына тыңлап утырган Ринат Сыраев мыек астыннан гына елмаеп куйды. Дамирның саннар тезүен мактануга охшатты, шуңа елмайды ахры дип уйларга да өлгермәдек, авылның өч җитәкчесе үзара карашып көлеп җибәрделәр.

— Әгәр самолет китереп, сатабыз дисәләр, аны да алырлар иде,— дип куйды Ринат Сыраев ни өчен көлешүләрен аңлатырга теләгәндәй.— Халык бай. Җитенкелекле тормышта яши анысы ...

— Ул байлыкның нигезе нәрсәдә соң? Юкса, гадәти бер авыл бит инде!

— Безнең өчен гадәти булса да, башкалар өчен бик үк гадәти түгелдер дә әле ул,— дип сүзен дәвам итте колхоз җитәкчесе бераз шаярткандай. Аннан җитдилә-

неп өстәп куйды.— Төп нигезе, әлбәттә, эшчәнлектә, хезмәт сөюдә. Шул жирсезлек сәбәп булгандырмы, бездә һәр кеше ике-өч төрле һөнәр иясе. Алары да әле иң кирәкле, сирәк очрый торган белгеч. Яз житүгә авылдан балта осталары, ташчылар, штукатурчылар чыгып китә. Оренбург ягына да, Түбән һәм Мордовиягә дә, Ульяновск өлкәсенә дә китәләр. Татарстанны инде әйткән дә юк. Жәй айларында елга житәрлек акча туплап кайталар.

— Икенче нигезе — кәсепчелектә,— дип ялгап алып китте Наил Вәлитов.— Әнә шул авылда эш житмәү, ләкин авылны ташлап китү йоласы булмаганлык, Шыгырдан кешесен мең дә бер ысул эзләргә этәрә дә инде. Менә безнең Шыгырданда тулы бер урамны итчеләр урамы дип йөртәләр. Шөгыльләре — тирә-як чуваш авылларыннан мал-туар сатып алып, Казанга ит ташыйлар. Тере мал ала, суеп сата. Төнге икеләрдә чыгып китәләр, иртән иртүк Казанга барып керү өчен. Менә базарда юри генә кызыксынып карагыз әле, һәр ит сатучы ике кешенең берсе Шыгырданнан булыр.

— Үзебезнең авылда мал асрарга көтүлекләр азрак. Шулай да хәзер 817 баш савым сыер исәпләнә. Байтак кына сарык тотучылар да бар. Кош-корт күп анысы.

— Соңгы елларда колхозда ат асраугa игътибарны арттырдык. Йөз алтмышлап ат бар. Шуларның алтысы юртаклар. Әле быел Казан сабан туена да бардык. Бер юртагыбыз Казан ипподромында үткәрелгән ярышта беренче, икенчесе дүртенче урынны алды,— дип өстәде Ринат Сыраев.

Без әле моннан соң да бик озак сөйләшеп утырдык. Колхоз житәкчесе Ринат Сыраев та, авыл хакимияте башлыгы Наил Вәлитов та, Дамир Нигъмәтуллов та Шыгырдан хакында шулхәтле мавыгып, яратып сөйләделәр, бу авылның, чыннан да, үзенә генә хас тормышы, яшәү рәвеше булганга бер генә тамчы да шигебез калмады.

Хәер, моңа ышану өчен әллә кайларга барып эзләнәсе юк. Барысы да күз алдында. Барысы да авылдашларның һәм килгән кешеләрнең күз алдында эшләнә. Шулай күрсәтеп эшләү ул менә мин булдырам бит әле дигәндәй, бераз гына мактануны да, горурлануны да аңлата кебек. Чөнки болар кемнәрдер өчен түгел, күз буяр өчен түгел, ә булдырыр өчен, үзләре һәм балалары, гаиләләре, якыннары өчен эшлиләр. Шуңа күрә боларда үзара ярдәмчеллек тә, кеше хәленә керә белү дә житәрлек. «Бүген миннән сиңа кулдан килгән ярдәм. Иртәгә минем дә синең ярдәмгә мохтаж булуым бар». Ләкин бу беркайчан да телдән әйтелми, мондый нәрсәгә бернинди ишарә-ым юк. Бу инде уртак бер гомумилектә яшәүче кешеләрнең канына сеңгән, бер кәррә уйланмыйча эшләнә торган, исәнләшү, рәхмәт әйтү кебек үзеннән-үзе аңлашыла торган бер гамәлләр.

## Тарихи белешмә урынына

Әлекке заманнарда үз сәүдәгәрләре булмаган татар авылын тарих белми. Яманмы-яхшымы, баймы, әллә урта кулмы — һәр авылның кибете дә, кибәтчесе дә, димәк, сәүдәгәре дә булган. Шыгырданда да шулай.

Октябрь түнтәрелешенә кадәр беренче гильдия купец-сәүдәгәрләре Әбделмән һәм Низам бай Шыгырданда гына түгел, бөтен Буа өязендә һәм Сембер губернасында байтак сәүдә әйләнешен үз кулларында тотканнар. Аларны күреп белгән өлкән буын кешеләре әле дә исән. Алар, совет власте урнашып житмештән артык ел үткәч тә, Буа өязен үз кулларында тоткан бу сәүдәгәрләр хакында риваятьләргә тартым итеп, горурланып сөйлиләр.

Хәер, барысы да булгандыр. Байларның китапларда язганча комсызлыгы да, алны-ялны белмичә мал артыннан куулары да. Ләкин, шул ук вакытта, киләчәк буынга истәлек булып алар салдырган мәчетләр, алар кордырган мәктәп-мәдрәсәләр калган. Алар химая иткән акчага укып гыйлем туплаган кешеләр дә калган бит.

Максатыбыз Шыгырдан феноменын, нәкъ менә Шыгырдан кешеләренә генә хас булып күренгән сыйфатларның тамырларын ачыклау иде. Ә аның өчен, күрәсең, булдыра алган хәтле үткән заманнарга да күз салырга кирәктер.

Элеккеге Буа өязендә, Шыгырданга якын гына (хәзер инде Батырга кушылып беткән) Юхма авылында туып-үскән чуваш язучысы Алексей Талвирның «Буа юлы өстендә» дип исемләнгән автобиографик романында да бар андый хатирәләр. Ул романны язучылар Шәрәф Мөдәррис белән Ләбибә Ихсанова татарчага тәрҗемә итеп 1958 елда Казанда да бастырып чыгарганнар иде. Моннан сиксәнсиксән биш еллар элек булып үткән вакыйгалар арасында безнең игътибарны жәлеп иткән юллар да бар.

Тимерче Луканы Байтуган исемле чуваш бае күкәй җыючы итеп чакыра. Тегесе баш тарта.

— Кара аны! — диде янап Байтуган,— соңыннан үкенергә булмасын! Шыгырдан татарын чакырып китерермен, аягыма егылсаң да алмам.

Байтуган бай, гадәттә, кеше яллап, Юхма базарыннан күкәй сатып ала һәм соңыннан аны, Мәскәү белән Питерга да кереп тормыйча, турыдан-туры Лондонга, Парижга озата, зур табыш ала икән ...

Икенче бер урында исә аклар тарафыннан Буа төрмәсенә ябылган Шыгырдан агаеның сүзләре китерелә: «Шылай, дус,— диде татар,— Юхмада мин күп булдым. Буа кебек зур авыл ул. Мин әллә кая да булдым. Таһир Каюмы дисәң, мине әллә кая да беләләр. Шылай, дус. Мин пиц цыгарып йөрим ... Буа үәзендә мин пиц салмаган бер авыл да юк. Таһир Каюмы дисәң, урысы да, татары да, чувашы да белә. Шылай, дус. Солдатка киткәнче малаем да пиц цыгарырга эрәнеп йөрде».

Күрәсең, инде ул елларда ук шыгырданлылар бөтен тирә-якта һөнәр иясе буларак дан тотканнар. Шулай булмаса, алар әдәби әсәрләргә дә барып кермәс иде. Шыгырданлыларга хас бер сыйфат — һөнәргә әвәслек булса, икенчесе — сәүдәгә, алыш-бирешкә хирыслык.

Ничек кенә булмасын, бүгенге Шыгырданда әле дә Әбделмән бай белән Низам бай хакында риваятьләр йөри.

Әбделмән бай якын-тирә авыллардан ашлык сатып ала, каз җыя торган булган. Чуваш авылларыннан килеп кызлар аларны йолыккан, эшкәрткән. Сөйләүләренә караганда, ул каз ите һәм бодайны патша сараена да җибәреп торган имеш.

Ләкин дошманнары аннан бик ямьсез итеп үч алган. Патша сараена китәсе иң яхшы бодай эченә песи үләксәсе тыгып җибәргәннәр. Үзен «Русиянең хуҗасы» дип атаган кеше өстәленә куеласы ризыкны болай мәсхәрәләү, табигый ки, тәхет иясен мыскыл итәргә теләү дип бәяләнә. Әбделмән байның гомере жандарм пулясыннан өзелә. Аның нәсел-нәсәбенең очы бүгенге Шыгырданда да калгандыр әле.

Низам байның да язмышы аянычлы төгәлләнгән. Ләкин авылда аның оныклары бүгенге көндә дә яшәп ята. Һәм начар яшәмиләр.

Авыл кешеләре сөйли: Низам бай ит, иген сату, тире-күн сәүдәсе һәм пушнина җыю белән шөгыльләнгән. Аның сәүдә олаулары Петербургтан башлап Әстерханга кадәр йөреп торган. Каз ите сату аеруча төшемле эш була. Елы-елы белән унар мең каз җыйган дип сөйлиләр. Аларны чуваш авылыннан кызлар килеп йолыккан.

Ашлык сәүдәсе дә шактый файда биргән. Бер-берсенә кырыгар мең пот ашлык сыйган амбарларның кайберләре әле бүген дә исән.

Низам бай малае Шакирны Сембердәге мәдрәсәдә татарча укытып кына калмый, урысча да белем бирә. Заманына күрә шактый белемле Шакир агай совет власте чыккач Мәскәүдә «Метрострой»да эшли, балаларын шунда алдырып тәрбияли. Ә инде 1946 елда яңадан Шыгырданга кайта һәм гомеренең соңгы елларына кадәр монда яши.

Шакирның бер малае Фатин бүген дә Шыгырданда. Озак еллар бабасы һөнәрен дәвам иттереп, Яльчикта хәзерләүче булып эшләгән, тирә-як авыллардан тире-яры, ит-сөт, йомырка, бәрәңге, яшелчә җыйган.

Низам бай үзе кызылларга ярдәм итеп йөрсә дә, мәгънәсез бер аңлашылмаучылыкмы, әллә гап-гади бер хөсетлекнең корбанымы — 1918 елда шул ук кызыллар кулыннан һәлак була.

Бу юлларны нигә яздык соң әле? Күптән үткәннәргә, элекке байларга багышланган юллар нигә кирәк булды? Үткәннәрен хәтерләмәсә, Шыгырдан Шыгырдан булмас иде. «Үткәнеңә мылтыктан атсаң, киләчәк сиңа туптан атачак» дигән канатлы гыйбарәне, бәлки, күпләрнең ишеткәне юктыр. Әмма аның мәгънәсен тоемлыйлар, беләләр. Авыл советы янындагы һәйкәлгә Икенче бөтендөнья сугышында һәлак булган 460 кешенең исем-фамилияләре уелган. Исән-имин кайтканнарның исемнәре мәктәп стендларында. Авыл зиратында таш куелмаган кабер юк. Шушы истәлекләр бүгенге кешене үткәннәр һәм киләчәк белән бәйли.

## Мишәрдә йола көчле!

Кайчандыр булган бер сөйләшү-бәхәс кызык кына уйларны кузгатты да җибәрде.

Тимер юлда, гадәттә, очраклы рәвештә бергә туры килгән юлаучылар, чит кеше алдында гомердә булмаганча тугарылып ташлыйлар.

Бу юлы да шулай булды. Тун изүләрен җилбәгәй җибәргән ир уртасы юлдашыбыз сөйләшү тансыклаган бер адәм булып чыкты.

Поезд Канаш тирәләренә җитүгә, ул тәрәзәдән тышка ымлады да әйтеп салды:

— Яратам шушы мишәрләрне. Ышанычлы халык: әйткәнен эшли инде ул,— диде.

Сүз иярә сүз чыккач, абзыебыз ни өчен ятарканлыгын да бер дә иренмичә аңлатып ташлады.

— Чөнки боларда йола көчле, гореф-гадәтне саклый беләләр,— дип дәвам итте ул проводник керткән кырлы стаканнан сыек чәйне уртлый-уртлый.— Боларда хатын-кыз үз урынында, ир-ат үз урынында. Бала-чаганы да үсендермиләр, олыларны да онытмыйлар.

— Нәрсәдә чагыла соң болар? Аңлатыбрак сөйли алмыйсызмы? — дигәч исә, тагын да җәелебрәк китте.

— Татарның асыл йолаларын беләсезме? — диде ул һәм безнең дәшми утыруыбызны күреп башын чайкап куйды.— Белмисез шул! Менә шуңа күрә дә хәзер ата улны, ана кызны белми. Татарны урыстан, хатын-кызын маржадан аера алмыйсың. Менә шушы чуваш ягындагы татар-мишәрләрне генә барып кара, һәммәсе үз урынында. Син монда хатыншаланып савыт-саба юып йөрүче ир-атны күрмәссең, иелә-сыгыла көянтәләп су ташыган егет-җиләнне очратмассың. Болар хатын-кыз эше. Инде дә килеп ирдәүкәләнеп утын ярган, пычкы тарткан хатын-кызны да таба алмассың. Әле бүгенгә көнгә хәтле кайбер өйләрдә тел яшерү дигән нәрсә бар. Килен кеше биатасы каршында күтәрелеп сүз әйтмәс. Болар нәсел-нәсәбен, җиде буын бабасын белмичә хатын алмас. Начармыни, ә? — дип сорап куйды ул тагын безнең сүзсез генә тыңлап утыруыбызны күреп.

Хәер, чыннан да, нәсәл-нәсәбен күреп, холкын-фигылен белеп өйләнү бер дә начар нәрсә түгел анысы. Алма агачыннан ерак төшми, ди бит. Димәк, син инде булачак җефетеңнең ниндирәк кеше, ниндирәк хатын буласын алдан ук чамалый аласың дигән сүз. Ләкин, тормыш гел без теләгәнчә генә бармый шул. Бу фикерләргә каршы «Мәхәббәткә маңка мишәйт итми», «Яратсаң маймыл да матур булып күренер» дигән мәкальләр дә бар бит әле.

Абзыйга шул хакта әйткән идек, ул бөтенләй кызып ук китте. Чәйле стаканын читкә этәреп, бәхәскә урын калдырмаслык итеп үзенең дәлилләрен тезәргә кереште.

— Әйе шул, сезнеңчә шулай шул! — диде ул ярсып.— Әнә шуңа күрә дә яңа корылган һәр ике ояның берсе җимерелеп бара. Элек булганмы шундый хәл? Булмаган! Хәзер генә сез белдекле, сез генә укыган, сез генә беләсез ... Элекке кеше бернәрсә дә аңламаган имеш. Аңламас, бар ...

— Абый кеше, нигә ул хәтле кызасыз. Бер дә начар сүз әйтмәдек бит әле сезгә,— дигәч, юлдашыбыз үпкәләгәндәй тынып калды.

Шактый озак вагон тәрәзәсеннән карап сүзсез генә бардык. Ләкин агаебыз түзмәде, чәй-шикәрен җыйнап өстәлгә урнаштыргач, гафу үтенгәндәй салмак кына сүз башлап җибәрде.

Аның тел очында йөргән сүзләрен чыгарып бетерәсе, әйтелми калганнарын әйтеп бетерәсе килә иде шикелле.

— Ярар, мине ачуланмагыз инде. Шулай кыза торган гадәтем бар,— диде ул бер тәрәзәгә, бер безгә карап.

— Шулай да, әйтеп карагыз әле, менә бу мишәрләрнең йолаларны, гореф-гадәтне шулай үҗәтләнеп саклавының сәбәбе нәрсәдә?

— Кем белә инде аны,— дип җилкә җыерганга юлдашыбыз канәгать елмаеп куйды:

— Ә сере бик гади аның. Болар беркайчан да диннән аерылмады. Татарстанда барлык мәчетләрнең манараларын киссеп, кырып-җимереп барганда болар саклап калды. Әнә бар син Горький өлкәсенә, Ульяга чык, шушы Чувашстанны кара: татар авылларының барысында да иң күренекле җирдә кукраеп мәчет утыра. Мәчет бар җирдә иман бар, иман булган җирдә бәрәкәт бар,— дип сүзен йомгаклады ул.

Соңыннан да әле без очраклы рәвештә юлда туры килгән бу агайны, аның сүзләрен искә төшереп йөрдек. Бәлки, чыннан да, шулайдыр. Шушы ук Шыгырдан авылы аңа мисал була алмыймыни?!

Апрель урталары иде. Басу-кырлардагы кар юрганы эреп җиргә сеңгән, җылыга сусаган кара туфрак күкрәген көяшкә ачкан язгы көннәр иде ул.

Урамда соңгы гөрләвекләр челтери, әле анда, әле монда сыерчыкларның җыр сузганы ишетелә, һәм кинәт... бу нинди могҗиза! Авыл җирендә генә була торган, сыерчыклар моңы белән генә сыеклатылган куе һәм тыгыз шушы тынлыкны азан аһәңнәре күмеп китте. Ирексездән туктап моңлы да, илаһи да яңгыраучы авазларга колак салдык. Ә азан тавышы туктамый, дулкын-дулкын булып авыл өстендә йөзә дә еракта күгелҗемләнеп торучы урманнарга барып бәрелә. Авылның ике башындагы ике мәчетнең биек манараларына көчле репродукторлар куелган. Алар халыкны кичке намазга, рамазан аеның изге гыйбадәтенә чакыралар.

Тынлыкны яшьрәк, түземсезрәк Рөстәм Султи бүлде:

— Бездә һәрвакыт шулай,— диде ул гаҗәпләнүебезне сизгәндәй.

Әйе, Сталин заманнарында да, торгынлык елларында да Шыгырданда мәчетләрне ябарга юл куймаганнар. Кичке шәфәкъ нурларында балкып утыручы ап-ак гөмбәзләр, авыл өстендә дулкын-дулкын булып йөзүче азан моңы авылдашларның әнә шул батырлыгына, кирәк кадәр үҗәт һәм үз дигәннәрендә тора белүләренә мәдхия булып яңгырый иде кебек.

Бу очрашу 1992 елның язында булган иде. Ә инде тагын бер елдан — 1993 елның көзендә кайтканда без авыл өстендә инде өченче манараны күреп алдык. Элеккегеләреннән, борынгы заманда салынганнарыннан бераз кайтышрак булса да, аның ак калай белән тышланган очлы манарасы «Менә, монда мин дә бар әле», дигәндәй җәйге күкнең ачык зәңгәрлегенә омтылган иде.

Яңа мәчетне карамыйча, аның өчен хәер сәдакасы бирмичә китү, Шыгырдан гадәтенә туры килмәс, гайре табигый бер эш булыр иде. Шунда юнәлдек. Иске бураны сипләп күтәрелгән мәчет әле төзелеп бетеп кенә килә икән. Әле эчендә дә, тышында да шактый эш бар. Иске бүрәнәләрне такта белән тышлыйсы, идәнен шомартасы, тәрәзә рамнарын буйыйсы... Хәер, яңа җирдә эш бетеп торамыни!?

Яңа мәчет шыгырданлыларның традицияләрне саклый белүләренә тагын бер дәлил. Аның капкасы янындагы калын имән тактага бу урындагы мәчетнең яшен сугудан харап булганлыгы язып куелган иде. Еллар узган, чорлар алышынган һәм менә, ниһаять, изге урында яңадан изге йорт калкып чыккан. Имән тактаның яңгырдан, җилдән шактый каралганлыгыннан чыгып фикер йөртсәң, мәчет инде байтак еллар элек әрәм булган. Аның елын хәзер төгәл генә хәтерләмибез. Изге җирдә кесәдән дәфтәр чыгарып язып йөрүне килешмәс бер эш булыр дибрәк уйлаган идек.

Мәчет авыл уртасында, бик җайлы урында булган. Әмма аның җиренә беркем дә кул сузмаган. Ул гына да түгел, янәшәдәге кешеләр үз бакчаларын кимитү хисабына булса да, аның ихатасын тагын да киңәйтү мөмкинлеге биргәннәр.

Безне башына кара кәләпүш кигән, картларча киенсә дә әле шактый таза һәм нык күренүче бер абзый каршы алды. Кесәсеннән ачкычлар чыгарды, ишекләрне ачып җибәрде.

Аяк киемнәрен баскыч янында калдырып эчкә үттек. Зал ягындагы идәндә төрле зурлыктагы намазлыклар тезелеп ята иде инде.

— Төзелеп бетмәс борын ук якын-тирәдәге картлар намазга йөри башлады,— дип куйды юл күрсәтүчебез.— Әйдәгез, манарасына да менеп төшик. Авыл манзарасын күрерсез.

Очар кошлар биеклегеннән, чыннан да, гаҗәеп матур күренеш ачыла икән. Шыгырдан табигатенә, ул утырган җирнең төрлелегенә хәйран калырлык. Юхма суы ярып үткән текә яр буйларында да, яссырак тау булып урманнарга барып терәлгән тигез җирләрдә дә, икенче яктан исә иген басуына тоташкан ачыклыкта да эреле-ваклы йортлар тезелеп киткән. Йортлар күп тә, төрле дә. Аларның элегрәк салынганнары ваграк, әмма заманына күрә ярап торырлык дип исәпләнелгән булса кирәк. Ә инде яңалары берсеннән-берсе биек, берсеннән-берсе матур, берсеннән-берсе төзек иде. Әйтерсең авыл кешеләре бер-берсен уздырырга тырышалар.

Манарадан төшеп өйалдына чыгуга «Бисмилла» әйтеп ишектән бер төркем хатын-кыз, карчык-корчык килеп керде.

— Мәчетнең ишек-тәрәзәләрен, идәннәрен юып чыгарга дип чакырган идек,— дип куйды мәчет карты.— Хәер, чакырып торасы да юк. Мондый изге эшкә бездә рәхәтләнеп йөриләр.

Без исә сораштыруыбызны дәвам иттек:
— Мәчетне төзергә акча каян җыелды соң?
— Халыктан җыйдык,— диде мәчет карты.— Әйттем бит инде, изге эшкә бездә халык акча җәлләми. Аннан соң колхоз идарәсе дә, авыл башлыгы да ярдәм иттеләр. Кирәк икән техникасын бирделәр, эшләшергә кеше җибәрделәр.
— Бу мәчет нәкъ авыл уртасында. Хәзер теләгән һәр кеше үзе ошаткан, үзенә якын мәчеткә йөри ала торгандыр инде.
Абзый кеткелдәп көлеп җибәрде.
— Ю-у-ук,— дип сузды ул.— Әле тагын ике мәчет салынасы бар. Берсен Сәгуд Гарәбстаны ярдәмендә эшлиселәр. Килеп урын сайлап киттеләр инде. Башта аны Чувашиянең башкаласында— Чабаксарда төзисе булганнар. Уйлаша торгач, татар иң күп яшәгән җир, дип безнең авылны тәкъдим иткәннәр. Икенчесен Германиядән кайткан Минач абзый салдыра.
Соңыннан белдек, икенче бөтендөнья сугышы елларында әсирлеккә төшкән Минач абзый Германиядә төпләнеп калган, шунда гаилә корган, кем әйтмешли, шунда дөнья көткән. Ләкин картайган саен, күрәсең, туган як чишмәләренең суын эчәсе килү, балачакта ялантәпи йөргән газиз туфракка яңадан басасы килү хисе үзенекен иткән. Минач абзый туксанны куып яткан җиреннән туган авылына кайтып егылган. Хәзер ул үз акчасына мәчет салдырырга җыена.
— Биш мәчет артык күп булмасмы соң?— дип сорап куйган идек, мәчет карты баш чайкап кына җавап бирде.
— Элек алай гына булмаган әле ул.
— Ничәү булган соң?
— Монысын мин әздереп кенә әйтә алмам инде. Әйтсә, шул Шәмсетдин абый әйтер. Динне бик кыскан, дин тотучыларны рәнҗеткән чакларда да мәчетне саклап калучылардан ул. Аның янына барып килегез әле.
Бу язмалардан Шыгырданда муллалар, дин сабагын белүче укымышлылар күп икән дигән фикер дә калырга мөмкиндер. Ләкин, чынлыкта, ул алай ук түгел. Авылда указлы мулла берме-икеме генә. Калган мәчетләрдә исә дингә хөрмәтен, татар йоласын тотуда мәчетнең урынын аңлаган картлар эшләп йөри. Алар ук азанын да әйтә, намазын да укый, дини бәйрәмнәрнең, йолаларның үтәлешен дә күздә тота, мәчетне карап тора.
Без сөйләшкән мәчет карты үзе бик озак еллар сату-алу эше белән көн күргән. Элеккеге төшенчәләр буенча аны спекулянт дип тә атап булыр иде. Ул Ташкент якларына лампа куыгы, кайчы кебек дефицит товарлар төяп китә икән дә, аннан бу якларда сирәк очрый торган йон буявы, кына, затлы ефәк ише нәрсәләр төяп кайта икән. Картаймыш көнендә менә ул да мәчет юлына баскан.
Ләкин, әйткәнебезчә, авылда мәчетләрнең саклануында башка кешеләр сәбәпче. Алар дин рәнҗетелгән елларда да иманнарын җуймаганнар. Шуларның берсе— Шәмсетдин абзый Сыраев.

## Мәчелә ой — тыныч ой

Шәмсетдин абзыйларның өе авылның иң кырыенда, зират янында диярлек урнашкан борынгы урамда. Еллар, чорлар алышына торган, әмма юан имәннән куелган урыс капканың баганалары җил-яңгырдан инде коңгырт-кара төскә керсәләр дә, элеккечә нык һәм төз утыра бирәләр. Мал иясенә охшар, диләр. Чыннан да шулайдыр! Инде тугызынчы дистәне куып баручы Шәмсетдин абзыйны күрмәс борын ук, йортына, каралты-кураларына, коймасына, капкасына карап, монда бик таза, эшен җиренә җиткереп башкара торган кешеләр яшидер дигән уй туа күңелдә.
Ишегалды да чисталыгы, пөхтәлеге, килеп керүгә үк күзгә ташлана торган пакьлеге белән аерылып тора иде.
Капка ачылганны ишетептер, түрдәге келәт ишегеннән Шәмсетдин абзый үзе дә күренде. Шәмсетдин абзый яшел чирәм өстендәге комганнан су агызып кулларын чайкап алды да коймада эленеп торган тастымалга сөрткәч, ашыкмый гына яныбызга килде.
— Йә, ни йомыш иде, оланнар?
— Менә Шыгырдан мәчетләре турында белешеп йөри идек әле, Шәмсетдин абый. Алар элек күпме булган? Ничек эшләгән. Шуларның тарихын бераз ишетәсе килгән иде ...
— Изге юлда йөрисез икән, Алла куәт бирсен,— дип куйды ул.— Ә без менә һаман дөнья куабыз әле. Келәт эчендәге базны бераз тирәнәйтмәкче идем ...

Аның ни өчен күрешер алдыннан кул юып йөрүен шунда гына аңлап алдык. Шәмсетдин абзый нәкъ без күз алдына китергәнчә, типик татар карты иде. Чал кунган ап-ак чәчле, түгәрәк йөзле. Сакал-мыегы да нәкъ мөселманча китәрелгән. Аякларында йон оекбаш, тирән галош, ак күлмәк өстеннән кара камзул киеп җибәргән. Ләкин болары түгел, ә куллары игътибарны җәлеп итте. Бер-бер бармагы уртачарак ирнең ике бармагына тиң зур сөякчел куллар иде алар. Яшь чакларында бу кулларда, бу беләкләрдә нинди генә көч уйнамагандыр да, нинди авырлыкларны уйнагандай гына чөеп ыргытмагандыр. Бөек Ватан сугышын башыннан ахырына кадәр үткән Шәмсетдин абзыйга тормыш җиңел генә бирелмәгән шул. Хәер, аны тугызынчы дистәне куып бара дип әйтерлек түгел әле. Аллага шөкер, гәүдәсе төз, кулы нык, карашы ачык.

— Әйдәгез, өйгә үтик. Нишләп ишегалдында сөйләшәбез соң әле,— диде ул картларча матур елмаеп һәм икебезне аркабыздан кагып ишеккә таба этәрде.— Әйдәгез, әйдә! Чәй янында сөйләшербез.

Өйгә кердек, кычкырып сәлам бирдек. Мич янындагы чаршау артыннан карчыгының ак йөзе күренде. Сәламебезне алуга ул яңадан чаршау артында югалды да. Күрәсең, карчык кешенең үз мәшәкатьләре җитәрлек. Мишәрдә хатын-кызның ир кеше сүзенә катнашу гадәте юк. Тәрәзә төбендә, кына гөлләре утыртылган чүлмәкләр арасында, өй хуҗаларының үзләре шикелле үк карт мәче ята иде. Без кергәч ул күзләрен зур итеп ачты, тавыш чыгармый гына иснәде дә сөякләре шыгырдаганчы киерелеп, яңадан сузылып ятты. Ә күзләре һаман безгә төбәлгән иде әле. Әйтерсең, карт мәче безне гипнозлый, үзе шикелле үк тынычлыкка, салмаклыкка өнди иде. Мәчеле өй тыныч өй, тавыш-гауга булмый торган бәрәкәтле өй. Гадәти авыл өе иде бу. Тәрәзә кашагаларында бизәкле тастымаллар. Бүлмә уртасындагы өстәлдә киндер ашъяулык. Караватлардагы берсе өстенә берсе өелгән мендәрләрдә чигүле япма. Ләкин шушы гадәтилектә ниндидер аңлатып булмый торган бәйрәмчәлек, үзенә күрә бер матурлык бар иде сыман. Гадәтилек дигәнебез чын татарча өй бизәү рәвеше, без инде сәхнәләрдә генә күрергә күнеккән бер стиль ләбасы. Бәйрәмчә рух әнә шуннан килә торгандыр да әле.

Шәмсетдин абзый өстәлгә китаплар чыгарып салды, калын пыялалы күзлеген борын өстенә атландырып, борынгы язмалар өстеннән күз йөгертеп алгач, элеккеге картларга гына хас бер макәм белән дога укып җибәрде.

Безнең эшебезгә үзенчә фатиха бирүе булгандыр, күрәсең.

Ә без исә сүзне ерактан уратып тормыйча, үзебезне кызыксындырган сорауларны тезәргә тотындык.

— Шәмсетдин абзый, хәтерләмисезме, элекке заманнарда авылда ничә мәчет булды икән?

Тәмамланып килүче гасырдан тугыз яшькә генә кечерәк абыебызның хәтере шактый яхшы әле. Ул аз гына да уйланып тормыйча әллә кайчангы, үзе бала чагында ук күргәннәрне тәфсилләп сөйләргә кереште.

— И балалар, мәчетләр күп иде ул бездә ... Революциягә хәтле сигез мәчет эшләп торды. Сигез мәхәлләдә сигез манара балкып утыра иде. Әле ул гынамы?.. Һәркайсысы янында мәктәп бар иде. Уйлап кына карагыз, бер авылга сигез мәктәп! Укуын дәвам иттерәсе килгәннәр Сембер мәдрәсәсенә бардылар. Тагын да укыйсы килгәннәр Бохарага китте. Укуның кадерен беләләр иде. Укый-яза белмәгән кеше юк иде авылда.

— Ул заманнарда ук Шыгырдан халкына җир җитмәгән, әмма авылны ташлап китүчеләр булмаган диярлек. Менә безнең шуны аңлыйсы килә, нәрсә бәйләп тота икән халыкны авылга? Шуны бер генә сүз белән әйтеп бирә алмассызмы?

Шәмсетдин абзый бер генә мизгелгә уйга калды да тагын ашыкмый гына сөйләргә кереште.

— Бу хакта үземнең дә уйланганым бар, ләкин алай гади генә җавабын таба алмыйм, оланнар,— диде ул алдындагы китапларны сыйпый-сыйпый.— Элек тә ягага китү бар иде. Себергә алтын прискаларына йөргәннәр. Бодайбо, Артем шахталарына. Акча туплаган да кайтып өй төзегән, йортын караган.

«Читкә китеп эшләү» дигәнне Шәмсетдин абый шулай «ягага китү» дип сөйли. Шыгырданлыларның теле Сергач, Саранск якларындагыча каты мишәрчә үк булмаса да, шактый ук үзгәлеккә ия. Хәер, аларны сүз сөреше буенча аңлау бер дә кыен түгел. Бераз гына «ц»ләштереп, «а» авазын бераз утыртыбрак сөйләшкәнне тыңлап утыру үзенә күрә бер рәхәтлек тә биргән кебек әле.

Шәмсетдин абый тагын бераз гына сүзсез утырды. Күрәсең, безнең сорауга мөмкин кадәр кыскарак җавап эзли иде булса кирәк. Шул чакта әллә нәрсә булды, өйгә кергәндә генә сузылып киерелгән мәче күз алдына килде дә күз

кабаклары авырая башлады. Каләмдәшемнең дә башы аска иелгән, күзләре йомылган иде. Керфекләрен челт-челт йомып ул да миңа карап елмаеп куйды. Чиратлашып дигәндәй, йокы белән көрәшәбез. Керфекләргә, әйтерсең, берәр кадаклы гер асканнар. Бер генә мизгелгә онытылып кителгән кебек иде. Колаклар берни ишетмәс булды. Күзләрне ачканда Шәмсетдин агай безгә көлемсерәп карый-карый салмак кына сүзләр тезә иде.

— Белмим ... Авылны ташламау гадәте шул борын заманнардан ук килә торгандыр ул. Ятага китеп югалганнар картлык көнендә булса да авылга кайтып егыла. Шыгырдан кешесе үзенең тормышта урын тапканын иң элек Шыгырданга кайтып күрсәтергә тиеш. Авылдашларның тануын, аларның белүен тели кеше, югалып калмаганлыгын ул бары тик авылда гына күрсәтә ала. Читтә син хет министр бул, әмма авылыңа кайтып күренмәсәң, сине беркем дә министр дип танымаячак.

Без әле шактый озак сөйләшеп утырдык. Шәмсетдин абый үзе дә 1926—1933 елларда Мәскәүгә барып бәхет эзләгән. Аннан соң авылга кайтып райфода, аннан соң Батыр МТСында нефтебазада эшләгән. Карчыгы Сәрбиҗан җиңги белән биш бала — бер кыз, дүрт малай үстергәннәр.

Хушлашып чыгып киттек. Ерак та китәргә өлгермәдек, өйдә чакта изрәткән йокымсырауны кул белән алып ташладылармыни, күзләр ачылды, йомшарган буыннарга көч әйләнеп кайтты кебек. «Мәченең гипнозы бетте ... » Бер-беребезгә карашып көлеп җибәрдек. Күрәсең, бу минутларда икебезнең дә башында бер үк уйлар бөреләнгәндер.

Хәер, Шамсетдин абый күп нәрсәләрне сөйләп бетермәде. Авыл хакында, йолалар, гадәтләр, кешеләр хакында сорашканда сүзе шактый күп иде аның. Ә йомгак очы үзенә килеп терәлүгә, әйтерсең, сүз куәсе бетә дә китә иде. Юкса, яхшы беләбез, авылда мәчетләр сакланып калуда Шәмсетдин абыйның өлеше шактый зур бит. Нәкъ менә ул иренмичә халкыннан имзалар җыйган, район һәм Чувашстан башлыклары белән генә чикләнеп калмыйча, авылдашлары белән Мәскәвенә барып җиткән, мишәргә хас үҗәтлеге белән җитмеш җиде ишекне каккан, әмма Шыгырданда тагын бер мәчет төзетергә рөхсәт алып кайтканнар. Болар барысы да хәзерге заманда түгел, ә дин, мәчет, йола дигәнне ишетүгә сыртлары кабара торган райкомнар заманында, торгынлык елларында.

Халкының йолаларын, гореф-гадәтләрен моңлы бер җыр итеп әсәрләренә сала алган грузин язучысы Нодар Думбадзе үз заманында мондыйрак фикер әйткән иде: «Ваграк милләтләр милләт булып калу өчен гореф-гадәтләрен, көнкүрештәге үз йолаларын үтә дә бер үҗәтлек белән сакларга тиешләр. Шунсыз алар милләт буларак яши алмый».

Чувашиядә чын татар утравы булып яшәүче шыгырданлылар грузин әдибе сизгән хакыйкатьне инде бик күптәннән беләләр һәм тормышларында кулланалар. Мәчетләрне үҗәтләнеп саклау, йола-гадәтләрне элекле үтәп бару да шуннан. Шушы игътибар мәктәпләргә карата да яшәп килә. Мәктәп дигәндә шыгырданлылар хәтерендә вакытыннан элек гүр иясе булган Хәлфә Солтан да бар. Чувашстанда хәтта чуваш мәктәпләре дә урысчага күчерелеп беткән бер заманда да ул Шыгырдан мәктәбенең татарча, туган телдә эшләргә тиешлеген, шуның зарурлыгын исбатлый алган. Шушы мәсьәлә белән кайларга гына барырга, кемнәрнең генә ишекләрен шакырга туры килмәгәндер аңа!..

Уйлап-уйлап куясың да гаҗәпләнеп һәм сөенеп баш чайкарга гына кала: әгәр шушындый кешеләре булмаса, Шыгырдан Шыгырдан да булмас иде кебек.

Әйе, үзенекен итә белгән, үҗәт һәм үзсүзле кешеләр яши Шыгырданда. Ләкин болар начар мәгънәдә түгел. Кирәгендә яхшы сүзе белән генә түгел, гамәле белән дә алдыра шыгырданлылар.

## «Бездә ярышып яшиләр...»

Алдагы бүлекләрдә сүз, нигездә, урта һәм өлкән буын кешеләре хакында барды. Әйе, бүгенге авылның шушындый булуында, Шыгырданның үзенә генә хас микроклиматында, яшәү кануннарында аларның һәм алардан алдагы буыннарның яшәү рәвеше, тормыш тәҗрибәсе ята.

Ә яшьләр шушы яшәү рәвешен дәвам итәргә әзерме? Бүгенге Шыгырдан хакында алар ни уйлый?

Бу сорауга җавапны без Шыгырдан өчен гадәти дип атала торган яшьләрдән алырга теләгән идек. Һәм безгә шофер егет Фәһим Мохитов исемен әйттеләр. Хәер, аны һөнәре буенча шофер дип кенә әйтү дөреслеккә бик үк туры килеп

бетмәс. Чөнки бу егетнең кулы алтын икән. «Белмәгән эше юк»,— дип тә куйдылар. Әтисе Алимҗан абый озак еллар Батыр «Сельхозтехника» берләшмәсендә шофер булып эшләгән, үзе әйтмешли, гомере буе юлда. Әнисе Камәрия апа исә колхозда эшләү белән бергә, сәфәрдән кайтып керә белмәгән ире урынына да дөнья йөген тарткан, йортны караган, мал-туар асраган, әтисе шикелле үк машина җене кагылган өч ташбаш малайны тәрбияләп үстергән. Фәһим шуларның иң кечесе — төпчеге, татар гадәте буенча, төп йортта каласы малай.

...Алимҗан абый да, Камәрия апа да, Фәһим дә өйдә иде.

— Яхшы булды әле, барыгыз бергә җыелган чакка туры килдек,— диюбезгә йорт хуҗасының йөзенә канәгатьсезлек билгесе чыкты.

— Өйдә ятар чакмы соң!? Менә икебез дә бил белән интегәбез әле,— дип җавап кайтарды ул, башы белән Фәһимгә дә ымлап.— Көтүгә чыккан идем дә, җил бәргән, кыймшана да алмыйм. «Ора алмаган олы күсәк күтәрер», дигәндәй, малай авыр күтәреп билен кузгатты. Ятабыз менә хәзер җан көеге булып, әнисенең күзенә карап ...

Мондый чакларда гадәттә сөйләшенә торганча, һава торышы, авыл хәлләре турында гәп куертып алдык та, үзебезне кызыксындырган сорауларны тезәргә керештек. Безгә инде башта ук Фәһимнең үз көнен үзе күрүче эшлекле егет икәнен әйтеп куйганнар иде.

Шуңа күрәдерме, монда кергәнче күз алдына Казандагыча күн куртка, спорт чалбары, аягына кыйммәтле «Адидас» кроссовкасы кигән, кем әйтмешли, «крутой» егет килгән иде. Ләкин алдыбызда бөтенләй башка төрле, ачык карашлы, якты йөзле гап-гади авыл малае иде.

— Монда ни тартканын үзем дә аңламыйм. Һавасы башкамы, белмим,— дип сөйләп китте ул.— Менә мин элек шофер булып эшли идем Ульяновскида. Шуннан Казанга йөк ташыдым. Шыгырдан нәкъ уртада. Дөресен генә әйткәндә, эше шундый булганга күрә урнашкан да идем инде. Чөнки кайтканда да, барганда да авылга кермәле. Берәр атналап юлда. Сагынуга түзә алмый идем. Цивильск бездән йөз чакрым. Шуннан йөздән бер дә киметмичә бер сәгать эчендә кайта идем. Шыгырданнан читтә яши алмам кебек тоела миңа.

— Хәзер авылда эшлисеңме?

— Әйе, Шыгырданда торам. Батырда кече предприятие ачып җибәрдек. Запчастьлар табып, иске йөк машиналары белән кайнашабыз шунда ...

— Килере-кереме бармы соң?

Бу сорауны ишеткәч, Фәһим елмаеп куйды да сүзнең беткәнлеген аңлаткандай урыныннан кузгалды. Ул арада Камәрия апа олы якта чәй әзерләп өлгергән икән, табын янына чакырдылар. Әңгәмә җебен беразга өзеп торырга туры килде.

Игътибарлы укучы сиземләгәндер, Шыгырдан халкының шөгыле күп төрле. Ләкин шулар арасыннан да иң киң таралганы — алыш-биреш ясау, сәүдә итү. Монысы татар халына борын-борыннан хас гадәт. Болгар дәүләтенең дә, Казан ханлыгының да олы сәүдә юллары өстендә утырганлыгы, бу мәмләкәтләрдә шаулап дөнья базарлары узганлыгы күпләргә мәгълүм. Элек-электән су буенда, җиде юл чатында урнашкан Шыгырдан халкының бу эшкә хирыслыгы да шул заманнардан килми микән әле. Тагын бер нәрсә — Америкада, мәсәлән, кемнең күпме алып эшләвен сорау әдәпсезлек саналган кебек, Шыгырданда да кемнең ни эш белән көн күрүен, күпме акча эшләвен сораштыру гадәтсезлек.— Җитә,— диде ул бераз уйланып торгач һәм тагын өстәп куйды.— Ашарга да, йортны алып барырга да җитә. Тагын ни әйтим ...

Артыгын сораштыру урынсыз булыр иде. Журналистиканың «Язган кешеңә зыян салма» дигән алтын кагыйдәсе бар. Кылт итеп шул искә төште һәм без сүзне яңадан авылга, аның кешеләренә таба бордык. Фәһимне тагын алыштырып куйдылар диярсең, кабынып сөйләргә кереште.

— Яңа урамнарны карадыгызмы соң әле? — диде ул һәм кесәсеннән машина ачкычы чыгарып учында биетергә кереште.— Әйдәгез, күрсәтеп кайтам. Юкса, бүгенге Шыгырданны белми китәсез ...

Бил авыртуы онытылды. Кинәт урыныннан күтәрелгән егет безгә сиздермәскә тырышып, билен угалап алды да житез адымнар белән ишегалдына атлады.

Өр-яңа КамАЗга утырып авылга чыгып киттек.

— Менә бу яктан Шыгырдан инде Батырга — район үзәгенә килеп җитә язды. Олы юл гына аерып тора,— дип сөйләргә кереште ул.— Бу урамны бездә шаяртып «Документальный урамы» дип йөртәләр.

— Нигә?

— Әнә, күрәсезме икешәр-өчәр катлы өйләр ... Түбәсен ак калай белән япкан. Хан сарае диярсең. Берәүдән сорыйлар икән: «Төзү материалларын кайдан

алдын?» дип. «Һәрбер әйбернең документы бар, документально оформленный», дип җавап биргән имеш. Шуннан шушы исем ябышкан да калган инде,— дип көлеп җибәрде Фәһим.— Аннан соң, беләсезме, Шыгырдан кешесе өен күршесенекеннән әйбәтрәк итеп салырга тырыша. Башкача булдыра алмый икән, ул аны һич югы ике-өч сантиметрга булса да биегрәк итәчәк. Бездә кеше шулай ярышып яши...

## Авылның тарту көче

Шыгырдан күп яктан безнең өчен табышмак булып кала бирә. Авылда без төрле даирә кешеләре белән очрашып сөйләштек. Аларның авыл хакындагы уй-фикерләрен, Шыгырдан феноменының асылын белергә теләп байтак сүз куерттык. Кыска гына итеп әйткәндә, аның асылына киңлек, хөрлеккә омтылу, авылны олы бер гаилә итеп күзаллау хисе ята булса кирәк. Хәтта Шыгырданлылар киленне дә чит авыллардан алмаска, кызларын читкә бирмәскә тырышалар. Шуңа күрәдерме, күршедәге Кызыл Чишмә авылында яшәүчеләр мондыйрак такмак та чыгарганнар.

Шыгыр-шыгыр арба,
Шыгырданга барма.
Шыгырданга барсаң,
Бер коштабак салма.
Салмасының тозы юк,
Миңа ярар кызы юк.

Хәер, моңа Шыгырданлыларның әлләни исе китми. «Буе житмәгәч, «йөземнәре пешмәгән» дип әйткән ди бит төлке» дип, елмаеп кына куялар.

Монда сүз эзләп кесәгә кермиләр. Сигезенче дистәне куып баручы Миңлесылу апа Алиева әйткәннәр әле бүген дә колакта яңгырап тора кебек.


— Заводында сыгыл-сыгыл да дүрт стена арасына кайтып егыл. Төрмә бит ул! Бикләнсәң дә ят, кер дә бикләнсәң!— дигән иде ул шәһәрдә яшәү турында.— Ун көн торып кайттым әле менә, гомердә булмаганны.

— Миңлесылу апа, балаларың китеп беткән икән, монда берсе белән генә калгансың,— дигәч, ул горурланган шикелле әйтеп куйды:

— Да!— диде. «Әйе»не монда шулай каты итеп, «а» хәрефен бастырып әйтәләр.— Уңмаган каз да сигез бәбкә үстерми. Минем сигез олан бит! Читтә булсалар да. Шыгырданнан аерылганнары юк. Кайтмый калган атналары сирәк. Әле берсе, әле икенчесе кайтып тора. Китмәгәннәр дә диярсең.

Авылның тарту көче нәрсәдә соң дигән сорауга бер генә сүз белән җавап бирерлек түгел. Шулай да алда тасвирлаганнарыбыздан азмы-күпме җавап табарга буладыр дип уйлыйбыз.

Шушы тарту көче Германиядә төпләнеп калган Минач абзый Измайловны да тугызынчы дистәне куып барганда Шыгырданга кайтып егылырга мәҗбүр иткән. Шушы тарту көче уңган егет Фәһим Мохитовны авылга бәйләп тота. Шушы көч Низам бай оныкларын: Казан университетының юридик факультетын тәмамлап Канашта прокурор ярдәмчесе булып эшләүче Рәкыйпне дә, ветеринария институтында укыган Нәҗипне дә, Чабаксарда сәүдә-финанс институтын бетергән Әнвәрне дә атна саен авылга кайтып йөрергә мәҗбүр итә. Алар үз тормышларын туган бишекләре Шыгырданнан башка күз алдына да китерә алмайлар. Шыгырдан ул — таяну ноктасы, аларга көч һәм дәрт бирүче изге жир. Ә инде сабан туйларын әйтеп торасы да юк. Июнь урталарында Шыгырданда туып-үскән һәр кеше авылына кайтуны изге бурычы дип саный. Ул чакларда авылда кеше саны, ким дигәндә, икеләтә-өчләтә арта. Менә шундый инде ул Чувашстан татарларының үзәге — Шыгырдан авылы.



# Әмирхан ага Еники белән әңгәмә

ӘДИПКӘ 85 ЯШЬ ТУЛУ УҢАЕННАН

*— Әмирхан ага! Сезнең белән менә шушы әңгәмәгә әзерләнеп йөргәндә мин, тагын да бер мәртәбә күздән кичерергә дип, әсәрләрегезне алдым. Исәбем аларга тиз генә күз йөгертеп чыгу һәм элек инде кат-кат укылган бу әсәрләрнең милләтебез өчен нинди рухи хәзинә икәнлекләрен тагын бер мәртәбә үз хәтеремдә яңарту иде. Әмма ләкин шунысы гаҗәп: Сезнең кайсы гына әсәргә кагылсаң да, күз йөртеп алу нияте белән аларның беренче җөмләсен генә, тәүге сүзләрен генә укысаң да — шуннан соң инде аларны кире кую, алардан аерылып китү мөмкин түгел икән. Әнә шуңа күрә байтак кына әсәрләрегез үзләреннән үзләре өр-яңадан укылдылар, тулысынча укылдылар.*

*Әнә шундый әсәрләр — безнең татар укучысын озак-озак еллар буена сокландырырдай гүзәл хикәяләр һәм повестьлар иҗат итүегез өчен барлык укучылар исеменнән бик зур рәхмәт Сезгә, Әмирхан ага!*

*Ә беренче соравыбыз менә мондый.*

*Күз генә тимәсен — Сез шушы гаять давыллы, гарасатлы һәм бик тә тотрыксыз Егерменче гасырның башыннан алып ахырына кадәр үтеп киләсез. Бу гасырны иң хөрмәтле әдипләребезнең берсе булып йомгаклыйсыз. Менә шул гаять катлаулы юлларны кичкәннән соң Сез үз күңелегездә туплаган иң зур хакыйкатьләр алар ниндиләр? Алардан иң мөһимнәре, иң кадерлеләре?*

— Минем әсәрләргә карата әйткән ихлас сүзләрегез өчен Сезгә рәхмәтемне белдереп һәм вакытны да ганимәт белеп, әңгәмәне турыдан-туры сорауларыгызга җавап бирүдән башлыйсым килә.

Мин гомерем буе рухи азатлыкка һәм фикри хөрлеккә сусап яшәгән кеше. Әмма яшәвем 8 яшьтән алып 80 яшькә кадәр тоталитар система шартларында узды. Бу системаның озак елларга сузылган бик әшәке, бик рәхимсез дәверен дә кичердек — Сталин заманын. Шулай ук аның йомшара, җылыта төшкән чакларын да күргәләдек. Ләкин, барыбер, алдау белән көчләүгә нигезләнгән систе-

мага яраклашып һәм буйсынып яшәргә туры килде. Сез сораган иң зур хакыйкать әнә шунардан гыйбарәт. Аның кадерле дип әйтерлек чагы булырга мөмкинме?!.. Әлбәттә юк!.. Тик кайчандыр күргән бик матур төшләр генә узган гомернең кадерле бер мизгеле булып искә төшкәли...

*— Япон халкының атаклы язучысы Ясунари Кавабата бар. Әнә шул прозаик әдипкә Нобель бүләге бирелгән вакытта мондый сүзләр әйтелде: «Япон халкының рухи дөньясын тирән чагылдыручы әсәрләре өчен!» Әгәр дә бүген «татар милләтенең нинди уй һәм кичерешләр белән яшәвен дөнья халыкларына танытырдай әдәби әсәрләр» дисәләр, минемчә, һич тә икеләнмичә, Сезнең хикәя һәм повестьларыгызны тәкъдим итәр идек. «Әйтелмәгән васыять»ләрне, «Тауларга карап»ны, «Матурлык»ны һ. б.*

*Әмма безгә шуны белү кызык: әдип буларак үсү, җитлегү чорында үзегезгә тормышта һәм әдәбиятта нинди факторлар аеруча нык — хәлиткеч дәрәҗәдә көчле тәэсир итте дип саныйсыз? Сезнең менә шушындый әдип булып формалашуыгызның иң мөһим алшартлары дип нәрсәләрне билгеләр идегез икән?*

— Язучылык талантының табигый үзенчәлеге тумыштан килә торгандыр дип уйлыйм. Минем атам мәрхүм нечкә күңелле кеше иде һәм каләм куәсе дә бар иде аңарда. Анам исә күп балаларын югалткан, хәсрәтен йота алган сабыр холыклы, кешеләргә шәфкатьле хатын иде. Алардагы бу сыйфатлар күпмедер дәрәҗәдә миңа да күчкән булса кирәк. Аннары үзебезнең әдәбиятны бик иртә укый башладым. Татар җанлы, татар телле язучы булып китүемә аның да тәэсире һичшиксез зур булгандыр дип беләм. (Бигрәк тә Тукайлар чоры әдәбияты). Шулар өстенә реаль тормыш йогынтысын да һич онытырга ярамый. Без яшәгән кырыс, бәгырьсез бер заманда намуслы, миһербанлы саф кешегә кытлык бик зур иде. Язасы килгәндә күңел һәм хыял күбрәк шундый кешеләрне эзләгәндер ахрысы. Гомумән, язучы булып формалашуның факторлары күп булырга мөмкин, тик язучы үзе аларның барысын да белеп бетерә алмый торгандыр ... Калганнарын, бәлки, Сез табарсыз.

*— Оста хикәячеләр турында сүз чыкса, урысның атаклы Чеховын, Бунинын искә алалар. Боларның беренчесен Сез бигрәк тә яратасыз шикелле. Чыннан да, алар кеше җаны турында — аның эчендәге төпсез упкыннар хакында — мәңге искерми торган әсәрләр иҗат иттеләр.*

*Хәзер безнең татар укучысы, үзен башкалар белән тигез һәм бәйсез күрергә теләгән милләт вәкиле, алар иҗаты белән Сезнең әсәрләрне ирексездән диярлек чагыштырып карый, янәшә куеп карый. Мактау өчен генә әйтү түгел: минемчә, Сезнең әсәрләр дә бер дә аларныкыннан ким түгел! Алар да олы сәнгатькә һәм тирән фәлсәфәгә ия. Минем үземә, мәсәлән, Сезнең проза әле тегеләрнекенә караганда шигъририрәк тә тоела. Ә бу сыйфат — олы Гармониягә якынлык дигән сүз бит ул!*

*Тик менә шунысы гына бераз күңелегезне тырнап тормыймы: тегеләрне бөтен дөнья диярлек укый бит ... Ә Сез инде Сез хәзер, олы яшькә җиткәч, моның шикле фани дөнья уйларыннан югарырак күтәрелдегезме? Моңа артык исегез китмиме? Хәзер инде бу хакта татар милләте үзе, аның җитәкчеләре кайгыртырга тиешме икән әллә?*

— Билгеле, мин Чеховны да, Бунинны да бик яратып укыдым. Аеруча Чехов хикәяләренең һәм аның әдәби иҗат турында әйткән фикерләренең уңай йогынтысы миңа зур булды. Ләкин бер вакытта да мин үземне алар рәтенә куеп карамадым. Хәтта юри генә дә. Чехов, Буниннар — рус әдәбиятының бөек вәкилләре, матур әдәбиятның дөнья күләмендә танылган даһи осталары ... Алар кебек танылыр өчен талант чамасы туры килү генә яки аерым әсәреңнең сыйфаты түбән булмау гына да җитми... Моның өчен беренче нәүбәттә татар халкының дәрәҗәсен һәм абруен күтәрергә кирәк. Татар халкы, Татарстан югары цивилизацияле демократик дәүләтләр рәтенә керергә тиеш. Менә шуннан соң, ихтимал, безнең кебекләрне дә күрә, таный башларлар. Ләкин көтеп ятмаска!.. Талантларны таба да, күрсәтә дә белергә кирәк. Талантларны халык тудыра, талантлар исә аңа дан китерә. Күптән билгеле шушы хакыйкатьне онытмаска кирәк.

*— Озак еллар буе коллыкта яшәгән милләтнең холкы безнең татар язучыларында бик тә нык сизелә. Аларда курку хисе аеруча көчле. Әнә шул хис күп чагында ялагайлану, тел яшерү тудыра, төрле хәйләләргә этәрә. Милләтнең намусы булырга тиешле язучы кешедә мондый җирәнгеч сыйфатларны күрү бигрәк тә авыр тәэсир калдыра. Элеккерәк елларда өлкә комитеты тирәсендә көн дә, төн дә бөтерелгән җитди генә иҗат кешеләре хәзер, үзгәреш башлангач, шундый ук дәрт һәм кайнарлык белән партияне сүгәләр ...*

*Ә Сез исә теге вакытта Намуслы Иҗат өчен генә әллә никадәр кыенлык күрдегез. Милләтнең чын әдибе, сатылмас әдибе булып танылдыгыз. Хәзер Яңарыш килгәчтен дә, Сез иң алдынгы көчләр белән артык якынаймыйсыз. Ә киресенчә, аларны тәэзәткәләп, дилбегәне тарткалабрак киләсез. Алар белән ачыктан-ачык бәхәскә дә ташланасыз ... Менә болар барысы да Сезнең барыннан да бигрәк Намус кешесе булуыгыз хакында сөйли. Сез кемнәргәдер ярарга, ошарга тырышып түгел, ә үз иманыгыз кушуы буенча яшисез һәм язасыз.*

*Шулардан чыгып мондый сорау күңелгә килә: иҗат кешесе нинди шартларда үзен чын иҗатчы итеп тоя ала икән? Безнең бүтән әдипләр дә бары тик Намус кушуы буенча гына язсыннар өчен нәрсә эшләргә икән? Әллә без озак еллар буе мескен милләтнең мескен язучылары киеменнән, шундый язмыштан котыла алмабызмы әле?..*

— Татар язучылары арасыннан бары мине генә намуслы дип тану белән мин, әлбәттә, килешә алмыйм. Намуслы әдип, шагыйрьләр бездә аз түгел. Саный китсәм, бик күпләрне искә төшерергә туры килер иде. Дөрес, намус берәүдә күбрәк, берәүдә кимрәк булырга мөмкин, ләкин аның үлчәвен кем белә, кем үлчәп карый ала?.. Әйтик, намуслыны — намуссыздан ничек аерырга?.. Намуссыз дип әйтергә мөмкиндер, бәлки, чеп-чи ялган язучыны, кешегә нахак яла ягучыны, яки үзеннән өстеннәргә ачыктан-ачык ялагайланучыны. Ләкин моны да исбат итәргә кирәк бит әле. Хикмәт шунда ки, без озак еллар бер генә идеологиягә буйсынып яшәргә һәм иҗат итәргә мәҗбүр булдык. Мондый шартларда бик намуслы әдип яки шагыйрьнең дә, үзе дә сизмәстән, алдануы да, ялгышуы да бик мөмкин иде. Безнең әдәбиятта моның да мисаллары күп булды. Әмма иҗат эше — ул асылда намус эше. Мәрхүм Такташның шигъри юллары искә төшә:

Анкеталарымда бик күп алдасам да,
Җырларымда — һичбер вакытта...

*(«Киләчәккә хатлар»дан)*

Менә мин дә күпме-азмы язганнарым турында бары шулай гына дип әйтә алам.

*— Шактый сәер күренеш килеп туды түгелме: хәзер без сүгә торган 70 ел эчендә татар әдәбиятында байтак кына чын сәнгать әсәрләре язылган. Алар арасында милләткә озак еллар буена хезмәт итәрдәйләре, искерми торганнары да байтак. Ә менә үзгәреш, Яңарыш еллары килгәч чын әдәби әсәрләр бик аз языла башлады ... Сезнең үзегезнең дә иң яхшы әсәрләрегез «торгынлык» дип аталган елларда иҗат ителгән бит.*

*Сезнеңчә, болар безгә нәрсә хакында сөйли?*

— Җәмгыятьтәге сәяси-иҗтимагый үзгәреш әдәбиятта һәм сәнгатьтә дә сизелерлек үзгәрешләр тудырмыйча калмый, билгеле. Сталин бу фани дөньядан китеп, җитәкчелеккә Хрущев менеп утыргач һәм аның тарафыннан шәхес культы фаш ителгәч, җәмгыятьтә яңа сәяси атмосфера туды, ә бу үз нәүбәтендә әдәбият-сәнгать өлкәсендәге һаваны да шактый җылытып җибәрде. Аны «оттепель» дип атадылар. Без дә күпмедер хөрлек сиздек, иркенрәк сулый башладык. Тормышны үзебез күргәнчә һәм үзебез аңлаганча яза алуга да ирешкәндәй булдык. Дөрес, иске догмалар бик көчле иде әле, идеология сафлыгын теше-тырнагы белән сакларга әзер торучылар да җитәрлек иде ... Ләкин инде тормыштагы үзгәрешләрне туктату яки кирегә бору мөмкин түгел иде. Хрущевтан башлап, 85 нче елга кадәрге вакыт безнең әдәбият өчен шактый уңышлы, бәрәкәтле бер чор булды дип әйтә алабыз. Әдәбиятка яңарак аяк баскан әдип вә шагыйрьләр бик тиз күтәрелеп киттеләр. Өлкәнрәк буынның да иҗади активлыгы көчәйде. Сез әйткән байтак яхшы әсәрләр нәкъ шушы елларда язылып та калды. Минем дә иҗади эшчәнлегемнең иң күп өлеше шушы вакытка туры килә.

Инде 1985 нче елның язы алып килгән сәяси-иҗтимагый үзгәреш үзенең яңалыгы белән дә, зурлыгы белән дә һич көтелмәгәнчә булып чыкты. Без аңа әзер дә түгел идек. Йә әйтегез, кем көткән иде хәбәрдарлыкны, фикер хөрлеген — ачыктан-ачык һәммәсен тәнкыйть итә алуны?.. Бигрәк тә, моңарчы тел-теш тидерергә ярамаган партиянең бөтен иске чирләрен, иске җинаятьләрен фаш итүне, яңа хәрәкәт, яңа партияләренең туа башлауын — кыскасы, безнең тимер-бетондай какшамас тоталитар системаның ишелә һәм демократиягә табан борыла башлавын, йә, кайсыбыз көткән идек?.. Боларның барысын да тиз генә колачлау, аңлау, сеңдерү, бигерәк тә әдәби әсәрләрдә чагылдыра башлау мөмкин түгел иде. Моңа кимендә берничә ел вакыт кирәк иде. Шуңа күрә дә күп язучылар

әдәби әсәрдән тизрәк публицистикага күчте яки кайчандыр язып та басылмыйча яткан әсәрләрен чыгара башлады. Мондый хәл барлык әдәбиятларда диярлек күзәтелә. Минем белән дә шундый ук хәл: хикәя-повестьларны онытып, мәкаләләр язарга тотындым. Элек кузгатырга мөмкин булмаган проблемалар да, әйтәсе килгән сүзләр дә күп җыелган иде. Бәлки болай жанр алыштыруның кирәге дә һәм файдасы да булгандыр, әмма язучының үзе өчен — бары тик зарар гына... Әдиплек (художниклык) сәләтеңне югалтуың бик мөмкин. Мин инде мәкаләләрнең кабат укылмавын, тиз онтылуын, китап булып чыга алмавын әйтеп тә тормыйм.

*— Әдипләр озак еллар буена чын кеше, кешелекле зат тәрбияләү өчен тырышты. Татар әдәбиятының максаты бигрәк тә шундый иде. Чөнки аның нигезендә ук «әдәб» дигән сүз, төшенчә ята.*

*Ә менә хәзер кино һәм телевидение (бигрәк тә Россиянеке!) яшь кешене эчтән җимерү эшен үтә актив алып бара. Экранда минут саен үтереш, талау, көчләү, секс. Бу инде хәзерге балаларны менә дигән бандитлар итеп үстерү дигән сүз! Масса күләм тәрбия менә шундый!*

*Биредә язучы нишли ала? Безнең татар зыялылары милләтнең киләчәген саклап калу өчен мондый очракларда нәрсә эшләргә тиешләр? Ә безнең җитәкчеләр, хөкүмәт?*

— Бөтен әйткәннәрегез белән килешәм. Әйе, рухи җимерелү дәвам итә. Россия җитәкчеләре аны күреп торсалар да туктата алмыйлар, хәлләреннән килми, бәлки әле туктатырга артык теләкләре дә юктыр. Чөнки бу рухи һәлакәт алар башлаган икътисади реформаның турыдан-туры нәтиҗәсе. Реформа (базар мөнәсәбәтләренә керү) кешеләрдә тизрәк кенә акча җыю, баеп калу теләген уятты. Ә бу теләк һичбер нинди мораль кагыйдәләр белән хисаплашып тормый — алдарга да, таларга да, үтерергә дә ярый. Җинаятьчелекнең коточкыч артып китүе шуның бик ачык мисалы ... һәм иң куркынычы — баеп калырга омтылу власть идарәләрендәге номенклатурага да күчте, алар дәүләт милкен кулларында тотучы монополистлар, яңа бизнесменнар, һәр төрле җинаятьчеләр белән укмашып, үрмәкүчтәй бинииһая олы бер мафиозга әверелделәр. Билгеле инде, аларга хәерчелеккә төшкән халыкны ниндидер әхлакка өйрәтүнең һич тә кирәге юк. Киресенчә, азгынлык, бозыклык, кансызлык, үтерү-талаулар экраннардан халыкка ничаклы күбрәк таралса, аларга үзләренең кара эшләрен үтәү дә шул чаклы җиңелерәк булачак.

Безнең Татарстандагы хәлләргә килсәк тә шул ук нәрсәләрне күзәтергә була. Бөтен ил күләмендә барган процесслардан читтә торып калу мөмкин түгелдер, билгеле. Шулай да ике нәрсә бездәге әхлакый атмосфераны беркадәр саклый иде кебек. Беренчедән, Татарстанның базар мөнәсәбәтләренә йомшак керергә тырышуы, икенчедән, татар халкына электән үк күпме-азмы тыйнаклык, әдәплелекнең хас булуы. Әмма бу ике таяныч көчсез икән шул: «йомшак керү» барып чыкмады (тешләрне җимереп керә башлады), нәтиҗәдә бөлгенлек бик көчәйде, ә бөлгенлек ул иң элек әхлакка китереп суга. Шулай ук тыйнаклык, әдәплелек тә көннән-көн кими бара. Экраннарда көн саен күрсәтелә торган җинаятьчеләрнең шактый өлеше яшь татар егетләре, үсмер малайлар...

Нәрсә эшләргә соң?.. Әлбәттә, әдәбият һәм сәнгать үзенең төп бурычын — халыкка рухи вә әхлакый тәрбия бирүен һичшиксез үтәргә тиеш. Бу изге эшнең иң зур өлеше мәктәпләр өстенә төшә — димәк, шуларда тәрбия эшләре бик яхшы булырга тиеш. Дин көчәя, мәчетләр салына, мәдрәсәләр ачыла — димәк, менә шуларда халыктан беренче нәүбәттә ислам диненең әхлакый кагыйдәләрен һәр җирдә, һәр эштә даими үтәүләрен таләп итәргә кирәк.

Җитәкчелек ни эшли ала?.. Билгеле, җитәкчелек вәгазь сөйләп йөри алмый ... Әмма ул, әгәрдә ки халыкның гомумән әдәпле, мәдәниятле булуын теләсә, һичшиксез әдәбиятка, сәнгатькә, мәгърифәткә вә дингә һәрьяклап ярдәм итәргә, кайгыртырга, акчасын да кызганмаска тиеш. Әхлакый яктан таза булуыбыз ул — бәйсезлегебезне ныгыту өчен дә, дөнья алдында абруебызны күтәрү өчен дә бик кирәкле шәйдер, Тукайча әйтсәк.

*— Бүген, безнең көннәрдә чын һәм җитди иҗат өчен ниндидер бер этәргеч бетте кебек. Олы бер стимул югалды сыман. Сез моның белән килешәсезме? Татар әдипләренә мондый хәл белән ризалашырга ярыймы?*

— Иҗатка стимул бар, минемчә ... Ул — безнең милләт буларак яңадан уяна башлавыбыз. Беренче уяну үткән гасырның ахрында, бу гасырның башында булып узган иде. Шул кыска гына чор дәвамында татар халкы искиткеч зур бер

күтәрелеш кичерде. Бу хакта бәлки тагын сүз булыр әле, хәзергә исә бер генә мисал: нәкъ шушы беренче уяну вакытында безнең классик әдәбиятыбыз туды, үсте, танылды. Ул заманда яңа туып килгән төрки әдәбиятлар, бездән үрнәк алып, үсә башладылар — алар моны үзләре үк әйтеп торалар.

Кыскасы, безнең милләт буларак яңадан уяна башлавыбыз иҗади көчләр өчен. Сез әйткәнчә, һичшиксез көчле этәргеч булырга тиеш. Моның инде галәмәтләре дә ачык күренә башлады — әдәбиятка күп кенә яңа исемнәр килде, газета-журналлар саны артты, халыкта үзешчән сәнгать бик җәелеп бара, тарихи эзләнүләр шактый ук көчәйде. Һәм боларның барсының да нигезендә милли азатлыкка сусау ята ... Әмма зур үкенечкә каршы, безнең бу табигый омтылышны соңгы еллардагы тирән икътисади бөлгенлек һәм иҗтимагый киеренкелек бик нык буып тора. Шуның аркасында киләчәгебез дә ачык кына билгеле түгел, сәяси хәлебез дә бик киеренке. Алда әле безне зур сынаулар көтә.

*— Дөнья үзгәрә! Бик нык үзгәрә ул һәм начар якка үзгәрә. Моннан күп еллар элек үк Сезнең әсәрләрегездә беренче чаткылары күрсәтелгән тенденцияләр, кызганычка каршы, тормышта тагын да көчәйделәр. Әрсез тигәнәк кебек бөтен җирне, дөньяны басты алар. Зөфәр Сабитовлар, Идеал Шәйхиевлар бүген дилбегәне кулда тота. Сезнеңчә, безгә нишләргә кала? Бирелергәме — ике кулны өскә күтәреп, ак флаг тотып, алар ягына күчәргәме?*

— ...Зөфәр Сабитов кебек бик сакланып кына, әз-әзләп кенә дәүләт милкен ташучы «инсафлы» тәэминатчеләр заманы күптән узды инде. Мәгәр аның бик ачык, бик гади фәлсәфәсе калды: бәхет ул — байлык, ә байлыкны һәркем үзе табарга тиеш!.. Бу фәлсәфә хәзерге реформаторларның постулаты ... Шуңа таянып бездә яңа бер җәмгыять төземәкче булалар. Идеал Шәйхиев кебек марксист галимнәрне шуның инициаторлары дип тә фараз кылырга була.

Ләкин ни өчен дөнья яхшырмый, Сез әйткәнчә, бары начар якка үзгәрә?.. Чөнки күптәнге иманнарыннан (социализм төзүдән) ваз кичеп «базар мөнәсәбәтләренә» керүне (ягъни капитализмга кайтуны) большевик җитәкчеләр башладылар. Ә большевикларга элек-электән үк бер сыйфат хас иде: алар өчен халык бар, әмма кеше юк ... Алар һәр эшләрен халык өчен диделәр, мәгәр бер вакытта да аерым кеше турында уйламадылар, аның белән хисаплашмадылар. Менә аларның ашыгып башлаган реформалары да нәкъ шул юл белән китте — кешеләрнең иң зур күпчелегенә бөлгенлек газабы, аптырау-йөдәү, өметсезлек китерде.

Хәлбуки, әшәкелекнең, бозыклыкның, явызлыкның һәртөрле җинаятьләрнең күбесе хәерчелектән килә. Без моны көн саен күреп, ишетеп торабыз. Инде хәерчелеккә милли шовинизм да өстәлсә, ул безне «базар мөнәсәбәтләренә» түгел, туп-туры фашизмга илтеп кертәчәк. Бу куркыныч хәзер көн тәртибендә — Ельцин артында әнә Жириновский басып тора!..

Без бит гел алданып яшибез. «Үзгәртеп кору» башланганнан соң да без инде әллә ничә тапкыр алдандык. Менә демократиягә бик ышанган идек, шуның тизрәк җиңүен көттек. Ә ул, большевизм карныннан туган «демократия», бик тотрыксыз, аумакай, гарип бер нәрсә булып чыкты. Әмма шуңардан башка нәрсәгә таяна алабыз?.. Черчилль әйткән имеш: демократия начар нәрсә, ләкин кешелек дөньясы аңардан юньлерәкне уйлап тапканы юк әле, дип ...

Чынлап та, кире үткәнгә — тоталитаризмга кайтып булмас, иншалла! (Чөнки артка борылу зур һәлакәт китерәчәк.) Шулай ук реформадан да баш тарта алмыйбыз, ул безнең тормышыбызга шактый нык керде инде; упкын аша сикергәндә ярты юлда туктарга ярамый, дигән шул ук Черчилль әфәнде ... Бәлки реформа, ахыр чиктә, илгә муллык китерер, муллыкка ияреп бәлки безгә тынычлык, иминлек, тәртип тә кайтыр.

Хәзерге шартларда каләм әһеле нәрсә эшләргә тиеш? Безнең белән бүген дә иске түрәләр идарә итәләр. Исемнәре үзгәрсә дә, гадәтләре үзгәрмәгәндер, мөгаен ... Язучының да бил бөгеп, «ләббәйкә» дип торганы, ихтимал, кулаерактыр аларга... Әмма без Исхакый-Тукайлар традициясенә тугърылыклы булып калырга тиешбез. Алар шикелле бары тик үзебез дөрес дип тапканны, бары намусыбыз кушканны язарга! — Башка чарабыз юк безнең бу болгавыр бер заманда да!

*— Сез әле һаман китапның һәм китап сүзенең куәтенә ышанасызмы? Киләчәктә әдәбият халык тормышында — татар милләтенең яшәешендә нинди урын биләр икән?*

— ...Әлбәттә, ышанам... Ышанмаганда, каләмне сындырып ташларга гына кирәк. Инде әдәбиятның милләт яшәешендә нинди урын тотканын аңлар өчен

Тукайның «Туган тел»ен генә искә төшерү дә җитә. Татарлар яшәгән бөтен авыл-шәһәрләрдә һәр зур җыелыш-мәҗлесләрдән соң халык бердәм торып, бер дәрт белән «Туган тел»не җырлый ... һәм ул көчле яшәү гимны булып янгырый. Гомумән, милләтләрне ике нәрсә саклый: дин һәм мәгърифәт. Ә әдәбият мәгърифәтнең иң татлы вә әче җимеше ул!

*— Дөньяда ыгы-зыгы, гауга-талаш нык артты. Адәм балалары алны-артны белмичә чаба, даулаша, сугыша, кан коя ... Менә шушындый йөгәннән ычкынган, азган гавәмне ничек итеп, нәрсәдән тотынып, нидән башлап дөрес юлга кертергә, дөрес яшәү рәвешенә иңдерергә икән?*

— Тормыш яхшылык белән яманлыкның (яки явызлыкның) көрәшеннән гыйбарәт. Бу — бик күптән билгеле хакыйкать. Төрле сәбәпләр аркасында әле берсе, әле икенчесе өскә чыга. Хәзер яманлыкның өскә чыккан чагы ... Әмма яхшылык бетте, җиңелде дигән сүз түгел. Яхшылыкка омтылыш бер вакытта да бетмәячәк, чөнки ул кешелек җәмгыятенең нормаль яшәвен тәэмин итеп торучы. Яхшылык яманлыктан көчлерәк, чөнки ул кешеләргә кирәгерәк. Шуңа күрә яманлыкның (явызлыкның) хәзерге өстенлеге, һичшиксез, үтәр, ә яхшылык иртәме-соңмы, барыбер, өскә чыгар дип бик нык ышанып торырга була. Башкача мөмкин түгел, башкача булганда дөнья бетәчәк.

Моңарчы без әдәбият һәм сәнгать кешеләрне бары яхшылыкка өнди дип ышана идек, хәлбуки алар яманлыкка да бик оста өнди беләләр икән. Соңгы елларда безнең экраннарны басып киткән чит ил фильмнарының бөтен күрсәткәне — фәхешлек тә ерткычлык!.. Һәм моның өчен беренче нәүбәттә дәүләт үзе гаепле, чөнки халыкның рухи тазалыгын саклау аның төп вазифасы булырга тиеш иде. Хәзер ни язсаң да, ни күрсәтсәң дә ярый диләр — әмма бу һәртөрле яманлыкка олы юл ачу дигән сүз бит. Акны карадан аера белергә кирәк.

*— Бүгенге кешегә нәрсә таяныч, терәк була ала? Киләчәккә ышаныч нинди нигездә туа һәм үсә ала?*

— Читен сорау!.. Таянычны һәркем үзенчә таба торгандыр инде.

Сайлау мөмкинлекләре хәзер бик киңәйде ... Мин тик бер нәрсәне беләм: кеше яшәргә тиеш. Менә шушы «тиеш» аның иң беренче таянычы. Чөнки бу табигать законы — зарурият!.. Икенчедән, яшәр өчен кеше гомер буена нидер эшләргә, нәрсәгәдер хезмәт итәргә, нинди дер максат өчен көрәшергә тиеш бит инде. Бусы да зарури ... Кеше матди вә мәгънәви терәк-таянычны бары эш-хезмәттән генә таба да ала, минемчә ... Кешелек дөньясының бөтен тарихы шуны исбат итә түгелме соң?!.. Үзебезнең олы затларыбызны гына искә төшерик: Мәрҗани, Риза Фәхретдин, Исхакый, Тукай һәм башка бик күпләрнең яшәешендәге мәгънәви таянычлары бары тик үз халкына армый-талмый хезмәт итүләрендә түгелмени?

Тукайның татар шәкертләренә: «Әйдә халыкка хезмәткә, хезмәт эчендә йөзмәккә» дигән бик шәп өндәмәсе бар ... Менә шул өндәмәгә хәзерге терәк-таяныч эзләүчеләр дә колак салсалар начар булмас иде!.. Хезмәттән дә тазарак нинди терәк булырга мөмкин, югыйсә?..

*— Моннан 37 ел элек язылган «Ялгызлык» хикәясе ... Тормышның бер-берсе белән гаять тә катлаулы мөнәсәбәттә булган ике зур көчен ачучы, иҗтимагый эчтәлеге белән хәтта ки романга тиң мәгънә сыйдырган онытылмаслык әсәр.*

*Бай рухи дөньялы Тамара Сергеевна һәм мәнсез шалопай Петр Котов ... Примитив бер адәм затының Олы Рухият кешесен халык алдында көлкегә калдыруы...*

*Югарыда әйтеп үтелгәнчә, рухи ярлы һәм хәйләкәр, шома кешеләр бүген тулысынча диярлек тантана итә. Менә шул чакны Сезнең әсәр исеме хәтердә өр-яңа яктан ачылып китә. Рухи яктан бай яшәүче кешеләр, бәлки, бу фани дөньяда гел әнә шул Тамара Сергеевна хәлендә, гел дә ялгызлыкта кала торгандыр? Бәлки бөек трагедия әнә шундадыр?! Бөек Тукай да: «... шат яратса да, җиһанга ят яраткан», — дигән бит...*

— Әйе, кызганычка каршы, Тамара Сергеевна кебек сизгер җаннар безнең арада сирәк очрый, ә Петя Котов кебек түбән бәндәләр атлаган саен очрап тора. Хикәя 1957 елда язылган иде. Дөреслекне яшерергә гадәтләнгән безнең Совет власте шартларында яхшы белән яман кеше мәсьәләсе мине һәрвакытта уйландыра, борчый торган мәсьәлә иде. Каядыр язып куйганым да бар: минем исәбемчә, Советлар Союзында халыкның 70 проценты яхшы да, начар да түгел. Ягъни, бу халыкның яхшы яки начар булуы үзенә карата булган мөнәсәбәткә

карап йөри, яхшыга — яхшы, начарга — начар! 25 проценттан торганы — начар халык, әшәкелек эшләүчеләр. Болар яхшылыкның нәрсә икәнен белми һәм белергә дә теләми. Бары 5 проценты — яхшылар. Болар күбрәк борыннан калган кешеләр — иске зыялылар, авылның бозылмаган карт буыны, эшчеләрдән дә бозылмыйча сакланып калганнары булырга мөмкин. Болар начарлык эшли белмиләр, хәтта бүтәннәрдән начарлык күргәндә дә үзләренең кешелек сыйфатларын саклап кала беләләр. Тәрбияләре шундый, чыгышлары затлы ...

Минем бу исәпләвем чагыштырмача тук, тыныч заманда иде, хәзер исә процентлар тагы да үзгәрә төшкәндер. Һәрхәлдә, «яхшылар» дигәнем, һичшиксез, шактый ук кимегәндер. Вәхшилек бик көчәйде. Кеше хәзер яхшы сыйфатларын көннән-көн югалта бара. Минем үземдә дә шул ук кайгы: ничек итеп кешелек сыйфатларын сакларга, ничек кенә түбән төшүдән сакланырга?!.. Беләсезме, кешеләр хәзергедәй явызланып, усалланып беткән бер заманда, яхшы булыйм дисәң дә, яхшы гына булулары бик читен. Моның өчен гаять зур рухи көч кирәк.

*— Сезнең буын белән совет чорында туып үскән бүгенге 60—70 яшьлекләр буынын без еш кына чагыштырып карыйбыз. Аерма шактый зур чыга. Кыскача гына әйткән вакытта: аларда фани дөнья мәнфәгатьләре ныграк өстенлек ала кебек, шайтан вәсвәсәсе дә ешрак бутый шикелле аларны... Сез моны нәрсә белән аңлатыр идегез икән?*

— Дөрес, безнең буын, аеруча бездән дә олырак буын белән Совет чорында туганнар арасында аерма шактый зур. Өлкән буын башлыча ата-ана кулында тәрбияләнгән, аларны апалары, әбиләре дә караган, шуның аркасында аларга ата-бабадан сакланып килгән күркәм гадәт-йолалар да күчеп өлгергән ... Аннары дини тәрбиянең йогынтысы бик көчле булган ... Шуларга тагын табигатькә, хайваннарга якын торуны да өстәргә кирәк. («Жигули»гә караганда ат кешене йомшаграк, шәфкатьлерәк итә.) Кыскасы, өлкән буынның холык-фигылен беренче нәүбәттә ата-ана һәм дини тәрбия билгеләгән. Мин моны үземнән шактый олы Бакый, Нәкый, Риза һәм Гомәр абзыйларга карап та әйтә алам. Әгәр миндә дә ниндидер әйбәт сыйфатлар бар икән, мин аларны бары атам-анамнан күчкән дип кенә беләм.

Совет заманында туганнарга исә дини тәрбия бөтенләй эләкмәде. Киресенчә, балаларга яслелән алып дингә нәфрәт кенә сеңдерелде. Шулай ук ата-ана тәрбиясе дә бик зәгыйфь булды. Чөнки көне-төне колларча эшләргә мәҗбүр булганлыктан, ананың баласын карарга җитәрлек вакыты да калмады.

Әмма төп сәбәп аңарда гына түгел ... Иң төп сәбәп Совет тәрбиясендә. Советлар (дөресрәге, большевиклар) 70 ел буена кешене-кешегә каршы куйдылар (сыйнфый көрәш), кешегә ышанмаска, шикләнеп карарга өйрәттеләр. «Халык дошманы» дип миллионлаган кешеләрне кырып бетерү сыйнфый көрәш теориясенең гамәлдәге эше ул ... Шул ук вакытта бик күпләрне җан саклар өчен эчке уйларын яшерергә, ике йөзле булырга, яраклашырга мәҗбүр итәләр. Бу «тәрбиядән» без дә читтә торып калмадык, чөнки гомеребезнең иң зур өлеше шушы вафасыз заманга туры килде. Шулай да әхлак ягыннан карт буын Совет заманында туганнарга караганда ничектер инсафлырак, тыйнаграк дияр идем. Ләкин моңардан гомуми кагыйдә ясарга җыенмыйм — картның кеме юк та, яшьнең кеме юк! Әмма хәзерге вакытта элеккеге Советлар Союзының бөтен почмакларында хөкем сөргән вәхшилек, ерткычлык, кансызлвк әнә шул 70 еллык «тәрбиянең» нәтиҗәсе ул!..

*— Хәзер, 85 яшьне тутырганда, Сезне язучы буларак биләгән иң зур уйлар нинди?*

— Бу яшьтә кеше үзенең үткәне турында күбрәк уйланырга мәҗбүрдер, ахрысы ... Йомгак ясыйсы килә торгандыр ... Бик күп картларның истәлекләр язарга керешүе дә шуңардан киләдер дип уйлыйм. Мин үзем дә еш кына үткәнемә кайтам, әмма ләкин уйларым бүгенге хәлләрдән ычкына алмый — ничектер ике уртада яшим кебек...

*— Сез татар халкының ике бөек әдибе Исхакый һәм Тукай буләгенә чыннан да лаек булган һәм аларны алган мөхтәрәм язучыбыз. Ничек уйлыйсыз: бу ике шәхеснең граждан лык батырлыгы барыннан да бигрәк нәрсәгә нигезләнгән?*

*Һәм шуңа ук ялганып китә торган аерым сорау: ни өчен нәкъ менә Тукай? Ни өчен нәкъ менә Исхакый?*

— Нәрсә дим?.. Бу махсус өйрәнүне, тирән уйлануны таләп итә торган бик җитди сорау. Ләкин Сез инде шундый сорау куйгач, мин кыскача гына шуны әйтә

алам: Була һич үзгәрми торган кешеләр. Үзгәрә тарихи вакыйгалар, үзгәрә тормыш шартлары, ә ул, үҗәт кеше, һич кенә дә үзгәрмичә үзенең төп мәсләгендә кала бирә. Хәтта вакытлы мавыгып китүләре булса да, андый кеше, барыбер, үзенең баштагы иманына кайтып төшә. Исхакый белән Тукай, минемчә, әнә шундый үзгәрә белми торганнардан. Күрәсең, бу аларның какшамас, тайпылмас нык характерларыннан килә торгандыр. Әгәр алар безнең заманда яшәсәләр, кичә — большевик, бүген — милләтче, иртәгә демократ була алмаслар иде. Чөнки вөҗдан бар, вөҗдан кушмый төрле кыяфәткә керергә. Андый кешеләр, гадәттә, сирәк очрыйлар.

Инде ни өчен Тукай, ни өчен Исхакый дисәк. Моның җавабы, миңа калса, бик ачык: алар икесе дә татар халкының уяну дәверендә мәйданга чыккан шәхесләр, икесе дә шул уянуның иң кыю, иң туры сүзле таңчылары ... Нәкъ менә мәсләкиманнары какшамас, үзгәрмәс булуы өчен дә заман үзе аларны сайлап алды һәм «кул җитмәс» биеклеккә күтәрде.

*— Язучы кешенең дан, дәрәҗә артыннан кууы аны ялгышрак юлга алып кереп китми микән? Бу очракта Олы Намус, Олы Гаделлек, Югары Кешелеклелек таләпләре бер читтәрәк торып кала ич.*

— Дан-дәрәҗә артыннан гына куучыларны китап, әлбәттә, мактамый. Ләкин бит кеше үзе алай уйламый, ялгыш юлга кердем дип тә үкенми — намусы аның тыныч. Андый кеше үзен аклый белә.

*— Әмирхан ага! Сез шәхсән нинди кешеләргә, ничек яшәүчеләргә чын-чынлап кызыгасыз? Матур мәгънәдә көнләшәсез?*

— Эшли һәм яши белүе белән миңа аеруча Бакый абзый Урманче ошый иде, аңа бик соклана идем. Ул, мәрхүм, 90 нан узганчы армый-талмый эшләде һәм тормышның ямен-тәмен белеп яшәде дә... Менә аңардан үрнәк аласы иде дә бит, тик ходай безне аның төсле үк итеп яратмаган...

*— Сез Аллага ышанмыйсыз шикелле. Ә менә бәрәкәтле иҗатыгыз нигезе булган эчке Ныклыкны, әхлакый һәм рухи тотрыклылыкны Сезгә нәрсә бирә?*

— Минем Алланы инкарь иткәнем юк. Инкарь итәрлек көчем дә юк. Иксез-чиксез галәмнең бик күп яшерен серләрен адәм акылы тәмам ачмыйча торып, Алланың (ниндидер кодрәт иясенең) юклыгын исбат итү мөмкин түгелдер дип уйлыйм. Ә барлыгына әле бик күп галимнәр дә ышаналар. Дөрес, большевиклар безне Алладан аердылар, әмма Алла исеме белән күңелгә сеңеп калган кешелек сыйфатларыннан бөтенләй үк аера алмадылар. Иҗатларыбызда, ихтимал, шулар чагыла торгандыр.

*— Язган әсәрләреннән чыгып карап без күп чагында әдип кешене идеаллаштырабыз. Аны дөньядагы иң яхшы кеше итеп күрә башлыйбыз. Ә баксаң, алай ук булып чыкмый ... Шул уңайдан Сез иҗатчы кешенең, язучы кешенең әхлакый ягы иҗат өчен ни дәрәҗәдә мөһим дип саныйсыз? Ә иҗатчының гражданлык хисләрен һәм аның бу яктан өлгергәнлеген? Ә бәлки без Иҗатка гап-гади эш дип кенә карарга тиештер? Иҗат кешесенә артык югары таләпләр куймыйча гына?.. Әмма бу очракта...*

— Язучы бит үзе — әхлакка өндәүче, бәс шулай булгач аның әхлакый ягы мотлак таза булырга тиештер инде. Ләкин язучы да кеше ич, ул да хатадан хали түгел. Мисаллар китереп торырга кирәкмәстер... Әмма намуслы язучы үзе белә кылган хатасын яки гөнаһсын. Шуның өчен газаплана үкенә һәм иҗат иткәндә мөмкин кадәр саф-пакь булырга тырыша. (Гүя юынып, ап-ак күлмәк-ыштан киеп, эшкә утыра.) Язучыны да аңлый һәм ярлыкый белергә кирәк.

*— Сез хәзер күбрәк нәрсәләр — нинди характердагы язмалар укыйсыз. Күңелегез нәрсәгә ныграк тарта? Нәрсә укудан үз күңелегезгә иң зур канәгатьлек аласыз?*

— Көтелмәгән үзгәрешләр башлангач, күбрәк вакытлы матбугатны укырга туры килде. Бөтен яңалыкларны һәм кызыкларны шуннан таба идек. Аннары кайчандыр язылып та дөньяга чыга алмыйча яткан яки чит илләрдә басылган әсәрләрне өлгергән кадәр укып бардым. Әйтергә кирәк, укыр нәрсә бик күбәеп китте, ә күзләр начарлана башлады. Хәзер инде бик сайлап кына укырга туры килә. Гәзит-журналларны ташласам, матур әдәбиятның бик әйбәтләрен генә укып ятар идем дип хыялланам, вәләкин көндәлек матбугаттан бер дә аерыла алмыйм шул. Он ашап өйрәнгән эт тегермән ташын яламыйча тора алмый, ди татар мәкале.

*— Кайчагында шулай да була: зур шау-шу куптарган һәм олы гына бүләкләр алган әдәби әсәрләр еллар узу белән үзләренең кызыгын югалталар, искерәләр. Безнең тарихи-революцион темага, нефть турында һәм КамАЗга багышлап, шулай ук эшчеләр сыйныфы һәм Совет Армиясе турында дип язган байтак кына әсәрләребез әнә шундый язмышка очрады. Кызганычыбызга күрә, алар арасында Г. Тукай исемендәге бүләкне алган әсәрләр дә бар. Шул уңайдан беренче сорау: әдәбиятка мондый карашның бездә һаман да өстенлек итүе һәм бүләкләрне дә шуннан чыгып бирү безнең яшь язучыларыбызны иҗатта ялгыш юлга юнәлтә түгелме?*

— Әдәбиятта конъюнктура дигән нәрсә бар, чөнки аңа сорау бар. Сорау булгач, тәкъдим итүчесе дә табыла, билгеле. Социаль заказ дигән төшенчә дә бар иде безнең әдәбиятта. Бу инде турыдан-туры Ленинның «әдәбият партияле булырга тиеш» дигән таләбенә туры килә. Менә шундый талап (заказ) буенча язылган әсәрләрнең дә әдәби яктан оста эшләнгәне булырга мөмкин. Оста эшләнгәне шунда ук югары бүләккә дә тәкъдим ителә. Әмма әдәби әсәрнең чын бәясен бүләк билгеләми, вакыт билгели ... Һәм күпмедер вакыттан соң әсәр искерә, онытыла башлый икән, димәк ул чын сәнгать әсәре түгел. Әкренләп аның укучы өчен кызыгы беткән макулатурага әйләнүе дә бик мөмкин. (Хәер, китап озак саклана торган нәрсә, укылмаса да тузан җыеп ята бирә ул.) Һәрбер әсәр иртәме-соңмы вакытның әнә шундый каты сынавын үтәчәк.

Инде бүләк мәсьәләсенә килсәк, монда сүз, бәхәс күп булачак. Бүләкне һәрвакытта, һәр очракта да дөрес, гадел бирәләрме — бу бик бәхәсле мәсьәлә ... Бу эштә кешеләрнең характерлары да бик нык чагыла. Берәүләр бүләкне сабыр гына көтә, икенчеләр исә аны тизрәк алыр өчен зур активлык, өлгергәнлек күрсәтә. Сабыр гына көтүчеләр еш кына бөтенләй алмыйча да калалар — андыйлар безнең әдәбиятта аз түгел. Әмма бу язучыларның әдәбиятта тоткан урыннары һәм абруйлары бүләк алучыларныкыннан һич тә ким түгел, бәлки әле артыграктыр да. Мин моны Нурихан Фәттах белән Шәриф Хөсәеновны истә тотып әйтәм.

Бездә Тукай бүләген алучылар бик күп җыелды. Арада күбрәк лаек, азрак лаек булганнары да бардыр. Әмма мин хаксыз алганнары бар дип әйтә алмыйм, чөнки минем моңа мораль хакым юк,— үзем дә бит «алучыларның» берсе. Тик шуны гына әйтәсем килә, бүләкләр өләшкәндә, яки исемнәр биргәндә абсолют гаделлек була алмый торгандыр ... Хәтта Нобель бүләген биргәндә дә!..

*— Иҗади мөхитебездә соңгы елларда яңадан группачылык, әшнәлек баш калкыта башлады. Сезнеңчә, бу ямьсез күренешнең тамырына ничек итеп балта чабып була икән?*

— Группачылык минем өчен бик ят нәрсә. Берсенә дә катнашмадым, берсенә дә мине тартмадылар. Шуна күрә мин группачылыкның нәрсә икәнен белмим диярлек. Группачылыкны әшнәлек нигезендә уртак мәнфәгатьләр тудыра булса кирәк. Кул-кулны юа дигәндәй, группага керүчеләр бер-берсен яклыйлар, мактыйлар, һәм эштә бер-берсенә ярдәм итешәләр. Шуның аркасында алар максатларына да тизрәк һәм җиңелрәк ирешәләр. Ә ялгыз кешегә читен, ялгыз кеше берәр теләгенә ирешер өчен күп көч сарыф итәргә мәҗбүр, күп кенә очракта аны әлеге «группа» читкә дә кага ... Әлбәттә, бу ямьсез күренеш. Моның җәфасы күбрәк эчкерсез, хәйләсез кешеләр өстенә төшә. Мондый күренеш элек тә бар иде, хәзер исә ул ачыграк та, әрсезрәк тә була башлады. Билгеле, моның ише үзара нык береккән һәм зур урын биләүчеләр белән эшнәләрчә бәйләнгән группачылыкны бетерү, мөгаен, бик читендер. Шул ук вакытта без яхшы мәгънәдәге иҗади дуслыкны да инкарь итәргә тиеш түгелбез. Тик бу очракта берсен икенчесеннән аера белергә кирәк.

*— Сезнең үз әсәрләрегез бик тә шигъри. Ә менә үзегез Сез шигырьләр укыйсызмы? Элегрәк укыдыгызмы? Яшьрәк чагында шигырь язганыгыз булдымы?*

— Яшь чагымда шигырьне күп укыдым, хәзер дә укырга тырышам. Шигырь сүзне дөрес кулланырга өйрәтә ... Шулай ук үзем дә язгалап карадым — яшьлек бит шигырь язудан башлана. Ләкин миннән шагыйрь чыкмасын тиз сизеп, вакытында туктый белдем.

*— Шигырь дигәннән, бу тормышта Сезнең нинди үкенечләрегез бар?*

— Үкенечләре булмаган кеше дөньяда бар микән? Миндә дә бар алар. Ләкин, һәрбер кеше шикелле үк, мин дә үзем генә беләм аларны. Гөнаһыга батып беткән бу заман кешеләре алдында ачылып бетү нигә кирәк?! Бер ходай үзе генә белсен дә, үзе ярлыкасын!..

*— Элек әйтелгәнчә, Сез бу гасырның башыннан алып ахырына кадәр үтеп киләсез. Күз генә тимәсен! Әмма Сез авыз тутырып: «Бу минем гасыр булды!» — дип әйтә аласызмы? Ә Сезнеке диеп әйтерлек гасыр нинди булырга тиеш?*

— Гасырны кеше үзе сайламый туа, кайсында туа, шунсында яшәргә мәҗбүр. Әлбәттә, бу XX гасыр мин теләгән гасыр булмады (һәм күпләр өчен булмагандыр ул), ләкин чырай сытып зарланасы да килми. Бер-бер артлы килеп торган шаккатыргыч вакыйгалары белән бу гасыр моңарчы кешелек дөньясы кичергән барлык гасырлардан да аерылып тора, минемчә. Шушы гасырда яшәргә туры килгән икән, моның өчен үкенүдән бигерәк горурланырга кирәктер бәлки ... Кем белә, киләчәк гасырларның бәхетле, тыныч яшәүдән туйган кешеләре безгә әле «кызык» заманда яшәгәннәр дип көнләшеп тә карарлар ... Ләкин бөтен хикмәт шунда ки, сугышсыз, һәлакәтсез, фаҗигасез гасырлар моңарчы булмаган шикелле, моннан соң да аларның булуына ышануы бик читен. Оҗмахтан куылган адәми затның азгын-бозык токымы үзара кырылышмыйча тора алмый ул.

*— Татар милләтенең иң якындагы 50 елын Сез ничегрәк итеп күз алдына китерәсез? Фараз итеп карасак...*

— Татар милләтенең 50 елдан соң ни хәлдә буласын, ай-һай, кем генә әйтә алыр икән?! Мин үзем 5 елдан соң ни буласын әйтергә дә кыенсынам. Без бик хәвефле бер заманда, бик тотрыксыз һәм ышанычсыз гаять зур дәүләт эчендә яшибез ... Язмышыбыз шушы дәүләт белән бик нык бәйләнгән, аның кулында диярлек, ә бу дәүләттә 5 айдан соңниләр буласын әйтүе дә читен. Менә шушындый шартларда нәрсә теләргә һәм нәрсә эшләргә мөмкин?..

Минем өчен иң төп, иң зарури теләк — бөтен Россия күләмендә татар халкының бөтенлеген һәм бердәмлеген саклау!.. Революциягә кадәр ул бөтен һәм бердәм бер милләт иде. Монархия шартларында Петербургтан алып, Ерак Көнчыгышка чаклы үзенең динен, телен, гореф-гадәтен саклап яши алды. Хәтта милли мәдәниятен үстерүдә зур уңышларга да ирешә.

Әмма Советлар вакытында без бу бердәм бөтенлекне бик тиз югалта башладык. Сугыштан соң инкыйразга табан йөз тотуыбыз аеруча көчәйде. Әйтик, мишәрләр илендә татар халкы милләт буларак югалды дисәк тә була. Ул төбәктән Шәриф Камал, Кәрим Тинчурин, Һади Такташ кебек олы әдип-шагыйрьләр бүтән чыкмаячак инде. Мондый хәлне күп җирләрдә күзәтергә мөмкин.

Соңгы елларда гына Советлар Союзының таралып китүе халкыбызның шактый өлешен бездән аерды. Инде Россия эчендәге халкыбыз өчен дә бүлгәләнеп, югалып бетү куркынычы туды. Бары Татарстанда гына торып калсак, вак, зәгыйфь бер милләткә әйләнүебез бик мөмкин, чөнки халыкның сан ягыннан кими баруы да иртәме-соңмы инкыйразга (бетүгә) китерә. Мондый фаҗиганы кичерүче халыклар Рәсәйдә аз түгел. Сәбәпләре билгеле, күп язылды, кабатлыйсым килми.

Әйткәннәрдән нәтиҗә: Татарстанның киләчәге һәм татар халкының язмышы бер-берсе белән бик тыгыз бәйләнгән. Аларны аерып карарга ярамый. Татарстанның үз җирендә мөстәкыйль, көчле дәүләт булып яшәве, ә читтәге татарларның бөтен бер милләт булып саклануы өчен алар бер-берсенә таянырга һәм терәк булырга тиешләр. Менә шул бердәмлеккә хәзерге Россия шартларында ничек, нинди юллар белән ирешергә — бу инде үзенә аерым бик житди, зур мәсьәлә. Ул хакта да уйлануларым бар, тик хәзергә сөйләп торуны кирәк тапмыйм.

*— Соңгы сүзебез итеп хөрмәтле укучыларга нәрсә әйтик икән?..*

— Әйдәгез, күпне күргән-кичергән халкыбызга киләчәктә дә һәртөрле авыр сынаулар аша исән-сау үтүен, бөтен иҗади көчләрен таза-сәламәт килеш саклавын һәм һәр җәһәттән дә үсүен, күтәрелүен, чәчәк атуын телик ... Амин, шулай була күрсен!..

Әңгәмәне **Мансур ВӘЛИ** алып барды

**Китап күзәтү**

# САБЫР САВЫТЛАРЫ БАР ИКӘН...

Ул сабыр булды, бик сабыр булды. Кайбер яшьтәшләре, каләмдәшләре кебек беркайчан да данга омтылмады. Дөресен генә әйтим: кеше белән аралашырлык урыннарда утырса да, аерымрак яшәде, ялагайлана да белмәде. Үзенчә, үзенең холкына яраклы рәвештә яшәде, язды.

Мин үзем дә Харрас Әюп иҗатына артык игътибар итми генә, кулга эләккән әсәрләрен укып, күргән чакта исәнлек-саулык сорашып, шулай гына бер-беребезне белеп яши идек. Менә хәзер минем кулда аның «Сабыр савытлары» дип исемләнгән китабы!

Башта болай уйлыйм: мәйтәм, сабыр савытларымы соң бу? Алай гына булса, шагыйрь моның белән нәрсә отар икән, нәрсә майтарыр икән? Шундый икеле-микеле уйлар белән ачтым мин бу китапны. Ә ачсам, беренче бүлек дөнья алдында бер дә аптырап кала торган кешенеке кебек аталмаган. Турыдан-туры «Дөнья яратылу» диеп куелган аның исеме.

Кайберәүләр ходай яраткан ди,—
Яралгандыр дөнья белмим нидән?
Тик нигәдер миңа бу тереклек
Башлангандыр сыман безнең өйдән.

Биредә «тереклег»еннән башка барысы белән дә килешәм. Чөнки Дөньяны тереклек итеп кенә карап булмыйдыр. Тик монысы әле башка мәсьәлә. Әмма Дөньяның безнең өйдән башлануы, кая куясың инде — хак нәрсә ич! Аннан соң шагыйрь өй тирәсендәге гади генә әйберләрне, мохитне Дөнья яратылу кебек илаһи бөеклек белән бәйли:

...Ходайныкын белмим, әммә миндә
Дөнья әнә шулай яратылган...

Әнә шундый бик самими һәм шул ук вакытта житди нәтиҗә ясала. Үз йортың, аеруча ата-бабалар йорты, кай чакларда бөтен Дөньядан да кадерлерәк шул «Ура! За родину! За Сталина!»— дип әллә нәрсәләр кырмаганбыз икән!

Гомумән, Харрас нинди генә темага тотынса да аның таяну ноктасы, басып торган жиренең кендеге — шул ата-бабаларының изге туфрагындагы нигез ташы, әтисеннән калган истәлекләр, авыл картлары, авыл карчыклары һәм аның өчен иң кадерле Әнкәсе.

Әткәй үлгән көнне язмыш мине
Иске каеш биреп алдаган...
*/«Мирас»/*

...Газиз әнкәй!..
Бала чактагыча син, житәкләп,
Алып киттең...
Инде адашмам:
Кыйбламны мин — туган туфрагымны
Бүтән кыйблаларга алмашмам!
*/«Кайтып барган чакта Мөслимгә»/*

...Сабырлыкны ходаеңнан сорап алдың,
Сабыр савытларың тулса, елап алдың...
*/«Авыл карчыклары»/*

Картлар гына ишетә ала торган
Моңнары бар, ахры, кичләрнең.
Гомер дигән төш күргәннәр бугай,
Бүлдермәдек микән төшләрен?..
*/«Авыл картлары»/*

Менә ул каян килә истәлекләр, юксынулар һәм, ниһаять, Олы Дөнья турында уйланулар!

Харрас әллә нинди югары материялар турында язмаса да, Зур Дөньяга бик гади генә булып тоелган капка баганалары аша керә белә. Мин аның «Капка баганасы турында баллада»сын баллада дип түгел, ә бәлки шигъри повесть дип атар идем. Гомумән, Харрас шигъриятенә бу табигый күренеш. Аның күпчелек шигырьләре /поэмалары турында әйтеп тә торасы юк/ сюжетка корылган. Баллададагы баганалар — алар шартлы баганалар да, шартлы түгелләр дә. Монда баганаларны, минемчә, нигез ташы дип тә аңларга буладыр. Әмма, алай дисәң, ата-бабаларның нигез ташын күчереп йөртеп тә булмый. Менә шулай күпне уйлап, аптыраштa калдыра торган баганалар ул. Хуҗалыгы янып, алырга бер нәрсәсе дә калмагач, хәзрәт «күмерләнгән ике баганасын...» казып алып китә дә «Яңавылга» күчереп утырта. Әнә шул баганалар тол калган мулла кызының

сугышта үлгән иренә тугрылыгы кебек: «Баганалар калды туры килеш...»

Китапта бу рухтагы шигырь, балладалар житәрлек. Хәтта кайвакытта бер-берсен бераз кабатлыйлар да шикелле. Әмма шагыйрь аларның һәрберсенә яңа төсмерләр табарга тырыша һәм моңа ирешә дә.

Мин Харрас турында: бу кадәр авылын сагынып, аны «үлеп» яраткан кеше шәһәрдә ничек яши ала икән, дип тә уйлап куям. Ләкин бер ягы бар бит әле. Әгәр дә читтә яшәмәсә, аны ничек сагыныр иде икән шагыйрь? Ул шулай кирәктер дә, дөнья шулай корылгандыр ул. Аеруча шагыйрьләр гомер буе сагынып, юксынып яшәргә тиешледер. Әйе, безнең күбебез авылдан чыккан, авыл турында язганнарыбыз да шактый. Әмма без хәзергә авылның хәлен аңлыйбызмы, хәзерге авыл кешесенең психологиясен беләбезме? Авылга барып клуб сәхнәсеннән биш-алты шигырь укып төшкәннән соң мул табында фәлсәфә сатып утыру гына авылны һәм аның кешеләрен белдем дигән сүз түгел бит әле ул! Шагыйрь әйтмешли:

Шәһәрнеке булып беталмадык,
Түгел инде авылныкы да син.

Менә шундыйрак хәлдә без, дуслар. Ни саланыкы, ни каланыкы... Авыл турында Харрас шикелле шулай борчылып, ачынып, аның киләчәген кайгыртып язган шагыйрьләребез бар барын. Ләкин:

Күпме өй урыны...
Елый торгач,
Сукырайган күзләр сыман алар,
Өе исән чакта никадәрле
Күңел нуры, жылы сыйган кадәр?!—

дип язганнарыбыз күпме соң?

Әйе, соңгы елларда авылларыбызда күпме өйләр, йорт урыннары бушап калды, аларны әрекмәннәр, тигәнәкләр, шайтан таяклары басып китте. Бу — мин үскән авылга да кагыла. Чулман елгасында ГЭС төзелер алдыннан «авылны су басачак» дип күпме кешене кендеге белән береккән нигезеннән куптардылар. Аларны чын мәгънәсендә мөһәжир иттеләр, зиратларыбызны сөреп ташлап, жир белән тигезләп куйдылар. Бу сүзләрне Харрас үзенчә куәтли:

Чит жирләрдә ни көткәнен белми,
Туган телебезне алып киттек.

Шагыйрь хаклы! Әгәр авылларыбыз бетә икән — туган тел дә үләчәк. Ярый әле безнең кебекләр аны алып китеп, үстерергә дә ярдәм иткәннәр. Юкса: «Телен сатып түрә булган...»-нар, ватып—жимереп урысча маташтыручылар аны каберлеккә озатырга тырыша иде бит.

Ләкин таралып бетмәгән авыллар калганда да, андагы табигатьнең төссезләнеп, таланып бетүе бик борчый шагыйрьне:

Урман булып урман яна сымак—
Ярдәм сорап безгә кычкыра ул,
Һаваларга менеп сөрән сала;
Гөнаһыбыз шулай зур микәнни?—
Кыр казларын кемдер корбан чала...

Ут күршеләр дә инде элеккечә бер-берсенә ярдәм итешеп яшәми, әллә бәлки «Көнләшүдән көеп шартлый хәзер».

Ут күршеләр...
Ата—аналары
Бер-беренә элек утка кергән.
Инде хәзер чёрт та кире чыкмас
Урыс капкалардан, юкка йөрмә!

Шулай, соңгы елларда авыл кешесенең дә психологиясе, холкы нык үзгәрде. Ә бит заманында:

Ничә еллар авылымның жаны
Безнең тәрәзәдән карап торган!—
Йокыдагы шәһәр өсләренә
Жан яктысын сирпеп таң аттырган.

Чыннан да, безнең авылдан чыккан Мәржәниләребез, Насыйриларыбыз, Исхакыйларыбыз, Тукайларыбыз булмаса, татарлар «йоклап яткан» шәһәрләргә кемнәр килеп кемнәр генә «Жан яктысын сирпеп таң аттырган» булыр иде! Ә бит безнең шәһәрләрдән чыккан шәхесләребез бик күп булмаган. Хәзер инде аларның татарча белгәннәрен бармак белән генә санарлык. Әйе, авыл жаны ул тәрәзәдән генә карап тормаган. Ул Жан шәһәрләргә килеп телебезне, иманыбызны саклап калырга нык ярдәм иткән. Чөнкин моны безгә аталарыбыз, аналарыбыз теләгән: «Тел ачкычы тели иде әнкәй, берәребез юлга жыенсак».

Ләкин шагыйрь өчен ата-ана теленнән башка әле табигать теле дә бар икән: «Иң кадерле серен сөйли урман Халыкара бөек тел белән».

Харрасның, әлбәттә, төп темасы — авыл һәм аның кешеләре. Тик чын шагыйрь болар белән генә чикләнеп каламы соң? Бөтен ижатыңны шуңа гына кайтарып калдырсаң — телисеңме, теләмисеңме, үз-үзеңне кабатлый башлыйсың. Кай очракларда Харрас белән дә шулай килеп чыга. Һәм шагыйрь болардан котылу өчен яшәешнең мәгънәсен, үзенең кемлеген жил-давыллардан, Кояштан һәм, гомумән, табигатьтән эзли башлый: «Бу

яшәү — тataштан жил икән», «Без Кояштан — Кояш яктысыннан», «Кояш белән бергә яшим мин», «Яфрак булып ярыл киләчәккә, «Тамыр булып тарал үткәнгә» һ. б.

Турыдан—туры әйтмәсә дә, кулыннан килсә шагыйрь учакка да канат бирер иде кебек. Менә бу юллар шуңа ишарәли сыман:

> Кемнәре бардыр биектә,
> Ник талпына бу чаклы?

Аңа учактан яктылык булып кемдер карап тора сыман була да, кинәт кенә аның башына: «Кайсыбыз яна далада учак микән, мин микән?..»— дигән уй китереп суга. Менә учакка ни өчен канат кирәк икән. Учакның бит шагыйрь үзе булуы да ихтимал. Тирән һәм, шул ук вакытта, тормышның үзе кебек каршылыклы шигырь бу.

Шагыйрь Харрасның романтика бәреп торган һәм бер үк вакытта моңсу йөзен күргәч, мин: «Бу кеше йә мәхәббәттә рухи тетрәнү кичергән, йә Блокча тормышка ашмый торган Олы мәхәббәтне эзлидер»,— дип уйлаган һәм аннан бик күп мәхәббәт шигырьләре көткән идем. Әмма тормышның үз кануннары барлыгын онытып жибәргәнмен икән. Фаразым бик үк акланып житмәде. Соңыннан аның бу моңсулыгы, сагышлы карашы шул таркалып барган авыллар, караучысыз калган карт—корылар һәм, гомумән, дөнья турында уйланудандыр, дигән үземчә бер нәтиҗә ясарга этәрде. Бәлки, мин бу юлы да хаклы түгелмендер... «Кеше күңеле чиксез дала»— диләр бит. Шагыйрьнеке бигрәк тә.

Харрасның мәхәббәт турында аз булса да «тәмле» шигырьләре бар, әлбәттә. Ул сөю—мәхәббәт турында язганда да үзенчә ачышлар ясый, аннан фәлсәфи тирәнлек эзли, аны халык язмышы, ил язмышы белән бәйләп бирергә тырыша. «Авыл картлары», «Сөю», «Мәхәббәт биргән каләм иде» кебек шигырьләрен укыгач, моңа тагы да ышана төшәсең. «Авыл картлары» шигыре дә гадәти мәхәббәт шигыре генә түгел. Ул үткән гомерне, димәк яшьлекне—кайчандыр булган беренче мәхәббәтне искә төшерү-юксыну да, гомер азагына якынлашканда гомер төшен күреп аптырап та калу кебек.

> ...Пар толымга таккан чулпыларның
> Чыңгылдавы, ахры, жаннарда—
> Сөю шулай сарылып калган бугай•
> Гомерләрдән узып барганда.

Алдарак әйткәннәремне раслау өчен шагыйрьнең менә мондый юлларын кабатлыйсы килә:

> Гөлләр беткән жирдә телләр беткән—
> Вакытларга нинди буйсыну!
> Йөзеп йөри Вакыт осләрендә
> Пар канатлар булып бу Сөю...

Менә шундыйрак Харрасның мәхәббәт шигырьләре. Бу инде «Мин сине яратам, приходи к воротам» түгел. Әйе, безнең шагыйребез мәхәббәтен тукып-тукып кабатламый, аны көчләп тә такмый, аны «пошлятинага»да әверелдерми. Аның максаты бар, аның иманы бар, аның туган жире бар, аның халкы бар. Димәк туган теле бар, аның Сөюе—Мәхәббәте бар!

Харрас шигырьләренә кем өчендер, нәрсә өчендер туктаусыз борчылу хас. Әйтерсең, ул берүзе дөньяның бөтен авырлыгын өстенә алган да, мыштым гына күтәреп бара. Яисә үзенең бер шигырендәге Чаң кебек:

> ...Яралы бер тимер йөрәк кебек,—
> Авыл уртасында иске чаң;
> Җирләр—күкләр тетрәп китәр сыман,
> Шул йөрәккә әгәр кагылсаң...

Ул вакытта:

> Без—сугышлар күргән буын түгел,
> Сискәндерә ботак сынса да...—

ди. Әмма, без күрмәсәк тә, кайдадыр, бик еракта да түгел, бара ул сугышлар...

«Су хәтере» поэмасы башта халкыбызга үпкә белдерү беләнрәк башлана:

> Кеше түгел бит ул онытырга—
> Хәтере бар суның, хәтере бар.
> Безнең ише хәтерсезләр өчен
> Кире кайта—кайта әйтере бар.

Хактыр, безнең хәтерне алып бетерә яздылар шул. Айтматовча әйтсәк манкортлар итеп бетерә яздылар. Ярый әле авылдан килеп шәһәрдә яшәүче саф татарча белгән татар зыялылары исән һәм бар! Аллага шөкер, соңгы елларда хәтер уяна башлады, димәк, ул бөтенләй үк сүнмәгән, ә халыкның чын милләтпәрвәрләре күңелендә читят күзләрдән сакланып, яшеренеп кенә яткан булган.

> Су хәтере — безнең хәтер!
> Туфан булып калкачак...

Калкачак ул, калкачак... Калкып та килә бугай инде...

«Көзге» поэмасы белән шагыйрь Харрас Әюп үзенең ижатын бер фокуска жыеп гомумиләштерә. Поэмада безнең үткәнебез дә, хәзерге көнебез дә, киләчәгебез дә көзгедәге кебек чагыла.

> Алларында гади көзге түгел—
> Ил—халкыңның намусыдыр ул.

**Эдуард МОСТАФИН**

# ЯҢА ТАБЫШЛАР

*Татарстан китап нәшрияты 1994 елда байтак кына кызыклы китаплар һәм альбомнар чыгарырга планлаштыра. Шулардан иң-иң кызыклылары, минемчә, матур бизәлешле итеп эшләнгән «Идегәй» дастаны, Кол Галинең «Йосыф кыйссасы», Гаяз Исхакыйның «Остазбикә» повесты булыр. Габделбарый Батталның «Казан төрекләре» хезмәте дә Казан төбәге татарларының килеп чыгуы белән кызыксынучыларны битараф калдырмастыр, мөгаен. Элек берничә мәртәбә Төркиядә нәшер ителгән ул хезмәт, ниһаять, үз җирлегебездә дөнья күрәчәк. Чөнки элек «буржуаз тарихчы» һәм «милләтче» тамгаларын йөрткән Габделбарый Баттал исеме дә үз арабызга кайта.*

Китап нәшриятының тагын бер күркәм эше — танылган шагыйрь һәм могтәбәр җәмәгать эшлеклесе, мәгълүм «Вакыт» газетасы белән «Шура» журналының һәм «Вакыт» китап нәшриятының нәшире һәм татар халкының олуг шагыйре булган Закир әфәнде Рәмиев-Дәрдемәндкә багышланган альбомыдыр. Ул альбом шагыйрь тууының 135 еллыгына багышланган бүләкләрнең зурысы булырга тиеш. Күләме һәм сыйфаты белән ул хезмәт 1986 елда Татарстан китап нәшрияты тарафыннан Габдулла Тукайга багышлап чыгарылган альбом чамасындарак булыр дип күзаллана. Дәрдемәндкә һәм аның чордашларына, кардәшләренә, балаларына бәйле байтак кына борынгы фотоларны (алар алтмышка якын) Оренбургта яшәүче, журнал укучыларына аерым мәкалә һәм очерклары буенча яхшы ук таныш булган Мәдинә апа Рәхимкулова туплаган. Дөресен әйткәндә, мондый изге эшкә без бик соң тотындык, билгеле. Дәрдемәндкә һәм аның якыннарына багышланган байтак кына фотолар инде югалганнар да. Мәсәлән, минем үземдә Дәрдемәнднең соңгы көннәрендә төшкән бер фотосурәтеннән алынган зәгыйфь кенә копия бар. Аны җитмешенче еллар башында миңа Түбән Тагил каласыннан Фәрзанә апа җибәргән иде. Аның атасы Камал Әдеһәмов Рәмиевләрнең бер прискасында баш белгеч булган (Әдеһәмовлар шулай ук Юлык авылы кешеләре, шагыйрьнең якташлары). Гасыр башындарак туган Фәрзанә әби, мөгаен, инде дөньяда юктыр. Һәм, мөгаен, аның карамагындагы фоторәсемнәр, истәлекле язмалар да юкка чыккандыр. Заманабыз шуңа бара, балалар, оныклар ата-баба мирасын күп очракта белергә, сакларга теләмиләр. Чөнки үз милли мирасларын белмиләр. (Һәрхәлдә, 1988 елда Юлык авылында булгандагы сөйләшүләрдән соң күңелдә шундыйрак фикер туган иде). Уралның, Урта Азиянең кайбер шәһәрләрендә, әлбәттә, әле андый мирасыбыз булырга, сакланырга мөмкин. Тик аларны туплаучыларыбыз, Мәдинә апа Рәхимкулова кебек эзләнүчеләребез дә житенкерәми шул әле. Ярый, болары сүз уңаенда туган ачынулы фикерләр генә.

Бүген без «Казан утлары» журналы укучыларына Мәдинә апа туплаган һәм минем шәхси архивымда саклансан кайбер рәсемнәрне тәкъдим итәчәкбез. Алар арасында әдәбият сөючеләргә генә түгел, әдәбият галимнәренең дә күпчелегенә таныш булмаган байтак кына шаһитнамәләр бар, безнеңчә.

Әйтик, бүгенгәчә матбугатта басылган бер генә хезмәттә дә дип әйтерлек Дәрдемәнднең чит илдәге сәяхәтләре тәфсилләп язылмый. Чөнки аның кайларда һәм кемнәр белән йөргәнлеген әтрафлы тикшерүче булмады кебек. Дөресен генә әйткәндә, кайберәүләр хәтта Шакир Рәмиев белән Закир Рәмиевнең тормыш юлына караган мәгълүматларны да бутап күрсәткәлиләр. Әйтик, Шакир Рәмиевнең Европа буйлап сәяхәтен Закир Рәмиев-Дәрдемәндкә «аудару» очраклары бар. Ша-

кир Рәмиев узган гасыр азагында Европаның байтак илләрендә була, ике атна чамасы Парижда яши — Бөтендөнья промышленность күргәзмәсе белән таныша. Аның тылмачы сыйфатында бу сәяхәттә булачак әдип Фатих Кәрими дә катнаша. Ул Төркиянең Дәүләт хезмәткәрләрен әзерләүче институтында укыганда француз телен яхшы үзләштергән була.

Закир Рәмиев-Дәрдемәнднең яшьлегендә Истанбулда ике ел чамасы укыганлыгы күпләребезгә мәгълүм. Ә менә 1914 елның язында аның шулай ук ярты Европаны гизеп, күп илләр белән танышып йөргәнлеге билгесез диярлек. (Аңа чаклы да шагыйрьнең Германиядә булуы ихтимал. Әмма үз шәхесен күпертеп күрсәтергә күнекмәгән Дәрдемәнднең тыйнаклыгы сәбәпле, бу мәсьәлә ачыкланмаган килеш кала).

1914 ел сәяхәтенә Дәрдемәнд бик ишле гаилә белән кузгала. Бу сәфәрендә аны элекке Сорбонна университеты шәкерте, бик тә мәгълүм җәмәгать эшлеклесе Садри Максуди (1879—1959) озатып йөри. Ул шагыйрьнең тылмачы гына түгел, билгеле. Бердән — фикердәш, иптәш. Икесе дә Икенче Дәүләт думасы депутатлары. Икенчедән — кияү кеше: Шакирның Камилә исемле кызының ире дә бит. Сәфәрләренең ике максаты була: беренчесе — чит-ят дөнья белән якыннанрак танышу булса, икенчесе — буй җитеп килүче ике егетне, Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсеннән соң шәһәрнең реальное училищесында белем һәм һөнәр үзләштергән кече Рәмиевләрне Бельгиянең Льеж шәһәрендәге институтына укырга урнаштыру. Укучыга тәкъдим ителгән **беренче** фотода шул вакыйга сурәтләнә. Фото Льеж шәһәрендә төшерелгән.



▲ Алгы рәттә көрси һәм урындыкларда утыралар (уңнан — сулга): Закир Рәмиев-Дәрдемәнд, Камилә Рәмиева-Максуди, Зәйнәп Закир кызы Рәмиева-Вәлиева, Әхәт Шакир улы Рәмиев. Басканнар: Садри Максуди, Гариф Закир улы Рәмиев, Искәндәр Зариф улы Рәмиев.

●

Искәндәр Закир улы Рәмиев бу вакытта инде Германиядә укып инженерлык дипломы алган була. Ләкин Гариф белән Әхәт өчен бу сәяхәт бик фаҗигале тәмамлана: тиздән Беренче Бөтендөнья сугышы башланып китә дә, алар илләреннән, туганнарыннан бүленеп калалар. Соңыннан Гариф Рәмиевнең Төркиягә һәм Финляндиягә барып урнашуы, 1978 елда Италиядә

вафат булганлыгы мәгълүм. Аларны, мөгаен, элегрәк Төркиягә Садри Максуди белән Камилә алып киткәннәрдер.

Шушы ук сәяхәтнең дәвамын тасвир иткән **икенче** фото — Рим шәһәрендә, Ватикан мәхәлләсе алдындагы бер мәйданда алдырылган булырга тиеш. Анда дүрт кешене күрәбез (уңнан — сулга): Закир Рәмиев-Дәрдемәнд, Зәйнәп, Камилә һәм Садри Максуди басып төшкәннәр. «Вакыт» газетасында кыскача хәбәр ителгәнчә, ди Мәдинә апа Рәхимкулова, шагыйрь шушы сәяхәт вакытында католиклар диненең башлыгы Рим папасы белән очрашып та сөйләшкән икән. Ягъни, папа аны, зур дәүләтнең бер могтәбәр эшлеклесе һәм мөхәррире сыйфатында кабул иткән.

▼



●



◀

**Өченче** рәсемдә шагыйрьнең хатыны, элеккеге Оренбург губернасы төбәгендә берничә кызлар мәктәбе ачкан һәм тоткан Мәһүбә Мостафа кызы Борнаева-Рәмиева.



**Дүртенче** рәсемдә олуг шагыйрьнең яраткан абыйсы һәм фикердәше Шакир Мөхәммәтсадыйк улы Рәмиев (1857—1912).



**Бишенче** рәсемдә Шакирның хатыны Гәүһәр Рәмиева (тумышы белән Каргалы авылыннан). Гәүһәр ханым шулай ук үз заманында мәктәп-мәдрәсәләр ачучы, аларны тоту, җиһазлау, кызлар өчен чигү, тегү ише һөнәргә өйрәтүче курслар ачкан шәхес буларак дан казанган татар хатын-кызларыннандыр. Әйтик, Юлык авылындагы Гәүһәр ханым оештырган шундый мәктәпне бүген дә олы яшьтәге әби-апалар мактап телгә алалар. *(Бу биш рәсемнең күчермәсен Зөфәр Бәширов башкарды.)*



**Алтынчы** рәсем. Юлык авылы каберлегенең урта бер җирендә Рәмиевләргә куелган алты-җиде кабер ташы бүген дә исән әле. Шулар арасында шагыйрьнең әнисе Биби-Хәнифә Дашкова-Рәмиевага куелган таш та бар. *(Кабер ташлары рәсемнәрен Юлык авылы урта мәктәбе укытучысы Ф. Әбүбәкерев төшереп җибәрде.)*


**Жиденче** рәсемдә шагыйрьнең 1918 ел февралендә Орск шәһәренә күчеп кайткач яшәгән йорты күренеше. Ул йорт иске шәһәрнең үзәгендә, хәзерге көндәге Совет урамында иде. «Орский рабочий» газетасының типографиясен киңәйткәндә, сиксәненче еллар уртасында җимерелде. Бу йорт шагыйрьнең кайнатасы Мостафа Борнаевныкы була. Аста ике бертуган Борнаевларның кибетләре, өстә яшәү урыннары. Шагыйрь гаиләсе монда ике ел чамасы яши. *(Абдулла Исәнбаев фотосы.)*



●

**Сигезенче** рәсемдә — Дәрдемәнднең гаиләсе соңгы кышын чыккан һәм 1921 елның азагынача яшәгән йорт. 1989 елда алынган рәсем. Иске шәһәрнең (Орск) Урал елгасы янәшәсендәге бер тыкрык башыннан икенче йорт. Шагыйрь аны ике-өч елга дип арендага алып тора (хуҗалары Мусиннар ул елларда бер казачий авылга китеп, кибет тоталар). Әлбәттә, Дәрдемәнд бу шәһәрдә бөтенләй төпләнеп калырга уйламаган. Оренбургтагы төп йортына кайтып гомер кичерү турында хыялланган. Анда аның эш бүлмәсе, бик зур китапханәсе кала бит. Ул аларны Орск шәһәренә күчерми. Оренбург картлары сөйләвенчә, авыр сугыш елларында бу китапханәне шул йортта яшәүчеләр мичкә ягалар. Чөнки кышлар бик суык килә, утынга кыйммәтчелек була...


▼



**Тугызынчы** рәсем. Оренбург шәһәрендә Закир Рәмиев-Дәрдемәнд йортына мемориаль такта кую тантанасы. Алгы рәттә шагыйрьнең оныгы Равиль әфәнде белән Мәдинә Рәхимкулова басып торалар. ▼



●



▲

**Унынчы** рәсемдә — Оренбург шәһәрендә унтугызынчы гасырның 90 елларыннан алып, 1918 елның февраленә кадәр Дәрдемәнд гаиләсе яшәгән йорт (хәзерге адресы: Ленин урамы, 31). Биредә шулай ук «Вакыт» газетасы һәм «Шура» журналы редакциясе һәм типографиясе дә урнашкан булган.

Сәхифәне **Лирон ХӘМИДУЛЛИН** әзерләде

**Марсель Әхмәтҗанов,**
филология фәннәре кандидаты

# КУЛЪЯЗМА КИТАПЛАРДА КЕЧЕ ЖАНРЛАР

**Иске кульъязма китап битләрендә һәм документларда XX гасыр башына тикле яшәп килгән кече күләмдәге әдәби жанрлар бар. Аларның бер ишеләре бүгенге көндә шактый дәрәҗәдә мәгълүм инде, кайберләре исә әдәби жанр буларак өйрәнелмәгәннәр. Искә алынган кече жанрны тәшкил иткән әдәби ядкярләр арасында васыятьнамәләр, ырымнар, хат язу калыплары, китап хатимәләре /ахырлары/, төрле төрки догалар, табышмаклар һ.б. бар. Бу исемлектә әлеге кече жанрны барлап бетердек дигән сүз түгел. Кульъязма мирасыбыз эченә керә барган саен без аның серләрен танып белүдә тирәнгәрәк карарбыз.**

**Безнең бу кече жанрлар дип аталган әдәби ләүхәләр (әсәрләр) язма әдәбият барлыкка килгәнче формалашканнар. Алар төрки ыру-кабиләләр арасында туып, шомарып җәмгыятьнең эволюциясе белән бәйле рәвештә үсә, үзгәрә килгәннәр. Мәсәлән, кульъязмаларда, эпиграфик истәлекләрдә сакланып калган васыятьнамә текстларын гына карыйк. Алар безгә ислам дине рухы белән сугарылган хәлдә килеп җиткәннәр. Ләкин васыятьнамә мирас бүлү мәсьәләсе белән бәйле документ. Мирас мәсьәләсе кешеләр арасында ислам, нәсрани (христиан), будда диннәренә карaганда да борынгырак мәсьәлә. Шуңлыктан төркиләр арасында Тәңре диненә табынган чакта ук мирас мөнәсәбәтенә бәйле язылмаган васыятьнамәләр булган. Алар бүгенге татар язма васыятьнамәләре чылбырының башы булганнар.**

**Төркиләр дәүләтләр төзеп яши башлагач, аларның рухи мирасына караган кече жанрлар да яңа оешкан җәмгыять мәнфәгатьләренә яраклаштырылган. Кече жанрлар тагын да камилләшеп киткәннәр. Шулай ук аларда ислам динен кабул итүнең тәэсирләре ачык күренә. Мәсәлән, язма табышмаклар сюжетында инде ислам дәүләтләре географиясе, оҗмах, кылыч тоткан егетләр, гарәп алфавиты үрнәкләренең үзенчәлекләре, орфография таләпләрге һәм башка мотивлар чагыла башлый.**

**Кече жанр үрнәкләре кульъязма китапларда, аларның баш һәм ахыргы буш битләренә теркәлеп киленгәннәр. Алардан бары төрки ырымнар системасы гына аерым җыентыклар рәвешендә йөргәннәре мәгълүм. Бу хакта жанрларга багышланган сәхифәләрдә бәян ителер.**

## Борынгы төрки ырымнар

Борынгы төрки дәверләрдән бирле килгән кече әдәби жанрның иң бай төркемен ырым догалары тәшкил итә. Алар бүгенге көннәргә кадәр язма һәм авыз әдәбияты үрнәкләре төсендә татар халкының барлык этник төркемнәрендә дә сакланган. Авыз иҗаты үрнәкләре булганнарының зур

бер колтәсе «Татар халык иҗаты. Йола һәм уен җырлары» /Казан, 1980, 33—40 бб./ китабына кертелгән. Татар фольклорын өйрәнүче Каюм Насыйри, И.М.Софийский, Һарун Йосыпов, Риф Мөхәммәтҗанов, Марсель Бакиров, Флера Баязитова һ.б. галимнәрнең хезмәтләрендә ырым жанрына игътибар ителенә. Ләкин алар кульязма үрнәкләргә тукталмыйлар.

Татар кульязма китабы борынгы ырым үрнәкләренең XVIII—XIX гасырларда ук теркәлгән күчермәләрен саклаган. Бу хакта фәнни әдәбиятта мәгълүматлар чыкты инде.[1]

Соңгы елларда ырымнар теркәлгән иске кульязма китаплар һәм ырым җыентыклары тагы да табылды. Фәнни тасвирлар язылып, алар Казанда Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты каршындагы кульязмалар бүлеге мирасханәсе 39 коллекциясендә №№ 5001, 5002, 5003, 5004, 5005, 5006, 5121 һ. б. шифрлары белән сакланалар.[2]

Ырым текстларына һәм кульязмаларга анализ аларның татар халык китабында саклануының сәбәбен ача. Ырымнар искедән бирле килеп, борынгы телебез үзенчәлекләрен саклап, халыкның тормышында мөһим урын тоткан. Халык табиблары алар ярдәмендә төрле чир-сырхауларны дәвалаган. Мондый тип ырымнар татар теленең инандыру юлы белән дәвалау өлкәсендә зур кодрәткә ия булганлыгын күрсәтә. Гипноз белән дәвалаучылар бүгенге көндә дә сүзнең бөек куәтеннән киң файдаланалар бит. Төрки-татар телендәге дәва ырымнарын XIX гасыр уртасында гарәптән кергән «Коръән» кәлимәләре кысрыклап чыгара. Кульязма китапларның андый үрнәкләре дә табылып, мирасханәнең 39 коллекциясендә саклана. /Мәсәлән, №№ 3426, 5122 һ. б./.

Гарәпчә догалыкларда инде татар телендәге чир исемнәре генә сакланган. Мәсәлән: «Баш агрыкы өчен», «Сул колак агрыкы өчен», «Уң колак агрыкы өчен», «Сул күз агрыкы өчен» һ.б.

Борынгы дәва ырымнары күз тигәннән, төрле бозулардан, сөйдергечләрдән, еланнан саклану өчен, аулау, бал кортына чактыруда кулланылганнар.

Язма ырым текстлары Татарстанда һәм Башкортстанда татарлар яшәгән районнардан табылды. Аларны чагыштырып карасаң, типологик, тел, образлар системасы ягыннан тикшергәндә, бер үк халыкның борынгыдан килгән мирасы икәнлеге раслана. Бу хәзинәнең башка төрки халыкларда сакланган милли вариантларын өйрәнү өчен әһәмияте зур. Алар аркылы тарихи кардәшлек ачыла. Ырымнар дин тарихы, тарихи этнография һәм этник тарихка карата да чыганаклар хезмәтен үти.

## Ырымнар — дин тарихы чыганагы

Татар халкының дин тарихы бүгенге көнгә кадәр язылмаган. Хәлбуки, бу тарих әдәбият үткән юлны өйрәнүгә дә ярдәм итәр иде. Бездә ислам диненә каршы юнәлдерелгән хезмәтләр басылгалап торды, ә бу өлкәдә тупланган объектив фәнни мирасыбыз барланмаган. Дин тарихын язу өчен беренче чиратта язма чыганаклар кирәк. Татарда ислам тарихы буенча нинди чыганаклар барлыгын тикшерү дә бик зәгыйфь хәлдә. Әлбәттә, бу өлкәдә бай әдәби-язма мирас бар. Мирасханәбездә кульязма «Коръән»нәр, шәригать, мантыйк, фәлсәфә, тәфсирләр, шәрехләр, рисаләләр, бәдәр сугышчылары исемлекләре, фараиз китаплары, силсиләләр һ. б. төрле темаларга караган меңләгән кульязма һәм басма китаплар саклана, алар нигездә соңгы елларда тупландылар.

Инде Исламга кадәр булган төркиләр диненә кагылышлы чыганакларга килсәк, алар бик аз. Алар нигездә ырымнар, унике еллык календарь системалары, каргышлар, теләкләр, чалпулар һәм кайбер кара ышанулар, йолаларга кайтып кала.

Тәңре дине системасын югарыда саналып киткән чыганаклар белән археологик материал һәм кытай, монгол, төрки, иран, юнан, рум, славян телләрен-

---

[1] Ахметзянов М. И. Из опыта анализа лексики древних татарских заговоров.— Сб.: Татарская лексика в семантико—грамматическом аспекте. Казань, 1988. 98-107 битләр; Ахметзянов М. И. Тексты татарских языческих заклинаний. Сб.: Формирование татарского литературного языка. Казан, 1989, 56-61 битләр; Төш юрау китабы. Казан, 1991, 33-40 битләр һ. б.

[2] Моннан соң кыскалык өчен бу урынны мирасханә исеме белән генә атарбыз.

дәге тарихи язмалар белән бәйләнештә өйрәнгәндә мөһим фәнни ачышларга юлыгырга мөмкин.

Татарның язма ырымнар системасы урта гасырларда Көнчыгыш Европага ислам һәм христиан диннәре таралганчы бу региондагы кавем-кабиләләрнең илаһи ышануларының типологик яктан бер-берсенә якын булганлыгын күрсәтү өчен татар һәм урыс чыганакларыннан мисаллар китереп үтик.

Татар дәва ырымы[1]:

«Йите дингезнең артында бер кара козгын бар. Борны көмеш, тырнакы алтын. Аны качан кеше бозса, бу фәләнне анда бозсын! Яман хәстә кит!»

Урыс аучылары ырымы[2]:

«VI. Заговор охотника на уток и гусей.

На море, на океане, на острове, на Буяне, на зеленой осоке сидит птица, всем птицам старшая и большая, а держит она грамоту неписанную, и велит она всем птицам слетаться на (*такие-то* — М.Ә.) озера и болота и велит всем птицам сидеть от утра до вечера, от утренней зари до вечерней, от ночи да полуночи. Заговаривая я, раб (*такой-то* — М.Ә.), уток, гусей и всякую птицу ведомую и неведомую сидеть и не сходить по мой приход. Мое крепкое слово во веки не нарушимо».

Татар аучылары ырымыннан бер өзек[3]. «Төлкеләргә ау кырып куйганда әйтелгән... Чүргәнчек үрелеп-чурылып ничек киләдер, һәр төрлү төлкеләр шулай килсеннәр. Әгәр төлкеләр бу фәлән йиргә килмәсә, бу төлкеләрнең яткан йирүнә, утырган йирүнә, баскан йирүнә имenә бетерсен!..»

Китерелгән мисалларда типологик якынлык, хәтта стиль якынлыгы да бик сизелеп тора. Татар кульязмаларында «Баш авыруыннан», «Бүсер ырымы», «Йөрәк авыруыннан», «Кан агуны туктатудан», «Күз тиюдән», «Теш авыртуыннан», «Эч авыруыннан», «Җен кагылудан» һ. б. төрле зәхмәтләрдән ырымнар бар.

Җыйнап әйткәндә, төрки-татар ырымнар системасы исламгача булган төрки җәмгыять халкының үзен төрле явыз көчләрдән саклау, Тәңренең рәхмәтен казанып, бәхетле-уңышлы эшләр өмет итү белән сугарылган.

## Ырымнар — тарихи чыганак

Халкыбызның әлеге мирасы бик кызыклы тарихи фактларны ача. Текстларда еш кына Алтын бикәҗ, Алтын кораганлар образлары тасвирлана. Әлеге образлар җансыз сыннарга карый. Кораганлар, ягъни үлгәннәр дигән сүз, ә хәзерге урыс, украин телләрендәге курган дигән сүз борынгы төрки кабер дигән мәгънәгә ия. Алтын бикәҗ — курчак. Борынгы төрки татарларда, себер татарларында әле XX гасыр башына кадәр курчакларга табыну булган. Гади халыкта курчаклар күбесенчә киездән әвәләнгән. Бу курчаклар чирләрне дәвалау йоласының кирәкле әсбаплары булганнар.

Ырымнарда борынгы мәҗүси төрки алла үмәк исеме сакланган. Үмәк алла кыргыз халкындагы борынгы ышануларда мәгълүм. Аның исеме борынгы скифлар алласы Умайга охшаш.

Борынгы төркиләрнең кояш турындагы төшенчәләре дә фантастик түгел. Аларча, кояш дингез эченә төшеп баеган һәм дингез төбеннән чыккан. Ырымнарда борынгы ант йоласы сүзе «җир кәсе» сакланган. Аның тарихи әһәмиятен XVI гасыр урыс миниатюрасындагы ант ритуалы күренешеннән аңлап була[4].

Ырым текстларының искиткеч бай, образлы матур тел белән язылганлыгы игътибарны җәлеп итә.

---

[1] Ахметзянов М. И. Из опыта анализа лексики древних татарских заговоров... 104 бит.

[2] Васильев М. Материалы по фольклору.— Труды общества изучения Татарстана. Том первый. Казан, 1930, 87 бит.

[3] Ахметзянов М. И. Тексты татарских языческих заклинаний... 58 бит.

[4] Бу хактагы мәгълүматны «Татарстан» журналының (1992, №№7-8) «Нәрсә ул «Җир кәсе»?» исемле мәкаләсеннән укырга мөмкин.

Әлбәттә, ырым текстларының тарихи әһәмияте бәян ителгәннәр белән генә чикләнми. Бу юнәлештә бик тирән эзләнүләр алып бару кирәк әле.

## «Каһәрнамә» догасы

Бу дога адәм балаларыннан чир куу, дәвалау өчен файдаланылган. Гәрчә ул борынгы гарәп алласының исеме белән аталса да, анда төрки-татарларның ерак гасырлардан килгән мәҗүси традициясе сакланган.

Әлеге догадан күренгәнчә, чир адәм балаларының бәдәннәренә кереп урнашкан явыз рух ул. Ул явыз рухны усал алла Каһәр көче-куәте белән куып чыгаруга ышаныч булган. Халык хәтерендә бу ышанулар бүгенге көнгә кадәр саклана әле. 1977—1978 елларда Татарстанның Әгерҗе районында моңа мөнәсәбәтле берничә риваять язып алырга туры килде. Риваятьләрдән күренгәнчә чир — кеше, эт кыяфәтләренә кереп күчеп йөри икән. Бу ышану XVII — XVIII гасырларда урыс халкы арасында да таралган булган. Бу дәвердән калган урыс графика сәнгате әсәрләрендә чирнең эт кыяфәтенә кереп чабып йөргәнен тасвирлаган күренешләр бар. Чирләрнең шулай хәрәкәте турындагы ышануларның төбе бик тирән тарихка китә. Аны безгә урыстан, яки урыска татардан кергән дип кенә раслап булмый. Бәлкем ул борынгы төрки дине системасының бер өлешедер. Бездә ул теманың өйрәнелгәне юк.

«Каһәрнамә»— борынгы мәҗүси чир куу ырымы. Аны мәгънәсез бер хорафат истәлеге дип кенә бәяләп булмый. Бүгенге заман табиблары да авыруларны еш кына инандыру юлы белән, сүз белән дәвалыйлар. «Каһәрнамә»— борынгы татар табибларының дәва чараларының берсе.

«Каһәрнамә»нең теле бай, образлы сөйләм үрнәге булып тора. Анда татар халкының ерак гасырлар эчендә мәңгегә югалып калган бай әдәби фольклор әсәрләренең сурәт чаралары сакланган. Әлбәттә, бай тарихи лексика үзе генә дә күпме борынгылыкны ача. «Каһәрнамә»дәге һәр юл борынгыларның бер тарихи образы, мифологик сюжеты булып тора.

Кыскасы, «Каһәрнамә» догасы тарих, әдәбият, тел, фольклор, медицина, дин тарихы, этнография фәннәре өчен чыганак булып хезмәт итә.

Әсәрнең тексты XVII-XVIII гасырдан калган кульязма ырым җыентыгыннан алынды. Җыентык 10 × 15 см зурлыктагы 8 кәгазьдән гыйбарәт, кульязманың 7-а — 8-а битләренә кара тушь белән язылган. Җыентыкта башка кызыклы ырымнар да бар, аларны аерым эшләп чыгу — алдагы бурычыбыз. Кульязма 1980 елларда Казанда табылды һәм бүгенге көндә Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты каршындагы мирасханәдә 39 коллекция, № 5006 эш булып саклана.

## «Каһәрнамә»

Каһәрнамә бу торыр дийү:

Фәригә[1] каһәр кылайгыл[2] тисәң, бу газимәтне[3] өч йулы укып, андин соң өргел, барчасы синдән киткәй. Әгәр үзеңә зәхмәт тигерсә, укып дәм[4] биргел, барчасы сәндин качгай. Ләйәкем[5] һәлак булгай. Дога-и каһәрнамә бу торыр. Бисмиллаһ ир-рахмани ир-рәхим.

Бисмиллаһ ир-рахмани ир-рәхим.
Газимәт галәйкем.
Йад йүфриләр,
Ак атлыглар,
Алла бер,— гаһлыклар,[6]
Алтын садаклыклар,
Көмеш көрсилекләр,[7]
Нәргис[8] күзликләр,

---

[1] Фәри — пәри.
[2] Кылайгыл — кыл.
[3] Газимәт — ният.
[4] Дәм — сулыш.
[5] Ләйәкем — яки.
[6] Гаһлыклар — ант итүчеләр.
[7] Көрсилекләр — урындыклылар.
[8] Нәргис — гөлнең бер төре.

Кяфрур[1] жажлыглар,[2]
Каләм кашлыглар,
Сәлдүс (?) түшәклегләр,
Йәшел фаршин[3] тунлыглар,
Гыйбер—гыйбрәтлегләр,[4]
Дашдан[5] куышлыклар,
Төрлег-төрлег тунлыглар,
Бүрек алтынлыглар,
Йылан камчылыглар,
Болыт менгәнләр,
Көлгә очканлар,
Таглар ашканлар,
Дәрьйа кичкәнләр,
Күлдә сулаганлар[6],
Җәмәнләрдә[7] төшкәнләр,
Үгүз[8] йирләрдә ултырганлар,

Чәш—чишмәлекләрдә бу Адәм углы вә кызының йите ин... матдә (?) урын тотучы.

Афәт оргучылар агыза йөкләдем Сөбхане газыйм ярлыкы берлән сезләрне күргәле, вә күчүргәле, вә китергәле келәдем.

Әй мәлгунлар, итләре бән үтләре, тәнләре, өч йөз алтмыш тамырлары, түрт йөз кырык сүйәкләре арасындин бу зәхмәт тигүргәнләр күчгил вә киткел.

Әй мәлгунлар, битараф шәркыйа угыр... вә ля куәте Аллаһ би Аллаһ әлгалюме әл-газыйм.

Әй туар котлуг фәриләр, вә әй сансыз жарикләр[9], бу адәм углы-кызыга белмәйен килеп, сезләр анламайын төшеп, сезләр дийүмүсезләр Бихак Хакы хөрмәте, Сөбхан хакы хөрмәте, йөз ун түрт сүрәлик «Коръән» хакы хөрмәте, вә Җәбраил, вә Микаил вә Исрафил, вә Газраил хакы кирү бәйан.

## Бәхет-дәүләт догасы

Төрки-татар телендәге борынгы догаларның сирәк кенә булса да матбугатта басылу очраклары да мәгълүм. Шундыйларның берсе «Бәхет-дәүләт» догасы. Ул догалык 1870 елда Казан университеты басмаханәсендә Түбән Масра (Арча районы) авылы кешесе Вәлит Ишмөхәммәт улы харәҗәте белән басылган. Күләме—8 бит.

Догалык татар теленең гаять нәфис үзенчәлекләренә ия. Аның образлы сөйләме күп каләм осталары өчен үрнәк булып тора алырлык.

Текст кыскартылып бирелде. Аның баштагы өлеше кыйммәтле, соңы дини кәлимәләрне кабатлауга кайтып кала. Бу әсәрнең дә исламгача булган йолаларыбыз белән бәйләнеше бар. Димәк, ул мәҗүси ырымнарыбыз системасында урын биләп тора.

## «Бәхет-дәүләт»

Бисмиллаһ ир-рахмани ир-рәхим. Әлхәмде иллал-лаһ раббелгаләмин вә әс-салават, вә әл-ислам. Әгәр бер кем ирсәнең бәхет вә дәүләте китмеш вә чикмеш булса, бу «Доган бәхетнамә»не җомга көн кич камил тәһарәт берлән, вә ихлас берлән укыса, дәрхаль (шул ук вакытта) бәхет вә дәүләте йөнә килгәй, вә һәркем бу «бәхетнамә»не үзе берлән сакласа, падишаһ вә әммарәиләр (хөкем сөрүчеләр) кашында хөрмәтлик булгай вә һәркем «Бәхетнамә»не үзе берлән сакласа: халайыклар күзенә һәм кадерле вә мәхәббәтле күренгәй, вә һәр кеше бу

---

[1] Кяфрур—хуш ис бирә торган камфара мае.
[2] Жажлыглар—чәчлеләр.
[3] Фаршин—палас.
[4] Гыйбер-гыйбрәтлегләр—мисал итеп сөйләрлек хәлләр.
[5] Даш—таш.
[6] Сулаганлар—яшәгәннәр.
[7] Җәмәнләрдә—Ямән илендә.
[8] Үгүз (үзгә?)—башка.
[9] Жарикләр—җәрәхәт ясаучылар.

«Догаи бәхетнамә»не үзе берлә орыш вә сугышка керсә, ук вә кылыч, вә гайре сугыш коралы аңа кяр (тәэсир) кылмайа. Ходай Тәгаля иманында кыла, ләкин арыйг (ару) вә пакь игътикад (ышану) илә үлә, вә һәркем бу «Дога бәхетнамә»не укыса, йә үзе берлә сакласа, ихлас илә үлә вә мондин гайре һәм хасиятләре (файдалары) күптер, һәм ничек гафил (абайламый калучы) улынмайа (булмагыз).

## Догаи бәхет вә сәгадәтнамә ушбудыр

Бисмиллаһ ир-рахман ир-рәхим, әссәламү галәйкем, йа бәхет-дәүләт!
Әйү вә хуш кил, йа бәхет-дәүләт!
Моңлуг мән кил[1], йа бәхет-дәүләт!
Көн вә кояш тик туга килгел, йа бәхет-дәүләт!
Йагмур тик йага килгел, йа бәхет-дәүләт!
Кар тик йага килгел, йа бәхет-дәүләт!
Кыш тик кышлайу килгел, йа бәхет-дәүләт!
Сәгадәт[2] кабалын ала кил, йа бәхет-дәүләт!
Сүйнечлек берлә кил, йа бәхет-дәүләт!
Нигъмәт капугын ача кил, йа бәхет-дәүләт!
Рәхмәт нурын сачә кил, йа бәхет-дәүләт!
Аллаһу Кадыйр Собхан хакы өчен килгел, йа бәхет-дәүләт!
Кәлямулла[3], инҗил[4] хакы өчен килгел, йа бәхет-дәүләт.
Зәбур[5] аятьләре хакыйчүн килгел, йа бәхет-дәүләт!
Форкан хәрефләре хакыйчүн килгел, йа бәхет-дәүләт!
Рәҗәб, Шәгъбән, Рамазан[6] шәриф хакыйчүн килгел, йа бәхет-дәүләт!
Йир-күк гарше[7], вә көрси ләүхә вә калям хаклары өчен килгел, йа бәхет-дәүләт!

## Чалпу ырымы үрнәге

Татар этнографиясендә Чалпу тәгәрәтеп (ягъни имләп) күмү дигән борынгы ышану бар. Әгәр кеше нинди дә булса жирдә егылып бәрәр әгъзасын авырттырса, зәхмәт тимәсен дип ырымлап язу язып, шул урынга күмәләр. Кульязмадагы ырым шундый бер очрак өчен язылган трафаретны тәшкил итә. Ул түбәндәгедән гыйбарәт:

«Алты юлның чатында этләр өреп киләдер. Кара тутлы, кара төлке чалпулар. Качан чалпуса, фәлән бине фәләндән чалпулар, андан чалпуса.

Йиде юлның чатына аюлар улап киләдер. Кызыл тутлы, кызыл төлке чалпулар. Качан чалпуласа, фәлән бине фәләндән андан чалпулар, андан чалпуса.

Тукыз юлның чатында аюлар акрып киләдер. Күк тутлы, күк төлке чалпулар, качан чалпуса фәлән бине фәләндән чалпулар, андан чалпуса».

Текст Казанда табылган иске кульязма фрагментыннан алынды. Ул XIX гасыр ахырларында язылган. Язма Институт мирасханәсендә саклана (39 коллекция, № 5121 эш берәмлеге).

## Васыятьнамәләр

Һәрбер мәдәни халык җәмгыять эчендәге үзара мөнәсәбәтләрне уртак килешү, кабул ителгән төрле кануннар аша хәл итә. Шәхеснең дәүләт, җәмгыять, үз гаиләсе мөнәсәбәтләрен көйләгән һәм барлык җәмгыять тарафыннан танылган тәртипләре була. Татар халкында да андый уртак килешүләр, тәртипләр күп

[1] Моңлуг мән кил — көйләр белән кил.
[2] Сәгадәт — бәхет.
[3] Кәлямулла — Коръән.
[4] Инҗил — Гайсә пәйгамбәргә күктән иңгән дини китап (Евангелие). Ул китап Исламда күктән иңгән дүрт китапның берсе дип таныла («Коръән», «Зәбур», «Тәүрат», «Инҗил»).
[5] Зәбур — Давыт пәйгамбәргә Аллаһе Тәгаләдән иңгән дини китап, борынгы яһүд телендә язылган.
[6] Рәҗәб, Шәгъбән, Рамазан — мөселманнар өчен изге айлар.
[7] Гарше — каршысы.

булган. Шуларның берсе мал иясенең үзләреннән соңгы дәгъвәчеләргә тигез итеп бүлеп биргән мөлкәт язуы — васыятьнамә була.

Татарда васыятьнамәләр, башка халыклардагы кебек, борынгыдан килгән ыру-нәсел традицияләренә нигезләнә. Борынгы чорларда аны ыру кануннары буенча хәл иткәннәр. Ислам динен кабул иткәч, яңа сыйфатлар, матдәләр дә өстәлгән.

Васыятьнамә текстлары үрнәкләре татарда XVII гасырдан сакланып калган: Галикәй Аталык /1639/, Кишбикә бикәч васыятьнамәләре, 1749 елда язылган Каныш Макиев васыятьнамәсе мәгълүм һ. б.[1]

XIX-XX гасыр башларында язылган васыятьнамә текстлары да бик мөһим. Алар тел һәм тарих чыганаклары буларак та кадерле. Бүгенге замандашларыбызга ата-бабаларыбызның яхшы гадәтләре гыйбрәт булырга тиеш. Татар васыятьнамәләрен, әдәби жанр буларак, аерым тикшерүне әдәбият галиме Әнвәр Шәрипов башлап җибәрде.[2] Васыятьнамә татар тормышында берничә йөз еллар дәвамында яшәп, тормышыбызда ныклы традициягә кереп киткән.

Коммунистик дәвердәге кысулар нәтиҗәсендә язма васыятьнамәләр яшәүдән тукталган булса да, телдән васыять әйтү соңгы елларга хәтле дәвам итә. Шунлыктан аның язма рәвештәге өлгеләре белән халкыбызны таныштыру фарыз эштер. Аларны тормышыбыз гамәлләренә әйләнерлек, һәркем белерлек итү кирәк. Васыятьнамә язмалары традицион мәдәниятебезнең матур гадәте. Алар җәмгыятьнең тынычлыгына, ныклыгына һәм законга хезмәт итәләр.

Безнең эзләнүләребез нәтиҗәсендә берничә васыятьнамә үрнәкләре табылды. Текстлар гарәп әлифбасында аерым кәгазьләргә һәм кульязма җыентыкларга, каберташларга язылганнар.

XIX гасырда «васыятьнамә» исеме белән төрле мөрәҗәгатьләр, листовкалар да таралган.

Аерым битләргә язылган васыятьнамә үрнәкләренең бер ишесе сәяси мөрәҗәгатьләрдән гыйбарәт. Алар арасында заман ахыры җитү, Оренбург губернаторы Сухтелинның татар егетләрен медицина уку йортларына укырга керергә өндәп язган, мөфти Тәфкилевнең урыс телен өйрәнергә өндәп язган васыятьнамә текстлары һ.б. бар[3]. Алар тарихи документлар буларак әһәмиятле.

Шәхси васыятьнамәләрдән Хәбибулла бине Яхъя Күкчәвинең 1860 елда шигырь белән язган әсәре кызыклы. Истәлек теркәлгән җыентыкны безгә язучы Мөхәммәт Мәһдиев бүләк иткән иде. Ул хәзер кульязмалар бүлеге мирасханәсенең 39 коллекциясендә 3430 эш берәмлеге булып саклана. Васыятьнамәнең авторына ул вакытта 70 яшь була. Аның әсәреннән бер өзек китерәп үтик:

Моның бәгъдәндә[4] язылды гарыздан[5],
Васыять әйләюб важиб[6] фарыздан.

Балаларым: укыңызлар сабакны,
Галим булып тотыңызлар таякны!

Надан калсаң, үкенерсең, әй углан,
Таләп кыл һәм җәһәт кыл, калма надан!

Таләптә һәм җәһәттә булса кяһил[7],
Диделәр, бу кешеләр улды җаһил[8].

Тарих һәм әдәбият өчен, кулларында зур матди байлыклар туплаган кешеләрнең васыятьнамәләре бик кызыклы. Татар-мөселманнар арасыннан күтәрелгән байлык ияләре һәрчак җәмгыять файдасына байлыкларыннан өлеш чыгара килгәннәр. Мисалга Орынбур татар миллионерлары Хөсәеновларның мәктәп-мәдрәсәләр тоту өчен булган малларыннан биш йөз мең сум акча васыять итәләр.

---

[1] Вельяминов-Зернов В. В. Исследования о касимовских царях и царевичах. III т. СП (б )1866 (232-240, 262-265, 449-452 бб.); Фасеев Ф.С. Старо-татарская деловая письменность XVIII века. Казан, 1982, 152-156 бб.; Фәхретдинов Р. Асар. 6 җөзьә, 280-283 бб.

[2] Шәрипов Ә. М. XVIII йөз әдәбиятының кайбер жанрлары (сәяхәтнамә һәм васыятьнамә).— «Татар теле һәм әдәбияты». Алтынчы китап. Казан, 1977, 98—106 бб.

[3] Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты, Кульязмалар бүлеге мирасханәсе (39 коллекция, 2501, 301, 5 эш.).

[4] Бәгъдәндә — соңрак.

[5] Гарыз — аңлату.

[6] Важиб фарыздан — үтәргә тиешлектән.

[7] Кяһил — ялкау.

[8] Җаһил — надан.

Кулыбызга хәзерге Казакъстанның Петропавловск шәһәреннән сәүдәгәр Дәүләткилдиевләр васыятьнамәсе төшкән иде. Аны безгә филология фәннәре докторы Фәрит Хәкимҗанов тәкъдим итте. Түбәндә аның гарәп графикасыннан хәзерге татар графикасына күчерелгән текстын тәкъдим итәбез.

## Васыятьнамә

Сәнәи миладия[1] 1909 нчы, мартның 12 нче көнендә, сәнә-и һиҗрия — 1327 нче рабигыләүвәлнең 3 нче көнендә — мин үз җортым илән Петропавел бәләдәсендә[2] торучы, Рязань губернасы, Касыйм өязе, Горскийда туган потомственный дворянин Мөхәммәтҗан Фәйзулла углы Дәүләткилдиев — хәл-хаятемдә[3] бер мең тәңкә акча сәдака әбәдия кылдым[4] — шул шарт иләндер: кем — дүртенче номер мәсҗед ихатасында үземез салдырган таш дөкәннәрнең[5] берсендә сәүдә кылдырып, хасил улган файдасыны, үземез салдырган таш мәдрәсә вә мәсҗед тәрбиясенә сарыф кылыныр[6]. Моның соңында, түбәндә, васыятьлыкка тәгаен ителгән[7] кеминәләр[8] сәнә ахры[9] булганда, ушбу мең тәңкә акчаның хисабын алып, мәдрәсә вә мәсҗеднең зарур булган урыннарына сарыф кылырлар, нәгяһ[10] әҗәл максуд ирешеп, вафат була калсам, миндин калган митрүкәгә[11] минем үземнең хәләл кәсебем илән пәйда кылган[12] малымдыр, шул малымнан варисларым әүвәл язылган сәүдә дәфтәренә карап, никадәр кархәм[13] булса, барчасын әда кылып[14] риза кылыныр.

2 нче: тәкфин-тәҗәннәрем өчен[15] бер мең тәңкә бирелсен.

3 нче: казага калган намаз вә рузаларым[16] вә башка вәҗабәтләрем[17] өчен бер мең тәңкә фидия бирелсен.

4 нче: бу әйтелмеш ике мең тәңкәдән башка ни кадәр акча булса да, вә сәүдә малын булса да, вә җорт-җир вә башка җанлы мал булса да — һәммәсенә варисларым: хатыным, угылларым вә кызларым — барчасы муафикъ шәрегъ шәриф гали фараизы Алла камәт кылып алырлар.

5 нче: вафатым соңында ошбу васыятьнамәне тиешле мәхкәмәгә[18] йөргезеп, тәмам кылмакны энем Мирхәйдәр Дәүләткилдиев илән углым Мөхәммәтмостафа Дәүләткилдиевкә тапшырдым.

Потомственный дворянин Мөхәммәтҗан Фәйзулла углы Дәүләткилдиев — гуаһ булып кулым куйдым.

Потомственный дворянин Мирхәйдәр Фәйзулла углы Дәүләткилдиев — гуаһ булып[19] кулым куйдым.

Потомственный дворянин Мөхәммәткәрим Хафиз углы Дәүләткилдиев — гуаһ булып кулым куйдым.

Петропавелский купец Мөһәммәткәрим Ибраһим углы Төмәнев — гуаһ булып кулым куйдым.

Петропавелский мещанин Мөхәммәт Хафиз углы Акчурин — гуаһ булып кулым куйдым.

/Васыятьнамә/ сүзе астында догалык язылган иде. «Коръән» сүзе беләк.

Рәхимә тәтәйдән сорашып әрвах хәлләрне кемнәр икәнен белдем. Фәйзулла Сәйфулла углы.

Мөхәммәтҗан Мирхәйдәр углы. Гали Фәйзулла уллары.

---

[1] Сәнәи миладия — христиан ел хисабы.
[2] Бәләдәсендә — шәһәрендә.
[3] Хәл-хаятемдә — сәламәт чагында.
[4] Әбәдия кылдым — мәңгегә бирдем.
[5] Дөкәннәрнең — кибетләрнең.
[6] Сарыф кылыныр — тотылыр.
[7] Тәгаен ителгән — билгеләнгән.
[8] Кеминәләр — кешеләр.
[9] Сәнә ахры — ел ахыры.
[10] Нәгяһ — көтмәгәндә.
[11] Митрүкәгә — документка.
[12] Пәйдә кылган — туплаган.
[13] Кархәм — зыяным.
[14] Әда кылып — түләп.
[15] Тәкфин-тәҗәннәрем өчен — кәфен сарган өчен.
[16] Рузаларым — уразаларым.
[17] Вәҗабәтләрем — тиешләрем.
[18] Мәхкәмә — осшма.
[19] Гуаһ булып — танышып.

Мөхәммәтсафа, Котлымөхәммәт Гомәр, Галим — Мөхәммәтҗан уллары.

Мәрьям, Өммегөлсем — Мөхәммәтҗан кызлары. Хафиз мулла Адәм улы.

Рәхмәтулла, Нигъмәтулла, Габдулла, Рамазан, Габдрахман — Рәхим уллары.

Газзә, Фатыйма, Хәдичә, Оркыя — Рәхим кызлары.

Зөбәйдә, Зәйнәп, Суфия — Галим кызлары.

Борһан, Исхак, Исмәгыйль — Галим уллары.

Бәдүш, Рәхимә, Галия, Нәйлә, Сара — Гомәр кызлары.

Оркыя, Рабыйга — Котлымөхәммәт кызлары.

Хәдичә, Өммегөлсем — Габдулла кызлары.

Ибраһим, Хәмзә, Габбас, Муса, Гайсә, Нуретдин — Котлымөхәммәт уллары.

Оркыя — Сабир кызы.

Фатыйма — Мөхәммәтҗан кызы.

Өммегөлсем, Әминә, Заһидә — Габдерахман кызлары.

Гомәр, Газиз — Мирхәйдәр әүләде.

## Эпиграфик васыятьнамәләр

Кульязма васыятьнамәләр халык тормышына шулкадәр керәләр ки, аларны хәтта кабер ташларга яза башлыйлар. Безгә Казан һәм Казан артындагы татар зиратларын өйрәнеп, андагы язмаларга игътибар итәргә туры килде. XIX гасырның урталарыннан үсеп киткән эпиграфик шигърият үрнәкләренең, васыятьнамә, канатлы сүзләрнең ташъязмаларда еш очравына игътибар иттек. Казандагы Яңа Бистә, Казан артындагы Олы Мәңгәр, Түбән Оры, Тәмте, Мәтәскә, Буа татар зиратларында һәм башка урыннарда аеруча кызыклы үрнәкләр табылды:

Кабер ташларына язылган васыятьнамә үрнәкләре:

№ 1. Нәсихәтем будыр әүләдләремә,
Дәхи ихванларым әхбәбләремә.
Ки мәгърүр улмаңыз дөнья малыйна,
Бакыңызлар атаңызның халинә!
Ничә җәһедлә малны җәмигъ иттем,
Сезә куйдым, бары кәфендә киттем.
Безең «Коръән» укырга хәлемез юк,
Тасдыйк һәм кыйлырга юлымыз юк.
Уян-буян бакып, дога котәрмез,
Хәер-ихсан дәхи өмид итәрмез!

. . . . . . . . . . .

Җария-сәдака калдырасыз,
Атаңызчүн мәсҗед һәм салдырасыз.
*Этнә районы, Олы Мәңгәр зираты [1846].*

№ 2. Васыятем будыр, и зәүҗ[1] гакыл,
Кәрәм[2] илә безә[3] даим[4] дога кыл!
Безем каберемеза гяһ-гяһ[5] киләсез,
Ки бездин гыйбрәт алубән китәрсез!
Тасдыйк[6] һәм вирергә...
Уян-буян бакыб, дога котәрмез,
Хәер-ихсан дәхи өмид итәрмез.
Безә «Коръән» укып багышлаясыз,
Гомер тиз үтәрен сагышлаясыз.
Фәкыйрьне догада кыйлыңыз яд,
Тасдыйклә рухымны кылыңыз шат.
*Казан, Яңа Бистә татар зираты, XIX гасыр.*

---

[1] Зәүҗ — пар, тиң.
[2] Кәрәм — юмартлык.
[3] Безә — безгә.
[4] Даим — өзлексез.
[5] Гяһ-гяһ — вакыт-вакыт.
[6] Тасдыйк — раслау.

№ 3. Мадəмəгə[1] җан тəндəдер,
Бел, форсатта, бу көн синдəдер!
*Буа татар зираты [1912].*

№ 4. Галəмəтдин морадым бер догадыр,
Бу көн бəңа исə, таңда сəңадыр!
*Буа татар зираты [1912].*

№ 5. Бактың исə минем кабрем ташына,
Гыйбрəт алгыл, төшəр һəр кем башына!
*Буа татар зираты [1906].*

№ 6. Бу көн вəгъдəм тəмам улды,
Иреште əмре раббани.
Ки тəслим əйлəдем, хакка
Əманəт иделəн җанни!
*Буа татар зираты [1916].*

№ 7. Əҗəл килде җилəктəй яшь чагымда,
Вакытсыз таш куелды баш ягымда!
*Буа татар зираты [1921].*

№ 8. Əҗəл угы тиде яшьли башыма,
Вакытсыз таш утыртылды баш очыма.
*Буа татар зираты [1957].*

№ 9. Васыятем будыр əүлəдлəремə,
Дəхи ихванларыма, əхəндлəремə[2].
Кəрəм[3] идүб, догада иденез яд,
Тасдыйклə[4] кыйлыңыз рухымны шад.
Килеп «Коръəн» укып, һибə идəсез[5],
Кəндин[6] гыйбрəт алубəн кидəсез.
Уян-буян бакып, дога көтəрмез
Хəер-ихсан[7] дəхи өмид итəрмез.
*Саба районы, Тəмте Мəтəскə авылы зираты [1842].*

№ 10. Карəм əйлəб дога илəн иденез яд,
Тасдыйклəп рухымны кылыңыз шад!
Бу кабер хəллəрен сагышлаясыз,
Безгə «Коръəн» укып багышлаясыз!
Безем «Коръəн» укырга хəлемез юк,
Хəер-ихсан кылырга малымыз юк.
*Əгерҗе районы, Мордыби авылы зираты [1881].*

№ 11. Кили, хаиф[8], үлемне ядең иткел,
Китəр мəнзилең[9] истигъдад[10] иткел.
Белер һəр адəм углы булса уйгаг,
Ватанның аслысыдыр икəн тумаг.
*Əгерҗе районы, Тирсə авылы зираты [1905].*

№ 12. Тормадың син, ташлап киттең тəңреңə,
Гомерлеккə ядкəр итеп, таш куябыз кабереңə.
*Санкт-Петербург, Волков зираты, татар каберлеге [1970].*

№ 13. Галəмəтдəн морадым бер догадыр,
Бу көн бəңа икəн, йəрин синадыр!
*Əтнə районы, Олы Мəңгəр авылы зираты [1899].*

№ 14. Кəрəм əйлəп, догада иденез яд,
Тасдыйкан рухымны кылыңыз шад!

---

[1] Мадəмəгə — чынлыгында.
[2] Əхəндлəремə — ир туганнарыма.
[3] Кəрəм — юмартлык.
[4] Тасдыйклə — раслап.
[5] Һибə идəсез — бүлəк итəсез.
[6] Кəндин — үзегез.
[7] Хəер-ихсан — булышлык.
[8] Хаиф — куркучы.
[9] Мəнзилең — урның.
[10] Истигъдад иткел — зирəклек белəн төшен.

Бу кабер хәлләрен сагышлаясыз,
Безгә «Коръән» укып багышлаясыз!

*Тирсә авылы зираты [1907].*

## Кулъязма китаплардагы табышмаклар

1. Ул нәдер кем, зәррә-зәррә[1] кан ирер,
Тәмам аның мивәсе җиндан[2] ирер.
Агзы бердер, теле ике, жаны юк,
Аны белмәй күп кеше хәйран ирер.

. . .

Ул нәдер кем, йөздер аның бармакы,
Сигез аяк өстиндәдер тормакы.
Башы бишдер, тәне бишдер, жаны түрт,
Ни гаҗәб, биш варыб, түрт кайткaны.

. . .

Ул нәдер кем, бер йыгач яратты хак,
Ул йыгачта тәмам унике ботак.
Ул ботакларда утызар яфрак,
Ул яфракның эче кара, тышы ак.

*Мирасханә, 39 коллекция, 2833 санлы кульязманың 40 нчы битеннән; күчерелү вакыты — 1886 ел; Лениногорск р-ны, Сарабиккол авылында табылган.*

2. Ул нәдер кем, синдә вар, бәндәдә вар, адәмдә юк,
Җөмләдә вар, жиһанда вар, галәмдә юк.
Бер-ике, өчдән зийәдә[3] улмады,
Дүртесе һичбер урында күренмәде.
Шамны күрән, өчесине күрделәр,
Мисры күрән, һичберен күрмәделәр,
Бу шигырьне белгән адәм гаклы кямилдән улыр,
Анламас пусәдин[4] хайван адәми агяһ[5] улыр.

*Мирасханә, 39 коллекция, 3026 санлы кульязма, 117-а бит.*

3. Хак тәгаләм чын яратмыш биш йимеш,
Ул йимешләр бер-берини күрмәмеш.
Икиси аның тән йөзини күрмәмеш,
Өчиси аның көн йөзини күрмәмеш.

*Мирасханә, 39 коллекция, 3719 санлы кульязма, 1 бит. Кульязма Тубыл ягыннан табылган.*

4. Әй ходая, кодрәтендин бар жирү бар,
Бер кодыхта[6] ике әлван[7] суы бар.
Үзгә сулар, утка тигсә, юк булыр.
Бу нә судыр, утка тигсә, нур булыр.

*Касыйм шәһәреннән табылган иске кульязмадан. Татарстан дәүләт музеенда саклана.*

---

[1] Зәррә-зәррә — тамчы-тамчы.
[2] Җиндан — чыннан.
[3] Зийәдә — артык.
[4] Пусәдин — үбештән.
[5] Агяһ булыр — хәбәрдар булыр.
[6] Кодыхта — коеда.
[7] Әлван — эчемлек.

Татар әдәбиятының борынгыдан килгән кече жанрларыннан берсе — кульязма китап хатимәләре, ягъни күчерүчеләр тарафыннан иҗат ителеп, күчереп яки язып тәгәлләнгән әсәргә өстәлгән кечкенә шигырьләр тора.

Хатимәләрнең безгә хәтле җиткән иң борынгы үрнәге Насретдин Рабгузи тарафыннан 1311 елда язылган «Кыйссасел—әнбия» китабына язылган булса кирәк. Аның зур тырышлык куеп һәм күтәренке күңел белән язылган хатимәсе чиксез талантлы әдибнең шатлыгын һәм киләчәккә өметен гәүдәләндерә. Шуннан соңгы татар китап күчерүчеләре хатимәләр язуны бер традиция итеп кабул күрәләр.

Алардан үрнәкләр:

1. Ошбу китап иясе,
Яшел чапан киясе.
Хак тәгалә теләсә,
Оҗмаһ эчрә керәсе,
Хур кызларын кочасы,
Моны язган шат улсын
Ике җиһанда шат улсын.

*1785 елны күчерелгән кульязма. 1979 елны Азнакай районы Сарлы авылында табылды.*

2. Ушбуны бән язмадым, язды каләм,
Ушбуның ардынча чук—чук сәлам.
Моны яздым ядкарь улмак өчен,
Укыганнар бер дога кыйлмак өчен,
Яза-яза йәшилә тулды күзем,
Инде ниләр язаем, бетте сүзем.

*Мирасханә, кол. 39.XIX гасыр уртасы кульязмасы.*

3. Тәмам булды китап әлһәмдү Аллаһ,
Һәмам[1] улды китап әлһәмдү Аллаһ.
Бителде[2] бу Габидулла гарибдән,
Өмид идүб догалар һәр карибдән.[3]
Укыяни, дынлаяни, язгани.
Фазлың[4] илә ярлыкагыл[5], я Гани[6].

Әгәр кушсаң Габидкә лафыз[7] — аллаһ,
Белүрсең, кем ирер[8], ки битек[9] агяһ[10].
Бу дөнья малына син кылма рәгъбәт[11],
Галимлеккә табылыр барча дәүләт.

*Мирасханә, кол.39. 1842 елда Габидулла бине Муса тарафыннан язылган. Кульязма 1979 елда Азнакай районы Митрәй авылында табылды.*

4. Моны язганда кыш ирде,
Каләмнәрем камыш ирде,
Эчем тулы сагыш ирде,
Шафигым, син сәламәт кыл.

---

[1] Һәмам улды — мәшәкатем булды.
[2] Бителде — язылды.
[3] Карибдән — кардәштән.
[4] Фазлың-өстенлеген.
[5] Ярлыкагыл — кичер.
[6] Гани — Алла.
[7] Лафыз-сүз.
[8] Кем ирер — кемлеген.
[9] Битек — язу.
[10] Агяһ — хәбәрдар.
[11] Рәгъбәт — омтылыш.

Моны яздым тәрәзәмнең төбендә,
Ходай урын бирсен җәннәт түрендә.
Моны яздым ядкарь улмак өчен,
Укыганлар бер дога кылмак өчен.

Яза-яза яшь илә тулды күзем,
Индениләр язаем, бетте сүзем.
Моны яздым тәрәзәмнең төбендә,
Күзем яшьле улып, җомга көнендә.

*Азнакай районы, Мәсгыйд авылында 1902 елда күчерелгән кульязмадан.*

5. Әй каләм, килеш,
Килмәсәң — корыш!

*Мирасханә. Кол. 39. Кульязма № 2687,39 бит. Саба районы, Шекше авылында 1885 елда язылган кульязмадан.*

6. Гәр хата булса, каләм берлән сияһы[1]
Фәкыйрь язгучының күптер гөнаһы.
Гәр хата булса, дөзәтмәй китмәңезләр,
Буны нигә язган дип, гаеп итмәңезләр.
Хата-хата, хатасын орма йөзгә.
Хатадин хали ирмәс[2], хакдин үзгә.
Каләм юндым, хат битедем, ушбудыр хатым.
Ушбуны язгучы, Габденасыйрдыр атым.
Ушбуны мин язмадым, язды каләм.
Ушбуның ардынча, чук—чук сәлам.
Каләм белгән бу кешеләр гөлчәчәк.
Каләмсез кешеләр сыгырдыр һәм ишәк.

*Мирасханә. Кол. 39. Кульязма № 2687, 39 б. Саба районы Шекше авылында язып алына.*

7. Каләм тартсаң, каләм изгегә тартыр,
Каләм тарткан кешенең зиһне артыр.

*Мирасханә. кол. 39. Кульязма № 2686, 1 бит. Саба районы, Шекше авылында язып алына.*

8. Ушбуны бән язмадым, язды каләм,
Ушбуны язучыга чук-чук сәлам.

*Мирасханә, кол. 39, кульязма № 2857, 37 бит. Лениногорск районы, Кирлегәч авылында язып алына.*

9. Каләм әйде: тагын әзрәк язасы,
Абыстайның күңелене аласы.

*Мирасханә, кол. 39, Кульязма № 2822, тышлыкта. Лениногорск районы, Югары Чыршылы авылында язып алына.*

10. Каләмле кеше кайда басса — сөчүк торыр,
Каләмсез кеше кайда барса, кечүк торыр.

. . .

Хат битегән гүрдә ятыр хурзәр[3],
Үзе үләр, хаты калыр ядкарь.
Каләм ирер ике дөнья дәүләте,
Каләм ирер ахирәтнең мөлкәте.
Каләм юндым, хат битедем,
Ушбудыр хатым.
Моны язган шәкерт —
Мозаффардыр атым.
Каләм үгрән, каләм изгегә тартыр,

---

[1] Сияһы — язу карасы.
[2] Хали ирмәс — хатасыз булмас.
[3] Хурзәр — кадерсез.

Каләм берлән кайда барсаң,
Гыйззәтең[1] артыр.
Каләмле кеше — кайда барса карчыга,
Каләмсез кеше — кайда барса карга.

*1836 елда күчерелгән кульязмадан. Шәхси архивта саклана.*

Кульязма китаплар ахырына теркәлгән мондый хатимәләрне тагын дистәләрчә истәлекләрдән китерергә мөмкин. Бу факт аның күп гасырлар аша кичә килгән традиция икәнен күрсәтә. Шунлыктан аны урта гасыр төрки-татар әдәбиятыннан калган бер кече жанр икәнен таныйбыз.

## Шигъри хатлар

Татар әдәбияты тарихында шигырь белән хат язу традициясе бик ерактан килә. Аның XVIII — XX гасырда язылган үрнәкләре дә бар. Бу өлкәдә Габдессәлам /1700—1762/, Габделҗаббар Кандалый /1797—1860/, Шәмсетдин Зәки /1825—1865/ кебек шагыйрьләр каләме белән язылган әсәр үрнәкләре безнең археографик эзләнүләребез вакытында табылып, кайберләре инде басылып та чыкты[2]. Шигырь белән хат язу үрнәге Мифтахетдин Акмулла мирасында яхшы мәгълүм[3].

Ләкин кульязма битләрендә мәгълүм шагыйрьләрнең шигъри хатларыннан тыш аерым шәхесләр тарафыннан язылган үрнәкләр дә очрый[4]. Шундый хатларның хәзерге Азнакай районы Митрәй авылында яшәгән Шәһидулла Һибәтулла улы /1860—1935/ тарафыннан 1885 елда язылган ике үрнәген табып текстологик эшләгән идек. Бу хатларда читтә укыган татар шәкертенең эчке халәте чагыла. Шигъри хатта алда китерелгән хатимәләр белән дә уртаклыклар, охшашлыклар күренә. Мондый шигъри хатларны да әдәбиятыбызның ерактан килгән бер традициясе дип карау дөрестер, мөгаен.

## Шәһидулла Һибәтулла улы хатлары

### Беренче хат

Сәлам кылды гариб бәндә[5] атага,
Дәхи Кәгъбә-й шәриф тик анага.
Дога берлә яд кылыңыз безләри,
Әһле бәйтемез берлән яд кыламын сезләрни.
Каләм юндым, хат битедем, ушбудыр хатым,
Моны язган Шәһидулладыр атым.
Гәр[6] түгел, әйтүбән керсәң юла,
Канда[7] варсаң Хак сиңа юлдаш ула.
Ул кешегә Хак назыйр[8] кошы булыр,
Ул кешенең ваем эше хуш булыр.
Бик күптер бу хатымның хатасы,
Һич юктыр арасында сафасы[9].
Төзәтүбән укыңыз бу хатымны,
Аның чүн беләсез фәһем азымны.
Хатасыны төзәтмәй китмәңезләр,
Догаңыздин фәрамуш[10] итмәңезләр.

---

[1] Гыйззәтең — кадрең.
[2] Әхмәтҗанов Марсель. Г. Кандалыйның яңа табылган әсәрләре. Казан утлары, 1984, № 9, 185—187 бб.
[3] Акмулла. Шигырьләр. Казан, 1981, 93—104, 147—150 бб.
[4] Андыйлардан Фәхрелбанат Сөләймания һәм Бибиәсмә исемле туташларның 1870 еллар чамасында язылган татар телендәге шигъри хатлары табылды.
[5] Гариб бәндә — иленнән аерылган кеше.
[6] Гәр — әгәр.
[7] Канда — кая.
[8] Назыйр — күрүче.
[9] Сафасы — кайгысызы, кәефлесе.
[10] Фәрамуш — оныту.

Ходаем җәзасын сезләргә дә вирсен.
Доганыз савабын безгә дә вирсен.
Насыйп итсен ходаем иманымызны,
Холяс улсын тәмугдин җанымызны.
Хак Тәгалә гомренезн кылсын озын.
Сезә-безә бирсен җәннәттә урын.
Илаһи кыл тәрхим[1] бәндәләригә,
Хосусән бән кеби шәрмәндәләргә[2].
Рәсүл әйде: «Дога кылса,
Өчен ата-анасыйга,
Пигамбәрләр догасы тик
Өммәт өчен икесе дә».

## Икенче хат

*Әл хат[3] нисфел—мөләкат*
Хәмед улсын[4] Ходаем Зөлҗәләлә[5],
Дәхи улсын рәсүл зөлкәмалә[6].
Ки мондин соң сәлам улсын атама,
Дәхи мөшфика[7], мөгазиз[8] анама.
Гали әт-тәгаен атамадыр сәламем,
Кабул итсен Ходаем Зөлҗәлалем.
Анамадыр сәламләрем һәмишә[9],
Ходаем әйләсен рәхмәттә пишә[10].
Сәламемдер дәхи карибләремә[11],
Гали тәхассыз[12] ирер һәм садыйкага[13].
Бу фәкыйрьдән сәлам улды ки сезгә,
Хәер илә дога кыйлың ки безгә.
Иребдер мән сезнең догага мохтаҗ,
Басма кылырсың арага идеб хаҗ,
Иребдер мән явызларның явызы,
Ирер дога явызларның хәбибе[14].
Мөдам[15] итсен ки дәүләтең Ходаем,
Инаныңлар, ки касд[16] итеп сораем.
Кабул кылса иде догамны Алла.
Тәзәррыг[17] илә сораем бән[18] валла.
Ходаем кылсайде сезләрә гыйззәт[19],
Ки әйләйүб сезә мескинене җәннәт.
Сөаль[20] улса ки безнең халемездән,
Бәян улсын[21] сезә әхвалемездән.
Бәнем халем бүгендәдер сәламәт,
Әй, әткәем, кыла күрмә догабәд[22].
Сезә яздым бу хатымны көйләбүк,

---

[1] Хат — күрешүнең яртысы.
[2] Кыл тәрхим — рәхмәтеңне кыл.
[3] Шәрмәндәләргә — оятлыларга.
[4] Хәмед улсын — мактау булсын.
[5] Зөлҗәләлә — Аллага.
[6] Зөлкәмалә — Мөхәммәд пәйгамбәргә.
[7] Мөшфика — шәфкатьле.
[8] Мөгазиз — газиз.
[9] Һәмишә — һәрчак.
[10] Пишә — эш, шөгыль.
[11] Карибләремә — якыннарыма.
[12] Гали тәхассыс — зур үзенчәлек.
[13] Садыйкага — әчкерсезгә.
[14] Хәбибе — сөеклесе.
[15] Мөдам — өзлексез.
[16] Касд — ният.
[17] Тәзәррыг илә — түбәнчелек белән.
[18] Бән — мин.
[19] Гыйззәт — хөрмәт.
[20] Сөаль — сорау.
[21] Бәян улсын — тасвирлансын.
[22] Догабәд — догасыз.

Эчемдәге серемне бән сөйләбүк.
Ки кылмаңыз явыз доганы безгә,
Хода вирер әҗрене ки сезгә.
Ки сезләрдин дога улса безә бәд,
Лаек ирмәс безә һәм асла җәннәт.
Идә күрсәнә бу фәкыйрьгә шәфкать,
бу мескингә хода вирсәйде җәннәт.
Моны язган кешене беләсең,
Ки гайнга раббыны кушасың.

## Елъязмалар

Дәүләтләр корып яшәү традициясе көчле булганлыктан, татар халкының балалары тарихи аңны саклауны фарыз эш дип санаганнар. Төрек каганаты, Алтын Урда, Казан, Әстерхан, Кырым һ.б. дәүләтләр яшәү заманнарында, әлбәттә, тарихи хрониклар да булган. 731 елны Күлтәгингә, 734 елда Билге каганга куелган таш елъязмалар безгә мәгълүмнәренең иң борынгыларыдыр.

Шул традицияләрне тотып, бабаларыбыз XVI—XIX гасырларда да тарихи хроника үрнәкләрен яза килгәннәр. Татарча елъязмаларда аерым нәселләр, тарихи вакыйгалар, иҗтимагый һәм географик-климатик режимдагы үзгәрешләр һ. б. язып барыла.

XVI—XVIII гасырга караган елъязма хәбәрләрен текстологик хәзерләгәндә еш кына төрле чыганакларга карап чагыштырырга туры килде. Аеруча XVI—XVIII гасырга караган мәгълүматлар арасында уртаклык һәм аермалар булуы да күзгә ташлана. Аларның чагыштырма фәнни басмасын хәзерләгәндә тарихи чыганакларыбыз борынгы хәбәрләрне күбрәк ачарлар иде. Елъязмалар тел тарихы чыганаклары буларак та киң мөмкинлекләргә ия.

Мисалга 1819 елда Хәлфин[1] һәм 1883 елда Җиһаншин[2] басмаларындагы елъязмаларны Өтернәс кульязмасы фактлары белән чагыштырсаң, Җиһаншин басмасы белән Өтернәс кульязмасының кайбер тарихи детальләре, әйтик, 12 еллык календарьның ел атамалары юклыгына игътибар итәсең.

Түбәндә без үзебез тапкан чыганакларның бер өлешеннән күчермә-өзекләр бирәбез.

## Татарстанның Саба төбәге Өтернәс авылыннан 1973 елда табылган елъязмадан өзекләр

Кульязма такта тышлы китап рәвешендә, XIX гасырның егерменче елларында зәңгәрсу һәм саргылт ак кәгазьләргә язылган. Баштагы битләрендә фарсы, урыс, гарәби календарьларны берләштереп төзелгән календарь бирелгән, аннан соң елъязма 1870 елларга кадәр дәвам ителгән, бүсер, авыз бозылганны дәвалау ысуллары өйрәтелгән. Авылның нәселләре беркадәр сурәтләнгән һәм дини эчтәлекле зур гына әсәр урнаштырылган. Китапның башы-ахыры юк. Ул бүгенге көндә Казанда Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының Мирасханәсендә саклана /Шәҗәрәләр коллекциясе. № 99, 1 тасвир, 215 эш/.

## Баб бәйан тарих

Тарих гарәбия тукыз йөз илле йитедә ирде, кән тотылды (1550 ел.—М. Ә.).

Йәнә тукыз йөз илле тукызынчы ел, сычкан елы ирде, гакрәбнең икенче көне ирде, Казан шәһәрен урыс алды /1552 елның 2 нче октябре/.

Йәнә тарих тукыз йөз йитмеш йитедә ирде, хан Шыгале дөньядин барды, Барыс елы ирде /1570 елга туры килә, ләкин аның үлеме 1567 елның 20 апрелендә дип санала.—М.Ә./.

---

[1] Хәлфин. Әхвале Чыңгыз хан вә Аксак Тимер. Казан, 1819, 87—91 б.

[2] Җиһаншин. Фаслы дастан нәселе Чыңгыз хан вә Аксак Тимер нәселеннән бәйан идәр. Казани, 1882, 43—45 б.

Йәнә тарих мең дә унда ирде, олуг ачлык булды /1602 елга туры килә.— М.Ә./.

Йәнә тарих мең дә ун йитидә ирде, Митри ягы булды /1609 елга туры килә, 1607—1610 елларда Ялган Дмитрий II һәм поляклар белән сугышлар тарихы турында сүз бара.— М.Ә./.

Йәнә тарих мең дә егерме түрттә ирде, Йанали ягы булды /1613 елга туры килә, 1609—1619 елларда Җангали житәкчелегендәге татар халкы милли-колониаль изүгә каршы кораллы көрәш алып бара/.

Тарих мең дә илле икедә Эсамга чирү барды, калмакга /1645 нче елга туры килә, 1640 елларда калмыклар Иделнең түбәнге агымына килеп чыгалар. Шунлыктан аларга каршы татар гаскәрләре җибәрелгән булган.— М.Ә./.

Йәнә тарих мең дә илле өчдә кенәз Әләкси Михайла углы падишаһ булды, халаек елады /1645 нче елга туры килә, Алексей Романов 1645—1676 елларда идарә итә.— М.Ә./.

Йәнә тарих мең дә алтмыш бишенче ел. Халаек эчендә мур булды /үләт эпидемиясе, 1655 елга туры килә.— М.Ә./.

Тарих мең дә йитмеш бердә ирде, пашкурт ягы булды /1661 елга туры килә, 1661—1665 елларда Уралда һәм Көнбатыш Себердә татарларның кораллы каршылык күрсәтүе була.— М.Ә./.

Йәнә тарих мең дә йитмеш тукызда Дун Казагы купты, йау башлады. Хажи Тарханны алды. Бер ел дошман булды, каршы Казан йиренә /1669 елга туры килә, 1668—1669 нчы елларда Степан Разин житәкчелегендәге Дон казаклары баш күтәреп, Хажи Тарханны алалар, Иран, Әзәрбәйжан жирләрен талап йөриләр.— М.Ә./.

Йәнә тарих мең дә туксан икидә ирде Сәед-Җәгъфәр ягы булды /1681 елга туры килә, 1681—1683 елларда Уралда Сәет-Җәгъфәр житәкчелегендә татар-башкорт кузгалышы була.— М.Ә./.

Тарих мең дә йөз дә йитидә ирде, Азауны урыс алды /1696 елга туры килә, шул елның 18 июлендә Петр армиясе Азак шәһәрен Кырым ханлыгы кулыннан басып ала.— М.Ә./.

Йәнә тарих мең дә йөз дә сигездә ирде. Камыйш дигән суның буенда казау булды, күп халаек кырылды /1697 елга туры килә.— М.Ә./.

Тарих мең дә бер йөз дә алтмыш икедә Пугач булган /1749 елга туры килә. Пугачев хәрәкәте 1773—1775 елларда була.— М.Ә./.

Сәнәи 1810 елда әүвәл кар дикәбрнең унынчы көнендә сиһшәнбе көн кич ирде. Шул кар торды. 1810 сәнә елда фибралның егерме икенче көнендә ягмур яга башлады. Ун көнгә тикле ягды, елы булды, сулар ташыды һәм гөрләвекләр акты, кар сай ирде, бетә язды, тегермәннәр суга керде, йәнә суытты мартның бишенче көнендә. Шул ук елда сентәбернең йитенче көнендә кар ягды, ашлыкларны йиргәй яткырды. Бәгъзе агачлар һәм... берлән екылды.

Сәнәи 1812 елда француз Мәскәүне алды. Сугыш күп улды. Өч елда биш йөзгә егерме сигез кеше салдат алды.

Сәнәи 1818 елда, июннең әүвәл көнендә бик олуг йил чыгып агачларны сындырды. Йәнә ягмур бик куәтле булды. Бәгъзе өйләрне су алды. Ягъни Байлар урны /Байлар Сабасы?— М.Ә./ шул ук елда, шул ук июннең алтынчы көнендә Шаһимәрдән /Шәмәрдән поселогы.— М.Ә./ буенда ягмур ягып, ундүрт тегермәнне су алды.

Сәнәи 1826 елда ел елы булды. Һәм бик яхшы булды, кар бик сай кырпак кына булды.

Сәнәи 1827 елда гыйнварның әүвәл көнендә кач манганчы /ягъни урысның крещение көне — М.Ә./ елы булды.

Сәнәи 1826 елда нуябердә ай тотылды.

Сәнәи 1927 елда апрельнең унбишендә кояш тотылды.

Сәнәи 1828 елда ел бик суык булды.

Сәнәи 1829 елда кар сай булды... яхшы булды.

Сәнәи 1832 елда апрельнең ун сигезенче көнендә чәчүгә...

Сәнәи 1845 елда гыйнварның әүвәл көнендә бик елы булды һәм мыш /тычкан.— М.Ә./ бик бәйләнде. Урысның кач манган көнендә мыш тәнгерәде һәм елы унберенче көннең кояшлы, елы булды, тәрәзәләр бик кипте, язгы кеби. Шул ук елда урыс маена чаклы аяз, елы булды. Урысның маеның бишенче, алтынчы көн бик буран булды. Чабтар бия колынлады.

Сәнәи 1845 елда, апрельнең әүвәл көнендә, йәнә икенче көнендә тегермән суга керде. Шул ук елда мартның унбишендә меңгә йите кеше салдат алды. Исмәгыйльнең Сиддукы китте.

Сәнәи 1846 елда гыйнварның әүвәл көнендә азрак катыргып, тимер суык булды. Икенче көн аяз булды. Кач мангучы /көн.— М.Ә./ һәм суык булды. Кач манган көндә кояш... чыкканда ике ягы салават күпере кеби булды. Янә тугыз сәгатьне суккан көн /көн озынлыгы 9 сәгать булгач — М.Ә./ бик кояшлы булды. Өченче көн ягмур ягды гыйнварның унтукызынчы көнендә. Янә фибралның әүвәл көнидә буран булды, бер айгача. Янә шул ук елда кыр казы китте уналтыны суккан көн. Янә орлыкны сачтек май башы берлән, бүтән ашлыкны сачә башладык, уналтыны суккан көн. Шул ук елда зөлхиҗҗәнең сигезенче көн сәхәр вакытында бер тавыш булды. Шул ук елда дикәбернең уникенче көн ягмур ягды. Янә дикәбернең егерме сигезендә суык була башлады... дүрт көнгәчә, бишенче көн ел башы булды... һ.б.

* * *

Сәнәи 1861 елда апрельнең әүвәл көнендә Бибигалимәне ярәштек. Пүкәлгә /Пүкәл — Саба төбәгендәге авыл. — М.Ә./.

Сәнәи 1861 елда июннең 4 көнендә тугды Кәлимулла кызы Бибиҗәмал. Якшәмбе көн 1862 елда гыйнварның 28 көнендә тугды Гайсә кызы Бибизаһидә.

Сәнәи 1863 елда, июннең әүвәлгесендә тугды Гали кызы Маһиҗәмал һ.б.

* * *

Күренә ки, әдәби мирасыбызда кече жанрга нисбәтләнгән елъязмалар әдәбиятыбыз тарихы өчен дә кызыклы чыганак. Алар халыкның тарихы, кадерле хәтере, шуның белән бергә, мавыктыргыч әдәбият энҗеләре дә булып торалар.

# БӘХЕТ КОШЫНЫҢ КАНАТЫ ТИЕП КИТКӘНДЕР...



Әйе, сәхнәгә гадәти бер профессионал музыкант кына түгел, ә бәлки моңга жаны-тәне белән гашыйк артист чыкса, ул инде тыңлаучыга илаһи сәнгать, аһәнле дөнья бүләк итә. Виолончелдә уйнау остасы Лариса Маслова нәкъ менә шундый музыкант, тыңлаучының күңелен яулап ала белгән сере-сәләте бар аның. Концерт залында ул яшьлеккә хас эчкерсез халәт тудыра. Маслованың, артистка буларак, үзенчәлекле бу сыйфатын аерым билгеләп китәсе килә: филармониядә егерме елга якын эшләп, ул артистлык хезмәтен гадәти һөнәргә генә әйләндереп калдырмаган (кызганычка күрә, артистлар арасында мондыйлар да очрый). Лариса музыканы чын ярату белән ярата, бәләкәй чактан ук моңга бай булып үсә. Шул чакта ук аңа бәхет ишекләре ачыла: Казан консерваториясе каршында талантлы балалар өчен махсус урта мәктәп — музыка мәктәбе оештырыла, Лариса мәктәп оешкан елны ук Иршат Хәйретдиновның виолончель классына укырга керә. Үзенең беренче укытучысы Иршат Насретдин улына виолончельдә уйнарга өйрәткәне өчен генә түгел, ә татар музыкасына мәхәббәт уятканы өчен дә Лариса мең-мең рәхмәтле. Әгәр репертуарында татар музыкасы булмаса, Лариса Маслованың сәхнәдәге иҗаты үзенең иң гүзәл сыйфатларыннан, тулылыгыннан мәхрүм калыр иде.

Бу мәктәпне тәмамлагач, Лариса Казан консерваториясенә укырга керә. Шул чорда язмыш Ларисага тагын бер бәхетле очрак бүләк итә: дөньякүләм танылган мастер Мстислав Ростроповичтан берничә дәрес алырга мөмкинлек туа. Күз алдына китерегез: шундый мәшһүр музыкант белән якыннан очрашулар, аның киңәшләрен ишетү Ларисага нинди иҗат шатлыклары китергәндер, яшь музыкантның иңнәренә илһам канатлары үскәндер. Лариса бүген дә әле Ростроповичтан алган дәресләре турында куанып исенә төшерә, бу дәресләр аның иҗаты формалашуга гаҗәеп күркәм тәэсир ясаган. Маэстро Ростропович музыкада беренче адымнарын атлаучы яшь кыз балада чын музыкант күрә. «Музыкада техникага ирешеп була, иң әһәмиятлесе — музыкантның йөрәге, күңеле... Музыкант кешелекле булырга тиеш... Синең күңелең кешелекле... Син музыканы җаның белән тоясың»,— ди ул Ларисага. Һәм Мәскәүгә килергә, үзенең шәкерте булырга тәкъдим итә. Ләкин рәхимсез язмыш атаклы музыкант Ростроповичны еракларга илтеп ташлый, ул туган илен калдырып, чит илгә китәргә, эмигрант булып еракта гомер сөрергә мәҗбүр була. Лариса Маслова Казаннан китми, консерваторияне бик яхшы тәмамлап, иң әйбәт билгеләр генә куелган кызыл диплом ала. Аннары ассистентура-стажировка үтә, үзенең укытучысы профессор Хәйретдиновның тугъры шәкерте булып кала.

Әле студент чагында ук Лариса Казан концертларында еш катнашып, үзенең эшчәнлеген башлап җибәрә, кулына виолончель тоткан яшь кыза бала әледән-әле сәхнәләрдә күренә, музыка сөючеләрнең игътибарын җәлеп итә. Бөтен илгә танылган күренекле дирижер Натан Рахлин җитәкләгән оркестр составында чыгышлар ясый, оркестр солисткасы буларак, Чайковскийның данлыклы «Рококо темаларына вариацияләре»н уйный. Консерваторияне тәмамлагач, Филармония каршындагы

шушы симфоник оркестрга эшкә керә. «Үзен оркестрның аерылгысыз нерв күзәнәге итеп тою, артистлык сәләте, музыкага кайнар мәхәббәт, интонациянең чисталыгы, матурлыгына ирешү — Лариса Маслованың музыкант буларак, тумыштан килгән табигый сыйфатлары»,— дип бәяли аны үзенең бер чыгышында Натан Рахлин.

1978 елдан Лариса бүгенгә кәнгәчә Г. Тукай исемендәге Татар Дәүләт филармониясендә солистка. Музыкант буларак, сәхнәгә ялгыз гына чыгып, йөрәге түрендә тыңлаучыга җиткерер моңы барлыгын ул, мөгаен, күптән тойгандыр. Дөресрәге, ялгызы түгел, үзенең якын дусты — виолончеле белән... Менә бер кечне симфоник оркестрда уйламаганда көтмәгәндә, шундый хәл килеп чыга: концертта виолончелист-солист кирәк була, Рахлин оркестрдагы барлык музыкантларга мөрәҗәгать итә — кем тәвәккәлләп уйнарга алына?.. Музыкантлар арасыннан яшь кенә кыз — Лариса торып баса. Гәүдәгә дә җыйнак, яшьүсмер бала кыяфәтле генә Лариса, тәвәккәлләп, солист булырга ризалык биргәч, оркестр музыкантлары аңа ышанып бетмичә, гаҗәпсенеп, эчтән көлемсерәп карап куялар. Шактый дәү виолончель янәшәсендә Лариса сабый бала кыяфәтендә риясыз басып тора. Тәвәккәллек — ярты уңыш, диләр. Лариса, тәвәккәлләп, Сен-Санснын «Аккош» дигән әсәрен башкара, бу әсәрнең нигезендә аерым бер символик мәгънә дә бар: аккош бит ул шундый кош, аның ялгыз калган чагы кешегә көчле тәэсир итә, кешене сагышландыра, моңайта. Ә көтү-көтү булып йөргән аккошлар кеше күңеленә артык тәэсир итми. Лариса сәхнәдә «ялгыз аккош» булып чыгыш ясый... Тыңлаучыны уйландыра, сагышландыра, күптән хыялында йөрткән беренче адымын атлый.

СССРның халык артисты, профессор Рахлин кебек күренекле дирижер житәкләгән симфоник оркестрда эшләгән еллары Лариса өчен зур мәктәп була. Кайтып-кайтып уйлана ул, оркестр аны зур музыка дөньясына әйдәде, хыялларына, өметләренә канат куйды, тыңлаучылар белән очраштырды...

Натан Рахлин «тумыштан килгән табигый сыйфатлары»н күреп, Ларисага зур бәя бирсә дә, музыка дигән сәнгать шундый катлаулы сәнгать бит ул, анда табигый сыйфатлар белән генә уңышларга ирешеп булмый. Чын мәгънәсендә танылу өчен музыкант тир түгеп эшләргә, тырышырга, үз-үзен аямый хезмәт итәргә тиеш.

«Чын профессионал музыкант тиз вакыт эчендә өйрәнеп чыгышлар ясарга, көтелмәгән кыен очракларда да сәхнәдә югалып калмаска тиеш»,— ди Лариса үзе. Бу сүзләрне ул хәзер, инде күп еллар узгач, артистлык хезмәтендә зур тәҗрибә туплагач әйтә.

Казан консерваториясе ректоры, СССРның халык артисты, профессор Нәҗип Җиһанов үзенең бер чыгышында артисткага мондый бәя биргән иде: «Маслова — талантлы виолончелистка. Башкару осталыгы белән бергә, артист буларак ягымлылыгы, эстрадада үзен тота белүе, эмоциональ уйнавы — менә аның уңышларының сере».

Әйе, Лариса Маслова сәхнәдә үзен гади, әмма ләкин бик сөйкемле тота. Тыңлаучылар аны яратып каршы алалар, алкышлап озаталар. Ул бер концерттан да баш тартмый, һәрвакыт, һәр концертта уйнарга әзер. Музыкадан яхшы хәбәрдар тамашачылар да, виолончель дигән инструмент турында ишетеп кенә белгән кешеләр дә яратып тыңларлык әсәрләр башкара ул. Бигрәк тә татар тамашачылары алдында чыгыш ясарга ярата. Ә бит виолончель татар халкы гомер-гомергә яратып уйнаган, яратып тыңлаган гармун да, скрипка да, курай да түгел. Ул татар тамашачысы өчен яңа, хәтта ят уен коралы дисәк тә ярый. Виолончель безнең татарларга революциядән соң гына кергән. Ә шулай да виолончель татар музыка сәнгатендә үзенең матур урынын яулап алды. Ул инструментның йомшак, ягымлы аһәңе татар халык көйләренең моңы белән ничектер бик тәңгәл, тылсымлы, сихерле көчкә ия шикелле. Бер караганда виолончель белән татар халык көйләре, бигрәк тә борынгы көйләре арасында бернинди дә бәйләнеш юк кебек. Борынгы бабаларыбыз бу инструментны күрмәгәннәр дә, белмәгәннәр дә. Ә шулай да Лариса кебек оста башкаручылар бүген виолончель белән татар халык көйләрендәге нинди дер эчке бәйләнешне табып, бу уен коралын кыю рәвештә татар концертларында да яңгырыталар.

Виолончель... Моннан биш гасыр чамасы элек дөньяга килгән кыллы инструмент. Аның башка бер инструментка да охшамаган яңгырашы һәм матур даны бар.

Көнбатыш Ауропаның Ренессанс культурасы чәчәк аткан чорда туган виолончель (скрипка белән бер чорда), әкренләп виоланы (зур скрипкага ошаган кыллы инструментны) кысрыклый, виола урынын ала бара, кешеләр виолончель белән скрипканың тавышы матуррак яңгыравын аңлый баралар һәм виолончельне өстенрәк күрә башлыйлар. Виолончель тавышы кеше җырлаган, кеше көйләгән тавышка охшаш, шуңа күрә дә ул кеше күңеленә тиз тәэсир итә. Бу уен коралының авазы

үзәкләргә үтеп яңгырый, ул күңел ачу инструменты түгел, аны бер вакытта да кафе рестораннарда уйнатмыйлар.

Узган елның апрель аенда җәмәгатьчелек кинәт вафат булган шагыйребез Мәхмүт Хөсәен җәсәде белән Язучылар йортында мәңгелеккә хушлашкан чакта Лариса шагыйрьнең баш очында бик моңлы итеп татар халкының борынгы көйләрен уйнады... Күпләрнең күзләрендә яшь иде... Виолончель ирләрчә тыенкылык белән үкседе, шагыйрьне соңгы юлга озатып, бәхилләшеп җылады. Шагыйрьне озатырга килгән халык әнә шулай бәгырьне юаткан өчен Ларисага рәхмәтле калды...

Лариса Маслова татар музыкасы өчен бик зур эш башкарды — виолончель өчен язылган татар музыкасы антологиясен төзеде. Татар дөньясында бу уен коралы өчен язылган барлык әсәрләрне җыеп, туплап, аларны тыңлаучыга җиткерде һәм бу — милли инструменталь музыка тарихында беренче тапкыр башкарылган зур хезмәт иде. Менә Лариса ун елга якын гомерен бирде. Китапханәләрдә онытылып яткан кульязмаларны актарды, композиторларның архивларын өйрәнде, чын мәгънәсендә зур фәнни эш башкарды. Әгәр композиторларның басылып чыккан әсәрләрен генә җыеп, программа төзегән булса, Лариса татар музыкасының гаять кыйммәтле энҗе-җәүһәрләрен туплап, антология төзү бәхетенә ирешә алмаган булыр иде. Аның бу эше көтелмәгән нәтиҗәләргә китерде. Татар музыкасында виолончель өчен махсус язылган әсәрләр бик аз диючеләр гаҗәпкә калдылар, чөнки андый әсәрләр бар икән, күбесе онытылган, күбесе заманча яңгырамый, искергән дип, игътибардан төшеп калганнар. Ә чынлыкта алар үзләренең күркәмлекләрен һич тә югалтмаганнар, үз башкаручысын көтеп ятканнар икән. Шундый әсәрләрдән, мәсәлән, Маслова композитор Мансур Мозаффаровның кульязмаларын тапты. Мозаффаров 1945 елда ук виолончель һәм фортепьяно өчен татар халык көйләрен эшкәрткән. 1989 елда Маслова концертында «Казан сөлгесе», «Кара урман», «Яз да була» көйләренең яңгыравы күпләр өчен яңалык булды.

Лариса виолончельнең татар көйләрен матур, моңлы итеп яңгырата торган мөмкинлекләре чикләнмәгән дип саный. Виолончель — кешесенә карап ачыла торган затлы уен коралы. Лариса кулында ул нәкъ менә чын татарча «җырлый» башлый... Чөнки Лариса үзе бик кечкенәдән татар көйләрен тыңлап, яратып үскән. Исеме, фамилиясе татарча булмаса да (әтисе рус милләтеннән), Лариса милләте белән татар. Аның әнисе Франгизә ханымның нәсел тамырлары Татарстанның Дөбьяз төбәгенә барып тоташа. Ә бабасының нәселе Зеленодол районыннан. Миңсылу әбисеннән Лариса кечкенә чагыннан ук та борынгы көйләрне шулкадәр күп белә, Ларисаның сабый күңеле барысын да үзенә җыеп бара... Лариса мәрхүм әбисен сагынып болай ди: «Минем әбием бик күп көйләр белә иде, ул аларны кычкырып җырламый иде, әкрен генә, авыз эченнән генә бик йомшак тавыш белән моңлы итеп көйли иде... Радиодан Илһам Шакиров җырлавын ишетсә, җылый торган иде... Бик музыкаль кеше булган минем әбием...»

Ә инде үзе артистка булгач, Лариса Илһам абыйсы белән якыннан танышa, Илһам Шакиров аңар татар көйләренең моң хасиятләре турында бик кызыклы киңәшләр бирә. Лариса аны үзенең остазы итеп саный.

Виолончельнең тагын бер кызыклы ягы бар: ул — көйне аккопанементсыз, ялгыз башкара торган инструмент. Ә бертавышлылык татар музыкасының иң әһәмиятле үзенчәлеге. Шуны истә тотып, Р. Кәлимуллин, Ф. Әхмәтов, М. Шәмсетдинова, Р. Әхиярова кебек копмозиторларның соңгы елларда бу уен коралы өчен күп әсәрләр язулары очраклы хәл түгел.

Лариса Казанда, беренчеләрдән булып, Аурупа классик музыкасын виолончельдә яңгыраткан музыкант. Классиканы уйнаганда, Лариса Маслова бүгенге көн сулышын да исендә тота. Аның концерт программасында Барток, Кодай, Бриттен, Гобәйдуллина әсәрләре бар. Артистканы таныган Мәскәү композиторлары В. Агафонников, А. Муравлев һәм В. Брумберглар виолончель өчен язылган әсәрләрен беренче булып башкаручы итеп еш кына чакыралар. Бу музыкант өчен югары бәя әлбәттә.

Виолончель моңында кеше тавышлары бар, дидек. Чит төбәкләргә, зур шәһәрләргә чыгыш ясарга барган чакта Лариса һәрчак үзенең дусты, аерылмас юлдашы — виолончель белән бергә булыр. Тулы хокуклы «гражданин» санап ул виолончельгә дә билет сатып ала. Самолетта яисә автобуста аны янәшә «утыртып», сөеп, иркәләп кенә алып бара.

Ил киңлекләрендә яшәүче төрле халыкларга Лариса татар моңын җиткерүче илче. Ул аны һәммә кешенең бәгыренә үтәрлек итеп оста башкара. Менә шундый талантлы, ягымлы кыз — ул — Татарстанның атказанган артисты Лариса Маслова.

**Вадим ДУЛАТ-АЛИЕВ,**
музыка белгече.

Ак бүре. *Татар халык әкияте*. 1993 ел. 26 бит, рәсемнәр белән. Бәясе 75 сум.
Һади Атласи. Себер тарихы. Сөембикә. Казан ханлыгы. 1993 ел. 446 бит. Б. 850 с.
Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. 1989 ел. 220 бит. Б. 2 с.
Галимҗан Ибраһимов. Казакъ кызы. *Роман һәм хикәя*. 1992 ел. 190 бит. Б. 20 с.
Исхакый Гаяз. Зиндан. *Сайланма проза һәм сәхнә әсәрләре*. 1991 ел. 669 бит. Б. 8 с.
Габдулла Тукай. Кәҗә белән сарык әкияте. 1991 ел. 14 бит, рәсемнәр белән. Б. 2 с.
Без бәләкәй чакларда. *Мәктәп китапханәсе*. 1993 ел. 236 бит. Б. 90 с.
Бишек җырлары. 1993 ел. 44 бит. Б. 18 с.
Резеда Вәлиева. Ялгыз аккош. *Шигырьләр, әкиятләр, поэмалар*. 1990 ел. 221 бит. Б. 1 с.
Әхмәт Гадел. Дәрт. *Шигырьләр*. 1992 ел. 166 бит. Б. 38 с.
Илдус Гыйләҗев. Өмет ае. *Шигырьләр*. 1993 ел. 103 бит. Б. 90 с.
Дамир Гыйсметдинов. Өметсез шайтан. *Юмористик хикәяләр*. 1990 ел. 76 бит. Б. 1 с.
Әбрар Кәримуллин. Татарлар: исемебез һәм җисемебез. 1991 ел. 160 бит. Б. 1 с. 40 т.
Иван Киндер. Алтынкай. *Хикәяләр*. 1993 ел. 44 бит. Б. 125 с.
Ирек Кирам. Хыянәт. *Хикәяләр*. 1993 ел. 63 бит. Б. 8 с.
Көмеш сылу. *Татар халык әкиятләре*. 1992 ел. 351 бит. Б. 330 с.
Галимҗан Латыйп. Үсәсе килә. *Шигырьләр, җырлар, әкиятләр*. 1993 ел. 93 бит. Б. 63 с.
Флүс Латыйфи. Хыянәт. *Роман*. 1993 ел. 285 бит. Б. 250 с.
Ләбиб Лерон. Тәгәрмәчле чана. *Әкиятләр, мәзәкләр*. 1993 ел. 95 бит. Б. 25 с.
Роберт Миңнуллин. Дөньядагы иң зур алма. *Балалар өчен шигырьләр, әкиятләр*. 1992 ел. 142 бит. Б. 6 с.
Александр Мәлик-Пашаев. Иҗат баскычлары *(Гаиләдә баланы сәнгати үстерү)*. 1990 ел. 142 бит. Б. 1 с.
Мөхәммәт Мәһдиев. Җир йөзендә алты кыйтга. *Юльязмалар*. 1992 ел. 111 бит. Б. 13 с.
Мәгъсүм Насыйбуллин. Күктән иңгән дәлил. *Детектив әсәрләр*. 1991 ел. 318 бит. Б. 3 с.
Вакыйф Нуруллин. Сайланма әсәрләр. *Повестьлар*. 2 томлык. 1991 ел. 1 том. 493 бит. Б. 2 с. 50 т. 2 том. 427 бит. Б. 2 с. 50 т.
Канәфи Нәфыйков. Үткәнгә сәяхәт. *Рәсемнәр китабы*. 1993 ел. 24 бит. Б. 200 с.
Гали Рәхим. Битлек. *Хикәяләр һәм әкиятләр*. 1993 ел. 95 бит. Б. 125 с.
Гәрәй Рәхим. Тимер торна. *Шигырьләр*. 1993 ел. 46 бит. Б. 84 с.
Сабантуй. *Шигырьләр, әкиятләр, хикәяләр*. 1993 ел. 127 бит. Б. 150 с.
Фәннүр Сафин. Яңгыр малае. *Шигырьләр, әкиятләр*. 1993 ел. Б. 63 с.
Сез яраткан җырлар. II чыгарылыш. 1992 ел. 63 бит. Б. 100 с.
Игорь Скурихин. Дөрес туклану серләре. 1990 ел. 237 бит. Б. 2 с.
Николай Сладков. Баллы яңгыр. *Әкиятләр, хикәяләр*. 1992 ел. 254 бит. Б. 20 с.
Илгизәр Солтан. Туган якта кунакта. *Шигырьләр*. 1993 ел. 61 бит. Б. 100 с.
Хәсән Сарьян. Нокталы өтер. *Повестьлар*. 1990 ел. 414 бит. Б. 2 с.
Нурия Сәяр. Бәхетлеләр илендә. *Әкиятләр*. 1993 ел. 110 бит. Б. 150 с.

Кадыйр Сибгатуллин. Гомерем дулкыннары. *Шигырьләр.* 1993 ел. 238 бит. Б. 100 с.

Татар әдәбияты тарихы. 5 нче том. 1989 ел. 542 бит. Б. 3 с.

Тәгәри китте йомгагым. *Мәктәп китапханәсе.* 1993 ел. 252 бит. Б. 94 с.

Әхмәт Фәйзи. Кечкенә Апуш. 1993 ел. 253 бит. Б. 117 с.

Ризаэтдин Фәхретдин. Болгар вә Казан төрекләре. 1993 ел. 286 бит. Б. 88 с.

Гали Хужи. Таныш күзләр, таныш карашлар. *Шигырьләр, поэмалар.* 1990 ел. 205 бит. Б. 1 с.

Заһит Хәбибуллин. Күңелле мажаралар. *Г. Тукай шигырьләренә язылган җырлар.* 1990 ел. 24 бит. Б. 1 с.

Лирон Хәмидуллин. Офыктагы рәшәләр. *Хикәя һәм очерклар.* 1990 ел. 222 бит. Б. 1 с.

Марс Шабаев. Әкиятләр. 1990 ел. 63 бит. Б. 1 с.

Лена Шагыйрьҗан. Иман әлифбасы. *Шигырьләр.* 1993 ел. 158 бит. Б. 75 с.

Афзал Шамов. Соры мәче. *Хикәя.* 1990 ел. 71 бит. Б. 1 с.

Фәнис Яруллин. Зәңгәр күлдә ай коена. *Әкиятләр.* 1990 ел. 270 бит. Б. 1 с.

Фәрит Яхин. Иман. 1993 ел. 206 бит. Б. 85 с.

Җәйләүдә. *Казакъ повестьлары.* 1993 ел. 478 бит. Б. 250 с.

Рашат Низамиев. Кызыл кар яугач. 1993 ел. 221 бит.

## МАТБУГАТ КОНФЕРЕНЦИЯЛӘРЕ

17 февральдә Президент М. Шәймиев җитәкчелегендәге Татарстан делегациясе вәкилләре Россия белән Татарстан арасындагы Шартнамәгә кул куюга багышланган матбугат конференциясе уздырдылар.

Матбугат конференциясен ачып, М. Шәймиев әлеге Шартнамә Россия Федерациясе Конституциясенә һәм Татарстан Республикасы Конституциясенә таянып, үзара ташламаларга ирешү нәтиҗәсендә кабул ителүен әйтеп китте. Бу Шартнамә күп кенә сәяси, икътисадый, социаль һәм мәдәни мәсьәләләрне хәл итүдә яңа мөмкинлекләр тудыра, яңа мөнәсәбәтләргә юл ача, Республикабызның дәүләтчелек үсешен ныгытачак.

Аннары делегация әгъзалары залдагыларның күп кенә сорауларына җавап бирделәр.

* * *

23 февральдә, Матбугат йортының пресс-конференцияләр залында, Татарстан Президенты М. Шәймиев район, шәһәр, республика матбагасының, радио һәм телевидениенең күпсанлы мөхәррирләре, журналистлары каршында матбугат конференциясе үткәрде. Конференцияне ТРның Мәгълүмат һәм матбугат министры И. Әхмәтҗанов ачты һәм алып барды.

Сүзенең башында Президент сәяси һәм икътисадый хәлләр, реформаларның барышы, базар мөнәсәбәтләренә күчү һ. б. мәсьәләләргә киң тукталды. Татарстан белән Россия арасында төзелгән Шартнамә игътибар үзәгенә әверелде. Унитар һәм империалистик дәүләтнең гомере кыска һәм гаугалы булачак. Безнең ике яклы Шартнамә менә шушы куркынычлы факторга чик куя, диде Илбашы.

Соңыннан Президент журналистларның күпсанлы сорауларына җавап бирде.

## АКАДЕМИЯ НЫГЫЙ, ЯҢАРА

Февраль урталарында Татарстан Фәннәр Академиясенең яңа сайланган әгъзалары ачыкланды. Академиклар арасында «Казан утлары» журналының редколлегия әгъзасы, күренекле галим һәм сәясәтче Таһиров Индус Ризак улы да бар. Котлыйбыз каләмдәшебезне! Шулай ук Фәннәр Академиясенең әгъза-корреспонденты булып галим, Язучылар берлеге әгъзасы Әхмәдуллин Азат Гыйльмулла улы да сайланды.

18 февральдә исә Татарстан Фәннәр Академиясенең бер еллыгына багышланган гомуми җыелыш булып узды. Төп докладны ТР Академиясе президенты, Язучылар берлеге әгъзасы Хәсәнов Мансур Хәсән улы ясады. Фикер алышуларда академиклар И. Таһиров, С. Дьяконов, А. Коновалов, әгъза-корреспондент, армия генералы М. Гәрәев һ. б. катнашты. Җыелышта ТР Президенты М. Шәймиев чыгышы зур кызыксыну уятты. Ул чыгышының зур өлешен Татарстан — Россия Шартнамәсенең тарихи әһәмиятен аңлатуга багышлады.

Берьеллык юбилей утырышында ТР Югары Советы рәисе Ф. Мөхәммәтшин, ТР Премьер-министры М. Сабиров катнашты.

## МИЛЛИ МӘҖЛЕС ҖЫЕНЫ

19 февральдә Милли Мәҗлеснең чираттагы корылтае булып узды. Милли Мәҗлеснең рәисе булып Язучылар берлеге әгъзасы, ТР халык депутаты Фәүзия Бәйрәмова сайланды.

## ЯҢА ЛАУРЕАТЛАР

Мәгълүм булганча, һәр елны Татарстан Язучылар берлеге һәм «Туган як» җәмгыяте инициативасы белән оештырылган идарә карары нигезендә лауреатлар билгеләнә.

Февраль аенда быелгы лауреатлар ачыкланды. Алар Башкортстанда яшәүче татар шагыйре — Нажар Нәҗми («Татар теле» дигән шигыре өчен); Рахмай Хисмәтуллин («Кыйбла җиле» китабы һәм әдәби-иҗтимагый эшчәнлеге өчен). «Казан утлары» коллективы лауреатларны — олы бүләк ияләрен чын күңелдән тәбрик итә.

## КОМПОЗИТОРНЫ ИСКӘ АЛУ

8 февральдә Татарстан дәүләт музеенда күренекле композитор, «Шүрәле» балетының авторы Фәрит Яруллинның тууына 80 ел тулуга багышланган кичә булды.

Музей фәнни хезмәткәрләреннән Роза Галимҗанова, Флера Степанова, язучылардан Вакыйф Нуруллин һәм Рашат Низамиев 1 нче номерлы гимназия укучылары алдында композиторның тормыш һәм иҗат юлы, татар сәнгатенең актуаль проблемалары хакында сөйләделәр, сорауларга җавап бирделәр.

## ЯКТАШЛАР ОЧРАША, БЕРЛӘШӘ

К. Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театры бинасында Апас районында туып-үскән якташлар очрашты. Анда күренекле шагыйрь Шәүкәт Галиев, җырчылар Фердинанд Сәлахов, Илсур Сафин һәм Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры артистлары Алсу Гайнул-

лина, Илсөя Төхвәтуллина, Мансур Ибраһимов якташлары алдында үзләренең җырлары, шигырьләре белән чыгыш ясадылар.

* * *

К. Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театрында Мамадышта туып-үскән якташлар очрашуы булды. Кичәне шушы район егете язучы Ринат Мөхәммәдиев истәлекләр сөйләп ачты. Татарстанның атказанган артисты Миңгол Галиев, районның үзешчән җырчысы-сандугачы Гөлнәзирә Талипова җырларын тамашачы яратып каршылады.

* * *

18 февраль көнне Теләче ягында туып-үскән шәхесләр — күренекле эшмәкәрләр, галимнәр, язучылар, сәнгать осталары, спортчылар һәм хакимият вәкилләре Казанда якташлык җәмгыятен оештыру мәҗлесенә җыйналдылар. Әлеге җәмгыять «Теләче йолдызлыгы» дигән исемне йөртәчәк.

Якташлык җәмгыятенең президенты итеп нефть продуктлары белән тәэмин итү буенча «Карамай» исемендәге тышкы сәүдә фәнни-производство берләшмәсе генераль директоры Алимас Вәлиев сайланды. «Теләче йолдызлыгы» март азагында Казанда үзенең беренче кичәсен уздырырга җыена.

## СИБЕЛГӘН ТАТАР ХАЛКЫ

Мәскәүдә нәшер ителә торган «Российская газета» кайда күпме татар яшәве турында мәгълүмат бастырып чыгарды. Чыннан да, кайларга гына сибелмәгән татар халкы?!

Татарстан Республикасында — 1,7 миллион. БДБ илләрендә һәм Рәсәйдә — 5 миллион.

Нижгар өлкәсендә — 58603, Ульяновск өлкәсендә — 159093, Пенза өлкәсендә — 81307, Мордовиядә — 47328, Волгоград өлкәсендә — 25973, Әстерхан өлкәсендә — 71655, Киров өлкәсендә — 45666, Удмуртиядә — 110347, Мари Элда — 43741, Чувашиядә — 35689, Башкортстанда — 1120702, Самара өлкәсендә — 115280, Пермь өлкәсендә — 150460, Свердловск өлкәсендә — 183781, Оренбург өлкәсендә — 158564, Чиләбе өлкәсендә — 224605, Курган өлкәсендә — 22567, Төмән өлкәсендә — 227423, Омск өлкәсендә — 49784, Томск өлкәсендә — 20812, Новосибирск өлкәсендә — 29428, Кемерово өлкәсендә — 63116, Красноярск краенда — 54052, Иркутск өлкәсендә — 39609, Сахалин өлкәсендә — 10699, Мәскәүдә — 157376, Санкт-Петербургта — 43997. (Редакция бу мәгълүмәтләрнең никадәр дөреслеге өчен җавап бирми).

## МӘЧЕТ МАНАРАЛАРЫ ИШӘЯ

Тиздән Казанда ике яңа мәчет корылып бетәчәк. Дәрвиш (Дербышка) поселогындагысы «Ислам» мәчете дип йөртеләчәк. Ул Татарстанның Халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү министрлыгының төзелеш идарәсе матди ярдәме белән төзелә.

Ә икенче яңа мәчет «Горки-2» торак массивында Берләшкән Гарәп әмирлекләре эшмәкәрләре ярдәме белән төзелә.

Берләшкән Гарәп әмирлекләре мөселманнарының матди ярдәме белән җөмһүриятебездә 12 мәчет төзелде инде.

## АВЫЛДА ЯҢАРЫШ

Изге рамазан ае алдыннан, җомга көнне, 11 февральдә Әлки районының Мулла авылында яңа мәчет ачу тантанасы булды. Әлеге иман йортын «Алпар» совхозы (директоры Әсхәт Шәйдуллин) һәм район төзелеш идарәсе (башлыгы Мәсгут Шәйдуллин) ярдәме белән авыл халкы төзеде. Мәчетне ачу тантанасына авылның яше-карты, читтән кайткан кунаклар җыелды.

Бәләкәй генә бу авылдан милләтебезгә игелек китерердәй шактый гына зыялылар үсеп чыккан. «Казан утлары» журналының бүлек мөхәррире, язучы Шамил Маннапов, Татарстанның атказанган артисткасы, бию остасы Гүзәл Вафина, «Мәгариф» нәшрияты директоры, язучы Мөдәррис Вәлиев (Салих Маннапов), Татарстан социаль тәэминат министры урынбасары Илдус Гиматдинов — әнә шундыйлар. Алар яңа мәчетне ачу тантанасында чыгыш ясадылар, мәчеткә бүләкләрен тапшырдылар.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Татар советы әдәбиятын үстерүдәге хезмәтләре өчен шагыйрә Энҗе Һилалетдин кызы Мөэминовага, ТР Президенты указы белән, «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде.



# МОНА ЛИЗА һӘМ ЗӘЙТҮНӘ

Чыңгыз Габдрахман улы Әхмәров — төрки дөньясында танылган рәссам, нәгышлы сәнгать җәүһәрләрен искә алганда аның хезмәтләрен читләтеп үтү мөмкин түгел. Чыңгыз Әхмәров — Үзбәкстанның һәм Татарстанның халык рәссамы, СССР Дәүләт премиясе лауреаты.

Озак еллар ул Урта Азиядә, Навои, Улугбәкләр рухы калган борынгы җирдә яшәп, Шәрекънең миниатюралары алымын сәнгатьтә яңадан торгызды һәм монументаль бизәк сәнгатен үстерүдә зур өлеш кертте. Ташкентның А. Навои исемендәге зур опера һәм балет театры А. Бируни исемендәге Шәркъ институты бинасы, Сәмаркандның Улугбәк исемендәге музее биналары аның талантлы кулы белән бизәлгән.

Чыңгыз Әхмәров Казанның М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театры диварларын бизәүдә дә зур осталык күрсәтә.

Татар темасы рәссамның нәгышлы әсәрләрендә бик ачык чагыла. Ул үзенең картиналарында бүгенге заманны гына сурәтләп калмый, ә ерак тарихыбызга да мөрәҗәгать итә. Милләтнең могътәбәр шәхесләре — Ш. Мәрҗани, Г. Тукай, Г. Исхакый, Б. Урманче иҗатларын ул яхшы белә, аларның сүз кодрәтеннән рух алып аны төсләр аша бирә, киндергә күчерә. Рәссам иҗатында үткән һәм бүгенге заманны гына бәйләп карамый, ә төрки галәмендәге мәдәниятнең уртак бирлегән бәян итә.

Тугандаш үзбәк һәм татар халкының арадашчысы булып нәкъ менә Чыңгыз Әхмәров хезмәт итә.

Без аның күпкырлы бай иҗади хәзинәсеннән аерып алыйк та җәүһәр кебек бер әсәренә игътибар итик әле. Бу рәсем гүя татарның Джокондасы. Мәңгелек гүзәллеккә табынган Леонардо ничә еллар буе үз Мона Лизасын тудыра... Шуның кебек Чыңгыз әфәнде дә бу картинасына үзенең бар илһамын сала.

Зәйтүнә... Тукай язмышы, аның йолдыз атылган мизгелгә сыйган гомерендәге үкенечле гыйшкы аша бу гүзәл кыз гадәти яссылыктан нәүмизле легенда биеклегенә күтәрелә. Зәйтүнә... Кайнап торган фирүзә-яшеллек арасында ул аккош кебек, моңлы күзле, нәзберек ак дөнья булып басып тора. Алдагы бәхеткә омтылганга күрә аның күзләрендәге моң хыял рәшәсе аша тыенкы дәрт-кайнарлык белән алмашына. Рәссам бер нәрсәне интуитив рәвештә тотып алган: Зәйтүнәнең торышы, күз карашы, гасыр башында дини тәрбия алган, азан моңнарын җанына сеңдергән мөселман кызының мөлаем чагылышы. Заман-чор кешенең күз карашына үзенең мөһерен сала күрәсең. Без бу сурәттәге гүзәлгә карап ислам дөньясында шигъриятне җанлы иткән күпме чагыштыруларны күңелдән пышылдыйбыз. Хәер, бу мизгелдә сүзләр көчсез — күңелнең өнсез генә тантана иткән мәле.

Шәрекъгә әйтелгәнчә, Ләйлә гүзәллегенә Мәҗнүн күзләре белән карарга кирәктер. Монда да шулай, гүя Шагыйрь кодрәте рәссам кулыннан тотып үзе йөртә, төсләрне сайларга булыша. Рәсемнән әйтеп бетерелмәгән матурлык сирпелеп тора.

Чыңгыз Әхмәров картиналарында сурәтләнгән образлар тышкы кыяфәте белән бер-берсенә охшаш кебек, алар сюжеты белән бердәм мотивны чагылдыралар сыман. Гүя ул портретларында да чынбарлыкта билгеле булган кешене ясамый, ә «халык сурәте»н бирә, милләтнең гомуми символын тудыра.

Чыңгыз Әхмәров бәхетле язмышка хөкем ителгән рәссам. Ул ике халыкның да кадерле улы. Ул төсләргә, дастаннарга бай борынгылык бишеге — урта Азиядән Казанга килә дә, Ауропа белән Шәрекъ кисешкән төбәктә үзенә яңа төсмерләр, яңа рухи азык алып тагын кайтып китә. Ә күңелендә шушы ике араны тоташтыручы Салават күпере, мең төскә таркалып, аңа илһам бирә.

**К. БУЛЫЧЕВА-ШАҺИЕВА**

**Тышлыкның дүртенче битендә:** танылган шагыйрь Рәдиф Гаташ.

**М. КОЗЛОВСКИЙ фотосурәте.**

# ЯҢА КИТАПЛАР

ИДЕГӘЙ. **Татар халык дастаны.** Казан: Татар. кит. нәшер., 1994, 253 б. Тиражы 10000 данә.




Моннан берничә ел элек, халкыбызның күңел җәүһәрләреннән булган «Идегәй» дастанының кабат халыкка кайтарылуы әдәбиятыбыз тарихында куанычлы бер казаныш булган иде. Быел тулырак мәгълүматлар, кайбер төзәтмәләр кергән, рәссам Рушан Шәмсетдиновның төсле рәсемнәре белән яңартылган басмасы дөнья күрде. Әсәрнең укучыларга янә тәкъдим ителүе, әдәбият тарихында гына вакыйга булып түгел, ә бәлки, күпләребез күңелендәге милли горурлык, милли аң үсешенә этәргеч тә булыр дип ышанасы килә.

Идегәйнең Идел-Йортка багышлап:

Әй Идел-Йорт, Идел-Йорт!
Идел буе имин йорт!—

дигән сүзләре бүгенге көндә дә халкыбызның мөстәкыйль яшәү, татар дәүләтен яңадан торгызу өчен көрәш юлында патриотик гимн булып яңгырый.

ӘХМӘТ ЕРИКӘЙ. **Сайланма әсәрләр.** Лирика.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1992, 192 б. Тиражы 1000 данә.




Әхмәт Ерикәй исемен ишетү белән күпләребезнең күңелендә 50 — 60 елларда бик популяр булып, әле бүгенге көндә дә матурлыгын җуймаган «Җырланмаган әле безнең җыр», «Җәйнең матур аяз таңнарында», «Юллар» h. б. җырлар яңара.

Татарстан китап нәшрияты тарафыннан укучыларыбызга тәкъдим ителә торган бу җыентыкка авторның лирик шигырьләре һәм җырлары тупланган. Үзләренең ихласлыгы һәм самимилеге белән сугарылган бу шигырьләрнең кабат тупланып дөнья күрүе Әхмәт Ерикәй иҗатын яратучыларга зур бүләк булыр.

Бәясе 330 сум

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал (на татарском языке)

Журнал включен в центральный каталог